ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2011





**Мәхмүт Галәү**
**(1886—1938)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

# 9
**(1067)**

<u>*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*</u>
***«ТАТМЕДИА»***
***ачык акционерлык җәмгыяте***

ТМ
татмедиа



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


*✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*☎☎: Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@yandex.ru*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Китек күзгә. *Бәян* ........ 5
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Яну дәверләрендә. *Роман-поэмадан өзекләр* ........ 45
Рәфкать КӘРАМИ. Сөеп туймас чакларың. *Роман* ........ 52
Рифат ЖАМАЛ. Үткәннәрдән кайтып киләм... *Шигырьләр* ........ 119
Гүзәл ӘДҺӘМ. Әтнәби. *Хикәя* ........ 123

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Рафаил СИРАЖИ. Шигырь ........ 136

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА. Карак һәм ашказаны. *Хикәя* ........ 137
Алмаз ХӘМЗИН. Имгәк ........ 141
Рәфикъ ЮНЫС. Эш күп әле! *Шигырь* ........ 144

**СӘНГАТЬ**

Аида АЛМАЗОВА. Нәжип Җиһанов һәм татар музыка сәнгате ........ 145

**ФИКЕР**

Зиннур ЗАКИРОВ. Динебез турында уйланулар ........ 150

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 160
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ........ 163

**ХӘТЕР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр* ........ 166

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Органга–өрделәр ........ 174

**АК ҖИЛКӘН**

Рашат НИЗАМИ. Төсле карандашлар ........ 179
Мамадыш районы Кече Кирмән мәктәбе укучылары иҗаты *(Д. Гыйззәтуллина, А. Исрафилова, З. Хаҗиев)* ........ 182
Дания ГАРӘФИЕВА-ШӘРИПОВА. Жеффи һәм Йомшакбикә ........ 184
Алсу НУРГАТИНА. Туган авыл. *Шигырьләр* ........ 185
Ким ШАКИРОВ. Ул үсмер чагында ук академик булган! ........ 189

«Казан утлары» архивыннан ........ 148
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Р. КАРАМИ «Пора прекрасной любви»,
повесть Т. ГАЛИУЛЛИНА «Разбитое зеркало», рассказ Г. АДХАМ «Атнаби»;
отрывки из роман-поэмы Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, стихи Р. ДЖАМАЛА.
«Творчество читателей»: стихи Р. СИРАЗИ.
«Сенной базар». Конкурс сатирических произведений. Рассказы Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, А. ХАМЗИНА; стихотворение Р. ЮНУСА.
«Искусство»: А. АЛМАЗОВА. «Н. Джиганов и татарское музыкальное искусство».
«Мнение»: З. ЗИННУРОВ. «Размышления об исламе».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Белый парус»: рассказ Р. НИЗАМИ «Цветные карандаши»; стихи А. НУРГАТИНОЙ.
«Наш календарь».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Дивная осень»; писательница Илюся Набиуллина.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by R. KARAMI «It's time to fine love»,
story by T. GALIULLIN «Broken mirror», story by G. ADHAM «Atnabi»;
fragments from novel-poem by F. GIZATULLINA, verses by D. JAMAL.
«Creativity of readers»: verses by R. SIRAZI.
«Hey market». Competition of satirical works.
Stories by F. ZAMALETDINOVA, A. KHAMZIN; poem by R. YUNUZ.
«Art»: A. ALMAZOVA. «N. Jiganov and Tatar musical art».
«Opinion»: Z. ZINNUROV. «Reflections about Islam».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Memory»: diary records by F. YARULLIN.
«White sail»: story by R. NIZAMI «Color pencils»; verses by A. NURGATINA.
«Our calendar».
From magazine photo archive.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Marvellous autumn»; writer Ilyusa Nabiullina.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.09.2011, график буенча 01.09.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–1291. Тираж 3855.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.



Тәлгат
Галиуллин

# КИТЕК КӨЗГЕ

БӘЯН

## I

Табигатьнең ямь-яшел төскә кереп, көязләнеп утырган көннәре. Егетенең чәчәк бәйләме белән каршы алачагына һич шикләнмәгән яшь кыз Мәскәү самолетыннан төште. Менә ул әйләнеп торган тимер тасмадан спорт чантасын алып, бер читкәрәк китеп, дустының озын, төз гәүдәсен пырдымсызланып эзли башлады. Кайтучыларның бәхетлеләрен якыннары машиналарында җилдереп алып китте, бәгъзеләре әрсез таксистларның татлы сүзенә алданды, кесә шәрифләре такырраклары автобус тукталышына титаклады. Берничә дәкыйка элек кенә умарта күчедәй гүләп торган алан хәтле каршылау залы бушап калды. Аэропорт хезмәткәрләре арлы-бирле йөренеп, чираттагы рейсны каршыларга әзерләнә башлады. Тик аның танышы гына күренмәде. Үпкә, ачу, гарьләнү тудырган дулкынлануы күзләренә, йөзенә, гәүдәсенә чыккан кыз үз ягына юнәлгән чит караш сизеп, сискәнеп китте. Урамга чыгу ишеге янында аның Алёшасыннан кыскарак буйлы, түгәрәк йөзле, җәйге ак костюм кигән бер ир-егет күптәнге танышы сыман, кызыксынуын яшермичә, аңа текәлеп карап тора икән. Нишләп бу абзый оялмыйча мине иләк аша уздыра торгандыр, бигрәк тәрбиясез кешеләр бар инде, дип уйлап, кыз үз-үзенә ул якка карамаска, ни пычагыма кирәк миңа мондый узгынчы дип әмер бирсә дә, аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләре хуҗабикәләренең ихтыярына буйсынмас булды. Күрер күзгә егерме биш-утыз яшьләрдә генә тоелса да, киң маңгаен капларга тиешле коңгырт чәчләре шактый мул артка чигенгән, ул да кемнедер көтә күрәсең, кулындагы машина ачкычларын уйнатып борчылуын яшерергә тырышканы сизелә. Көтү залында озын-озак басып тору икесенең дә көн тәртибендә каралмаган булса да, бичарадан ничара, алар могҗизага, зарыгып көткән кешеләренең капылт килеп чыгуына өметләнеп, бер-берсенә яшерен-орынтын караш ташлап, йөзләренә ваемсызлык төсмере чыгаргандай булып, урында таптанып торалар. Алёша

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) – *язучы һәм әдәбият галиме; күпсанлы китаплар («Дәгъва», «Тәүбә», «Эләмәк», «Төнге юллар», «Шигърият баскычлары» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

мине каршы алырга бу адәмне җибәрмәдеме икән кебек сагызлы уен Ләйлә кискен рәвештә кире какты, шактый горур, бәйсез басып торуына, өстендәге затлы киеменә караганда бер дә көнлекче, йомышчы малайга охшамаган иде. Егетнең якты нур шикелле үзенә төбәлгән карашында Ләйлә бөтен тән күзәнәкләре белән үзенә таныш булмаган җылылык, мәрхәмәтлелек сирпелешен тойды. Буш залны, диварлар буена тезелгән ясалма күн тышлы диваннарны өйрәнү дә озаккарак китте.

Рейсларны әйтеп торучы туктаган арада урнашкан зыңгылдап торган тынлыкны, язылмаган кануннар буенча, ир-ат заты бозарга тиеш иде. Егет кыз ягына вәкарь генә атлый-атлый, тиешле соравын бирде:

—Гафу итегез, кызыксынуым өчен, сезнең каршы алырга тиешле кешегез килеп җитмәдеме әллә?

Үзен кыю, тәвәккәл, бәйләнчекләрне тиз урыннарына утырта алучыга санап йөргән, «сезнең ни эшегез бар миндә, үз юлыгызны белегез», дип сорау бирүченең авызын капларга тиешле кыз, нәкъ шул сорауны зарыгып көткән кешедәй, үзен бөтенләй башкача тотты.

—Шулайрак килеп чыкты шул. Егетем каршыларга тиеш иде дә, күренми. Бик төгәл, тәртипле кеше кебек иде югыйсә.

Борчылуын, ышанычы акланмавын сиздермәскә тырышса да, тавышының дулкыннар сыртыннан элдерткән көймә шикелле тигезсез, калтырабрак чыгуы аның чарасызлыгына дәлил кебек кабул ителде.

—Шулай да булгалый. Иң ышанычлыга санап йөргән якыныңның авыр хәлгә куйганын сизми дә каласың,—диде егет әүвәл гомуми фәлсәфәгә өлеш чыгарганнан соң. Сүзләренә икегә бүлсәң, йөк җинелрәк күтәрелә дигән мәгънә салып.—Үзем дә шундыйрак хәлдә калдым. Кат-кат шалтыратып, каршы алуымны зинһарлап сораган кешем самолеттан төшмәде. Кәефем кырылды, болай да юк вакытымны бар итеп килгән идем,—дип өстәп куйды.

—Кайтырга тиешле кешегез хатыныгыз идеме?—дип, теленең кыюлыгына үзе таң калып, сорап куюын кыз сизми дә калды. «Сиңа барыбер түгелме, хәчтрүш» кебегрәк җавапка лаек булуын аңлаганнан соң бит алмаларының оялудан алсуланып китеп, чәч төпләреннән салкын тир бәреп чыгуны тойды. Дуамал сөаленнән кызның уңайсызлануын тойган егет битараф кешегә мондый сорау бирмиләр, дип кенә уйлап өлгерде.

Асыл затның кызыксынуын урынсызмы, тәрбиясезлекме дип тапкан егет, туры җавап бирүне мәҗбүри санамыйча:

—Иң авыр хәлдән дә чыгу юлы, һәр начарның таба белсәң, уңай ягы була, диләрме әле. Мин, мәсәлән, машина белән сезне, үзем шикелле үк бәлагә тарган кешене, өенә илтеп куя алам,—дип егет, җавап көтеп тормыйча, иелеп кызның спорт чантасын кулына алды. Кызның аңа иярүдән башка чарасы юк иде. Әмма рәхмәт белән чикләнәсе урынга кыз ачыкламыш сорау бирде.

—Сез һәр нәрсәгә, аеруча кыен хәлләргә философларча, гомумирәк бәя бирәсезме, һәр тискәредән уңай якны эзлисезме?

—Белгечлегең шул булгач, кая барасың инде. Үзеңнән качып котылып булмый, диләр. Һәр каршылыкның чишелеш ноктасын эзләргә туры килә,—дип егет сөйләнә-сөйләнә машинасының ишекләрен ачты. Читтәрәк басып торган кыз тарафына борылып:

—Шәт безгә танышырга да вакыт җиткәндер. Мин Марат абый булам. Мулла кушканы Морад булса да, җинеллек өчен французчалаштырыбрак әйтәм. Киемнәрегезгә, сумкаларыгызга караганда сезнең исемегез... Хәзер әйтәм. Регина, Эльмира, Эльвира, Карина, Альбина йә Алина кебегрәктер дип фаразлыйм.

—Менә ялгыштыгыз Марат—Морад иптәш. Ләйлә булам мин,—диде кыз машинага якынрак килә-килешкә.

—Дүрт көпчәкле атым искитмәле булмаса да, хуҗасын тынлый, кирәк жиргә алып бара,—дип Морад алгы ишекне ачып, кызны утырырга чакырды.

—Мин арткы утыргычка утырып йөрергә яратам. Мөмкин булса...

—Теләгегез. Рәхим итегез. Кунак теләге хужа өчен закун,—ди-ди Морад үз ягының арткы ишеген ачты.

—Мин сезнең кунак статусын алдыммыни инде. Алып кайткан өчен түли дә алам,—диде кыз, ни сөйләгәнен үзе дә бәяләп житкермичә.

—Акчагыз артык булса бирерсез. Аспирант кешегә анысы да ярап куяр,— диде егет көлә-көлә.

Машиналарны күргәләгән кыз булырга охшый, әле генә танышкан кеше белән янәшә утырып барырга теләмәве дә нәрсәнедер аңлата торгандыр дип уйлап куйды Морад. Атаклы якташыбыз академик-химик Арбузов бервакытта да йөртүчесе янына утырмаган. Сорасалар, элеккеге дворян баласы, «барин кучер белән янәшә утырып йөри алмый» дип жавап бирә торган булган.

Машина олы юлга чыккач, Морад эчке якта өскә элеп куелган көзгедән Ләйләнең чагылышына күз төшереп алды. Артык нәфис, гүзәл дип әйтерлек булмаса да, кыз сөйкемле йөзле, билләре эчкә тартылып торган жыйнак гәүдәле иде. Бит тиресенең кыйммәтле бизәнүләргә күнеккәнлеге, өстендәге киемнәренең юлга жайлаштырып сайланганы да, базар тауарлары булмыйча, кыйммәтле икәнлекләре күренеп торалар. Зәңгәр күзләренең кырыйларына күгелҗем буяу төшерелгән. Күрәсең, егетенә матуррак күренергә тырышып, самолетта да бизәнү әмәлен тапкандыр.

Эленеп торган көзгедән Ләйлә дә аны күзәтеп бара икән. Кайсыдыр мизгелдә Морад белән кызның карашлары очрашып алды. Егет зәңгәр күзләрдән чыгып бетмәгән ихласи балалыкны, кемгәдер рәнжү тудырган ажаган биеп алуны күреп өлгерде. Йөртүченең озак итеп көзгегә кадалып бару мөмкинлеге чикле булса, кыз исә гомерендә беренче тапкыр күргән иргә озаклап текәлеп торуны тәрбиясезлек санады.

Сүзне янәдән егет яңартырга тиеш иде.

—Тагын бер сорау бирим инде, гафу итәрсез. Сез самолеттан төшкәч, егетегезгә шалтыратмадыгызмы? Бәлки, житди сәбәбе бардыр, әйтик, чирләп киткәндер.

Сорау биргәннән соң: «Синең ни эшең, ни хакың бар, барыбер түгелмени» дип, Морад үзен битәрләп алса да, әйткән сүз очкан кош иде шул. Икенчедән, ул Ләйләне егетенең каршы алмавын эчтән хуплавына, хәтта канәгать булуына игътибар итте. Кыз исә әүвәл кечкенә, озынчарак бите өчен зуррак күренгән, ымсындырып торган кызыл иреннәрен түгәрәкләп, турсайтып алды.

—Минем кемгәдер ялына торган гадәтем юк. Алдан сөйләшенгән иде. Сүзендә тормаган кешене яратмыйм мин.

Артында нинди дер көч, терәк барын тоеп яши торган горур кыз икән дип нәтижә ясау өчен фәлсәфә белгеченә бу баш катырырлык житди табышмак түгел иде.

—Бер хатасы өчен егетегез сезнең мәрхәмәттән мәхрүм буламыни инде?—дигән соравына егет «хәзер уңга борылыгыз, аннан турыга, әнә теге йортны узгач, янәдән уңга китәрбез, килеп житәрәк тагын әйтермен», дигән жавапны гына ишетте.

Шулай кемгәдер юк-бар, сөйләшүчеләр өчен житди күренгән сорау-жөмләләр алышу вакытны кыскартты, машинаның Ләйләләрнең өе урнашкан Казан Рублёвкасы—атаклы Салмачыга килеп терәлгәнен сизми дә калдылар. Икесенә дә артык тиз кайтып житкәндәй тоелды. Кызый чөлтәрле

биек тимер койма эчендә, яшерен төймә ача торган кара иркен капкалы, кызыл үгез тиресен хәтерләткән кирпечтән төзелгән ике каты күренеп торган затлы сарайда әти-әнисе белән яши икән. Морад, ниһаять, кызның теге вакыттагы соравына да җавап бирүне кирәк дип тапты. Өч дистәсен тутырыга якынлашса да буйдак икән әле ул, кандидатлык диссертациясен яклауга әзерләп йөрмеш, ди. Сабакташы үзәк Дәүләт архивыннан бер документның күчермәсен алып кайтырга тиеш булган икән. Берәүне каршы алмаганнар, икенчесенеке кайтып кемнедер бәхетле итүне мәҗбүри санамаган. Тәкъдир, шул рәвешле, ике яшь йөрәкне аэропорт залында очраштырырга булган.

Ләйлә үзенең заманында ярты ел булса да Ленин бабай укыган белем йорты студенты булуы, бу көннәрдә чыгарылыш квалификациясе эшен якларга әзерләнүе, ә Мәскәүгә әтисенең сәяхәтләр оештыру ширкәтенең йомышы белән баруы, диплом алгач, үзенең дә шунда эшләячәге турында бәян итте. Кызык бу дөнья: ике-өч сәгать элек кенә бер-берсенең дөньяда барлыгы турында да хәбәрдар булмаган кешеләр, сере табылып кинәт ачылган сандык байлыгына тап булгандай, ашыга-ашыга үзләре турында мәгълүмат алыша башлады. Ләйлә Морадка ачык, шатлана белүчән, күзәтүчән, юморны аңлый торган, хисчән, әмма артык иркә кыз кебек тоелды. Ләйләгә егет тәртәгә утырган, тормышта кыйбласын тапкан, үз-үзен ирония белән бәяли алучы житди кеше мисле күренде. Саубуллашканда егетнең үзен ифрат тәрбияле тотуы, әрсезләнеп кочакларга ашыкмавы, ярымзыялылар кебек болагайланып, кулын үбәргә алынмавы һәм гади генә итеп ясаган тәкъдиме ошады:

—Ходай Тәгалә үзе оештырган бу очрашуны, кайгыларыбызны уртаклашуны иртәгә кичен берәр кафеда чәй яисә каһвә эчеп билгеләп үтүгә сез ничек карар идегез? Билгеле, каршы алырга тиешле егетегез рөхсәт итсә...

Ул иртәгә тирләп-пешеп чәчәк күтәреп килеп житәр дип өстәмәкче иде дә, артыграк булыр дип, үзен тыеп кала алды. Болай ук төрттерү дә кирәк булмагандыр.

— Яшь булсам да, үзем дөрес дип тапканча яшәргә яратам. Минем өчен бердәнбер авторитет—әтием Сахип Габбасов. Аэропортка килмәгән егет белән болай да арабызны өзәргә йөри идем. Үзе ярдәм итте. Рәхмәттән башка ни әйтим.

Ачылыргамы икән, юк микән дип уйланыбрак торганнан соң, көлемсерәп өстәп куйды.

—Ул каршы алса, сезнең белән очрашмаган булыр идек. Философлар һәр яңа кеше—ачылмаган дөнья диләр түгелме әле... Иртәгә кадәр. Кичке җиләләрдә капканың бу ягында көтеп торырмын,—дип кулын изәп, тимер капка артына кереп гаип булды.

Өй ишегенә алып барган плитә түшәлгән юлның ике ягында гөрләп үсеп утырган, салават күпередәй төрле төсле чәчәкләр арасыннан акрын гына атлаганда, янтавына нимес овчаркасы килеп борынын төртте. Томанның башыннан сыйпый-сыйпый кыз әлегәчә көчкә авызлыклап килгән хисләр ташкынына тышка агылып чыгарга ирек бирде. Дөресе, буаны тотып торырлык тәкате калмаган иде. Әүвәл рәнҗүен, гарьләнүен тозлы күз яшьләре белән туйганчы юды. Бераз тынычлангач, кое баганасыдай озын буйлы баскетболисты шалтыраткач әйтәсе сүзләрен, тәсбих төймәләре кебек, бер җепкә тезә башлады. Җөмләләренең бәгырьгә тия торган текәләрен, усалларын, зәһәрләрен, чагыштыруларның көндәлектә кулланылмый торганнарын эченнән кабатлап йөренгәндә, иреннәре әүвәл калтыранып алды, янаклары эчкә тартылды, соңрак бар хисе бергә укмашып, усал елмаю хасил иттеләр. Кызның эчке халәте кара болытларның җиһанны коендырыр алдыннан куерып, һаваның куырылып, тынчуланып алу мизгелен хәтерләтә иде.

Шул озын сыйрак Алина гына башына житте. Баскетбол уеннарына йөри-йөри бер латышка гашыйк булган. Бер мөһим очрашуга кыстый-кыстый Ләйләне дә алып барды. Күнелен тартмаган жиргә аяк атларга да ярамаганын чамаласа да, Ләйлә ризалашты. Уеннан сон, жинүчеләр кызларны шунда ук урнашкан кафега кичке ашка алып керделәр. Арыш камылы кебек тырпайган каты чәчлесе кич буе Ләйләдән күзен алмыйча карап утырды, соңыннан озатып куярга алынды. Шуннан китте очрашу-күрешүләр, матчлардан сон кафеда чәй-мәй эчүләр. Акрынлап Ләйлә анын озын буена да, ясалма елмаюына да күнекте. Бу аралашуны мәхәббәт дип атап булырлык түгел, Ләйләнең баскетболистка мөнәсәбәте салмак кына, үз жае белән генә агып яткан елга сыман иде. Егет белән бер елга якын очрашу дәвамында ана кулга өйрәтелгән мал кебек ияләште, Алёшанын икегә аерылып торган иягенә астан өскә карау ошый, егетнең үбешкәндә төркмән котүчеләре кебек чүмәшә белүе яисә таза кулларына күтәреп алуы, иркә песи баласы кебек анын култык астына кереп ятуы, бер очракка чаклы Ләйләгә кызык, яна тоелды. Тик озаккарак сузылган бу уеннарнын уймагы, коймакнын төере килеп чыкты шул.

Кыз узган гомере турында уйга чумып, ялагайланып койрыгын болгап торган Томаннын маңгаена тырнакларын катырак батырды бугай, эт чинап жибәрүгә Ләйлә дә айнып киткәндәй булды. Әле генә көмеш нурларының салкыны белән коендырып торган ай да жылылык иңдереп алгандай тоелды. Яшәү барыбер иң кызык шөгыльләрнең берсе икән. Морадны искә төшерү айны да ямьләндереп жибәрде бугай. Шул арада тавышка әтисе йөгереп чыкты.

—Ләйләм кайткан икән. Ник бер хәбәрен булсын. Каршы алырга машина жибәргән булыр идем,—дип сөйләнә-сөйләнә, кызын эчкә уздырды. Өстендәге жиңел кызыл курткасы белән Ләйлә авыр уйларын салып ташлагандай булды. Артык борчылуны яратмаган башы бер кичтә өелгән хәлләрдән талчыккан булса да, әтисенә, шул арада икенче каттан төшкән әнисенә соңгы яналыкны әйтми түзә алмады.

—Шатланыгыз. Бик әйбәт татар егете белән таныштым. Аэропорттан өйгә ул алып кайтты.

Чуар пижамасын киеп алган әтисе, гадәтенчә, озаклап сөйләшүгә әзерләнеп диванга барып чүмәште.

—Ә, теген... каршы алмадымы?—Кыз, күзен дә йоммыйча, әтисенең күңеленә хуш килердәй жавап бирде.

—Мин ана үзем килмәскә куштым. Әти каршы ала дидем.

—Кызык,—диде әтисе.—Сине алып кайткан егет ничек туры килде?

—Анын да көткән кешесе самолетта булмады,—дип котылды ялганын тоттыра язган Ләйлә.—Иртәгә сөйләшербез, арыдым, йокым килә,—дип кызга үз бүлмәсенә кереп киту иң хәерлесе иде.

Әтисенең төпченергә, нәсел-нәсәбе турында сораштырырга, елганың төбенә төшәргә, кинәшен кызганмыйча бушка бирергә яратканын белгәнгә күрә Ләйләнең кичерешләре белән бергә-бер каласы килде. Кызынын иң яшерен серләре турында хәбәрдар әнисе кызын мөлдерәмә кара күзләре белән иркәләп, монсу гына карап алды да, төнге кефир әзерләргә аш-су бүлмәсенә юл тотты. Ләйләнең күңеле тыныч була алмавын ана жаны тирәнтен сиземли иде. Татар егете белән танышуы яхшы, ахыры хәерле булсын. Тик колга баскетболистнын кылган этлеген ул ничек кабул итәр, мужиклар кебек бәйләнчек, үч саклаучан булып чыкса, тату гаилә турында хыялланырга гына кала.

Кызынын төзәтеп булмаслык бәлагә тарганын маңгаендагы жыерчыкларынын тирәнәюеннән, монсулык ингән күз карашыннан, йөрүенең авыраеп китүеннән ана жиденче тоемы белән сизде. Харап булган кызым, монысы да апасы кебек бәхетсез булыр микәнни дигән ачы фикер миен тырнап узды. Ләйлә әүвәл

сөйләмәскә тырышса да, әнисенең басымына түзә алмыйча, гасабиланып урынында таптанды да, йөрәген буып торган хисләр ташкынын тыя алмыйча, кычкырып елап җибәреп, әнисенең иңбашына башын куйды...

Җир шарында йөзәр, әллә ничә меңәр кат кабатланган һәм тагын да булачак гадәти хәл килеп чыккан. Ләйләнең шампан шәрабына мөкиббән китүен яхшы белгән, хатын-кыз мәсьәләсендә тәҗрибәле баскетболист, сиздермичә генә чәркәгә аракы кушып эчерткән. Үтә күренмәле эчемлек Ләйләнең башына киткән. Җитмәсә кош мамыгыдай җиңел кызны күтәреп бүлмә буйлап зыр-зыр әйләндереп тәмам миңгерәүләтеп, чистый хәлен алып, йомшак ятакка илтеп салган. Яклаучысыз, чарасыз калган кызны Алёша шашып-шашып үбәргә, көчле куллар өлгергән алма кебек тулышкан күкрәкләр аша әллә кайларга кереп киткәч, кызның бөтен тәне-җаны тыпырчына башлаган. Мондый хәлнең кияүгә чыкканнан соң гына булырга тиешлеген ата-анасыннан, сугыш ветераны бабасыннан кат-кат ишеткән кыз «ярамый, ярамый» дип карышкандай булып караса да, егетне этеп җибәрергә әллә көче җитми, әллә ихтыяры шартлап сына. Иң аянычы: үзенең дә тыелган оҗмах алмасын татып карарга теләге тудымы шунда, соңыннан үзе дә өздереп әйтә алмады. Хәзер үкенүдән ни файда. Әтисе сизмәсә дә, ана кешедән бернәрсәне дә яшереп булмый шул. Ләйлә әнисенә, үзендә дә кинәт дуамал дәрт кабынуны гына танымыйча, барысын бәйнә-бәйнә бәян итеп бирде. Белеме буенча медицина туташы Халидә ханым кызын бүлдермичә, ишкәнсең икән дигән сыман ачы лимон капкан кешедәй чыраен сытып тыңлап бетергәч, «аның сиңа өйләнергә нияте бармы», дигән соравына, «миңа кияүгә чык» дип әйткәне, «үземнең миңа өйлән дип бәйләнгәнем булмады», дигән, бу хәлдә мөмкин булган иң тулы җавапны ала.

—Балага гына уза күрмә! Хәзер егетләр кызның инсафлы булуыннан бигрәк, ата-анасының матди хәленә, белгән урынына игътибар итәләр. Ирең беренчең булса, аны кулга алуы, үз кубызыңа биетүе ансатрак була анысы. Нинди кеше насыйп булыр инде, кызым үзеңә. Апаң Регинаның да тормышы шулайрак килеп чыкты. Әүвәл әтиең киявебез Рәхимнең салгалавын өнәмичә, «кызым, яшь чагыңда ташла син бу алкашны», дип тенкәсенә тиде. Балалары булмауны да аңардан күрде. Врачларга алып барып, тикшертеп, «Рәхимнең балалары булмаячак» дигән кәгазь дә алып кайтты. Гиппократ антына тугрылыклы, намуслы врачларны көндез шәм яндырып эзләсәң дә табуы кыен. Кемнең дәрәҗәсе бар, кайсы күбрәк түли, теләсә нинди диагнозны куеп бирәләр. Шуңар да типсә тимер өзәрлек ирләр, җигеп сабан сөрерлек таза хатыннар оялмыйча инвалидлык книжкаләрен селкеп йөриләр. Апаның элеккеге ире өйләнгән, рәхәтләнеп ике бала үстереп ята, диләр. Атаңа шул хакта сөйләгән идем, сул як борын тишеген генә кабартты да, «кызым чибәр, бай, үзенә тиңен тапмый калмас әле», «яше уза бит, бала табарга соңарып бара» дигәч, «юк белән башымны катырма», дип бүлмәсенә кереп бикләнде. Хатасын тану юк.

Халидә ханым кызының иңнәреннән тотып, күзләренә карап, өстәп куйды:

—Кызым, спортсменыңны кылган явызлыгы өчен каһәрләсәң дә, каршы алырга бармаганы өчен рәхмәт әйтергә тиешсеңдер. Ул килсә, татар егетен очратмас идең. Бик итагатьле, зыялы адәм, дисең. Өлкәнрәк булуы да яхшы. Әтиеңнең тормыш алып бару өчен ирләр олырак, тәҗрибәлерәк булса әйбәтрәк дип гел такылдап торган көне.

Юлда арганлыкка сылтап әтисенең сораштыруларыннан җиңел генә котылса да, үзеңнән качу мөмкин түгел икән. Ләйлә җәһәт кенә бүлмәсенә кереп бикләнсә дә, җанына тынычлык килмәде, тәнен кая куярга белмичә, мендәрен әйләндерә-тугландыра, таң атканчы чәбәләнде. Морад белән

танышу китергән талгын шатлыкны үкенеч, сөенечне үткен тырнакларын әллә кайларга батырган хәсрәт сөреме алыштырды. Утлы кайгы йөрәге буйлап үтеп канлы эз калдырып үткәндәй тоелды.

## II

Ләйлә черки сыткан җинеллек белән очрашуга вәгъдә биргәч, Морад юл буена көтелмәгән танышулары, кыска вакытта туган ниндидер эчке якынлыклары турында уйланып кайтты. Нәрсә булды соң әле бу? Очраклылыкмы, әллә язмыш уенымы? Гаиләләр тарихы күрсәткәнчә, кешеләр икенче яртыларын шулай көтмәгәндә очратып, гомерлеккә яр, иң якын затлар булып калалар, холыклары тәңгәлләшсә, бәхеткә тарып яшиләр, ә инде уртак тел таба, мал бүлешә алмасалар, дошманлашып аерылалар. Икенче яртыларын таба алмыйча интеккәннәре дә буа буарлык. Гасырлар дәвамында гаилә коруга ярдәм иткән ярәшү, баш кодалар институты да телевизор каналында кемгәдер акча эшләү өчен генә хезмәт итә бугай. Үзен Ләйлә дип таныштырган кызга ышанырга буламы? Кызлар күңеле—кызган казан, учакка утын өстәп тормасаң, тиз суына диләр бит. Икенче яктан утызын вакларга әзерләнеп йөргән Морад буйдак тормышыннан бик канәгать, мөстәкыйльлеген бик югары бәяләүче зат иде. Гаилә тормышы аны беркадәр куркыта да. Мәктәптә, бигрәк тә югары уку йортында бергә белем эстәгән таныш-белешләренең, дус-ишләренең, никах укытып, рәсми язылышып яшәгәннәрнең дә шактые бераз торып карауга, мәхәббәт агачының суы кибә башлауга, нарасыйлары хакы белән дә санашмыйча, тәртәләрен төрле якларга боралар, дәрьядагы караблар кебек таралышалар. Статистика дигән ата ялганчы мәгълүмат бирмәсә дә, югары белемлеләр, шәһәрдә яшәүчеләр арасында аерылышу очраклары күбрәк тә бугай. Чүп чиләген кем чыгарырга, баланы бакчадан кем алырга, тәрәзәне ачарга ярыймы кебек вак-төяк бәхәсләр олырак җәнҗалларга күчкәч, мәхәббәтне нәфрәт пәрәвезе күмә. Эчкечелеккә сабышмаса, дөнья, мал-туар мәшәкате белән мәшгуль авыл кешесенең хатыны белән «аңлашып» утырырга вакыты да калмый бугай.

Әлбәттә, әле бер тапкыр аралашу гына бернигә дә мәҗбүр итми. Аңа да иреклe, азат тормышы белән саубуллашып, гаилә исемле кара урманга кереп китәргә туры килер микәнни? Аны үзләренә өйләндерергә, муенына камыт кидерергә тырышып караулар булмады түгел. Тик берсе дә Ләйлә кебек күңел кыңгырауларын уята, зиһенен чуалта алмаган иде. Икенче көнне Морад машинасы белән кара капка янына килеп туктауга, аннан иптәш кызы белән Ләйлә дә килеп чыкты. Куе болыт төсле кара, күпертелгән чәчле, өзелеп төшәргә әзер өлгергән карлыгандай күзле, озын муенлы, нечкә билле икән дусты. Буе Ләйләдән озынрак, кыска кара итәге аякларының төзлеге белән сокланырга тулы мөмкинлек бирә. Мондый чибәрләрнең иргә баш бирмичә, мөгез куярга маһирлыклары, ахыр чиктә, ялгыз калулары Морадка мәгълүм иде. Андый гүзәл затлар тирәсендә сырпаланып, ымсынып йөрүчеләр күп булса да, чәчләрен гомерлеккә бәйләргә ашкынып торучылары санаулы була.

Ләйлә Морадка мөрәҗәгать итеп, рөхсәт сорагандай тавыш белән:

—Дустым Айсылу килеп чыккан иде хәл белергә. Безнең белән аралашасы килә.

Ләйлә күрешергә үзе кулын сузгач, егет аның йомшак учын үзенекендә, мәгънә салып, озаграк җибәрмичә торды. Айсылу белән башларын иеп кенә исәнләштеләр. Нинди максат белән ахирәтен ияртергә булды икән Ләйлә? Үзенә караганда матуррак шәриктәшенә кармак салып, аның артыннан сөйрәлә башламасмы дип сынау өченме, әллә, киресенчә, егетләр сайлауда тәҗрибәле дустыннан зәвыгына бәя алу өчен дәшкәнме? Үен зурдан баргандай

тоелды аспирантка. Машина янына килгәндә дә, ишекләрне ачып утыртканда да Морад яшертен-орынтын гына Айсылуны өйрәнүен дәвам итте. Кыз тышкы гүзәллекнең сихри чигендә тора. Рәсемдәге сынны ныграк өйрәнгән саен элек игътибар ителмәгән яклары ачыла барган кебек, аңа гел карап торасы килә. Күзләрне камаштырырлык гүзәл Айсылу көндәлек мәшәкатьле тормыш өчен яратылмаган, чын татар кызы шундый да була ала дип күрсәтү өчен җәннәттән иңгән асыл кош кебек иде. Кояш нурлары шактый мул кунган аяклары белән гөнаһлы җирдән атлаганда, чиләкләре су белән тулы көянтәне иңендә калтыратып баргандай, билләре Шәрекъ биюен искә төшереп, уйнаклап тора. Морад котырынып алырга әзер нәфесен авызлыклау әмәлен тапты. Бу гүзәл сында Ләйләгә хас мөлаемлелек, ихласи елмая белү, ягъни ир-ат халкын үзенә карата торган самими җылылык җитенкерәми. Әгәр аңа күк галиҗәнапләре белән идарә итүчедән, «икесеннән күңелеңә ошаганын сайлап ал, Алла колы», дигән әмер килсә, ул һич икеләнмичә Ләйлә тарафына борылыр, кочагына аны алыр иде.

Учын кулында тоткан мәлдә Ләйләне игътибар беләнрәк өйрәнә алды. Кыз аэропортта чибәррәк, өлкәнрәк, усалрак күренгән иде. Гәүдәсен җыеп куйган кыска күлмәк кигәч, бала-чага булган да куйган. Урынында тыныч кына басып тора алмавын әйтми дә инде. Аяклары «төнге күбәләкләрнеке» шикелле колактан үсеп чыкмасалар да, нечкә биленең табигый дәвамы булып ир-ат кулын сыйпарга котыртып кына торалар кебек. Зәңгәр күзләре елмаеп, бит урталары көлгән саен эчкәрәк батып, назлы чокырчыклар хасил итәләр. Биек, ачык маңгае белемнең үзенә җинел бирелүенә ишарә ясап тора. Матур матур күренмәс, сөйгән матур күренер, дип юкка гына сайрамыйлардыр гашыйклар.

Ике гүзәл затны тугызлы «Жигули»енә утыртып, Морад машина куярга җайлы урын табып, кызларны төрек кафесына алып керде. Айсылуның матурлыгын төрек кардәшләр дә «чок гүзәл» дип, телләрен шартлатып бәяләделәр. Морадка аның ягына бернинди максатсыз, хиссез булса да күзен тондырмас өчен, су салу, салфетка бирү кебек мәҗбүри булмаган шөгыльләр табарга туры килде. Тиздән Айсылу «иптәшләр, гафу-гафу, минем барасы җирем бар, сезнең белән дөньямны онытып утырам» дип, озатып куюдан баш тартып, Ләйлә күрмәгәндә Морадның җилкәсенә орынып, кәс-кәс атлап чыгып та китте.

Алгарак китеп булса да, шул хәтлесен дә искәртү мөһимдер. Айсылу белән тагын берничә тапкыр уртак мәҗлестә булырга туры килде егеткә. Яшьләрнең туй мәҗлесендә дә түрдә утырды чибәр кыз. Аннан соң ул юкка чыкты. Байтак вакыт узганнан соң гына Ләйлә мондый җөмлә ычкындырды:

—Айсылу сиңа гашыйк булган икән теге чакта. Интернет аша танышып, Австралиядә яшәүче татар егетенә кияүгә чыкты. Иремне яратмавымны тормыш муллыгы, табигать матурлыгы тулыландыра дигән бер хаты гына килде.

... Ләйлә белән Морад ул кечне кафеда икәү генә калгач, рәхәтләнеп, җәелеп, үзләрен таныштырган вакыйганы көлешеп искә төшереп утырдылар. Һәр кечтеки деталь, машина көзгесендә күзләрнең очрашып алуы, икесенә дә оят булып китү алар өчен ифрат мөһим тоелды.

—Ә син, Морад, күзләремә чумдың.

—Синең күзләрең миңа төбенә зәңгәр күк йөзе төшеп утырган серле кое күк тоелды.

Мондый гәпләшеп вакыт уздырулар икенче, өченче, тагын әллә ничәнче очрашуларда дәвамын тапты, концерт залларына, танцы мәйданнарына алып килде. Һәр яңа күрешүдә егет Ләйлә холкының күркәм якларын ачып, кызның үзенә торган саен ныграк ошый баруын, аны берничә көн күрми торса, бик әһәмиятле, кыйммәтле әйберен югалткандай хис итә башлауны сизде. Яшь булса да, аның һәр шәйгә үз бәясе, хөкеме булуы, шат күңеллелеге, хәтта үзенчә тәмләп, дөньясын онытып үбешә белүе хатын-кыз назын шактый

татыган Морадны да әсир итте. Чын-чынлап, малай-шалай кебек ихтыярымны югалтырлык дәрәҗәдә гашыйк булам түгелме дип, шатланыргамы, кайгырыргамы икәнен тәгаенли алмыйча хисләнеп, кичерешләр дөньясына чумып утырулары еш була башлады. Нишлисең, бу фани дөньяда синнән тормый, ихтыярыңа буйсынмый торган көч тә бар, күрәсең. Мәхәббәткә һәммә инсанны канәгатьләндерерлек анлатма-билгеләмәнең табылганы юк бит әле. Һәркем үзенчә акылдан шаша. Ләйлә дә миңа битараф түгел бугай. Юкса көненә әллә ничә мәртәбә телефоннан шалтыратып, һәрдаим очрашуга әзер булып тормас иде. Бәлки, без гашыйклардыр, бер-беребезне гадәти булмаганча эзләп табуны югары көчләр оештыргандыр. Кемгәдер бик буш, мәгънәсез күренгән уртак танышлар, студент тормышы, кием-салым турында сөйләшү-көлешүләрдән тәм таба торган булдылар. Ләйлә бервакыт «Морад җаным, мин сине гомерем буена дулкын арасыннан аккош көткәндәй эзләдем» дип, каядыр укыган, ишеткән ясалмарак җөмлә ычкындыргач, егет тә үзенең «белгечлегенә» кереп китте.

—Ләйлә матурым, мәхәббәт ул җан белән тәннең бердәмлеген табу билгесе, язгы суларның инрәп ташуларына, күк күкрәүләренә, яшеннәргә тиң бөек хис, олы бүләк, тетрәндергеч халәт. Аны саклый, кадерли белергә кирәк. Ул зиһен белән аңлап бетерә алмаслык илаһи көч, күктән ингән бәхет,—дип кызны сәрхушләндергәнче сайрады.

Күрәсең, еш-еш, утлы сулаудан, Морад теленнән төшкән матур сүзләрдән Ләйләнең каптырма сәдәпләрдән торган йон күлмәгенең өске өлеше чишелеп китә. Кыз берни уйламыйча:

—Морад, сәдәпләрем ычкынды, каптырырга булышмассыңмы?,—ди. Сәдәп төймәләү капчык ташу яисә эссе көндә печән чабу түгел ич, бу шөгыльгә егет бик теләп алына. Мәгәр күлмәкнең өске өлешен каптырырга гына вәкаләтле куллар күкрәкнең тигез кырда калкып чыгып, тырпаеп торган биеклегендә тукталып калалар. Өлгергән алманы кыскан куллар төймә каптыру турындагы вазифаларын онытып җибәргән мизгелдә Морадның бөтен тәне буйлап ток җибәрделәрмени, үзе әйтмешли, бала-чага кебек теше тешкә шакылдап бәрелгәнче калтырана башлый. Аякларын урында тыпырдатуына караганда сәдәпләрне заманча «каптыру» кыз күңеленә дә хуш килә. Ашыктырмый, көйсезләнми. Морадка аның тавышы ерактан, мәңгелектән килгәндәй тоела:

—Абзыкай, әй, абзыкай, мин сездән күлмәк төймәләрен каптырырга сораган идем, сез аларны чишеп барасыз түгелме?

Ләйләнең тавышы да тамагына юкә балы утырган кешенеке кебек карлыгыбрак, дөресе, күкрәктән, егетнең кулы тирәсеннән чыккандай тоела. Икесенә дә отыры рәхәт иде. Кызык инде, нибары ике ай элек дөньяда яшәүләреннән дә хәбәрдар булмаган кешеләр иңнәрен иңнәргә терәп, янәшә атлап киләләр дә, туктап, беренче күргәндәй, озак итеп бер-берсенә, мишәрең әйтмешли, багып торалар. Ике арада сузылган наз җебе, күрешмичә торганда да, йөрәкләренә яшәү дәрте биреп тора.

—Китап укыганда да синең йөзең күз алдымда: ачык битенең сул ягында хәрефләр бии, уң ягында син елмаеп басып торасың, Морад. Аэропорт залындагы кебек.

Шул мизгелдә кызның күзләрендә шаян ут чаткылары бии. Тик Морад кызның катлаулы эчке халәтен аңлап бетерми. Кирәге дә юк. Алар бер-берсен күптәннән белгәннәр, тик очрашу сәгате генә кичектерелә килгән. Моннан соң Алла юк, булса да, вак-төяк, артык шәхси хәлләргә юнәлеш биреп торырга житешми дип кара!

Бөтен барлыгын онытып, кызышып сөешкән мизгелләрдә дә Ләйләнең күзләреннән моңсулык сөремен юып төшерә алмаган ике сәбәп бар иде. Аң төпкелен туктаусыз тырнап, борчып торган серне Морадка да чишеп

булмый шул. Киләчәкләре өчен нәкъ аңа белдермәү хәерле. Һәрхәлдә, туй узганчы. Берсе—баскетболистның дәгъваларыннан котылу, китергән зарарын сиздермәү, үзеннән биздерү булса, икенчесе—яраткан әтисенең төпченүеннән, әхлакый кинәшләреннән файдалы гына арыну иде. Алёша Мәскәүдән кайтып төшкәннең икенче көнендә үк шалтыратып, «мин бик ашыгыч рәвештә башка шәһәргә китәргә мәҗбүр булдым, кесә телефонымны өйдә онытып киткәнмен, зинһар, гафу ит, сине югалту куркынычы янагач, төн йокыларым качты, мәхәббәтемнең Урал тауларына тиң олылыгын аңладым, бүген безнең уенны карарга килегез, соңыннан иң бәһале ресторанга алып барырга да риза», дип сөйгәненә очрашуга чакырган сандугач кебек сайраса да, аның поезды тукталышны узып киткән иде. Күңелен башка ялкын биләгән кыз, спортчының гомуми сүзләрен колагы яныннан уздырып, дәгъвачыга бернинди өмет калдырмыйча, кискен җавап төшерде.

—Яратуың чын булса, мин аңа шикләнәм, Алёша, миңа бүтән шалтыратма. Үтенеп сорыйм. Үзенә кирәген талап, минем киләчәк турында уйламыйча алдың. Яшьлек хатам өчен гомерем буена күз яшьләрем белән түләргә туры килмәгәе. Сборларга йөрүеңне, буең белән алдавыңны дәвам ит!

Тыелган алманы тәмләгән баскетболчы соңгы тапкыр булса да очрашып, сөйләшеп утыруны кат-кат сорады, әзерләп куйган зиннәтле бүләкләре белән дә кызыктырып карады. Өйләнергә теләге барлыгы турында кат-кат тәкрарлагач та, кызның чакма ташы мисле каты торуын күргәч, соңгы чараны—коткыны эшкә җикте.

—Синең яңа егетең турында мәгълүматым бар. Аның хатын-кызның башын әйләндерү тәҗрибәсе зур, диләр. Уйлап кара: аны утыз яшенә җиткәнче өйләнмичә яисә сезнең нәселне таптамыйча яшәгән дип уйлыйсыңмы? Шуның өстенә ул иске, шалтыр-шолтыр йөри торган тугызлы машинадан башканы күрмәгән хәерче аспирант.

Олы спорт даирәсендә кайнаучыларның рухи дөньялары сай, акчага береккәнлеген, мактанудан тәм табуларын, үзләрен әллә кемгә куярга маһирлыкларын белгән Ләйлә озын егетнең авызын тиз япты.

—Мин аның тормыш мажараларын яхшы беләм. Һәммәсен бәйнә-бәйнә үзе сөйләп бирде.

Шунда ук үз ялганыннан кызарып китеп:

—Кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Тиздән гөрләтеп туй уздырачакбыз.

## III

Морадның үзенә җитди мөнәсәбәтен, киләчәген бәйләргә җыенуын акылыннан бигрәк, хисси тоемы белән ачыклагач, Ләйлә әтисе белән сөйләшергә, киңәшергә булды. Шуңа инанганчы әтисенең сораулы карашын сизмәмешкә салышып йөрде.

—Әти, без Морад белән бик якынаеп киләбез. Ул миңа көннән-көн ныграк ошый бара.

Бөдрәлегән саклаган аксыл-җирән чәчле, зәңгәр төс йөгергән соры күзле, уртача буйлы, җитез хәрәкәтенә караганда, яшьлегендә йә йөгерешче, йә биюче булганлыгы сизелеп торган әти кеше олы залдагы күн тышлы диванга җайлап утырып, янында басып торган кызының кулын учына алып:

—Әйбәт булган, кызым. Хуплыйм. Юкса Ләйләмнең дә кәҗә бәтие кебек сикеренеп, бушка вакыт уздырып йөрер көннәре үтеп, үз учагын ягып җибәрер сәгате узып китмәсен дип борчылып йөри башлаган идем. Кызлар бит кыяр кебек, тиз өлгерә, момент бозыла.

Ләйлә әтисенең сүзләреннән юри чыраен сыткан булды, сары кашлары, таң атканчы көрешергә ашкынган Сак-Соклар кебек, бер-берсенә тартышып куйдылар.

—Юкка хафаланасың, әти, һәр нәрсәнең үз вакыты, җае бар. Әллә миннән туйдыгызмы, бу кыздан тизрәк котыласы дигәнрәк хыял белән янып-көеп яшисезме?—диде, уенын-чынын бер ми казанында кайнатып.

—Ничек инде сезнең язмышыгыз, киләчәгегез өчен без борчылмыйча яшик ди. Баланны бөтен өметенне баглап үстер дә, аның иртәгесе көне турында уйлама, имеш. Бигрәк тә кыз баладан аерылу авыр икән. Кадерленне бөтенләй белмәгән, чит-ят кеше кулына тоттырып, кош баласын очырган кебек, ояннан чыгарып җибәр әле. Хәлемнән килсә, үзегез риза булсагыз, газизләремне гел янымда гына тотар идем дә, балалар тизрәк өйдән чыгып китү ягын карыйлар шул,—дип Сахип әфәнде ихластан көрсенеп алды. Әтисен бераз кызганып куйса да, кәефе хуштан Ләйлә югары дәрәҗәдәге гәпләшеп утыруны янәдән шаянрак эзгә төшерү ягын каерды.

—Мине яныгызда тотасыгыз килсә, ике як та хупларлык вариант тәкъдим итәм.

—Нинди?

—Өйләнешкәч, Морадны монда алып кайтырмын. Өенә чакырганы булмаса да, сөйләвенә караганда, аның бер бүлмәле фатиры безнең Томан оясыннан аз гына зуррак булырга тиеш.

—Кая яшәү мәсьәләсен әтиең исән-имин чакта хәл итәр. Урамда калдырмам. Безнең янда, оҗмахта яшәргә теләмәсәгез, әниеңне килен итеп төшергән хрущевкабызны да саклап тотам.

—Гомер агышы шуңа җайланган инде,—диде Ләйлә җитдиләнеп.—Ата күңеле балада, бала күңеле далада дип юкка гына әйтмәгәннәрдер,—дип өстәде, кайчандыр ишеткән мәкальне исенә төшереп.

Әти кеше бу фикерне ошатмады, кызының шаяртуын да кабул итмәде.

—Бу тәрбиясез, ата-ана мәхәббәтен күрмәгән, бәяләп җиткермәгән балалар турында әйтелгән мәкаль. Син аны башыңнан чыгарып ташла,—дип, килде-китте сөйләшүне хупламаганын күрсәтү йөзеннән булса кирәк, урыныннан торып, йөренеп алды.

Озаклап сөйләшеп, теңкәгә тия торган вәгазь укырга җыена бугай дип уйлап куйды атасының холкын яхшы белгән Ләйлә. Һәм ялгышмады.

—Кызым, тормыш юлында нинди генә кыенлыклар, бәхетле, ничек диләр әле шагыйрь иптәшләр, мизгелләр булмасын, синең өчен таяныч, якты маяк төсле әти-әниең торса, аларга яхшы мөнәсәбәтең күңел тынычлыгы алып килер. Кешеләрне нәрсә якынлаштыра? Сахип галәм серләрен ул гына белгән кешедәй, имән бармагын алтатар көпшәседәй өскә күтәрде.—Кан уртаклыгы, кызым. Шул гына кешеләрне бәйләп, җепкә тезеп тота. Ни өчен гаиләләр еш таркала—димәк аларны уртак кан бәйләп, укмаштырып тотмый.

Сахип әфәнде яраткан мәүзугына кереп киткәч, туганлык мөнәсәбәтләре турында туйганчы, озаклап фәлсәфә сатты. Ләйлә әүвәл аны кызыксынган булып, мәктәптән иркеле алып кайткан укучы бала кебек бирелеп тыңлады. Күңеленә кызыклы бер фикер килгәч, урындыгында боргалана, бит очларына чокырчыклар чыгарып, елмая ук башлады. Билгеле нәрсәләр хакында шулай озак һәм эчпошыргыч итеп сөйләүчене кая тыңлаганы бар соң аның? Шуны исенә төшерү күңел шәрифләрен күтәреп җибәрде. Бөек Толстой каләменнән төшкән Каренин шулай нотык тотарга, акыл сатарга, өйрәтергә яраткан ич. «Анна Каренина» романын укыган иде, күптән түгел фильмын да карады, күрәсең, унышсыз мәхәббәте белән бер рәттән Анна карт иренең вәгазьләреннән туеп поезд астына сикергәндер. Каренин ролен уйнаучы артистның фамилиясен хәтерләмәсә дә, артык тигез, төссез сөйләве белән аның нәкъ әтисенә охшап торганын тәгаен хәтерли. Аның нотыкчыны бүлдереп, янәдән уйнаклап, шаяртып аласы килде. Ләйлә,

марилар биюендәге шикелле, аякларын урында тыпырдатып алды да:

—Уртак бала кан йөрешен үзгәртеп, кешеләрне якынлаштырмыймы? Мәхәббәт вакыт узгач сүнсә дә, рухи якынлык, уртак мәшәкатьләр, зәвык, ахыр чиктә, истәлекләр кала бит.

Кызының үзен бүлдерүен, сүзләрен җитди кабул итмәвен Сахипның диванда боргаланып утыруыннан, күзләрен каплый язырдай салыныбрак төшкән аксыл кашларының калтыранып алуыннан сизде тыңлаучы. Әти кеше баланың аң төпкелендә яткан борылышларны да тоеп ала шул. Сахип та сүз елгасын башкага борып җибәрү кирәклеген сизде.

—Шатланып бетә алмыйм, Ләйләм.

—Нигә диик инде, әтием?

—Балаларым икесе дә кыз булды.

—Анын ни аермасы бар? Ир бала да бала, кызы да бала.

—Юк шул. Кызлар, бердән, ягымлы, иркә булып үсәләр, үзләрен тудырып, үстергән, канат куйган якыннарын—әти-әниләрен ташламыйлар. Ә егетләрне хатыннары алып китә дә, вәссәлам, бигрәк тә тормышы җайлы буразнага төшсә, аларга ата-ана да, әби-бабай да кирәкми. Җүнсезләре пенсия алган көнне «хәл белергә» килеп җитәләр.

Сөйләшүнең янарак юнәлешен иярләгән Сахип аталар белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында рус, татар әдәбиятларыннан мисаллар китерә-китерә кызын тәмам алҗытты.

Ләйләнең пырдымсызланып, сәгатенә карап-карап алуы буенча каядыр ашыгуын сизеп Сахип (яшьләр акыллы фикерләрне, акыл сату дип ялгыш бәяләп, өлкәннәрне тыңларга яратмыйлар шул), төп фикерен кызының колагына индереп калырга ашыкты.

—Егетең сиңа тәкъдим ясадымы соң әле?

—Үзем, миңа өйлән, дип әйтермен яме,—диде Ләйлә иреннәрен сузып.

Кызының ирониясен кабул итмәгән ата кеше:

—Гадәттә кушылу, гаилә кору турындагы фикер әүвәл ирләрдән чыга. Хатын-кыз әле бераз уйланыбрак торырга, бу сүзне күптән көтеп яшәгәнен сиздермәскә тиеш.

—Мин ана әтинең тиз арада кияүле буласы килә, сузма дип әйтермен.

—Мин синең белән олы башым белән киләчәк тормышың, язмышың турында сүз алып барам. Гел уенга борып утырасың. Тормыш ул театр дип раслаучылар булса да, сәхнәдә озак яшәп булмый. Спектакль беткәч, артистлар да өйләренә таралыша.

Кызым минем, сиңа бик зур үтенечем бар: син безнең борынгы, ерактан, ханнар заманыннан килгән Габбасов фамилиябезне сакларга тиешсең. Аның юл башында атаклы муллалар, зыялылар торган. Ул безнең горурлыгыбыз, рухи мирасыбыз. Улыбыз булмагач, нәсел дәвамчысы буларак син каласың. Үзең беләсең, минем энекәшнең хатыны башка милләт кешесе. Аның балалары сонрак фамилиябезне үзгәртеп, бозып бетерәчәкләр. Котдус Кутузовка, Әклим Климовка, Нуретдин Нардинга әйләнгән шикелле аны да берәр Габисовка яисә Абисовскийга үзгәртәчәкләр. Апаң Регина мине тыңламыйча, иренең фамилиясенә күчте, ә гаилә бәхете булмады.

Апасының ире белән аерылышуында әтисенең өлешен яхшы белгән, өстәвенә үҗәтлеге дә берничә кешегә җитәрлек Ләйлә мондый тәкъдим белән килешергә ашыкмады.

—Габбасова булып калып кына мин бәхетле булырмынмы? Гаиләмне сакларга ярдәм итәрме?

Сахип Миндрахманович мәсьәләгә кинрәк карашы белән кызының шиген, шөбһәсен таратырга булды.

—Үзең күреп торасың, шул фамилия белән мин нинди уңышларга ирештем. Әүвәл нәсел фамилиягә хезмәт итә. Соныннан ул барчасына югарыга үрмәләргә булыша. Син университетның иң престижный факультетын тәмамлап киләсең. Укырга кергәндә берничә балың җитмәсә дә, фамилиябез артында торган кешеләрнең абруе мәсьәләне унай якка хәл итте дә куйды.

Ләйләнең әгәр дә әнең олы түрәләрнең күзенә чалынып, тугрылыклы хезмәте белән өскә күтәрелә алмаса, сине үз артыннан сөйрәп бармаса, һаман да техникумда информатика укытып, вак-төяк сәүдә белән шөгыльләнеп көнеңне күрер идең дип ярып салырга теле кычытса да, кызыл рубинлы алка, мәрәкә ширкәтеннән бизәнү әйберләре алу өчен акча сорыйсы исенә төшкәч, үзгәрәк четерекле сөаль бирү белән чикләнергә булды.

—Ни өчен әнием үз фамилиясендә калмады? Теләмәдеме, әллә синең тәти фамилияңә кызыктымы?

Туры җавап бирәсе урынга, Миндрахман улы Сахип пакосны кинрәк алдырырга булды.

—Әниең чибәр, чая ханым. Мишәрләргә хас гадәтләрнең күбесен үзенә сеңдергән. Тоткан җиреннән өзмичә җибәрмәс. Менә мине дә бик тиз ЗАГСка алып китте, мин аңгы-минге йөргән арада апанны, сине табып, үзенә гомерлеккә әсирлеккә төшерде. Тик үзенә әйтә күрмә: әниең чабаталы нәсел баласы. Анын кыз фамилиясе Гыйздуллина иде. Хикмәт озынлыкта, авыр ямьсезлектә генә дә түгел. Анын туры бабасы Гыйздулла исемле була. Яңа ясалган, тарихы кичә генә башланган фамилияңең кай җиренә ябышып ятасың. Борынгы фамилияләрен саклап калу өчен бик күп буын бабаларың зур көч куйганнар, көрәшкәннәр дип уйлыйм. Басып алучыларга нәсел җебен югалткан маңкортларны буйсындырып тоту җиңелрәк булгандыр.

Ләйләгә дә фамилияләре борынгы, серле һәм күп мәгънәле тоела. Баш бирмәс б хәрефләренең янәшә килүе, а ның эчке рифма ясавы үзе ни тора. Татар теле дәресләрендә Әлфия апасы сингармонизм кануннарын аңларга тикмәгә генә өйрәтмәгәндер. Тик бу гамәлне тормышка ашыруда урыстан инсә дә, үзебезнеке булып киткән ну кисәкчәсе тырпаеп, эчне пошырып тора. Бу хакта Морад белән ничек сүзне башларга? Ул укыган кеше, бәлки, ваклашып та тормас, үзенә кара дип фикерен тәгаенләп әйтмәве дә бар. Яһүдиләрдә генә бит ул нәсел башында аналар тора диләр. Ә татар-төркиләрдә хатынның ир фамилиясенә күчүе бәхәс тудырмый торган хакыйкать санала.

Кичә Ләйлә зәңгәр экраннан кинчә битеннән, бәрәнге борыныннан, чем-кара күзләреннән, эре сөякле гәүдәсеннән кыпчак нәселеннән икәнлеге күренеп торган Фәрдәния Газиз кызы Нигъмәтуллинаның, рус егетенә кияүгә чыгып, Иванова фамилиясен алуы турында горурланып сөйләвен тыңлап, милләттәше өчен оялып утырган иде. Бәс, шулай булгач, ни өчен Ләйлә иренең фамилиясенә күчмәскә тиеш. Дөрес, Морад үзенең фамилиясен яратып бетерми. Сәлимуллин имеш. Тел төртелерлек авазы да юк. Артың белән бозлавыктан шуып барган кебек кенә. Бәлки, булачак ирем үзе безнең фамилияне алыр. Габбасовлар булып, кулга-кул тотынышып, Муса Җәлил һәйкәле яныннан узсак, ничек күңелле булыр иде. Юк, ошбу тәкъдимне әйтергә кыюлыгым табылса да, Морад риза булмас, үз тәкәбберлеге үзенә җиткән. Мәскәүдә яисә башка рус шәһәрендә кунакханәгә урнашканда, фамилиямне дөрес яздыра алмыйча интеккәнем шактый булды дип көлә-көлә сөйләгәне хәтердә. Саломуллин дип язалар, йә икенче л ны төшереп калдыралар. Төрки дөньяда Сәлим киң таралган исем, төрекләрнең атаклы солтаны Сәлим исемен йөрткән. Ул да, абзаң шикелле үк, алдынгы карашлы булган, яраткан хатынын менә болай күтәреп алып, беләгендә үчти-үчти

иттереп йөрткән дип язганнар бер югалган китапта дия-дия тәмләп теленә салынганы хәтердә. Морадның Ләйләне кулына күтәреп алып, баскетболист шикелле үк булдыра алмаса да, шактый әйләндерүе күңелдә.

Әтисенең җавап көткәне кызның келт итеп исенә төште.

—Әти, мин фамилиябезне сакларга тырышып карармын. Бу мәсьәләгә Морадның мөнәсәбәте ничек булыр бит әле. Нәсел тамгасын саклыйм дип иремне югалтуга бармаячакмын.

Сахип Миндрахмановичның ачыклыйсы, күңелен бимазалап торган сөальләре бетмәгән икән әле.

—Әти-әниләре кем диик инде булачак киявебезнен. Кайларда яшиләр?

—Кайсыдыр район үзәгендә көн итәләр, икесе дә мәктәп укытучылары, белүемчә.

—Шкраблар дисеңме? Совет чорында аларны шулай дип кенә йөртәләр иде. Школьные работники була инде. Укытучы минем өчен буш моралистның синонимы. Ул аңардан торган, нәрсәнедер булдыра, хәл итә алган кешедәй күп сөйли, сорамасаң да киңәшен бирә. Кыскасы, буш куык...

Тырнаклары алсу төскә буялган кулын җавапка әзер укучы кебек өскә күтәреп, Ләйлә янәдән атасын бүлдерергә җөрьәт итте.

—Иптәш Габбасов, беренчедән, үзегез дә хезмәт юлыгызны мәктәптә булмаса да, укытучы буларак башладыгыз, икенчедән, иң әдәпле, тәртипле балалар укытучылар гаиләсендә тәрбияләнәләр, дип сөйләгәнен хәтердә.

Сахип әфәнде кызының аңлатмасын колак яныннан гына уздырып, үз дугасын бөгүне дәвам итте.

—Синең нинди нәселдә туып-үскән былбыл баласы, бик кадерле кыз икәненне беләме соң егетең?

Ләйлә тавышына мыскыллау төсмере чыгарып:

—Безнең кул житмәслек бөеклек, галилек, илаһилек, кызыңның кул тидерергә ярамаслык дәрәҗәдә иркә, асыл зат булуы турында Морадның үзенә бәйнә-бәйнә сөйләп бирерсең. Бик беләсең килсә, ярты елдан артык очрашып йөрү вакытында нәрсә турында гына сөйләшмәдек, тик сезнең кем булуыгыз, фатирларыгыз турында бер генә тапкыр булса да, юри генә дә кызыксынмады. Барысын да аңлау өчен аңа безнең йортны күрү дә җиткәндер.Ул сезнең банктагы акчаларыгызга өйләнергә җыенмый. Аңа мин генә кирәк. Таләпләре зур түгел, тик ул горур, мөстәкыйль егет. Жаны тиз рәнҗүчән, бәллүр савыт кебек диләрме әле.

Сахип Миндрахманович кызын бөтенләй аңламас булды. Каян ингән аңа шундый усаллык, бөтен изгелегебезне сызып ташлап, булачак ирен хәзер үк бездән өстен куеп маташа түгелме? Шулай да бик онытылып китмәсен, аңа тормыш асылын, кемнең кем икәнен аңлата башларга вакыттыр.

—Кызым, ирең буйлы, чибәр, укыган булса да, аның матди хәле, хезмәт урыны буенча синнән түбәнрәк дәрәҗәдә торуы лазем (төрекләргә кара май сатып баеп алган әтисе кан кардәшләренең сүзләрен кыстырып җибәрергә ярата иде), шундый гаиләләр ныграк була.

Әтисенең үзләрен мактауда, нәселләрен күтәреп куюда чама хисен югалтуын яхшы белгән Ләйлә «әйе, дөрес сөйлисең», дип башын селкеп, үз уйларына чумып, оеп утыра бирде. Кызының үзен игътибар белән тынламавын сизгән Сахип әфәнде сүз жиленең борылышын үзгәртеп Ләйләне тормышчанрак сораулар белән китереп кысарга булды. Йөзенә, бөтен гәүдәсенә бик борчылучан кеше кәсафәтен чыгарып; кызыктыргыч җим ташларга булды.

—Кызым, киләчәктә мәшһүр рус язучы исемен йөрткән урамдагы фатирыбызда пропискасыз гына яшәрсез. Син бездә язылган килеш калырсың,

ул үзендә. Туй бүләгемнең берсе, иң мөһиме, сәяхәтләр оештыру ширкәте булыр. Хуҗасы булып үзем калам, син җитәкче—башкаручы, ирең урынбасарың вазифаларын үтәр. Хәерче аспирантка анысы да зур бүләк инде, аңласа.

Ләйлә атасына төртмәле караш ташлап, кабартма иреннәрен бөрештерде.

—Синең вәгъдәләреңне күңелең булсын дип игътибар белән тыңладым. Минем тормыш иптәшемнән икенче чүпрәк Габделбәр үрергә җиенуынны аңламыйм да, гафу итә дә алмыйм. Минем Морад турында сөйләгәннәремне җитдигә алмадың бугай. Ул—тәкәббер түгел, әмма горур кеше. Ачка үлсә дә, вокзалда яшәсә дә беркайчан кемнеңдер үкчәсен яламаячак. Аны мыскыллап, таптап яшәү турындагы хыялыңны корыт!

Кызы файдасына гел дөрес сөйләвенә шикләнмәгән Сахип абзыйны Ләйләнең ихластан очынып әйткән сүзләре дә, йөзен каралткан канәгатьсезлеге дә туктата алмады. Яшь әле, берни аңламый, рәхмәтен соңрак, авызы пешкәч әйтер.

—Фикеремә ачыклык керткәч, бу карарымның дөреслеген аңларсың. Сүз булачак киявебезне кимсетү турында бармый. Сез эшләячәк агентлык нигездә Алжир, Швейцария, Канада, Квебеке кебек француз телле илләр, Франциянең үзе белән эш йөртә. Аңлавымча, аспирантың Наполеон телен ни билмис. Без аңа бу карарыбызны, беләсеңме кайчан... нотыкчы хәйләкәр итеп сул күзен кысып алды... туйдан соң, дөмбер вакытында, башы авырткан мәлдә генә әйтербез. Француз теле курсларына йөреп алгач, сине исполнительный директор итеп куярбыз дип шомартырбыз. Вәгъдә бирү урман кисү түгел.

Әтисенең сүзләре бер колагыннан кереп, икенчесеннән шарлавыктан аккан судай чыга торды. Ул Морадның начальнигы булырга тиеш, ди түгелме. Кызык. Арсланга хуҗа итеп безнең Томанны куйган шикелле. Ләйләсен бу көннәрдә нәрсә борчыганны белсә, атасы сафсата базарында көнбагыш сатып утырмас иде. Кызының җанын агач корты кебек билгесезлек тырнап утыруын, иренә иң зур бүләге, күчтәнәче булырдай шифасын саклый алмаганын белсә, башкачарак сайрар, Толстой Каренины кебек эчпошырып тыңкышланып, баш катырып утырмас иде кадерле әтисе.

Утыз яшенә тикле муенына камыт кидертмәгән Морад күпне күргәндер, ятак тормышы серләреннән дә хәбәрдардыр. Әгәренки, ул ата көнчеләр кебек тавыш чыгарып, бергә яшәмәс борын аерылышырга бирсә, нинди тишеккә кереп качарсың. Әтинең байлыгы, безгә бирәсе иске фатиры гына коткарып кала алмас шул.

—Әдәбият дөньяның барышы белән мәхәббәт идарә итә дип раслый. Ишетүемчә, Иван Грозный Казанга һөҗүм белән килгәндә, төрек солтаны татарларга ярдәмгә җиенгач, яраткан хатыны—хохлушка Оксана, аны үгетләп, сорап, ялынып ярдәмгә җибәрмәгән. Мәхәббәт син әйткән кан кардәшлек теориясеннән өстен булып чыга түгелме?

Миндрахман улың ышанычыннан чигерә торган көч юк иде бугай.

—XXI гасыр, кызым, мәхәббәт, бурыч, намус, әхлак дип балавыз сыгып утыра торганга охшамый. Исәп-хисап, хәрәмләү, алдау, шомарту, акча, байлык заманасы килә. Яңа гасыр бер төрле сөйләп икенче төрле эшләүчеләр кулына күчеп бара. Мәхәббәт дигәнең, инглиз галимнәре раславынча, биш елдан дилбегәсен йомшарта, иртәнге томан кебек эри. Кешеләрне бер-берсе белән бәйләп тотардай нәрсә кала. Кланнарны, төркемнәрне тудыручы кан кардәшлеге төп көч булып алга чыга. Хәзерге көндә, нанәм, кияүгә чыгарга уйласаң, як-ягыңа каранып, төрле ягын уйлап хәл итәргә, солдат портянкасы юып яшәү көненә калмаска тиешсең.

Әтисенең озынга киткән нотыгыннан туя башлаган кызы, пырдымсызланып:

—Морадны күздә тотсаң, Морад хәрби түгел, ул—аспирант.

Фикерен артык берьяклы аңлау белән ризалашмавын сиздереп, Сахип Миндрахманович аскы иренен тешләп алды. Шул алымын эшендә ярдәмчеләренә шелтә белдерәсе килгәндә уңышлы куллана иде.

—Аспирантның тишек оегы солдат портянкасыннан күпкә аерылмый торгандыр дип уйлыйм.

Шунда ук, бүләк өләшкәндәй, йөзенә ясалма елмаю чыгарды. Бусы—аппарат уеннарында оста түрәләрнең яраткан алымы иде.

Әтисен бүлдереп, чыгып китү турындагы хыялын сизенгәндәй, күктән ялынып сораганны җирдән бирде, шул мизгелдә Ләйләнең кесә телефоны шалтырады.

Морад булуына бер кәррә дә шикләнмәгән Ләйлә, күрше бүлмәгә йөгереп чыгып, телефон төймәсенә басты. Мәгәр шалтыратучы каһәр суккан мунча пәрие, телеграф баганасы баскетболист булып чыкты. Көтмәгәндә эләккән тәмле пирог белән сыйлануын дәвам иттерәсе килүне яшерми.

—Сөекле Ләйләм, бик сагындым үзеңне. Зинһарлап сорыйм, соңгы тапкыр булса да очрашып алыйк инде. Һәркөнне сине төшемдә күрәм, уянып китсәм, Ләйләм янымда юк.

Йа Ходам, ни өчен мине шулай үткәнем эзәрлекли икән, заманында үзен биергә чакыргач, йөзен чөеп, баш тарткан Артур дигән кыланчыгы һич уйламаганда урамда очраткач, карале, син ничек матураеп, тулыланып (элек шыр сөяк идең диюе булгандыр), чын мадонна булып киткәнсең, әйдә бер күрешик дип бәйләнде. Шәриктәшләре аның өйләнеп, хәзер хатыны белән аерылышып йөрүе турында җиткергәннәр иде. Анысыннан «теге вакытта кочакланышып биегәнебез әле дә үткән елгы яшенле яңгыр кебек хәтердә, сөеклең янына кайт», дип котылган кебек булган иде. Тик анысына гомуми сүзләр белән ләтчә саткан арада телефон номерын бирүе сонрак өстәмә мәшәкать тудырды. Менә бу чучкасы тагын дип уфтануга, әтисе өйрәткән сүзләр келт итеп исенә төште.

—Мине яраткан булсаң, зинһар элеккеге мәхәббәтебез хакына артык борчыма. Кияүгә чыгам дип хәзерге рус телендә, аңларлык итеп әйттем, ләбаса. Яшьлек чәчәгемне өзеп, болай да онытыла алмаслык явызлык кылдың инде.

## IV

Сахипҗанының кызы белән сөйләшүен, яшәргә өйрәтүен ачык ишектән тыңлап торса да, мондый бәхәсләрне мәгънәсез вакыт уздыруга, кирәген тормыш үзе әйтеп тора дип санаган Халидә ханым Ләйләнең кесә телефонын тотып башка бүлмәгә чыгуын күрүгә, үзенең кичектермәслек санаган тәкъдиме белән сүз алды.

—Карале, атасы, бер кырые китек, син яраткан көзгене теге вакытта өске катка меңгереп куярга кушкан идем. Әллә төзәтергә илтеп бирикме дип кинәшмәкче идем.

—Кызыбызның киләчәге ачыкланган, шул хакта кызып-кызып сөйләшкән вакытта китек көзгең белән эчпошырып йөрисең. Хатын-кыз важный мәсьәлә белән вак-төякне аера белми шул. Фәлсәфи караш җитенкерәми. Кстати, көзгене ватып зур хата эшләгәнсез. Кайсыгызның кулы кычыткандыр. Аның пыяласы ифрат калын, аны чүкеч йә балта белән махсус ватып кына булырлык иде.

Кызының нәкъ шул мизгелдә бүлмәгә атылып килеп керүен күрми калган Халидә:

—Ләйлә аны ялгыш ватып төшерде.

Шунда ук Ләйләнең бирелә икәнлеген шәйләп, сүзен борыбрак җибәрергә тырышты. Ифрат җайсыз килеп чыкты.

—Ул болай да чатнаган, кителеп төшәргә генә тора иде,—дигән ачыкламышы, гөнаһ кылган кешенең урынсыз акланы кебек кенә яңгырады. Китек көзге турында сүз куерту әзер камырга чүпрә өстәгән кебек булды. Әйтерсең лә, Ләйләнең өстенә чиләге белән салкын су койдылар, тигез, матур тешләре бер-берсенә бәрелеп, бөтен тәнен бизгәк тоткандай калтырата башлады.

Тагын шул китек көзге—аның бәхетсезлегенең мәңгелек юлдашы. Көзгене ватуга алып килгән вакыйга яман төш шикелле, хәтер күзәнәкләрен уятып, болай да һәрдаим борчып тора. Ләйлә үзен-үзе белештермичә диярлек:

—Һаман китек көзге. Башка сөйләшер нәрсәгез юкмы әллә,—дип яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып кычкырды да, иң ышанычлы дусты Томан янына йөгереп чыгып китте.

Әти-әнисе бер-берсенә карашып тораташтай катып калдылар. Халидә белгәнен сөйләүне кирәк тапмыйча, аш-су бүлмәсенә юнәлде. Шул чорда башыннан узган, яшьлеге белән күпертеп бәяләгән вакыйга, кино кадрлары кебек, Ләйләнең күз алдына килеп басты.

Кем өчендер әһәмиятсез күренгән бу хәл Ләйләнең үзенә һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәткә карашын үзгәртте дә куйды. Бу көннән соң күпме кызыклы, аянычлы, мажаралы хәлләр яшь кызның башыннан узды. Ә тегесе... Киләчәк тормышына күрәзәлек иткәндәй, һаман зиһенен борчып тора. Урта мәктәпне тәмамлауга багышланган чыгарылыш кичәсендә булды бу хурлыклы, бөтен халәтен баштан аякка әйләндереп куйган вакыйга. Барысы да олуг бәйрәмнәренә иң затлы киемнәрен, күбесе әти-әниләре әле генә юнәткән яңаларын киеп, яңа чапкан печән исе килеп торган битләренә иннек-кершәнне кызганмыйча яккан, хушбуйны мул итеп сипкән кызлар, гыйнвар кары кебек ак күлмәкләрен галстуклар белән бизәп куйган арыслангандай егетләр очлы башлы туфлиләре белән бик эре генә ялтыравык паркетта сикерә-чүгәли бииләр. Һавада шатлык, өмет, киләчәккә ышаныч рухы—барысы бергә укмашкан. Бәйрәмне алып баручы хатын-кызлар вальсы игълан итүгә дөнья бизәкләре башкалар минекен чакырырга өлгермәсен дигәндәй, күзләре төшеп, беришесе якын итеп, яратышып йөргәннәре бер почмактарак төркем булып, беришесе утырып, күбесе басып торган егетләр ягына ашыктылар. Дингез дулкыннары кебек бер күтәрелеп, бер төшеп һаваны ерып барган күкрәкләр арасында Ләйлә Габбасова да бар иде. Күптәннән читтән күз атып, ошатып йөргән күрше сыйныфта укучы Артурны биюгә чакырып, үзенә мөнәсәбәтен ачыклау иде нияте. Кара костюм, ак күлмәк кигән, әтәч койрыгы кебек чуар галстук таккан озын буйлы, үзен югары бәяләве, тәкәбберлеге алсу чыраена язылган егетнең каршына килеп басып, җыйнак гәүдәсен алгарак иеп, Ләйлә үзенең теләгән белдерде. Теге җүнсезе, банкир томшыгы үз каршысына килеп баскан гүзәл затны күрүгә сикереп торып, чакыручының кулын алып, биючеләргә кушылды дип уйласагыз, бик нык ялгышасыз. Кызга күз кырые белән карап, сул аягы өстенә атландырып куйган уңын селкетмичә дә, «я вальс не танцую и не люблю» җөмләсен генә нечкә иреннәре арасыннан кысып чыгарды. Һәм вәссәлам. Аның уенча, отыры эффектлы килеп чыкты, Ләйләнең гомер агышына утлы күсәк белән тондыргандай сабак булды егетнең бу кыланышы.

Сүзләрнең әйтелеш рәвешеннән, яңгырашыннан Ләйлә йөрәге, тән күзәнәкләре белән «мин сине яратмыйм» дигән мәгънә чыгарды. Беренче мәхәббәте булырга тиешле егет аны боз базына ташлады, кешелеклеген аяк астына салып таптады. Үзенә сиздермичә генә артыннан күзәтеп, башкалар белән сөйләшеп торганда күзләре талганчы карап, төшләрендә саташып, сөйләшеп, җинелчә генә сөеп яшәгән кешесе, идеалы аны ничек

мыскыл итте. Хурлыгы, гарьлеге ни тора. Биюгә чакыруының җирлеге дә бар иде кебек. Бервакыт яныннан узып барганда Артур аңа елмаеп карагандай тоелган иде. Шуңа нигезләнеп ул миңа битараф түгел бугай, ачыклыйсы, аңлашасы булыр дип Ләйлә беренче адымны ясарга җөрьәт итте. Артурның иреннәрен кәлемсерәгәндәй җәюе мыскыллау, нинди ике аяклы бөҗәк буталып йөри минем тирәмдә диюе булган икән. Ул ахмак шуны да аңламаган.

Сыйныфташларының берәрсе аның мәсхәрәгә юлыгуын күреп калган булса эш харап, җир тишегенә качып та котылып кала алмассың. Ул үзеннән өстәп, «Ләйлә Габбасова Артурны ялынып, ялварып биергә чакырды, тегесе «мин сине яратмыйм, син минем зәвыкта түгел, артык мине борчымавыңны сорыйм», дип күзенә карап мыскыллады диебрәк хәбәр таратып, сөйләп йөриячәк. «Бу серне сиңа гына чишәм, башка берәүгә дә әйтә күрмә» җөмләсе Ләйләнең үзенә килеп җиткәнче, өстәлеп, болганып, беришесен шатландырып телдән-телгә күчеп йөриячәк. Ярый әле урта мәктәпне тәмамлаучыларның иң соңгы кичәсендә булды Ләйләгә мәңгелек сабак биргән бу хәл. Әти-әнисе мактаганга, туган апасы Регина «син гүзәл, бар җирең урынында, бал-майсыз кабып йотарлык», дип авыз суларын корытып сайраганга ышанып, үзен чибәрләр рәтенә кертеп бик нык ялгышкан булып чыкты. Ул бүгенгә чаклы тормыштан аерылган хыялый дөньяда яшәгән икән. Өлгергәнлек аттестаты бирелгән көндә иң төгәл, дөрес бәясен алды.Үзенең ямьсез, шыксыз үрдәк бәбкәсе икәнлеген ниһаять бер кеше аңлатып бирде.

Башка бер кичәдә Артурның бик нәзакәтле итеп вальста әйләнүен күргән Ләйлә берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, хәтта күзәтеп йөргән укытучылары белән дә саубуллашмыйча, залдан җәядән ычкынган ук кебек атылып чыгып китеп, өйләренә ничек, нәрсә белән кайтып җитүен дә хәтерләми. «Я вальс не танцую» җөмләсе төрле мәгънәви эчтәлек, аһәң белән җан канатларын көйдереп, колагын зыңгылдатып торды. Йортта каршысына томырылып килеп чыккан Томанның дусларча койрык болгавына да игътибар итмичә, өйгә килеп керүгә киемнәр элгече янына кадаклап куелган көзге каршында торган артлы урындыкка лып итеп утырып, үз чагылышына кадалды. Көзгедән почык борынлы, кыска буйлы, көнбагыш чәчәге кебек сары чәчле, сытык чырайлы, күзләре тундырылган балыкныкы шикелле тонган бер ят кызчык Ләйләне шул кирәк сиңа дип үртәп тора. Челтәрле көмеш бөҗра белән каймалап алынган, каршысында сәгатьләр буе утырып ыспайланырга, бизәнергә яраткан пыяладан тискәре дулкын килеп торгандай тоелды үзен-үзе куралмаган кызга. Көзге аны юри шулай томсыз итеп мыскыллап күрсәтә түгелме? Үзе-үзен белештермичә диярлек, аягындагы нечкә, озын үкчәле туфлиен алып, бар көчен, бөтен үчен, гарьлеген салып, көзгенең өске өлешенә китереп тә тондырды. Сугуны көтеп кенә торгандай, көзгенең уң як кырые кителеп төште. Ләйлә аңына килеп күтәрелеп караса, аннан инде ямьсезлеге җитмәгән, колаксыз кыз аны үчекләп торгандай тоелды.

Пыяла ватылган тавышны ишеткән әнисе Халидә йөгереп килеп җитте.

—Ләйләм, нәрсә булды?

—Көзгенең бер чите убылып төште. Көзге ватылу бәхетсезлеккә, диләр бит.

—Анысына исең китмәсен. Әтиең аны урнаштырганда ук аз гына чатнаган иде ул,—дип алдашты Халидә, кызның эчке сызлануын күреп.

Әнисе килеп башыннан сыйпагач, Ләйлә елап җибәрде.

—Әни мин шыксыз, бәхетсез кыз.

—Кем әйтте аны, кызым. Син бик ягымлы, мөлаем бала. Минем кызыма «син ямьсез» дип әйтергә берәүнең дә теле әйләнмәс.

—Менә берәүнен теле бик шәп әйләнде шул. Янагыма китереп тондырган булса, җинелрәк кичерер идем. Ә ул ничек мыскыл итте.

—Кем ул сине шулай рәнҗетте?

—Барыбер түгелмени? Әти-әнигә үз баласыннан матур бала юк. Керпе дә үз баласын йомшагым дип иркәли дигәненне оныттынмы әллә? Ә мина ошатып йөргән, беренче мәхәббәтем булырга тиешле кешем шуны өздереп, бәбәгемә карап әйтте.

—Кызларга «син ямьсез» дип әйтергә теле әйләнгән егет кеше түгел инде ул.

Әнисе кызын рәнҗеткән адәмне хурлык тактасына кадаклап куярлык усал сүз таба алмагач, кулын гына селкеде. Сүзне башкага күчерергә теләп:

—Бу көзге коттеджга күчкәч алган беренче җиһазыбыз иде. Аны әтиен һәр иртән шуннан синен төз, матур аякларынны күрәсем килә, дип алды. Тарихи көзгебез әрәм булган! Әнисенен ихласи сүзләре Ләйләгә житә калды.

—Сина көзге жәл. Ә минем—фажига. Беренче мәхәббәтем үз урыныма төртеп күрсәтте. Өлгергәнлек аттестатын алгач, эшкә керермен дә тагын да зуррак көзге сатып алып бирермен. Әти белән икәүләп матур аякларынны карап утырырсыз.

—Син нәрсә сөйлисен, Ләйлә. Бу хәтле явызлык каян килгән сина. Кемгә охшагансын икән син!

—Берегезгә дә охшамаганмын. Изге Мәрьям баласы Гайса кебек жилдән яралмаганмын. Төз, озын аякларынны миннән кызгангансын. Сыйракларым, чәчләрем, тән, бит төсләрем тач әтинеке инде. Күзләрем генә—әбинеке.

—Телен нәстә туглаганны анлыйсынмы син, кызым. Син—мәхәббәт жимешебез. Хәзер синен кебек жыйнак гәүдәле, аксыл чәчле, мөлаем кызлар модада. Ялтыравык чибәрләрне бәхет әйләнеп уза. Аларны каен жиләге кебек өзеп кенә кабалар, кәндигә дә жыеп тормыйлар. Үзенә тиненне табуында һич шигем юк. Бу синен әле мәхәббәт тегел, тәти уенчыкка кызыгуын гына. Сине рәнжеткән Артур көнләшерлек итеп яшәргә тиешсен. Бәлки, ул егет чыннан да вальсны бии белми, яратмый торгандыр. Хәзерге яшьләрнен күбесе зыр-зыр әйләнергә иренә.

—Минем анын вальс биегәнен күргәнем бар.

—Бәлки ботинкасы аягын кыскандыр, галстугы жайсыз бәйләнгәндер. Тормышта төрлесе була. Син анын сүзләренә әллә нинди мәгънәләр салып, үзенне бимазалап йөрисен,—дип ана кызын тынычландырганчы сөйләнде. Ана белән кыз беренче тапкыр олыларча сөйләшүдән арып, диванга утырып, икесе дә елап жибәрделәр. Кыз әнисенен тезенә башын куеп, Халидә Ләйләнен чәчләрен бармаклары белән сыйпый-сыйпый бусы да өлгереп житте, олы бала—олы проблема дип уйланып утырды.

Әни кеше тизрәк анына килеп, пешеп яткан ашын карап килде.

—Кызым, мин—ямьсез, китек көзге бәхетсезлек билгесе дип кабатлап йөрсән, нурлы йөзенә дә кара болыт төсе инәр, бәхет кошын да кулыннан очып чыгар. Матур матур күренмәс, сөйгән матур күренер, дип жырлый иделәр без яшь чакта. Мин, кызым, башка нәрсәдән куркам.

—Ватык көзгедән дә куркыныч нәрсә бармени дөньяда,—диде Ләйлә, үзендә шаяртуга көч табып.

—Әтиеннен начар гадәте сина сенә күрмәсен.

—Акчасын кысып калдырамы?

—Юк ла,—дип кулын селтәде әнисе.

—Синен өстән йөриме, сөяркәсе бармы?

—Анысына да түзеп булыр иде. Һич югында рәхәтләнеп себеркесенен чәченнән өстерәп йөреп кайтыр иден.

—Тилмертмә! Әйт! Яшь булсам да, ир-атның ике иң зур кимчелеген таптым бугай,—диде кыз, йөзенә тантаналы, җиңүчел кыяфәт чыгарып. Янәдән кызының тигез шома маңгаена куна башлаган җыерчыкларның тирәнәеп китүенә игътибар итте ана кеше.

—Көнчелек,—диде Халидә ханым, тавышын күтәрмичә генә.—Сорауларыңны бирмичә, күзләреңне тондырмыйча гына тыңла. Алдан ук кисәтәм, сүз син уйлаган женси көнчелек турында бармый. Буыннан-буынга күчә килгән бу торыш ике яклы үткен пычак кебек. Бер ягы бик файдалы, бәрәкәтле, үтемле. Анысы тормышны алып барырга ярдәм итә,—чак кына син ваткан дип ычкындырмады, кызының әле һаман дымы кипмәгән күзләрен кызганып, үзен тыеп кала алды—теге... көзгене кунакка барган җиребездән Рәис абыйларында күреп, Казанның кермәгән кибетен, айкамаган базарын калдырмыйча, нәкъ алардагы кебекнең игезәген эзләп тапты. Күрше прокурорның йортында су бассейны барын белгәч, үзебездә ясатты. Рәсми дәрәҗәгә омтылганда, бизнеста мин башкалардан калышмаска тиеш, мин талантлы дип үзен ышандырып, шактый уңышка иреште. Иншалла, өстебез бөтен, тамагыбыз тук.

—Бусы пычакның файдалы ягы дисәк, ә икенче ягы?..

—Анысы белән кулны кисәргә, кешегә җәрәхәт ясарга мөмкин. Бусы аңлатуы да кыен көнчелек. Аның төбендә якыннарын артык ярату ята.

—Бу житешсезлек буламы инде, әнием?

— Габбасовлар нәселендә баланы изгеләштерү еракта килә,—дип сүзен дәвам итте әнисе. Бал татлы, бала балдан да татлы дигән мәкаль әтиеннең төп бер сыйфатын чагылдыра да куя. Үз дәвамын яратмаган ата-ана сирәк була. Габбасовлар исә балаларын аерым бер үҗәтлек, комсызлык, вакыты белән аның шәхси тормышына зыян китерерлек дәрәҗәдә яраталар. Апаңны да шул сыйфаты аркасында иреннән аертты. Исеңдә тот, әгәр ирең үз фикерле, укыган кеше булып, аның сүзеннән чыкса, үзенчә яшәргә омтылса, әтиең аны кабул итмәячәк. Ирәңнән сине көнләшәчәк. Кызларын үзеннән бер адым да читкә җибәрмичә, үз янында гына тотар иде, мескенкәем. Габбасовлар бала мәсьәләсендә чирле нәсел, әтиеңдә бу чир аеруча көчле.

— Бу бит әти безне ихластан ярата дигән сүз түгелме?

— Күкрәк астында йөртеп үстергән балаларым мина да бик якын. Сезгә куркыныч янаса теләсә кемнең бугазын чәйнәп өзә алам. Тик ярату балага зарар китерерлек эгоизмга күчмәсен иде, кызым. Барысы да ул теләгәнчә яшәп, аның кубызына гына биеп торсыннар. Син, кызым, безнең сүзне тыңла, тик үзенчә яшә. Минем кебек ир колы булып, аның көен көйләп яшәү, бәлки, дөрес үк түгелдер.

Әнисенең соңгы җөмләсе бер вакыйганы исенә төшереп, ирексездән Ләйләнең иреннәрен җәеп җибәрде. Халидә ханым үзе сөйләгәнчә үк, җебегән кеше түгел. Дөрес, ул гаилә, тормыш төбенә җигелеп яшәү өчен яратылган. Кеше алдында ул бервакытта да ирен бүлдермәс, каршы әйтмәс. «Сахипҗан син хаклы, дөрес сөйлисең», дип тәкрарлаудан туймыйча, хуҗасының ирлек горурлыгына хилафлык китермәс. Үзләре генә калганда ул үзен башкачарак тота, әйтәсен өздереп әйтә, теләген уздыра белә. Хәтта, Ләйлә фикеренчә, арттырып җибәрүгә дә күп сорамый. Кинәеп елмаеп алуына да бер вакыйганы исенә төшерү сәбәпче булды. Әтисе озак вакытка Мәскәүгә эш белән барырга, шунда калып, ял йортында иркәләнеп алырга җыенгач, шул хәбәрне колагы аша уздыруга, Халидә ханым кигәвен тешләгәндәй, урыныннан сикереп тора да, авыр эштән курыкмый торган йодрыгын Сахипҗанының борыны төбенә китереп куеп, куркыныч хәрәкәтләр ясый башлый. Әйтерсең лә, тәрәзәдән яшен ташы

килеп кереп, Миндрахман абзый улының бите янында ялт-йолт килеп, шомлы бию башкара.

—Менә сиңа, анда тәртипле генә йөрмәсәң. Ял йортына сөйрәлчегенне ияртеп китәсендер әле. Берәр нәрсә сизсәм, кара аны малай. Йодрыкны күрсәтеп кенә калмам.

Зур бер коллективны эһ тә итмичә, буйсындырып тоткан Сахип әфәнде югалып кала. Аңына килеп:

—Син нәрсә Халидәкәем, беркемгә алыштырмаслык мәңгелек ярым син минем,—дип мыгырданып кына котыла.

Бу вакыйганың шаһите Ләйлә теге вакытта сыер дуласа аттан уздыра дип кенә уйласа, хәзер утсыз төтен чыкмый, әнинең чыгырыннан чыгуының сәбәбе булгандыр дигән нәтиҗәгә килә.

## V

Беркөнне Морад Ләйләгә телефоннан, кызым, дип эндәшә. Ошбу табышы үзенә дә ошады бугай, жае чыккан саен шул сүзне, төрле мәгънә төсмерләре салып, әле назлы, әле корырак, әле теләк уятырдай иркәләп, кабатлавын белә. Күрәсең, ир-ат халкының ата булыр вакыты житкәч, фәрештәсе жирдәге вазифасын исенә төшереп, шул сүзне әйтү ихтыяжын уята торгандыр.

Тик Морад уртак гаилә кору турындагы тәкъдимен генә сузды да сузды. Үзе кандидатлыгын да яклады, Ләйлә кызыл дипломын кесәсенә салды. Кызым, кызымка дип бәхет кояшын Ләйләнең күнел түрендә ялтыратып ала да, янәдән уртак чәй эчү, иркәләү белән чикләнеп, сөйгәнен монсусагышка салып, бер бүлмәле фатирына кайтып китә.

Ниһаять, Морад бөтен шартын китереп, уртак гаилә кору турында сүз каткач, Ләйлә булачак ире белән әти-әнисен таныштырырга булды. Дөрес, аның тәкъдиме барыбер романнардагы яисә совет чоры киноларындагы шикелле кытәренке, могжизаи эффектлы булып чыкмады. Чираттагы очрашудан соң, кара капка янында үбешеп туйгач, Морад гадәти тавыш белән:

— Кызым, безгә бергә яшәргә вакыт түгелме икән? Кызышып яшәү генә сине туйдырмадымы? Кечкенә фатирымда синең кош мамыгы кебек очып, балерина кебек биеп йөрүеңне теләр идем.

Соңгы жөмләсе пыскып янган учакка коры утын ташлагандай тәэсир ясады кызга.

—Бу мине кияүгә чыгарга чакыру буламы инде? Баш тартыр дип уйласаң, бик нык ялгышасың абзыкай.

Икенче көнне Ләйлә, тантаналы рәвештә диярлек, Морадны әти-әнисе кырына китереп бастырды.

Булачак бабай белән кияү күзләренә карашып, ирләрчә каты итеп кулларын кысыштылар. Сахип киявенең үзеннән озынрак, кулының көчлерәк булуын хәтеренә алды. Морадка барыбер иде, ул бит Ләйләгә өйләнә. Башына ак яулык бәйләгән, кара күзле, түгәрәк иякле Халидә ханым белән баш селкеп кенә күрештеләр.

—Минем кызым белән гаилә корып жибәрергә уйлагансыз икән. Бик яхшы. Иртәме-соңмы һәркемнең үз гаилә учагы кабынырга тиеш. Сезнең хакта сөйләп, мактап Ләйләбез колак итебезне ашап бетерде инде. Төкле аягыгыз белән диләрме әле нәселгә яңа кеше килеп кушылганда,—дип, сүзне Сахип башлап жибәрде. Морад артык иркенәеп, шатлык хисләрен бәйдән ычкындырып тормыйча гына:

—Чынлап та, сез каршы килмәсәгез, без Ләйлә белән уртак фикергә килеп, гаилә корып жибәрергә булдык,—дип жаваплады.

—Кызыбызны бик яратабыз, үзебезгә дә артык түгел. Син дә безнең кебек аны ихтирам итеп, иркәләп яшәт инде. Хәерле сәгатьтә, балалар, — дип өстәде һәрвакытта иң кирәкле җирдә, тиешле сүзе белән чөй шикелле килеп кысыла белгән Халидә ханым. Иренең күзен алартып куюына бик исе китмәде мишәр кавеме баласының. Ул—бәхетле иде. Ахыры хәерле булсын. Сахипның «туй расходларын үзем күтәрермен, кирәкле транспорт чаралары да миннән булыр», кебек сүзләренә дә Морад эреп төшмәде.

—Алдан ук килешеп куйыйк. Никах укытырга үземнең таныш мулланы алып киләм. Согуд Гарәбстанында укып кайтты. Туй чыгымнарын күтәрерлек хәлем бар, аспирантурага кергәнче, КамАЗ администрациясендә эшләгән идем. Бөтен чыгымнарны кыл урталайга бүләрбез... Сәяхәт кылырлык та рәтем бар. Ул хакта күптән сөйләшелгән.

Булачак хәләл җефете тарафларына мөлаем карашын индереп өстәде:

—Кайсы илне бәхетле ясыйсы килүе турында Ләйләм үзе әйтер.

Мондый мөстәкыйль, хәтта бөердән чыгарып сөйләшүнең җаваплы урын билгән Сахип Миндрахмановичка ошап бетмәгәне аңлашыла булыр. Ялагайланып, шомартып сөйли белмәвенең үзенә киләчәктә шактый кыйммәткә төшәчәген гашыйк-мәҗнүн күз алдына да китерә алмый иде әле.

Никах һәм язылышу көннәрен көтү Ләйләгә ифрат озын-озак тоелды. Үткәндә калырга тиешле танышлары да тынгы бирмәделәр. Баскетболистын әйтми дә инде, беркөнне аңардан йөз чөергән Артур шалтыратты. Косасыны китерерлек дәрәҗәдә төчеләнеп, теге вакыттагы хатасы өчен үкенүе турында озак итеп сөйләргә исәбе бар иде, Ләйлә аны бик кискен, коры итеп бүлдерде. Артур сине рәнҗеткән өчен мең тапкыр үкенәчәк дип аны тынычландырган әнисе хаклы булып чыкты.

Ләйләнең «беренче мәхәббәте» белән аңлашуны югары нотада өзүе булды, кесә телефоны янәдән телгә килде.

—Кызымка, нихәл, исәнлек-саулыкмы? Кем белән шулай тәмләп, озаклап сөйләштең.

Ничек «тәмләп» сөйләшкәнне Морады тынлап торса, бәлки, кызына шалтыратмас та иде. Нихәл итәсең, адәм баласы үзеннән тормаган сәбәпләр аркасында алдашырга, кәлтә еланы кебек боргаланырга мәҗбүр була. Кыен хәлләр туганда хатын-кызның хыялы акылына ярдәмгә килеп, хуҗабикәләрен коткарып куя.

—Туй күлмәген тегәргә биргән ательедан шалтыратканнар иде.

—Соң, күлмәк кайчан әзер була ди. Унмаган тегүче аркасында туйны кичектерергә туры килмәсен тагы.

—Бер-ике тапкыр булса да, киеп, үлчәп карау мәҗбүри диделәр.

—Сине әбәдкә, төшке ашка чакырмакчы идем. Ризамы? Әһ, дигәнче килеп җитәм.

Ләйләнең әтисе, Алёша, Артур белән сөйләшүләрдән соң, үзе генә каласы, фикерләрен тәртипкә китерү теләге янәдән алдашырга мәҗбүр итте. Бу уе каяндыр астан, аң төпкеленнән күтәрелеп, хуҗбикәләренә тел ачкычы бирде.

—Морад, хәзер үк чыгып китә алмыйм шул.

—Нинди ашыгыч эш, кайгы-хәсрәт бәйләп тота икән минем кызымның газиз башкаен мондый җылы көнне өендә?—дип телен чарлауны дәвам итте сөеклесенең нинди хәсрәтләр белән хафаланганын белмәгән булачак кияү.

—Аш пешерә башлаган идем. Суыткычтан туңган ит алып, әле генә кәстрүлгә салдым.

—Минем эчемдә ач бүреләр улаганны белеп аш пешерә башлагансың икән. Хәзер бер көпчәгем монда калса, икенчесе сезнең өй янына китереп җиткерер.

Ләйлә ялганы тотылыр дип чын-чынлап пошаманга төште.

—Ике сәгатьтән генә өлгерер минем аш. Лучше мин аны сүндерим дә, берәр жирдә тамак ялгап алырбыз. Шул хәтле сагындым үзеңне,—дип сөеклесенең салпы ягына салам кыстыруны кирәк тапты.

—Булды, кызым, сөйләштек, юлга чыгам.

Кыз фамилиясендә калу, туйдан соң кайда яшәү турында житди сөйләшүләрне Ләйлә кичектерә килде. Менә никах көне дә килеп житте. Яшьләрне кавыштыру, гаилә кору мәжлесенә Сахип Миндрахман улы кияүнең сүзен житдигә алмыйча, иң абруйлы мулланы үзе алып кайтты. Шул көнне Морад кунарга коттеджда калды. Халидә ханым ине-буе бер киң тахтага урын җәеп, эчәсегез килсә дип, лимон суы кертеп кадерлесе ягына кара күзләреннән нур көлтәсе бөркеп чыгып киткәч, үтеп киткән көн, мулланың тавышы, кунакларның үзләрен тотышы турында бик озаклап сөйләшеп утырдылар. Морад Ләйләнең киеренке халәтен аңлап, мәзәкләр сөйләп, хатынының кәефен күтәрергә тырышты. Гадәттә Мораднын иркәләүләреннән дөньясын онытып туарылып китә торган Ләйләгә әллә нәрсә булды. Никахлы ире биленнән кочаклап, муенына иреннәрен тидерүгә тәне, бөтен күзәнәкләре бернәрсә тоймас дәрәжәдә катып калды. Әйтерсең лә, ул жанлы кеше түгел, ә юеш мамык тутырылган капчык. Хатынының «әйдә сонрак, бүген сөйләшеп кенә утырыйк» кебек кипкән иреннәре арасыннан кысып чыгарган сүзләрен колагы янынннан уздырып, Морад аны чишендерүен белде. Киеренке гәүдәне ятакка күтәреп салгач та, аннан соң да, еш-еш сулаган ир, соңыннан:

—Һм... дип кенә куйды.

Нинди генә мәгънә юк иде ике хәрефтән торган бу ымлыкта. Гажәпләнү, ышанмау, рәнжү, үкенү, сыктану, үпкәләү, гафу итүгә якын аңлау һәм тагын әллә нинди хисләр бар иде ошбу ыңгырашып куюда. Бик озак яттылар яшьләр сөйләшмичә үз табышмакларын чишеп. Морад икенче якка әйләнеп яткач, Ләйлә бик кыюсыз гына аның ачык жилкәсенә кагылган иде.

—Мин бик арыдым бүген. Йоклап алыйм әле,—дигән жавап алды.

Әлбәттә, икесе дә таң атканчы, күрше әтәче яңа көн туу белән котлаганчы, күз дә йоммадылар. Халидә ханым ишек шакып иртәнге чәйгә чакырырга кергәндә икесе дә өсләренә киенеп, аяк өстендә басып торалар иде. Туйны, бигрәк тә зөфаф кичен көтеп аласын, ә ул кояшлы көнне килеп яуган яңгыр кебек, уза да китә.

Шул көннән Һм Ләйләнең иң яратмаган ымлыгы, сүзе булып калды. Сонрак, чәче, күзләре, гәүдәсе белән әтисенә охшаган кызы солы боткасын яратмыйча, Һм дип куйгач, бер гаепсез баланы тиргәп, хәтта чәбәкләп алды.

Фамилия турында Ләйлә ЗАГС ишеген атлап керергә ике көн калгач сүз катты.

—Морадкаем, минем сиңа бик зур үтенечем бар.

—Рәхим ит, кызым!

—Миңа әти-әни фамилиясендә калырга рөхсәт итмәссеңме икән?

— Бу сиңа нәрсә бирә диик инде? Минем Сәлимуллиным ошамаган өченме?

Ләйлә үзенең дәлилләре турында күп уйланып, аклану, аңлату сүзләрен кат-кат кабатлап йөрсә дә, жавабы артык гади килеп чыкты.

—Алар мине тәрбияләүгә, аякка бастыруга күп көч куйганнар, фамилияләрендә калу минем рәхмәтем, өлешчә бурычымны үтәү булыр иде.

Мораднын бу аңлатуга карашы әзер иде.

—Ата-ананың жир йөзендәге төп вазифасы бала үстерү, нәсел агачын саклау түгелме соң? Кешелек жәмгыяте фәлән еллар дәвамында шул

язылмаган канун буенча яши. Гел элгәргеләр фамилиясенә, исеменә ябышып ятсак, барыбыз да Адамов, Әдәми, Адамян кебек кенә аталыр идек.

Ләйлә Морадны мантыйк белән җинә алмавын аңлагач, әти-әни улыбыз булмагач, син хет фамилиябезне сакла дип үтенделәр дияргә мәҗбүр булды.

—Димәк, бу уй Сахип Миндрахманович башында туган.

Ләйлә сүзсез генә башын селкеде.

—Үз фамилиям бик атаклы да, яңгырашлы да булмагач, мин риза. Тик бер шартым бар. Дусларым, таныш-белешләрем, хәтта туганнарым да бу гайре табигый хәл турында белергә тиеш түгелләр. Реклама булмасын.— Ләйлә сөенеченнән баскан урынында сикеренеп, кулларын өскә күтәреп чәбәкләде.

—Мең рәхмәт, Морад. Мине аңлавыңа шикләнмәгән идем. Син минем чын хуҗам да, зыялы дустым да.

Мәгәр ЗАГСта көтелмәгән хәл килеп чыкты. Морад белән Ләйләнең чираты килеп җитүгә кайгыртучан һәм юмарт Сахип Миндрахман улының чакыруы буенча килгән татар һәм рус телләрендә тапшырулар алып баручы ике телеканал пәйда булды. Алар кул кую, балдаклар белән алышу, шампан шәрабы ачу өлешләрен төшереп алу белән генә чикләнмичә, яшьләрне сораулары белән интектерделәр.

«Сез кайда, ничек таныштыгыз?»—дигән сөальгә җавапны Морад бирергә тиеш иде.

—Безнең очрашуны күкләр оештырды дип уйлыйм. Чөнки без һич уйламаган төштә, аэропортның көтү залында таныштык. Бер карауда гашыйк булыштык һәм гаилә корып, бергә яшәргә уйладык.

—Ләйлә ханым, сез кыз фамилиягездә, Габбасова булып калырга карар иткәнсез. Ни өчен ирегез белән уртак фамилиядә йөрергә булмадыгыз?

Хәбәрченең соравында төрттерү дә, ирония дә барын Морад аңласа да, Ләйлә югалып калды һәм турыдан бәрде.

— Мин әтиемә борынгы фамилиябездә калырга вәгъдә бирдем. Сүземдә тордым.

Сахип әфәнденең соравы буенча, бу тапшыруны туктаусыз кабатлап тордылар. Морад бу хурлыклы клипны әүвәл кара янып тынлады, соңрак телевизорны сүндереп куя торган булды. Күңеленнән шул кирәк сиңа мужиклык сыйфатыңны җиргә салып таптаткач дип үзен тиргәсә дә, Ләйләне битәрләп, ләм-мим сүз әйтмәде. Чөнки ризалыкны беркем авызыннан көчләп тартып алмады.

Яшьләрнең тормышы үз агымын тапты. Бер-ике атна Морадның кечтеки бүлмәсендә яшәп алгач, Сахип белән Халидәнең иң бәхетле, баллы чоры узган өч бүлмәле хрущевкаларына күчеп, асыл ташлы пар алкалар, тамаклары карлыкканчы гөләүләреннән үзләре канәгать күгәрченнәр кебек яшәп киттеләр. Ике башны бер мендәргә салып йоклау бер-береңнең уңай хисләре белән уртаклаштыра икән дип, бер мендәрне идәнгә ташлап йоклауга өстенлек бирделәр. Көтеп алган, әби-бабайга кадерле уенчык булып киткән кызлары туу аларны туганлык җепләре белән бәйләп куйды.

Яңа туган сабый куаныч-шатлык белән бергә өстәмә мәшәкатьләр дә алып килә шул. Иң әүвәл, халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын искә алып балага исем кушарга кирәк. Ул мөмкин кадәр тизрәк, сабый туганнан соң җиде көн эчендә башкарылырга тиеш. Бу йола балага яман күзләр төшмәсен, елак булмасын өчен эшләнә дип аңлатты Халидә ханым. Мәгәр исем мәсьәләсендә бәхәсләр шактый булды. Сахип әфәнденең дә, Ләйләнең дә тәкъдимнәре яңгырады. Татар исемнәренә багышланган китапларны да

кат-кат сөреп чыктылар. Бу сөйләшүләргә, холкын күрсәтеп, Морад нокта куйды. Нарасыен кулына алып:

—Йола буенча исемне ирләр, күп очракта ата кеше куя. Мин күптәннән күнелемдә йөрткән, төрекләрдә кин таралган Айзизә дигән исемне кушарга булдым кызыма,—дип Морад мулла чакырырга чыгып китте.

Халидә ханымга исем ошады, кыз белән атага бер-берсенә карашып куюдан башка чара калмады. Габбасовлар нәселендә ерактан килгән балага табыну, изгеләштерү Ләйләне кайгыртучан ана буларак ачты. Кызларын татар теленә өйрәтә торгач, үзләре дә туган лөгатьләренең нечкә, сыгылмалы серләренә, күчерелмә мәгънәләренә тирәнрәк үтеп керделәр. Айзизәнең бабасы да, ана телен яхшы белергә кирәк, чит, рус телләренә яшәү ихтыяҗы болай да өйрәттерәчәк дип такылдап торды.

Морадның бабасы белән мөнәсәбәте әүвәл таба төбе кебек шома, тигез баргандай тоелса да, акрынлап майламаган арбадай шыгырдый башлады. Соңрак кына Морад Сахип Миндрахман улының аны «урынына утырту», ул теләгәнчә яшәргә өйрәтү теләге белән янып-көеп яшәгәнен тойды.

Сахип әфәндегә Халидәнең бертуган сеңлесе Әсма ире Габделбәр кебек «баш өсте, ничек әйтәсез» дип сүзен тыңлап, янында бөтерелеп йөри торган кияү кирәк иде дә, нишлисең. Дөньяда иң яраткан җан иясе кызының теләгенә каршы бара алмады. Ул-бу килеп чыкса, Ләйләсе бәхетсезлегендә аны гаепләр. Балалар алар өчен генә яшәгәнне, тырышканны бәяләп җиткермиләр шул.

Бабасының күзендә вакыт-вакыт кабынып алган эчке явызлыкның сере Морад өчен каты тышлы чикләвек, тирән сер булып кала бирде. Морад аның белән сүзгә кермәде, кимсетмәде, кинәшләре белән бимазаламады. Әллә кандидатлык диссертациясен яклап, ярты ставкага укытырга урнашуы җенен котырттымы? Сәяхәтләр оештыру ширкәтенең башкаручы җитәкчесе итеп кызын билгеләүне, хатынының урынбасары булып калуын да дәгъвасыз кабул итте Морад. Француз теле курсларын үткәч, сине баш итеп куярмын дигән вәгъдәсен дә елак баланы тәти уенчык белән алдарга маташу дип кенә фаразлады. Эштә хатыны хуҗа булса, өйдә ул командир кебек кыланыр. Әти-әни җилкәсенә салынмыйча, үз көнен үзе күрүгә, кеше исәбенә яшәүгә өйрәнмәгән Сәлимуллин чын күнелдән, кальбен биреп эшләде, укыткан җиреннән, таныш-белеш даирәсеннән шактый кешене үгетләп, аңлатып, ширкәтнең үсүенә җитди өлеш кертте.

Эш хакын карточкага күчереп бару сәбәпле, Морад үзенең кем булып эшләве, нинди вазифалар үтәргә тиешлеге белән кызыксынмады, белмәде, хатынын машинасына утыртып алып килә, якты көн дәвамында сәяхәтчеләрнең көен җайлап, сайраша-сайраша бергә өйләренә кайталар.

Көннәрнең берсендә Айзизәләре чирләп Ләйлә өйдә калырга мәҗбүр булды. Морад хатыны белән бер бүлмәдә утыра иде. Хуҗасының эштә юклыгын белмәгән озын буйлы, бөдрәләтелгән аксыл чәчле, кәгазьләрен күтәреп бүлмәгә атылып кергән бухгалтер кыз күзләре белән Ләйләне эзли башлады.

—Банк кәгазьләренә кул куярга иде.

— Китер, үзем кул тамгамны салыйм,—дип Морад кәгазьләрне алырга кулын сузды.

Хисапчы кыз кадерле уенчыгын яшергән бала кебек, документларын читкәрәк алды да, беркатлылыгы белән турыдан ярып салды.

—Сезнең имза ярамый. Банк уздырмаячак.

Берни аңламаган Морад кулына каләмен ала-ала:

— Хуҗа булмаганда, гадәттә, аның урынына урынбасары куя. Банкта да минем фамилия булырга тиеш.

—Сез бит приказ буенча урынбасар түгел, ә шофер-экспедитор гына,—

дип Морад нәрсәнедер аңлап, авызын ачканчы, тәмле хушбуй исләрен калдырып, тиз-тиз атлап чыгып та китте.

Нишләп инде ул юк вакытын бар итеп, хуҗабикәсенең йөртүчесе белән озаклап ләчтит сатып утырсын ди, тузга язмаганны.

Морад башын тотып, селкенмичә шактый уйланып утырды. Ул—фәннәр кандидаты Ләйлә Габбасова иптәшнең шәхси шоферы гына икән. Шуны да белмичә йөргән. Бу гамәле Сахип әфәнденең яшьләр арасына каккан беренче чөе, җинел кулдан бүлмәгә кертеп җибәргән кара мәчесе иде. Абзыйның бу гамәле Ләйлә белән килешенгән булса, бигрәк тә аяныч. Яраткан хатыны куркыпмы, ирен кызганыпмы, әллә әтисенең басымы аркасындамы аны мыскыл итүгә юл куйган булып чыга түгелме? Гомер юлыбызда төрле хәлләр, авырлыклар очрар, хәтәр мизгелләрдә моннан соң аңа таянып булырмы?

Морад очраклы ачылган сер, дөресе, үзен кимсетү, җир суалчаны дәрәҗәсенә төшерүләре турында бабасына да, Ләйләгә дә сүз катмады, тик үз эченә генә бикләнде. Ләйлә Морадының аны мөкиббән китергән мәзәкләрне сөйләми башлавына, сәяхәтчеләр белән аралашуны туктатуына, күз төпләрендә кара сызыкларның барлыкка килүенә игътибар итсә дә, берни аңламады, исәнлеге турында сорашудан узмады.

Бу хәл егетне бабасының, хәтта сөеклесенең мәрхәмәтенә ышанып ятмыйча, киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итте. Беренче сентябрьдән тулы ставкага укытырга кучү иң кулае булыр дип күнеленә беркетеп куйды. Ришвәт бирсәләр алыр, бирмәсәләр өлкән укытучының хезмәт хакы да ипи-тозга житеп торыр. Ришвәт бит юрист, экономист, финансист кебек уч төбендә йөртелгән белгечләргә генә тәти, синең фәлсәфәң кемгә кирәк, буш сафсатага акча түгеп торырга ахмаклар нема.

Ходай Тәгалә яраткан колына чыгарып куяр юлына дип юкка гына әйтмиләр икән. Киләчәк язмышы турында кара янып, пеләш башын кашып утырганда, аңа талиплык чоры дусты, чүл гарәбе шикелле кара Рөстәм шалтыратты.

—Морад, сәлам. Хәлләрең ничек?

—Ярыйсы. Аллага шөкер, кыз үстерәбез,—диде, тавышына мөмкин кадәр шатлыклырак төсмер индерергә тырышып.

—Тиз генә күрешеп аласы бар. Минем конторага ярты сәгатьтән явиться бул әле. Житди эш бар.

Бу күрешү Морадның бөтен киләчәген унай якка борды да куйды. Нәриман урамында урнашкан эш урынында, студентларның ижат жимеше—«бөдрә чәч» кушаматлы Рөстәм аны колачын жәеп, авызын колакларына кадәр озатып каршы алды.

—Мин дә, малай, өйләндем бит.

—Тузга язмаганны сөйләмә инде. Беренче хатынның хыянәтен фаш иткәч, башка мәңге өйләнмәячәкмен дип ант иткән иден.

Уку дәверендә бер бүлмәдә көн итеп, соңгы телем ипиләрен бүлешеп яшәгән дуслар арасында сер дә, әйтәсе сүзне чүпрәккә төреп бирү дә юк иде.

—Кемгә икәнне әйтсәм, урындык барын онытып, шап итеп артың белән идәнгә барып төшәчәксең!

—Йә, сузма. Бер яшь, чибәр бай кызын жәтмәгә эләктергәнсеңдер әле.—Бөдрә чәч дустын чеметеп алды.

—Син ди мин.

—Һм... Бер ноль синең файдага. Күбегез шулай уйлый шул, кызганычка каршы.

—Әмрикан кызына өйләндем бит, малай.

Морад аны һаман житди кабул итмичә, шаярта, сызгыра, теленә салына, һич югында хыялы белән уртаклаша дип, Хуҗа Насретдин ишәге кебек, башын чайкап утыра бирде.

—Ярый, сузмыйм инде. Йә йөрәгең тотар. Рус телен гаиләдә яшәп өйрәнергә Америкадан килгән ханым минем әбидә урнашты. Фатиры зур, кече кызы белән икәү генә яшиләр. Әбинең дә, апаның да русчалары ындыр артына алып чыгарлык кына. Чит ил кунагын өйрәтмәгә абзанны чакырдылар. Бер ай дәвамында мин аны рус, ул мине инглиз теленә өйрәнә-өйрәтә торгач, бер-беребезгә үлепләр гашыйк булуыбызны сизми дә калганбыз. Бик бай генерал кызы булып чыкты, бахыр. Бездә яшәргә риза булмады, рус, татар телләренә өйрәтүне АКШта дәвам итәрсен дип, рәсми якларны кайгыртуны үз өстенә алды. Морад ахири, мин боларны сине көнләштереп, кәефенне кыру өчен сөйләп утырмыйм. Монысы преамбула гына. Минем шактый үрчемле бизнесем бары сиңа мәгълүм. Өйләнеп, башка өлкәгә кереп китмәсәң, бергә эшләргә дә чакырмакчы идем. Банкта тупланган акчаларны гына алам да, ширкәтемне тулысы белән сиңа калдырып китәм. Үземне куып кайтарганчы. Эш анда хәтле барып житмәс дип уйлыйм, син дә Рөстәм шунда төпләнеп калсын дип дога кылып тор. Кухня җиһазлары, буяулар сату белән эш итә торган кибетләремне тулысы белән сиңа яздырып китәм. Хатыным шундый шарт куйды. Монда үз исемеңдә бизнесың калса, гел Рәсәй ягына карап яшәячәксең, ди. Минем бер генә теләгем булыр: кайткан-киткән вакытта мине каршы алып, чыгымнарымны түләп, озатып калу.

Морад күктән ингән бәхетне ничек бәяләргә белмичә аптырап, таң калып, карышкан булып маташкан арада ширкәт хуҗасы булуына таныклыкны кулына китереп тоттырдылар. Рөстәм берничә көннән дәрья аръягына китеп тә барды.

Югары уку йорты укытучысы дәрәҗәсенә дә ризалашкан Морад, аз-маз гына эшмәкәрлек күрсәтсәң, шактый табыш китерә алырлык ширкәт белән җитәкчелек итә башлады.

Яңа эшкә чыкканчы, Ләйләгә бу хакта әйтмичә торды. Кичен, чәй эчеп утырганда, артык гадәти әйбер турында хәбәр иткәндәй, тонык тавыш белән генә:

—Ләйлә, мин башка эшкә күчәргә булдым. Сине эшкә йөртергә, өйгә алып кайтырга башка шофер эзләргә туры килер.

Ханым ашавыннан туктап, каушаудан кашыгын идәнгә төшереп җибәрде.

—Морад, мин берни аңламыйм. Укытырга күчәргә булдыңмы?

—Юк, сиңа таныш дустым Рөстәм Айтуганов ширкәтен миңа калдырып, үзе Америкага яшәргә күчә, —диде дә өстәл яныннан торып китте.

Соңрак, һәрнәрсәдән хәбәрдар Габделбәрнең сөйләвенә ышансаң, Ләйлә әтисе белән жылый-жылый бик каты аңлашкан, тавыш күтәргән.

Морад исә, Тукайның алны-артны карамыйча утын кискән Былтыры кебек, җиң сызганып, яңа вазифасын үтәргә кереште. Әлбәттә, ул Рөстәмнең киләкмиенә карап кына аны табыштан мәхрүм итәргә җыенмады. «Нобель премиясе урынына», туган көнгә дигән булып Рөстәмгә әледән-әле акча күчереп торды, «Әмрикә кияве» үзен аякка бастырган бабасын күмәргә кайтканда, бер артына бер алдына төшеп, кунак итте. Туганыннан, бабасыннан тәтемәгән итле калҗа калдырып киткән дустыңны зурларсың да. Алыш-бирешкә корылган дөньяда сирәк очрый торган бәхеткә тарды Морад. Ямаулык турында хыялланып йөргән яшь галим затлы тунлы булды да куйды.

Рөстәм калдырган ширкәтне үстерүгә вакыты белән санашмыйча,

үзен-үзе җәлләмичә эш аты кебек тырышуның тагын бер өстәмә, арка йонын күпертеп торучы сәбәбе бар иде. Аңа сарафан радиосы бабасының, ягъни мәсәлән, Сахип әфәнденең «мөстәкыйль эш алып баручы кешегә охшамаган минем кияү, булганын әрәм-шәрәм итеп бетерер дә, аягыма килеп егылыр», дигән сүзләрен ирештерде. Күрәсең, Морадның бизнеста үзе белән бер дәрәҗәгә күтәрелү мөмкинлеген, баш бирмичә, мөстәкыйльлеккә омтылышын сизенгәч, көнчелек кытыгы уянгандыр. Ничек була инде ул, сәүдә шөгыленең серләрен миннән өйрәнеп, киңәш-табыш итмичә, әллә ничә кибет хуҗасы булып утырсын ди, укытучы баласы. Һәр бытбылдык үз урынын белергә тиеш. Бабасының шул хакта тузынуын да Сахипның иң ышанычлы шымчысы саналган Габделбәр житкерде. Берәүне саткан кеше сине дә шалкан бәясенә ычкындырмас дип уйлап бик нык ялгыша шул Морадның тәкәббер бабасы. Сәлимуллин Казан ханлыгы язмышы белән бәйле бер риваятьне еш искә төшерә.

Озак еллар дәвамында Казанда типтереп, алып-сатып яшәгән, хәзергечә әйтсәк, әрмән диаспорасы Иван Грозныйга казанлылар эчә торган су юлын, дарының кая саклануын, шартлату урыннарын күрсәтеп, бүләкләр көткәннәр. Казан егылгач, гаскәр башлыгы «әрмәннәргә ничек рәхмәт әйтик» дип сорагач, патша «барысын да кылыч аша уздырыгыз, бер хуҗасын саткан кавем, файдасы күренүгә икенчесен дә сатачак», дигән имеш.

## VI

Сахип Миндрахман улы киявенә үгет-нәсихәтне кызы аркылы житкерергә тырыша. Тик кызы ирен шәхси йөртүчесе итеп мыскыллауларны фаш ителгәч, гел Морадны яклап чыга торган булды.

—Кызым, игътибар иттеңме икән, ирең тәмәке тарта, кисәт, ул бик зарарлы. Өйдә дә тартса, минем фатирны сасытачак, ярыкларга тулган төтен үпкәләргә күчәчәк,—дип Морадны тәнкыйтьләвенә Ләйлә бик тиз җавап бирә:

— Морад житлеккән ир. Нәрсә эшләргә, ничек яшәргә икәнен үзе белә. Ул бик затлы папирос кына тарта. Аңа вак-төяк киңәшләрең белән бәйләнүеңне ташла.

Ләйләсе тулысы белән ире ягына авышкандай тоелгач, Сахип әфәнде башка гаилә әгъзаларын Морадка каршы әзерләү әмәлен эзли башлады. Кеше уйлап та өлгерми, аны гамәлгә ашыру юллары шунда ук табыла.

Кичке чәйне көтеп, китап шүрлегенең тузаннарын сөртергә әзерләнеп йөргәндә, Сахип бер мәҗмуганы кулына алып, авторның фамилиясен дә карап тормыйча, ваемсыз гына битләрне актара башлый. Шунда шигырь булып житмәгән, прозага дәгъва итә алмаслык бер куплетка юлыгып, кычкырып көлеп җибәрә. Сенлесе Әсма белән аш-су бүлмәсендә маташкан җинел сөякле Халидәсе ире янына йөгереп чыга.

—Нәрсә булды, Сахипҗан? Үзеңне Шүрәле кытыклады дияр идем, янында беркем күренми.

—Карале әнисе, бер китапта безнең кияүне мактап язганнар. Шуңа тап булдым әле.

Иренен ирониясен аңламаган беркатлы Халидә:

—Язарлар да, яхшы кеше бит. Әти-әнисе аны кызыбыз бәхетенә үстергәннәр,—дип киявен мактарга керешә.

—Мә, укы. Юк, үзем таныштырам. Син жиренә житкереп укый алмассын.

—Тыңла! Әсма, син дә чык.

Сәхнә таләпләреннән шактый ерак торса да, үзенең текстка мөнәсәбәтен белдереп, туктый-туктый, илһамланып укый Миндрахман абый малае.

Егет яшь тә түгел, карт та түгел,
боек та түгел, шат та түгел, биек тә
түгел, тәбәнәк тә түгел, чирле дә
түгел, сәламәт тә түгел.

Сахип, күзлеген салып, канәгатьлеген яшерүне кирәк тапмыйча, өнсез калып басып торган тынлаучылар ягына борыла.

—Йә, ничек. Безнең кияүгә тач ябышып тора. Акча түләп яздырсаң да шундый төгәллек белән бәя бирә алмаслар иде.

Нәрсә, кем турында сүз баруын аңламаган Әсма риясыз күзләрен апасы ягына борып сүзсез сорау бирә: ничек инде ул кеше берүк вакытта озын да, кыска да, чирле дә, сәламәт тә була алсын ди.

Иренең дөньясын онытып «шигырь» укуыннан югалып калган Халидә, Әсманы чыгарып җибәргәч, аның терекөмеш кебек хәрәкәтчән табигате өчен озын-озак паузадан соң, телгә килә.

—Кешедән көләргә яратасың инде, Сахип. Син бөтен кешене үзенчә яшәргә, синеңчә уйларга өйрәтмәкче, үз кубызыңа биетмәкче буласың. Син бит дөньяда берәү генә...

—Аңламадым. Нинди мәгънәдә берәү генә? Яхшы чуттамы, начармы?

Халидә сүзләренә аңлатма бирүне кирәк тапты.

—Син кияү Морадтан көлүеңне, ана каныгуыңны ташла. Аның мина ошамаган яклары булса да, ул горур, үз бәясен белеп яши торган кеше. Бер читтән икенчесенә сикерә торган җилбәзәк тегел. Мин сезгә Морад күпме түләсәгез дә, шофер йә хезмәтче булып йөри торган адәм тегел дип сразы әйттем. Сүземне тыңламадыгыз. Ана яхшы эш тәкъдим итмәгәч, барысын үзе хәл итте, хәзер бизнеста синең дәрәҗәгә күтәрелеп бара.

Сахип хатынының акыл өйрәтүен кабул итмәвен, ризалашмавын сиздереп, борын тишекләрен кабартып, авызын турсайтып, бүлмә буйлап йөренеп алды.

—Син хатын, ориентирыңны югалтып барасың түгелме? Мине яшәргә өйрәтергә керештең. Абзаң нинди зур коллектив белән уңышлы җитәкчелек иткәнне оныттың бугай.

Кыпчак каны дәрт, дәрман биреп, кыздырып торган Халидәне борчыган фикерен, бәясен әйтүдән туктатып калдырырлык көч юк иде кебек.

—Син Сахипҗан үпкәләмә, күңеленә авыр алма. Чит-ят кешеләрне кимсетеп, башкалардан гел начарлык эзләвең аркасында туган көнеңә әтиеңне карап торучы хатынын чакырмыйча, икесен дә рәнҗеттең. Бар кунаклар парлы-парлы килеп, кәеф-сафа корганда әтиең моңаеп утырды. Әниеңнең фани дөньядан иртәрәк китүендә Хәерниса апаның ни гаебе бар? Әтиегезне хәленнән килгәнчә тәрбияләп яши. Өсте-башы чиста, тамагы тук, ир-атка тагын нәрсә кирәк. Сезгә атагызның хаҗәте юк. Чакырсагыз да сезнең сазлыкка аяк та басмаячак.

Тәнкыйтьне кабул итмәгән Сахип, сүз елгасын әлеге дә баягы акча ягына борып җибәрергә ниятли:

—Әтинең хәрби пенсиясенә кызыгып килгәндер әле Хәерниса апаң.

Халидә үзен берьяклы аңлаганга үрсәләнеп:

—Сахип бәгърем, син нишләп кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне, рухи якынлыкны байлыкка, акчага кызыгуга гына кайтарып калдырасың. Халык юкка гына ач тамагым, тыныч колагым дип әйтми торгандыр. Өлкәннәр арасында эчке уртаклыкның, хәтта мәхәббәтнең булуын күз алдына да китерә алмыйсың. Сез әтиегезне җылы канаты астына алган мәрхәмәтле апага рәхмәт әйтеп яшәргә тиешсез. Ул үзе сугыш ветераны, инвалид булса да өч малай үстереп, барысын да укыткан, тәрбия биргән. Сезнең

холкыгызны яхшы белгәнгә, мөстәкыйльлеген югалтасы килми.

—Әнисе, үзенә дә житәр-житмәс акылын көчләп тагарга маташучылар болай да житкән,—дип Сахип, кул сырты белән муенын сыдырып алды.— Син дә моралист булып киләсең. Әллә картаясың инде, хатын.

—Син минем фикеремне аяк астына салып таптарга мөмкин. Бер сүз кузгалгач, күңеленә авыр алсаң да, әйтеп бетерим инде. Ирең эчә, ялкау дип өлкән кызыбызны гел котыртып, араларын бозып, гаиләләрен таркатуга шактый өлеш керттең. Нәтиҗәдә кызыбыз өебездән үк чыгып китте, элеккеге хәләл җефете калдырган фатирда яши. Икенче яртысын һаман таба алмый. Кияүне төрлечә түбәнәйтергә тырышып, араларына тыкшынуыңны куймасаң, Ләйләнең дә бәхете көзге пыяласы шикелле уалып төшәчәк.

—Яшәсеннәр. Мин каршы түгел. Бөтен тырышканым, карьерам, байлыгым кызыбыз өчен.

Сахипны почмакка китереп кыскан Халидәнең әле туктарга исәбе юк иде.

—Ни өчен дип инде Ләйләне фамилиясен сакларга мәжбүр иттең. Киләчәкләре турында уйлаган ир белән хатын, балалары уртак фамилиядә йөрергә тиеш. Бик күптәнге, зыялы фамилия имеш, әнә югары дәрәҗәгә ирешкән, нәселләре йомшак креслода утырганда Табеев, Батыев, Репеев фамилияләре күнелдә шом уята иде. Хәзер алардан нәрсә калды. Пшык. Габбасов фамилиясе борынгы дигән булып кына, эшләмәсәң, тир түкмәсәң, бирәү дә китереп бирми. Казына башласаң, әлләни күптәнге дә түгелдер әле фамилиягез. Еникеев, Апанаев, Максудов кебек борынгы китапларда очрамый шул фамилиягез, аның шөһрәте энеңнән, синнән, кара алтын табучы туганыгыздан гына башлана торгандыр дип уйлыйм. Исемең матур кемнәр кушкан дип кемнең хезмәт хакын арттырганнары, бушлай машина биргәннәре бар. Кияүгә каршы алып барган мәкереннең ахыры ни белән бетәр, соңыннан терсәкне тешләп булмый, абзыкаем. Кызларыбызны, бигрәк тә Ләйләне акча белән боздың. Без аны яшь әле дип гел уч төбендә генә биетеп, гаилә тормышына, кирәк чакта иргә буйсына, тыңлый, кичерә белергә өйрәтмәгәнбез.

Сахип Халидә ханымның соңгы җөмләсенә үз бәясен бирергә ашыкты. Батып баручы саламга ябышкандай, сүз дилбегәсен үз кулына алуга омтылуы уныш алып килмәде.

—Тыныч кына ашап-эчеп утырганда бәйдән ычкынгандай йодрыгыңны минем бит тирәсендә уйнатуың Ләйләгә гаилә тәрбиясе бирүгә керәме?

Халидә теге вакытта көтмәгәндә ярсып китүе өчен кызарып алса да, сәбәбе исенә төшкәч, җилкәләрен күтәребрәк куеп, Сахип файдасына булмаган аңлатмасын чыгарып салды.

—Миңа шул көнне дусларың Чаллы якларындагы сөйрәлчегең турында тулы мәгълүмат бирделәр. Һаваны йодрык белән айкау гына аз булды әле. Башкачарак чаралар күрәсе булыр.

Халидәнең соңгы җөмләсен тышкы ишекнең шыгырдавы өзмәсә, сөйләшү-аңлашу тирәнгәрәк китәргә дә мөмкин иде. Мунчаның әзер булуы турында хәбәре белән Габделбәр килеп керде.

## VII

Тормыш сәхнәсендә һәркайсыбызның үз урыны булган шикелле, Габделбәр исемле Алла колының да язмышлар уенында беркем белән дә алыштыргысыз кимәле бар иде. Каһарманнарыбызның киләчәге күпмедер күләмдә Габбасовлар коттеджының бер читендә вакытлыча яшәү урыны тапкан Габделбәргә да бәйле булып чыкты. Ни өченме?

Габделбәрнең холкын ятимлек гарасаты һәм тирәлек калыплаштыра.

Рәсми әтисе билгесез, ЗАГСта гына Мөбарәк улы дип язылган бала әнисен дә хәтерләми. Аңа өч яшь тулганда сәер авырудан әнисе дә фани дөньяны, бердәнбер газиз улын ташлап китә. Малайны Казан янындагы район үзәгендә үз йорты белән яшәүче, әнисенең абыйсы Тажи асрамага алып китә. Житешмәүнең, кагылу-сугылуның ни-нәрсә икәнен инәсеннән җебенә тиклем татый малай. Кул астына керә башлауга: «Габди, утын яр, су алып кер, чоланны юып чыгар, бәрәңге әрче, чиләкне түк» кебек мәҗбүри үтәлергә тиешле бертөсле эшләрдән косасы килер дәрәҗәдә гарык булса да, әрекмән колак абыйсы аны тормышка, көчле белән бәйләнмәскә, каршы әйтмәскә, баш өсте дип ризалашып, үтәми калу юлын эзләргә, хәйләгә, хәрәмләшергә өйрәтте. Барысы да илләм кирәк булып чыкты тормышта. Әчке чыҗымы аңа тотылмас өчен сөйләшкәндә әмер бирүченең күзенә туры карамаска «кинәшен» бирә. Дөнья матурлыгын бәяләү өчен мангай астына уелган чокырчыклар хуҗаларын сатып җибәрергә дә күп сорамыйлар икән. Күзеннән кешенең ни уйлаганын, әңгәмәдәшенә мөнәсәбәтен, хәтта менәзен—характерын да белеп була, диләр. Кирәксә-кирәкмәсә дә эш кушарга, кулын ходка җибәрергә маһир абыйсы, үзеннән өстәп сөйләргә яраткан җиңгәсе уена төшенмәсеннәр дип, сөйләшкәндә күзен яшерергә, яисә читкә карап торырга өйрәнә. Әрекмән яфрак абыйсы:

—Дуңгыз малай, ник минем белән сөйләшкәндә читкә карыйсың, күзләреңне яшерәсең,—соравына:

—Печән бушатканда чүп кергәние,—дигән җавап ала.

Абыйсы «күзгә карап сөйләш» дип бер әйтә, ике кисәтә, канга батырганчы кыйнап та карый, мәгәр файдасын күрмәгәч, чүп җыярга маһир күзләр хуҗасына бәйләнмәс була.

Габделбәрнең иң сөймәгәне мәктәп, дәрес әзерләүне таләп иткән укытучы, җүнләп өйрәтә белмәгән дәреслекләр булып чыга. Ул физикадан йә химиядән мәсьәлә чишү урынына бер әрдәнә утын ярырга риза булып яшәде. Табигать сәләтен кысып кына тамызу өстенә тырышлыгын да кызганган икән. Министр буласы юк, түрәләргә дә хезмәтчеләр кирәк дип, тугыз сыйныфны этеп-төртеп тәмамлаткач, абыйсы аны уку белән артык борчымас була. Бер класста икешәр ел утырган Габделбәрнең солдатка каралу яше дә килеп житә.

Алдаша, хәрәмләшә белүе, куштанлыгы армиядә хезмәт итү чорында бик тә ярап куя. Сержант аны ярдәмчесе, күзәтүчесе итеп гел үз янында йөртә. Солдатлар Габделбәрне кыйнап та, ашатып та карыйлар, әмма ул сержантка барысы өстеннән әләкләвен дәвам итә. Армия срогын тутырып кайтып, берничә атна ял итүгә, әрекмән колак абыйсы көтелмәгәнрәк белдерү ясый.

—Энем, үзем исән чакта сине башлы-күзле ясап калдырырга ниятләдем әле.

Өйләнү хыялы ике ятып бер төшенә дә кермәгән Габделбәр югалып кала. Уйламаган тәкъдим. Шатланырга да, кайгырырга да белми.

—Мин бераз ял итеп, эшкә урнашып, кешеләр белән аралашып, күңелемә ошаганрак кызны очратып, соңрак гаилә корырмын дип планлаштырган идем.

Абыйсының җавабы кискен һәм катгый була.

—Юкка башыңны ватма. Синең өчен уйларга мин бар. Тәк вот. Минем муенда утыру срогы узды. Үз балаларымны укытып бетерәсем бар. Сине бик әйбәт, хәлле, тәртипле гаиләгә урнаштырам. Мин аңа өй салыштым. Шунда хатынының сеңлесе безгә аш-су әзерләп йөрде. Өй хуҗасы белән синең турыңда сөйләшенгән. Акыл белән яшәсәң, күзләренә туры карамыйча, иренмичә хезмәт итсәң, авызың балда-майда булыр.

Габделбәр абыйсыннан «мине өйләндерергә уйлаган кызыгыз матурмы, эшчәнме, әти-әнисе бармы», дип сорарга өлгермәде, абыйсы нотыгын дәвам итте.

—Әти-әнисе авылда яшиләр. Абыйсының теленә, үзенә кирәккәндә, шайтан төкергән диярсең.—Кызның йөзе шикәр төсле ак, күзе—чакма, куллары—каз муены. Кияүдәге апасы янында шәһәрдә яши.

—Минем кебек туганнарының хезмәтчесеме,—дип абыйсына төрттереп алуы тегенәргә тузынырга, нәгърәләр орырга, эчендә җыелган бар күбекләрен чыгарып ташларга сәбәп була. Үксез бала асрасаң авызың борының кан булыры да, көт рәхмәт, алырсың нәгъләте дә, берсе дә калмый. Габделбәре дә солдатта үҗәтлеккә, үзенә тиешле ботканы сугышып булса да алырга өйрәнгән иде шул.

—Дөньяда мәхәббәт, яратышып, һич югында йөреп өйләнү дигән нәрсә дә бар диләр бит әле.

—Болар барысы да йомшак авызлар, селәгәен агызып йөрүче буш бугазлар, ялкаулар уйлап чыгарган нәмәстәкәйләр. Гаилә кору, балалар үстереп, нәселне дәвам иттерү килде-китте хистән өстен. Мәхәббәт дигән әкәм-төкәмнең нигезендә теләк кенә ята. Ә теләкне хатын-кызның мул күкрәге, бүселеп торган арты, балага узганчы билләрен сыгылдырып-бөгелдереп йөри белүе тудыра. Шунда шалт итеп мәхәббәт күтәрелә. Синең булачак хатыныңда боларның барысы да артыгы белән, үзе ягымлы, эш сөючән, дип кызны янәдән Габделбәрне арытканчы мактарга керешә.

Өлешемә тигән көмешемдер, урамга чыгып кыз эзлимме, тапсам да аны кая алып кайтыйм, нәрсә ашатыйм, туй чыгымнарын кем күтәрер кебек уйлар да керә мөстәкыйль карар кабул итүне яратмаган егет башына. Көчленеке замана икәнлекне ул армиядә бигрәк тә яхшы төшенә. Бәдрәф юучылар, бәрәңге чистартучылар арасында ул генерал дими, хәтта майор баласын да күрмәде. Иртәме-соңмы һәркем үз гаиләсендә яшәргә, хезмәтчеләр нәселеннән булса да дәвамчысын калдырырга тиеш. Куркактан куркак, колдан кол гына туасын чамалый иде ул. Абыйсы да ятимнән туйгандыр. Үзе исән-имин чакта аны урнаштырып калдырырга тырышуын да аңлап була.

Көзен оешкан гаиләләр бәхетле була дип абыйсы аны Габбасовларга агачлар яфракларын кызыл, сары, тагын әллә нинди төсләргә буяган чорда үз машинасына утыртып алып китте. Җил исү уңаена яфракларның күз яше сыман җиргә төшүләрен тәрәзәдән күзәтеп баруы күңелле икән. Үзенең мул уңышлары, сары сагышлары, моңлы инрәүләре белән көз килә. Ул фани дөньяга тулы хуҗа. Абыйсының танышлары кырмызы кирпечтән салынган, әйләнә-тирәсе биек кара койма белән әйләндереп алынган авыл клубы хәтле өйдә яшиләр икән. Йортта салкын белән тартышып утырган көзге чәчәкләр, тышкы ишекне үтүгә бик җайлы киемнәр элгече, шунда ук куелган гәҗит-журналлар өстәле, бигрәк тә ике зур бәллүр люстра эленеп торган, таба төбе кебек шома паркет идәнле бүлмә—абыйсының агач өеннән, солдат барагыннан башканы күрмәгән Габделбәрне таң калдырды. Яшиләр бит кешеләр дип уйларга да өлгермәде, күзләре җиләк-җимеш, яшелчә, кыздырылган тавык, туралган тел, колбаса, чикләвекләр, ак күмәчкә ягылган кызыл уылдыклар, тагын ул белмәгән нигъмәтләр белән тулган әгъла өстәлгә төште. Абыйсын шулай хөрмәт итәләрме, әллә кыздан котыласылары киләме, анысы соңрак ачыкланыр, тизрәк ашарга утыртсыннар иде.

Дүрт почмаклы өстәл өстен инләп алганнан соң, Габделбәр түр ягында утырган, халатынамы, күлмәгенәме өлгергән кызыл җиләкләр төшерелгән, киемнәренә сыеша алмыйча тырпаеп торган мул күкрәкле кызны күреп

алды. Ул да кунакка килгән кеше кебек, урынынан чак кына күтәрелеп, өлеш тарелкаларын, чәнечке-пычакларны урнаштыру белән мәшгуль. Өлкәнрәк ханым кебек икенче бүлмәдән ризык ташымый. Җилкәсенә сыланып торган коңгырт чәч, түгәрәк бит, ризыкны әләктереп алу өчен әзерләнеп куелгандай алгарак чыгып торган тулы иреннәр, үрелгәндә күренеп алган сыгылмалы билләр Габделбәрнең күңеленә хуш килде. Мин бу туташка әүвәл гашыйк булырга, аннан соң өйләнергә тиеш булам бит инде. Һәрхәлдә, шул тулы түшле кыз минем гомерлек юлдашым, таянычым булыр дип фаразлана. Әгәр аңа ошамасам нишләргә? Хәер, алары башларны уртак түшәккә салгач килә торгандыр. Әрекмән колак абыйсы юлда килгәндә шулай дип аңлатты. Тын тартырга да өлгермәделәр, кулларын бер-берсенә ышкый-ышкый хуҗа да бүлмәгә килеп керде.

—Белми дә торам, кадерле кунаклар, булачак кодалар өемдә утыра икән. Халидәсе дә алданрак кисәтмәде. Йәле, карчык, бардан Шотландиянең үзеннән үк килгән эчемлекне алып кил әле.

Элеккеге нигъмәтләр янына рюмкалар, виски, шампан шәрабе дигәннәре өстәлде.

Түргә, үзен Әсма дип таныштырган кыз янына утыртылган Габделбәр беренче мәлдә үзен ашка төшкән таракан кебек, бик киеренке тотты. Теле, әйтерсең лә, аңкауга ябышкан, тиешле сүзләрне дә укмаштырып чыгара алмый. Шулай да егет гомерендә бик сирәк күргән, беришесе бөтенләй яңа ризыклардан баш тарта алмады. Рөхсәт булуга Габделбәр атна буе ач торган кешедәй өстәлдәге төрледән-төрле тәмле азык-төлекне ашыгып-кабаланып авызына тутыра башлады. Әйтерсең лә, барысын тиз генә капкаламаса кемдер кире алып китәргә кулын сузган. Әсма егетнең әле уылдыкка, әле сёмга, форель балыкларына, төрле чикләвекләргә ташлануына көлемсерәп тә, аның хәлен аңлап та күзәтеп торды. Бер-ике чәркә шәрабны тәгаенләп куйгач, мәҗлес үз җаен алды, өлкәннәр гаилә бәхете, аның киләчәге, ярдәмнәреннән ташламаулары турында сүз куерткан арада Габделбәр песи баласы кебек йомшак, җылы нәрсәнең янтавына орынганын сизде. Әсма кулын кая куярга белми интегә икән. Габделбәр аны киң учына алды. Дымлырак кулдан таныш булмаган дулкын бөтен тәненә таралып, җинелчә калтырауга күчте. Рюмкалардан кыюлык алган егет кулын Әсманың итәгенә елыштырды, төртеп җибәрү урынына кызның кулын тирәнгәрәк тартканндай хәрәкәте күңеленә аеруча хуш килде. Өстәл артындагы юк-бар, чынлыкта яшьләрнең киләчәге, язмышлары турында сөйләшүләрне төш күргән шикелле генә кабул итеп утырдылар. Абыйсы вәгъдә иткән мәхәббәте тугланып ятканда, Габделбәр өчен өстәл артындагы сөйләшүләрнең бер әһәмияте юк иде. Абыйсы нәрсә турында хәл кылганнарын соңыннан аңлатты. Яшьләр өйләнешкәч, Габбасовлар коттеджында торачаклар икән. Бүлмәләре элек гараж дип уйланылса да, җылы кертелгән, аерым ишеге бар, ди. Шуның өчен аларга йорт эшләрен үз җилкәләренә алу, болын хәтле бакчаны карап, бассейнның суын алыштырып, мунчаны ягып, этне ашатып тору вазифалары йөкләнә икән. Әсма көненә өч тапкыр аш әзерләү белән шөгыльләнергә, Габделбәр хуҗаларының гипермаркетында тауарларны кабул итеп, килеш-китешне барлап, Сахипның сүзеннән чыкмый торган күзәтүчесе, ярдәмчесе функцияләрен өстенә алырга тиеш була, ди.

Тәүге мәҗлес күп нәрсәне үз урынына куйды. Яшьләрнең ризалыгын сораучы да булмады. Әсма кунакларны озатырга чыкмады, өстәл артыннан аз гына күтәрелеп, кулларын изәп кенә саубуллашты. Никах вакытында да мулла бабайның әйткәннәрен кабатлап, кыз өстәл янында гына утырды. Язылышкан вакытта да, туй күлмәге идәнгә төшеп тору сәбәпле, Габделбәр кызның абыйсы бармакларын шартлата-шартлата мактаган тулы челтәрле

аякларын күз нурында коендыра алмады.

Туйның икенче көнендә өстенә кыска халат киеп чәй әзерләп йөргән Әсмасы ана, бодай сугып кайткан көзге тук каз кебек, як-якка авышкалап йөргәндәй тоелды. Сул як җилкәсе атлаган саен аскарак төшеп ала. Ятагыннан күтәрелергә иренеп яткан бәхетле Габделбәр сорап куйды:

— Хатыным, аллә кичә аягыңны авырттырдыңмы, аксабрак атлагандай... Туйда биемәдең дә кебек.

Ир хатыны булу морадына ирешкән Әсма сүз гадәти нәрсә турында баргандай гына итеп:

— Юк, авырттырмадым, минем тумыштан сул аягым кыскарак. Сиңа әйтмәделәрмени?

Габделбәр йөзе белән мендәргә капланып, шактый дәшми торганнан соң, бөтен үкенечен салып, ыңгырашып куйды:

—Йа, Ходам. Ятим баланы монда да алдадылар.

Бәйләнчек әтәчтән качкан тавык кызыгырлык тизлек белән Әсма күрше бүлмәдән кечкенә түгәрәк көзге алып чыкты.

—Габделбәр, яле үзеңне көзгедән кара. Минем йөземне, мамыктай тәнемне исеңә төшер. Әти мин яралган көннәрдә эчеп-тузып йөргән. Балаларыбыз сау-сәламәт булып, безнең кебек хезмәтчеләр дәрәҗәсендә калмасыннар дисәң, шайтан суыннан ераграк торырга тиешсең.

Әсма үзе дә аягыннан оялып яшьләр белән аралашмыйча, аңа дигән бер гарибе килеп чыкмый калмас әле дигән якты өмет белән яши. Казанга апасы янына күчеп килүенең төп сәбәбе дә шул була. Кеше күп яши торган калада үзенә тиңе, чиләгенә күрә капкачы табылмый калмас әле. Ире аның өчен Алладан соң икенче олы зат булачак. Аш-суга осталыгы бар, туган авылларында да гелән казан тирәсендә булды. Механизаторларны, мал караучыларны, колхоз кунакларын сыйлады. Кеше көен көйли, тун йөрәкләрне дә сүзе, җылы карашы белән эретә белә. Тоемы көчле. Ике бармак киңлегендәге маңгайлы, бәрәңге борынлы, түң бияләй кебек шапылдап торган иренле булса да, көрәк хәтле куллы, дугадай алга чыгып торган күкрәкле, бүрәнә сорап торган таза җилкәле Габделбәр янына килеп утыруга, «бу минеке, моны ычкындырмаска» дип, күңеленә беркетеп куйды.

—Мин сине, Габделбәр бәгърем, ишектән килеп керүгә ошаттым, янәшәмә килеп утыргач, гашыйк булдым. Синнән салкын көнне көтеп алган җылы җил шикелле ягымлылык килеп тора. Без бик тату, яратышып яшәрбез. Тупырдап торган балалар үстерербез. Мин сине өрмәгән җиргә дә утыртмам,—дип сөйләнә-сөйләнә Габделбәрнең дуамалланырга әзер җан канатларын урыннарына утыртты.

Абыйсы Таҗига «ник Әсманың кимчелеген алдан әйтмәдең» дигән үпкәсенә җавап урынына, «кызлыгын саклаган идеме соң», дигән сорауга гына лаек булды.

Мондый борылышны көтмәгән Габделбәрнең ак борыны кызыл бәрәңге төсенә керде. Гомерендә сирәк була торган киеренкелек белән үткән төн мажараларын исенә төшереп, канәгать елмаеп:

—Шулайрак иде кебек. Авырттырасың, ашыкма дигән булды. Мин бит хатын-кыз белән беренче тапкыр.

—Соңгысы булмасын. Аксаклыгы турында нәрсә әйтим. Сиңа кыз да булсын, буаз да булсын. Бәлки, сиңа чибәркәйне Париждан йә Варшавадан алдырырга кирәк булгандыр? Яшәргә урын бирделәр, акыл белән кинәшкәләсәң, эш урының төшемле. Ятакта аякның кыскалыгы, озынлыгы беленми. Абыеңа көнегә өч тапкыр булса да, рәхмәт әйтеп, яшәвеңне бел.

Әсма белән алдан килешеп куйганнар диярсең:

—Хатынынның аксаклыгы бәгыренә тигәндә, үзенне көзгедән караштыр. Соңгы сүзем: сиңа кире юл юк. Безгә күчтәнәчләренне төйнәп кунакка килгәләргә генә рөхсәт бар.

Тажи машинасының зәңгәр төтенен калдырып китеп тә барды. Хәзер Габделбәр абыйсы урынына калган яңа хуҗасы Сахип Миндрахман улына хезмәт итәргә тиеш була. Кибеттә эшли башлагач, тормышы тәмам җайланып китеп, кесәсенә акча керә башлады. Беренче балалары туганчы дип, Сахип абыйларыннан фатиха алып, Төркиягә ялга да барып кайттылар.

Хуҗа кеше Габделбәрне сынау барышында алдына куелган бурычларны катлауландыра торды. Ул шул ук олы кибет белән җитәкчелек иткән Халидәсенең кемнәр белән аралашуы, туганнарыннан кайсыларының кереп-чыгып йөрүе, акчаны кая туздыруы һәм бигрәк тә, олы кызының шәхси тормышы килеп чыкмагач, кечесенең гаиләсен саклау нияте белән, кияве Морадның кемнәргә сәлам бирүе, дөнья бизәкләре белән кызыксынуы, ягъни сөяркәсен (хәлле ир-атның сөяркә тотмавына ышанмый иде) ачыклау бурычы куелды. Габделбәргә шымчылык бик ошады дип әйтү дөрес булмас иде. Мәгәр өстәмә һөнәр буларак ул ифрат төшемле икән. Шулай булмаса дөньясын шпионнар басмас иде. Берәүләрен фаш итеп торсалар, икенчеләре акча алганда тотылса, өченчеләре шул көнне үк эшкә керешә. Урын бирдаим да буш тормый. Һәр яңа хәбәрнең Габделбәрнең кесәсен калынайтуы хак. Башка вакытта ифрат кысмыр Сахип абыйсы хатыны, кияве турында кызыклы яңалык алып килсә, акча янчыгын киң итеп ача торган булды. Айзизә тугач кына Халидә гел оныгы белән чәбәләнде. Күзәтү үзегендә берише кибет, офис хезмәткәрләреннән башка, Морад кына калды. Дөрес, ул баҗасын башбирмәс холкы, бөтен кешене тигез күрүе өчен хөрмәт итә. Тик хөрмәтне май урынына ипигә ягып булмый шул. Бер көнне Сахип абыйсы аңа ифрат авыр, әмма уңышлы чыкса бик төшемле бурыч йөкләде. Әйтергәме икән, әйтмәскәме икән дип, маңгай сырларын йөнтәс кулы белән угалый-угалый уйланып торгандай булды да, сүзен Габделбәрнең салпы ягына үткән елгы саламны кыстырудан башлап җибәрде.

—Энем, син минем иң ышанычлы ярдәмчем, намуслы дустым. Иң тирән серләремне сиңа гына ышанып тапшыра алам. Кайвакыт икебез бер кеше булып китәбез кебек.

«Берәүнең дә күпертеп мактау сүзләренә ышанма» дип, миенә сеңдерә килгән Әсмасы, бу хакта сөйләгәч, җизнәсенең сүзләрен шик астына алды.

—Кемгәдер берәр этлек кылырга җыена торгандыр әле. Арзанга сатылма. Бала караватын куярга да урын җитми. Үз фатирыбыз да булырга тиештер, өе барның гына көе бар,—дип иренә юнәлеш ноктасын тоттырды.

— Морад артыннан ныклабрак күзәтәсе иде. Башка хатыннар белән чуала торган гадәте юкмы икән? Утыз яшенә чаклы өйләнмәгән ирнең таныш хатын-кызлары арасында сөяркәсе дә булу ихтималы бар. Үзе фирма хуҗасы булып алгач, артыгын кылана башлады, сәнәктән көрәк булган укытучы баласы. Чиста суга чыгарыйк әле үзен.

Габделбәр хуҗасының күзенә карамыйча гына:

—Сез әйткәннең барысын да эшләрмен, безнең фатир мәсьәләсен дә ничектер хәл итәсе иде бит.

Әсмасы вак-төяк акчасы кирәкми, анысын үзең дә табарсың, квартираны шарт итеп куй дигән иде.

—Морадны хатын-кыз белән тотсаң, анысын да эшләрмен,—дип өзде Сахип абыйсы сүзне.

Габделбәр өчен бу шактый катлаулы шөгыль булып чыкты. Эшләгән урыннары арасындагы юлны, машина бөкеләрен дә исәпкә алсаң, шактый

җыела. Иртән үз кибетләрендә күренеп, сатучыларга яңа тауарларны өләшә дә, Сахип абыйсы биреп торган машинага утырып, Морадның ширкәте, кибетләре урнашкан тарафка юл тота. Айга якын ышкылып йөрү берни бирмәгәч, «Сахип абый яңалык юк, вакыт уздыру гына бара, киявегез гел эштә, үзен бик әдәпле тота», дип өстеннән төшермәкче булган иде, нәкъ шул минутта Морадның 438 санлы зәңгәрсу машинасы күзенә чалынды. Ну и что, диярсез. Бөтен хикмәт «ну и что да» шул. Руль артында, Морад урынында аксыл чәчле, ак тәнле, ымсындыргыч тулы гәүдәле бухгалтеры утыра иде. Габделбәр детектив фильмнардагы шикелле, күздән югалтмаслык кына ара калдырып, джип артыннан элдертте. Юкка мине беркатлы дип уйлап йөри Сахип абыйның кияве, Габделбәр, каты итеп чеметкәндә дә, елмая белә. Ханым әүвәл банкка, аннан соң базарга кереп чыкты һәм, эзне югалтырга теләгәндәй, шәһәр буйлап шактый боргаланып йөргәннән соң, биш катлы кирпеч йорт янында машинасын калдырып, сумкасын иңенә элеп, кәс-кәс атлап подъездга кереп гаип булды. Габделбәрнең озакка юкка чыгуын хупламаган Халидә ханым үзенең кесә телефоныннан: «тауар кайтты, бушатырга кеше юк, тиз генә килеп җит», дип бик каты кисәтсә дә, артында чын хуҗа торган Габделбәр селкенмәде дә. Бәхет кошы кулга керәм дип торганда, тауар бушатып йөримени ул тузга язмаганны. Кияүне чиста суга чыгарсаң, фатирлы итәм дип торганда, ул ярты юлда туктап каламы соң инде. Ханым ике сәгатьтән соң гына урамда пәйда булды. Машинасын ераккарак куеп, карт юкә астында угры кебек биеп торган Габделбәргә ханымның күзләре каймак ашаган мәченеке төсле ялтырагандай, бит очлары алсулангандай тоелды. Хатын-кызның ир-ат белән якыннан аралашканнан соң шулай алланып, матураеп китүе аңа мәгълүм иде. Ханым машинасына утырып киткәч тә, Габделбәр Морад килеп чыгарга тиешле тимер ишеккә өмет белән озак карап басып торды. Теге шайтан укыган кеше шул, бик хәйләкәр булып чыкты, тәки Габделбәрнең хәленә кермәде. Бәлки, подъездның икенче ягында да ишек бардыр дип әләкче эш урынына юл тотты.

Шул кичне сөенечле хәбәре белән Сахип абыйсы янына керде.

— Эләктердем мин теге тәти егетне. Боргаланырлык бер хуты калмады.

—Йә, сөйлә тизрәк, көттермә!

—Өсләренә бастым дисәң дә була. Морадның беркемгә, хәтта хатынына да рульне бирми торган машинасында фирмасының бухгалтеры, ак чәчле матур хатын ду китереп йөри. Очраша торган йортларын да беләм. Киявең алданрак килеп хатынны квартирада көтеп торды бугай.

—Син машинаның номерын бутамадыңмы?

—Юк, юк. Менә язып та алдым. Мин аның зәңгәр джибын йөз машина арасыннан таныйм.

—Ярый, рәхмәт. Күзәтүеңне дәвам ит,—дип, мөнәсәбәтен тышка чыгармыйча, кабинетына кереп китте.

Сахип Миндрахман улы чит илдә командировкадагы кызын ач кеше мичтә пешеп яткан бәлеш көткәндәй, зар-интизар булып каршы алды.

Юлдан кайткан кешенең хәл-әхвәле, чит илдән алып кайткан яңалыклары турында да белешеп тормыйча, Ләйлә шул хәбәр турында хыялланып кайткандай, үз янына диванга тартып утырткач:

—Кызым, миңа ышанмыйчарак йөрдең, ничә тапкыр Морад сиңа хыянәт итә, дип кисәттем. Исең дә китмәде. Хәзер аңа боргаланырга урын калмады. Үзенең бухгалтеры, син белгән Мария белән бутала икән. Алма кебек кызымны кемгә алыштырган бит. Явочный квартиралары да мәгълүм.

Бу хәбәрне Ләйлә бик авыр кабул итте. Йөзе әүвәл агарынды, соныннан

өлгергән помидор кебек кызыл төскә керде. Битләрен матур куллары белән каплап, сорарга көч тапты.

—Синең Морадны яратмаганыңны беләм. Аны пычратырлык дәлилләрең бармы?

—Бар, җитәрлек. Менә шул Мария дигән сөйрәлчеге көннәр буена иреннең машинасында йөри. Мин Морадның кемгәдер үз машинасын биргәнен хәтерләмим. Ул аны синнән бүтәнрәк яратып, беркемне якын китерми торганые,—дип Сахип җинүче кыяфәтен сиздермәскә тырышып, кызын сүз белән дөмбәсләвен дәвам итте.

—Кем күргән аларны бергә, шаһитың бармы?—дип кенә сорый алды Ләйлә.

—Габделбәр очраклы рәвештә тоткан үзләрен. Узып барам, таныш джип ди. Тавыш биреп туктатмакчы идем, руль артында башка кеше. Иманеп киттем. Күзәтеп барып, кереп киткән өйләре янында унайсызланып озак басып тордым, ди. Үзе кая икән соң әле?

—Халидә, Габделбәр бүлмәләрендәме икән, чакыр әле.

Һәрвакыт өй эшләре йә оныгы белән мәшгуль Халидә керә-керешкә юеш кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә.

—Хәзер чакырам, аны өске катка син яраткан китек көзгене тагын бер кат ябыштырып кара әле дип менгереп җибәргән идем. Аптырап беттем инде. Беркая да төзәтергә алмыйлар. Нинди унган Габделбәр дә төрле-төрле җилем белән ябыштырып карыйм, ябышкан төсле була да, янәдән кителеп төшә, ди.

Ләйлә, елап арып туктаган бала кебек, әллә нинди инәлүле, үкенечле тавыш белән кычкырып җибәрде.

—Тагын шул ватык көзге. Минем бәхетсезлегем тамгасы. Көтмәгәндә күктән ингән бәхет, кадерен белмәсәң, башкалар белән бүлешсәң, көзге кебек уала да төшә икән. Әти, син сорамаганны эшләп, минем гаилә тормышыма тыкшынып, максатыңа ирештең. Котлыйм!

Күнеленә үрләгән икеләнүен, шиген җиңеп, сөекле әтисе көткән сүзне йөрәгеннән кысып чыгарды.

—Мин дә Морадны киселгән икмәк кебек тормышымнан кире ябышмаслык итеп чыгарып ташлыйм.

Чалшайган авызы, яшьле күзләре белән болай ук кабул итүне көтмәгән атасы ягына борылып, әмер биргәндәй каты итеп:

—Син бар нәрсәне булдырасың. Дусларың ашамы, акчаң ярдәмендәме тиз генә аерылышуны оештыр,—диде Ләйлә, һәлакәт юлына соңгы адымын ясаганын аңыштырып та бетмичә. Шуны әйтте дә, олы яшьтәге апалар кебек, авыр атлап бүлмәдән чыгып китте.

Үзен якын итеп кабул итмәвен, гади йөртүче булып кызы янында гына буталып йөрисе килмичә, ширкәт хуҗасы дәрәҗәсенә күтәрелүен хупламавын сизенсә дә, Морад бабасының мәкер юлына басуын көтмәгән иде. Баласы тугач, аны үстерергә булышучылар кирәк дигән сылтау белән Ләйлә үзе дә әти-әнисе ягын каера башлады. Командировкадан кайтканда, Айзизәкәемне сагындым дигән булып әүвәл аларда туктый, берничә көннән соң гына шәһәр үзәгендә затлы фатир сатып алган ире янына килә. Морад болай гаилә саклап булмый, син әүвәл төп йортыңа, минем янга төшеп, аннан соң теләсәң икәү, мине ияртергә кирәк тапмасаң, үзең генә әтиләреңнең хәлен белергә барырсың дип үгетләп, үзе кирәк санаганча аңлатырга тырышты, кат-кат үгетләп карады. Файдасы тимәде, Айзизәгә анда күбрәк ошый, монда кайтасы килми дигән сылтау белән, үзе мәгъкуль күргәнчә, яшәвен дәвам итте. Күрәсең, атасының аңлатулары, вәгъдәсе, үгет-нәсихәте үтемлерәк булгандыр.

Беркөнне Морад ямьсез төш күреп, куркып уянып китте. Имеш, ул Ләйләне очраткан аэропортның көтү залыннан каядыр очып китәргә җыенып йөри. Билетларны күрсәтеп, тиешле тамгаларны салдыргач, чыгу ишегенә якынлашканда, түбә ишелеп төшмәсенме! Морад кулындагы тәгәрмәчле чемоданын ташлап читкә сикерергә өлгерә. Кинәт уянып киткәч, нәрсәгә ым булды инде мондый куркыныч төш, кызыбыз гына сау-сәламәт булсын дип, озак уйланып ята. Төшнең мәгънәсе тиз бүртеп чыкты. Ләйлә араларын өзү юнәлешендә җитди карар кабул иткән икән.

Яраткан хатынының аерылышуга гариза бирүе турында үтәлү кәгазе килеп төшкәч, берни аңламыйча, әйләндереп-тугландырып кат-кат укыды. Аңлагач, әйтерсең лә, җанына кара кисәү тыктылар. Һавасы да аның халәтен аңлагандай, чыраен сыта. Эчпошыргыч, вак яңгыр ява. Канны мәлҗерәтә, йокыны китерә торган тымызык яңгыр. Ә тегесенең кешеләр фаҗигасендә кайгысы юк, түбә калаенда табигать көен башкара да, тәрәзә пыялаларыннан җылый-җылый кечтеки елгачыклар булып агып төшә.

Морадның башында уйлар тилерә, җанын кая куярга белми? Шулай тиленәрчә яратышып башланган тормыш кемнендер теләге белән җимерелергә тиешме? Аның рухын кемдер сындырырга тели, яшәешенә аяк чала.

Аерылышуны оештыручы кешенең кем икәнен сизенсә дә, Ләйләнең шулай бик тиз коткыга бирелүенә ышанасы килмәде. Хатынын телефоннан эзләп табып, аңлатуны үтенүгә «хыянәтне гафу итә алмыйм, ялган белән мәхәббәтне саклап булмый», дигән җавап кына алды. Тавышы салкын тимергә кагылгандай тәэсир калдырды Морадта.

Айзизәнең киләчәге өчен булса да гаиләбезне саклап калыйк дип үгетләүгә дә каршы якта теләктәшлек тапмагач, Морад та эчтән сыкранып, уфтанып, арты белән суга чумган аптыраган үрдәк кебек, мәхкәмәнең беренче утырышын инкарь итсә дә, икенчесенә килеп, ризалыгын бирергә булды. Дөньяны җил бозар, адәмне сүз бозар дип юкка гына әйтмиләр икән. Мәхәббәт җимеше—яңа яшь гаилә шулай тиктомалдан яшәүдән туктый. Мәхкәмә залына керер алдыннан гына, ишек төбендә Морад Ләйләгә берничә сорау бирергә өлгерә.

—Ләйлә, яратуың шулай тиз уздымени? Беренче сынауны да үтә алмадык. Аерылышу, кызыбызны ятим итү турындагы карарың үзеңнекеме, чын-чынлап уйладыңмы?

—Мин хыянәтне күтәрә алмыйм дип әйттем бит инде,—кыска җавабына «мин олырагын да кичердем» дип өстәмәкче булган иде дә, үзе кылган үкенмәс, теләсәң ни кыйлан дигән мәгънәдә, кулын гына селкеде. Әлбәттә, Морадның фатирын, машинасын, ширкәтеннән башка бөтен мөлкәтен урталай бүләргә дигән карар чыгарып, суд гаиләне таркатуга ризалык бирде. Рөстәм Айтуганов калдырган кибетләрне бүлә алмадылар. Хәйләкәр «бөдрә чәч» бер урында «вакытлыча» дигән сүзне кыстырган. Шул байлыгын коткарып калды.

Шул рәвешле, Сахип әфәнде теләгенә ирешге: кабул итмәгән киявен хур итеп, кызы белән оныгын үз янына кайтарды. Җинүенең өченче көнендә үк йөрәк парәләрен Франциянең атаклы курорты Вишарага ялга алып китте. Бәһале, затлы санаторий, диңгез суы Ләйләне дә бераз суытты. Гаилә көймәләренең комга терәлүен тәкъдирдә шулай язылгандыр, китек көзге шул хакта күптәннән искәртте, илдә яшәүче хатын-кызның яртысы балаларын ялгыз үстерә, минем бит әле үземне, оныкларын мәҗүсиләрчә яраткан әти-әнием бар дип, үзен юатырга тырышса да, тынычлык килмәде. Морадка битараф түгеллеген, аның ифрат зыялы, итагатьле кеше булуын очрашулар, яратышулар үткәндә калгач кына бөтен барлыгы-җаны, тәне

белән аңлады. Вакытлыча юатырга хатыннары янына ашыгучы ирләре табылыр. Кыланчык Артурның да очрашасы килә, баскетболист та һаман яратуы турында такылдый. Шулай да ирсез хатын—йөгәнсез ат дәрәҗәсенә төшәсе килми Ләйләнең.

Ялдан кайтканнан соң, әчке чакыруына, җан тартуына буйсыныпмы, машинасын бер көнне Морад ширкәте ягына борды. Нәриман урамы тарафында бер йомышы да юк иде. Автомобильләр кую өчен махсус эшләнгән мәйданчыкта янәшә диярлек үк куелган ике зәңгәрсу җипны күргәч, күзләренә ышанмыйча, тагын да якынрак килеп, тормозга басты, кукраеп утырган машиналарны игътибар белән карагач, төсләре, маркалары, зурлыклары арасындагы аерманың шактый булуын ачты. Иң гаҗәбе: икесенең дә артында берүк 438 саны эленеп тора. Тик хәрефләре генә үзгә. Берсе—В, икенчесе—М белән башланганны күргәч, ахмак Габделбәрнең һәлакәткә алып килгән хатасын аңлады. Машиналарның маркасын танымаган, серияләренең төрле булуын исәпкә алмаган. Шуны аңлагач, күзен кара болыт каплагандай, йөрәге урыныннан күтәрелеп бугазын томалагандай, утлы үкенеч бөтен тәнен яндырып алгандай булды.

Уеннан уймак чыгу буламы бу, әллә язмыш шаяртуымы? Габделбәргә ышанган әтисенә рәнҗү йөрәгендә төер булып укмашты.

Иреннән аерылгач, апасының ни өчен коттеджлагы оҗмах тормышны ташлап китүенең серен Ләйлә аңлый башлады кебек. Әтиләренең кызларын шәхси милек кебегрәк бәяләвендә мөстәкыйль тормышларына урын каралмаган икән.

Кем гаепле соң аның фаҗигасендә? Әлбәттә, үзе. Морад белән очрашып, күзгә-күз карашып аңлашу, һич югында әнисе кебек борын төбендә йодрык уйнату урынына дуамалланып, әтисе судка язып биргән гаризага кул куеп, нинди төзәтеп булмаслык хата эшләгәнен Ләйлә хәзер генә бөтен тирәнлеге белән аңлады. Үзенең халәтендәге үзгәрешкә дә игътибар итте. Кирәксә-кирәкмәсә тозлы суларын агызырга әзер күзләреннән яшь чыкмый, ә күңеле елый да елый.

Ләйләнең машинадан төшеп, Морад янына йөгереп кереп, сөешеп йөргән чактагы кебек, кешеләргә дә игътибар итмичә, муенына ташланасы, ахмаклыгы өчен гафу үтенәсе килде. Мәгәр ул Морадның аңа ышанмыйча мәкер аркасында гына гаилә таркатуын, олы мәхәббәтләрен аяк астына салып таптауларын гафу итмәсен белә. Кызын ташламас, әмма Ләйлә ягына әйләнеп карамас.

Барасы юлыннан кире әйләнеп кайтып, өйләрендә чәй эчеп утырган әтисенә ике бертөсле машиналарны бутау, аермаларын ачыклый белмәү аркасында гына гаиләнең таркалуы, гомергә төзәтелмәслек хата ясалуы турында кызының кызып-кызып бәян итүен Сахип Миндрахман улы чәйле касәсен өстәлгә куеп, тыныч кына тыңлаганнан соң, ике нәтиҗә ясады.

—Кызым, хәзер дөресен әйтим инде. Ирең сиңа лаек түгел иде. Кадереңне белеп, бәяләп яшәмәде. Бу хәл булмаса, башкасы килеп чыгар иде. Шыпырт кына безнең ширкәттә эшләп йөрисе урынга, үзенең хуҗа буласы килде. Әлеге очракта дивана Габделбәр гаепле. Аңа үз башыңны биреп торып булмый ич.

Ләйлә әтисенә гомердә булмаганча усал итеп, үтәли сөзеп караганнан соң:

—Хезмәтчеңнең әйтүенә караганда, синең кушуың буенча Габделбәр күптәннән шымчылык итеп йөргән икән. Төп гаеп синдә. Морад миңа лаек түгел дисең. Минем кебек асыл затка, хур кызына тиң торырдай кешең бармы соң? Дәүләт сере булмаса, ул кайсы илнең принцы, һич югында миллиардер баласы, генерал улыдыр инде. Аның белән кайчан таныштырасың, юкса

яшьлегем заяга узып бара. Хәер, апаның гаиләсен алданрак тараттың, әүвәл аңа кияү тап, аннан соң минем турында кайгыртырсың,—дип, бар җыелган ачуын әтисенең ябылыргамы, ачылыргамы белмичә чепиләнеп торган күзләренә карап чыгарды да, җавап көтеп тормыйча, үз бүлмәсенә кереп китте.

Сахип әфәнде башбирмәс киявен төп башына утырту белән канәгать булса да, кызының аерылышуны шул чаклы авыр кичерүен күз алдына да китерә алмый иде. Габделбәр фатир турында сүз каткач, хуҗаның талканы коры булды, бар гаепне аңа сылап калдырды.

—Нинди квартир турында сүз булырга мөмкин. Синең дивана шымчылыгың аркасында кызымның гаиләсе таркалды. Эштә дә, башкасын эзләп тапканчы, вакытлыча гына калдырып торам. Миең черегән күзле бүкән.

Кызын тынычландыру, ата-ана мәхәббәтенең бар нәрсәдән өстенлеген, аның арка терәге нык булуны аңлату нияте белән кызының бүлмәсенә сугылса, бөтен әйбернең асты өскә китерелгән тамашага тап булды. Ләйләнең һәрвакыт тәртиптә тотылган, һәрнәрсәнең үз урыны булган бүлмәсе карт буйдак яһүд фатирына охшап калган иде. Кызы ашыга-ашыга, ничек эләкте шулай Айзизәнең уенчыкларын, үзенең киемнәрен көпчәкле зур чемоданга тутырып ята иде.

—Ләйлә, моны ничек аңларга? Кая барырга җыенасың?

Хатын шөгылен калдырып, акрын гына күтәрелеп, өстенә өелгән йөкне алып ташлагандай, аркасын турайтып:

—Сиңа нәрсә булганны аңлатып торыргамени? Балага мондый мәхәббәт буламени? Мине яраткан иремнән аердың, гаиләмне изеп-таптап ташладың. Әйдә, тантана ит, син җинүче. Кызымны да шундый язмыш көтмәсен дип, сездән аерым яшәргә, үзем менә хәзер генә аңлаганча тәрбияләргә булдым. Апам янына күчәм. Бәлки, соңрак Морад та гафу итәр. Сезнең янда калсам, ул минем якка әйләнеп тә карамаячак. Ул бит безнең фаҗигане кем караламасы буенча эшләнгәнен бик яхшы белә. Морад бик акыллы, сизгер кеше.

Йөгереп чыккан әнисенең аһ-ваһына, чәбәләнүенә, әтисенең балтасын суга төшергән кешедәй югалып, өнсез калуына игътибар итмичә, бер кулына кызын, икенчесенә тәгәрмәчле чемоданын тотып, алдан чакыртып куйган таксига чыгып утырды. Күптән түгел гөрләп, тирә-юньгә шатлык бөркеп торган кызыл кирпечтән салынган өй машина артыннан моңаеп, йокымсырап карап калды. Үлем тынычлыгын җанландыруга җыенгандай көзге яңгыр сибәли башлады. Яраткан апасының үзен ташлап китүен аңлапмы, туган йортына килгән фаҗигане күнеле белән сизепме, кара капканы эчтән тырный-тырный Томан шыңшырга кереште.

Сахип Миндрахманович үзен бик тиз кулга алып, әүвәл Томанга кычкыргач, тантаналы җыелышны япканда кулланылган тавыш белән әйтеп куйды:

—Син артык борчылма, карчык. Кызыбыз нервларын тынычландыруга, мунча кереп, бассейнда коенасы килүгә әйләнеп кайтыр. Габбасовлар тәрбиясен алган кеше ич ул.

*2010 ел.*



# Флера Гыйззәтуллина

## ЯНУ ДӘВЕРЛӘРЕНДӘ

РОМАН-ПОЭМАДАН ӨЗЕКЛӘР

### Мин—Тукайның сеңелкәше

*Бишек җыры җырлап шигырь көйлим:*
*Ятимлектән иңгән тәмугта...—*
*Гыйбрәт өчен, берсен-берсе тотып*
*Ашар чиккә җиткән халыкка.*

**Бай баласы балда, майда коенганда**
**Ятим-җилпе борчак-борчак күз яшь түгә.**
**...Күңелем тулды... Ике яшьлек Апуш**
**миңа**
**Көтмәгәндә: «Сеңелкәш...»—дип эндәште дә.**
**...Аңа—ике!.. Миңа инде биш тулганда**
**Очраштык без шыр ятимлек кочагында.**
**Ул ашамый—минем өчен саклап тоткан**
**Шешәдәге өч-дүрт бөртек борчагын да!**
**Безнең арадагы охшашлыкны Тәкъдир**
**Ачлык, ялангачлык белән бәйләндергән,**
**Очрашканда зар елатмас өчен, ахры,**
**Сак-Сокларга соңра безне әйләндергән,-**
**Тукай язын дүрт-биш гасыр алдан тоеп**
**Шөкер кылып иманнары исән-саута—**
**Арча халкы Грозныйдан качып китеп**
**Нәсел типкән безнең мәгърур Чатыр таута.**
**Әнкәм яклы әбкәм, ахры, Арчадандыр:**
**Шәмсекамәр—Ай-Кояш бит, исем-аты!..**
**Исемнәре җисеменә туры килгән,**
**Якташларның моңы тирән, йөзе якты.**
**...Елдан-елга үрчи Сак-Сок күрәчәге—**
**Кол-качакның юл өстенә тау игә дә...**
**Мәмдүдәнең моңлы гаме рифмалашып**
**Дәвам иткән минем әнкәм—Мәүгыйдәдә.**

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА—*шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

**Ятимлеккә тарган сабый баланыңмы,**
**Ананыңмы—бакыйлыкта җаны тына?!.**
**Габдулланың күз яшьләре тама сыман**
**Борчак ашы бүлеп куйган савытыма.**
**...Яшь бөртеге исәбеннән саный китсәң:**
**Мин—Тукайның күп гасырлык сеңелкәше!**
**Әмма исрафлыкта узган ул вакытны**
**Нинди назлар түгеп кабат терелтәсең?!.**
**Ни әйтәсең—тук чырайлы әзмәвергә—**
**Үзен: «Тукай токымы!!!»—дип таныткандa,**
**Борчак бөртегедәй ымсындыргыч**
**Өметеңә синең каныкканда?!.—**
**Ут казаларыннан аралаган булып,**
**Суд җәзаларына кабат тарттырганда?!**
**Бер гөнаһсыз сак-сок чагымнан ук**
**Мин адашып калдым мәллә ят**
**урманда?**
**Уралдан да, Җаектан да ары китеп,**
**Шәфкатьсездән рәхим-шәфкать, ирек көтеп,**
**Көтекләндем,**
**китекләндем,**
**теткәләндем...**
**Белгән Тукай: көткән ирке буылмаса**
**Тыны бетми үпкәләрнең.**
**Еламасаң, күрер күзләр сукыраймый!..**
**Ил авазын ишетмәсәң—тонмый колак...**
**Картаеп һәм кибеп-корып, сукыраеп**
**Хатирәләр гөрелтесен тыңлый Болак.**
**Кара-каршы ярларыннан Илне күзли**
**Гасырларның чарасызлык шәрәлеге...**
**Сорый берәү: «Төптән типкән бу**
**фонтаннар—**
**Шагыйрьләргә тиеш шампан шәрабеме?»**

***

**Риваятьләр сөйли, Болак төбенә**
**Түшәлгән дип, юллар алтын-көмештән.**
**Төпләренә аның кем төшкән соң,**
**Көмеш шампаннарын кем эчкән?**
**Ай нурына манып бу ярларда**
**Бәйге корган кемнең якташы?**
**«Якташ» дигән саен күз алдында**
**Сурәтләнә Арча парчасы.**
**Парчаланган моңнар**
**борынгыдан**
**Күчеп килгән монда Арчадан...—**
**Йөрәкләргә шаулап кагыла да,**
**Шунда таба агыла барча дан!..**
**Идел, Чулман, Агыйделләр аша**
**Тукай моңы яулый Уралны...**
**Шул моң кышын безнең йөрәкләргә**
**Ак бураннар булып уралды.**
**Туар таңга кайгы җиле какса—**
**Ышыклады таңны ак болыт!..**
**...Шәраб түгел... фани фонтаннардан**
**Күз яшьләре тора атылып.**

Күз яшедәй чиста шигърият
Меңәр гасыр, диләр—кимендә:
Вөҗдан өлгеләрен хаклап тора—
Күк гөмбәзен тотып иңендә.

## Азатлык ул—бишектәге сабый

*Болак буйлап, тарих буйлап атлыйм:*
*Суткән гомрем—парча төргәге!..*
*Ватан тарихына колак салсам,—*
*Ишетелә күк этләр өргәне.*

Бу дөньяның моң танымас җиде яты
Татар милләтенә эттәй ыргып торды.
Тәмуг түрәләре безне эткә тиңләп
Яламакка коры сөяк ыргыттырды.
Милләт өнен яралаган сөяк-санак
Үлем утлый—дәверләрдән дәвам алып.
Бер-берсенә каршы шуыша Кафтау—Урал
Әрни-әрни караканга табан манып.
Урталыкта—җитмеш җиде юл чатында
Сер бирмәскә тырышып вөҗдан газаплана.
Азатлыкка тарту көче арткан саен
Өмет өне таш кыяга кадаклана.
Канат даулап көрмәкләнә тел төпләре
Богаудагы Муса Җәлил сыны төсле.
...Таң кояшы нурын сибеп тукландыра
Буыннарда тоткарланган ирки көчне.

***

Сугыш үткән барлык мәмләкәттә
Таш һәйкәлләр күкрәп чәчәк ата.
Гаделлеккә хезмәт түгүчеләр
Күрәләтә кылмый гөнаһ-хата.
Шигъри чишмә төбе ахак ташлы,
Ике баштан ачык улаклары!..
Утка салсалар да томаланмый:
Каләмнәрдә—галәм колаклары!
Чишмәләр дә җырлый таулар җырын:
«Шигъриятсез, моңсыз булмый яшәп»...
Таулар белән таулар бәрелешсә дә,
Дошманлашмый чәчәк белән чәчәк.
Агыйделнең ак яулыклы Айсылуын
Кем биздерер икән бишек тибрәтүдән,
Сабыена сөеп керфек каккан саен:
«Сөбханалла, күз тимәсен...»—дип әйтүдән?!

***

...Туктаталмый һичкем!..—Бишек җырын—
Ул кыйбласын азатлыкка яра...
Ирек белән коллык арасында
Кул сузымы кадәр генә ара!..
Азатлык ул карындагы сабый:
Тумый тулгак тотып тулганмаса...
Көрәш таләп иткән күрәчәгең
Сөю нурларында нурланмаса...

## ...Сөю рәнҗеше тотмасын...

*Ана өчен татлырак җим булырмы—*
*Сабый бала сулышыннан да?!*
*Сабый сафлыгы ул тере чыга*
*Атом-ядрә сугышыннан да...*

**Сабыйларым күптән балигъ булды,**
**Шөкер, төгәл булды саннары!..**
**Алар тибрәп үскән талбишекне**
**Мин күршемә бирдем аннары...**
**Өннәремдә аягөсте күргән**
**Төшләремне аңа сөйләдем:**
**—Мин ут йотып Прометейны сөйдем,**
**Хәләл ирне, никтер сөймәдем.**
**Шуңа, ахры, иркем кысрыкланды**
**Иске карурмандай тутыгып,**
**Хурлыгымнан көн-төн җөй җөйләдем**
**Елан авызында утырып.**
**Язмавыма куанучы дуслар**
**Шатландылар моңа шулчаклы:**
**—Браво!!!**
**—Браво!!!**
**—Бравоссимо!!!—диеп,—**
**Маңкортларга хәтле кул чапты.**
**Шул тавышка, күптән төпкә баткан**
**Аждаһа да өскә калыкты:**
**—Уңган ханым, колларыңнан куан!!!—**
**Матурлыкка мандың халыкны...—**
**...Шул мизгелдә җиде җәннәт иркен**
**Тойдым мин дә табан астымда!**
**Сөенечтән ташланырдай булып**
**Карап торам язгы ташкынга.**
**Ятимнәргә атап шигырь язам,**
**Язам поэмалар, дастаннар...**
**Алар исә сабырлыктан язып**
**Хәтта Илдән чыгып качканнар.**
**Әверелгәннәр хәтта очар кошка,**
**Җилгә, гөрләвеккә, яшенгә...**
**_ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _**
**...Яшеннәр дә моңга талган быел**
**Яшьнәп Тукайның күз яшендә!!!**
**Моң дәрьясы иҗат итеп мин дә**
**Тирәнәйдем, рухи котайдым:**
**Беркем талап алалмады миннән**
**Апуш кына чагын Тукайның.**

## Кайту

*Минем гомрем Тукай гомереннән*
*Өч тапкырга артык: санадым!..*
*Сансызлыктан, аңсызлыктан түгел,*
*Ялсызлыктан яна табаным.*

**Гомер белән гомер аралары**
**Янды безнең үксез упкыннарда.**
**Безнең буын берни дауламады,**
**Хакның-хагын язып кыркылганда.**
**Һәм... Без инде әҗәл кармагында!—**

Күргәнебез: каза арты каза!
«Тыныч илдә рәхәт яшәгез!!!»—дип,
Илбашчылар безгә котлау яза.
Шуңарга да күңел була, әйе,
Бер мизгеллек рәхәтлеккә талам!
Олуг Сөембикә—ханбикәдән
Фәрештәләр фәнен отып алам.
Күреп алам бөтен Европаны
Сыртка салган сугыш заманасын;
Газиз әткәемнең буразнада
Басып калган атлы сабандашын.
Күреп алам сабан тургаеның
Күктә кунып сайрар ноктасын...
Сагышларга нокта куелмагач
Ул сугышлар ничек туктасын?!
Боек күңел ничек күтәрелсен
Сайрар сандугачсыз, тургайсыз...
...Җил иркендә җилләп иҗат итү—
Миңа шул кадәрле уңайсыз.

***

Берәр җилбәзәге юатыр шәт:
—Син генәме—милке таркалган!??
...Юк.. Юатмый һичкем...
шагыйрьләргә
Җилләр генә исә арканнан.
Идел генә өнди: «Иңнәреңә
Сал!—дип, Айның көмеш урагын».
Сагыш урып милли аһәң таптым
Җилләргә мин сафлык юрадым.
Инде: «Сагыш чәчеп исмәгез!?»—дип,
Инәликме искән җилләргә?
Елан авызына сыйдык... әмма
Сыймадык без туган Илләргә.
— — — — — — — — — — — — — — —
Инде җир шарына сыймабыз күк:
Җырга җирсу чөнки зурайган.
...Тумыштагы зурлыгыма кайтам:
Гафу үтенер өчен тургайдан.
Азнакайдан мин Арчага кайтам
Нәсел тамырларым буенча.
...»Арча гимнын» тыңлап бетермичә
Үлмәм әле, Алла боерса.
Үлмәм әле...
үлмәм—
Бөек Тукай:
Туган күреп мине таныса...
Ватан сагышына сабышканнар—
Кайчан да бер күршеп кавыша!..

## Көрәш рухы

*Сизенепме алдан, тар эчленең*
*Аклык сөенечен хупламасын:*
*Арча халкы Тукай иҗатының*
*Һәр сүзенә салган култамгасын.*

Туган якны сайлап алып булмый,
Сатып алып булмый базарлардан.

**Базар буранында туңган Апуш**
**Тукай булгачтын да тазармаган.**
**Фәкыйрь, сукыр заман ятименә**
**Нинди генә тузан, кер тукмәгән!..**
**Якташлары, әмма шигърияттен**
**Саф алтынга тиңләп бөртекләгән.**
**Еллар әйләнәли җыен җыеп,**
**Сый-хөрмәтен куеп түр табынга—**
**Көрәш рухы белән дәртләндергән**
**Батырын да чорның, куркагын да.**
**Йә, әйтегез! Кайсы як моңсары**
**Тукай белән тигезләшә алыр?!**
**...Үз моңсарын танымаган якташ**
**Килгән иманын да кире кагыр...**
**Зевс Прометейны кадаклаткан сыман**
**Таш кыяга кадаклатыр нәсел-затың...—**
**Бер шаһитсыз, яклаучысыз, аклаучысыз:**
**—Мин гаепсез!—дип, әйтергә бармы**
**хакың?**
**«Азатлык!!!»—дип, утка ташланганнар белә:**
**Азат хезмәт—өлгер килен, киндер килен...**
**Рухташларын зурлый белгән затлар өчен**
**Ефәкләнгән киндерләргә тиңдер Илем!**
**Көр акыллы моңсарларның уй-гамәле**
**Тиңдер могҗизалы галәм гамәленә.**
**– – – – – – – – – – – – – – – – –**
**...Җир йөзендә тәмуг ачкан кара кяфер**
**Галәмне дә бәйләп тота хәраменә.**
**...Хак яраткан матурлык та, рух та безнең**
**Һәлак булды сатлык җаннар измәгендә...**
**Хәрабәләр, көлләр генә аунап калды**
**«Бөек шигърият»нең бәхет бизмәнендә.**
**Тукайҗанны өзелеп сөйгән Зәйтүнәнең**
**Керсез мәхәббәтен басты кара кайгы...**
**Мәхәббәткә гөрзи белән орган өчен**
**Афродита[1] елый-елый**
**хәлдән тайды...**
**Коръән белән бәйләнмәгән бер фән дә юк**
**Үрле-кырлы мәдәният дөньясында.**
**...Елан-елан булуыннан туктый алмый—**
**Патша булып кем торса да Ил башында.**

## Парчаланган өлгеләр

*Моң әҗерен кирәк диләр акларга—*
*Көнең-көткең, сүзең үткен чагында.*
*Шигырь сөйләп үрсәләнә шагыйрьләр*
*Җан-фәрманын тотып иман сагында.*

**...Көнчыгышта... Көнбатышындамы—**
**Әтиләрен өткән ут кайда?..**
**Сугыштан соң туган шагыйрьләрдә—**
**Якынаю көчле Тукайга.**
**Моңлы күңел күк гөмбәзе төсле:**
**Әйтерсең лә Арча парчасы!**
**Шаулап янган бакый гасырларның**
**Парчаланган моң бит—барчасы.**

[1] Афродита – мәхәббәт Алласы (грек риваятеннән)

Татарны бит борын-борынгыдан
Бизи: «моңлы, матур...»—дигән сүз.
Тормыш үзе матур—матурын да...—
Дошманнары гына иләмсез.
...Ошбу иләмсезлек инде... минем
Оныгымны тора сагалап...
Шуңа күрә елан турындагы
Кыйссам сөйлим аңа чамалап.
_ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _
Сөйлим кулга каурый-каләм алгач
Тәкъдир язып канатланганымны...—
Ил өстенә Кояш чыксын өчен
Тау күчереп газапланганымны.
Сөйлим тиңләп шигырь тудыруны
Җир астында галәм тудыруга.
Таң сулары белән хакыйкатьнең
Тирән хәтер күзен юдырырга.

***

...Хәтер күзе шөкер: аермачык!—
Яндык явыз белән кан алмашып,
Офык саен «якты кыйбла» ачып,
Җиде ятлар белән туганлашып.
Канда үзәкләшкән комсыз токым
Киеп алды биткә—кара битлек!..
Айсыз, кашагасыз ишекләрдә,
Тәрәзләрдә иңри тимер читлек.
Буыннар да инде тимерләнде
Хиссез кара күмер өемендә...
Алыпсатар алтын белән хаклый
Төкерекле сыңар тиенен дә...
Шунлыктанмы, әрнеп күзгә бага
Үз бәһасен җуйган бар тереклек.
Тик кызганыч: җуелганны даулап
Чаң сугарга тәүдә без өректек.
Чак-чак килми калган азатлыкка
Без чыгардык бары бәет кенә:
Язмышларның канлы тастымалын
Итәк өсләренә җәеп кенә...

**Редакциядән:**
***Шагыйрәнең бу айда түгәрәк юбилее. Аны олуг бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, иҗат уңышлары, исәнлек-саулык телибез!***

Рәфкать
Кәрами

# СӨЕП ТУЙМАС ЧАКЛАРЫҢ

РОМАН

## XIV

Ул тыныч күңел, күтәренке дәрт белән юлга чыкты. Әмма чираттагы ялының беренче көне үк күңелсезлек китерде. Июльнең егерме тугызы көнне, гөнаһ шомлыгына каршы, аларның самолеты очмады. Кичектерә-кичектерә көн узды.

Ләкин егет тулай торакка кайтып тормады. Чөнки барыбер иртүк киләсе бит. Аннары, анда сагынып торган кешесе, елап утырган баласы юк. Тулай торакта гомер сөргән егет-җилән дигән «асыл кош»ның хәле билгеле: «Кашым да күзем, маңгаем да үзем»,—дип кайда якты чырай күрсәтсәләр, җылы урын бирсәләр—шунда кунакларга өйрәнгән.

Тулай торакта көтәргә кешесе булмаса да, үз өйләрендә аны сөйгән яры сагынып утырадыр. Кызы янына барса була булуын, ләкин бер саубуллашып киткәч, бимазалап йөрисе юк. Бәлки сагынмыйдыр да. Өендә дә юктыр... Ул бит шәһәр кызы...

Шуларны уйлагач, егет монда гына калырга, төн уздырырга карар кылды.

...Ул залның икенче катында җайлап кына бер креслога чумды да кулына гәзит алды. Аннары урамда йөреп керде, тамак ялгады, янә урынына килеп утырды, сумкасыннан чыгарган китапка күзен текәде. Байтак вакыт укып күзе аргач, сәгатенә күз салды: стрелка секундларны саный, секундлардан минутлар җыела, ә соңгылары янә бер сәгать гомерне юкка чыгара. Әйләнә-тирәдәге юлчыларга бакты, уйлап куйды: кемнекен артка чигерә, ә кайберәүләрнекен алга куа.

Ике рәт тезелгән кресолоарда юлаучылар урнашкан: кемнәрдер туры утырып китап укый, икенчеләр гәзит-журнал актара, өченчеләр—йокы хәстәрен, ә дүртенчеләр инде төш күрә. Әнә бер ир-ат аякларын бөкләп утыргычта җайлашкан, пиджак белән башыннан ук бөркәнгән; янындагы ике баланың берсе аякларын салындырып, башын кыңгыр салып йоклый, икенчесе кыш чыгарга әзерләнгән суалчан кебек, креслода бөгәрләнеп яткан, үзе нидер чәйни; янәшәдә йомарланып утырган әниләренең башы салынып төшеп киткәндәй була да хатын дерт итеп уяна. Монда халык чуар: каланыкылар да байтак, саланыкылар да җитәрлек; әнә авылча киенгән, җитмеш яшьләр чамасындагы карт әледән-әле ютәлли; күршеләре—егет

*Ахыры. Башы 7нче санда.*

белән кыз—сөйләшеп утыралар, тыйнак кына көлешәләр.

Шулай тыныч кына тирә-юнен күзәтеп утырган егет кинәт катып калды: чөнки залга ике бала күтәреп ир белән хатын керделәр: озын буйлы, затлы киемле ир-ат күргән-белгән, күзенә чалынган кеше түгел, ә кыска җинле озын ак күлмәк кигән, зифа гәүдәле хатын... сөйгән да каплаган Рәйсәнә. Охшаса да охшар икән шулхәтле...

Габделнур, инде төн уртасы булганга, әллә йокымсырап киттемме дип, башын селкеп куйды, челт-челт күзләрен йомгалады. Юк, йокы исереклеге белән генә күзенә күренми, төш тә түгел. Бу нечкә билле, аяк башларын балериналарча як-якка каратыбрак атлаучы ханым Габделнур бер күрүдә үк гашыйк булган, яратып йөргән, аны Әлмәттә озатып калган Рәйсәнә иде. Ноябрьнең шыксыз бер көнендә, военкомат каршында, оялып кына аның кочагында торган һәм күз яшьләрен күрсәтмәс өчен йөгереп китеп барган асыл зат иде. Солдатның төн йокыларын качырган, хәрби хезмәтенең беренче көннәрдәге авырлыкларын җиңәргә, тешен кысып түзәргә булышкан, өзлексез хатлар яудырып торган сөйгән кызы иде. Әйе, йөреше дә, буй-сыны да, чәчләре дә... мине дә шул ук. Тик... аның кулында йокыга талган нарасый, янәшәсендә уртак сабыйларын һәм чемодан күтәргән ире бар.

Нидер йөрәген кисеп үткән кебек булды Габделнурның. Беренче талпынышы—тору һәм барып исәнләшү. Әле ярый үз-үзен тыеп өлгерде. Моннан ике ел элек хастаханә ишегалдында очраткан шәфкать туташының сүзләре исенә төште: «Ире бик көнче нәрсә... Хатыны баганага сөялсә, аңа да күзен акайта...» Керүчеләр, алан-йолан каранып, Габделнурдан шактый еракта, почмакта буш калган урыннарга урнаштылар.

Егет тиз генә китабын сумкага салып, баягы гәзитне алды, аны йөзенә каплап ук диярлек укырга кереште. Әмма хәзерге мәлдә аңарда уку кайгысы түгел. Бу—үзенне үзең алдарга маташу гына. Шуңа күрә укуы уку булмады: хәрефләр берсе өстенә берсе ябырылды, юллар пыран-заран килеп буталды, уй-фикерләр саташты-чуалды. Ул бернәрсә дә аңламады. Башына сулык-сулык кан бәрде, йөрәге дөпелдәгән аваз чыгарып типте. «Тынычлан, сабыр бул, карама, ул якка карама!»—дип үз-үзенә әмер бирде. Тик күңеле аны кабул итми, үтәмәскә азаплана, ниндидер яшерен көч башын «теге»нең ягына борырга чамалый...

Ә тегеләрнең чит кешеләрдә гаме юк: җайлап кына чөмәштеләр, иплəп кенә гәп корып җибәрделәр, оланнарның икесе дә әти-әниләре кулында йоклап та китте...

Егет, ара-тирә гәзит өстеннән яисә яннан караштыргалап, аларның ни-нәрсә турысында сөйләшүләрен, үзара нинди мөгамәләдә булуларын белергә тырыша. Сүзләрен ишетмәсә дә, бер-беренә ачу белән эндәшмәүләрен, елмаюлы йөзләрен күрә, ике арада дустанә, тату әңгәмә баруына, бер-беренә яратып-сөеп җылы карауларына төшенә. Теге шәфкать туташы тасвирлаганнан соң Рәйсәнәнең ире хакында аңарда ни өчендер тискәре фикер туган иде. Үзен күрмәсә-белмәсә, егет аны әле һаман да гел начар ягы белән генә искә алыр, сөйгән кызының шундый бәндәгә тап булуына пошыныр иде. Ә хәзер... Ул кеше бер дә хатынын җәберләүче, көнчел адәм, дигән тәэсир калмады. «Бәхетле генә булсын!» дип куйды егет. Әлбәттә, бу теләк Рәйсәнәгә атап һәм чын күңелдән әйтелде. Чөнки ул Рәйсәнәгә карата бернинди дә ачу сакламый, менә хәзер ике бәби анасы мөләем ханым буларак күргәч бигрәк тә.

Бер уйласаң, армиягә киткән егетләрен кызлар көтмиләр икән, димәк, сәбәпләре бар. Козьма Прутков әйтмешли, тамырына багып фикер йөртсәң, Рәйсәнә хаклы булып чыга бит. Кызга унтугыз тулып киткән. Авылдагы

«музыкан» бабай ничек җырлый иде әле: «Эскерипкә ни дип әйтә, мияу, мияу, дип әйтә, кызлар егермегә житкәч, кияү, кияү, дип әйтә». Әйе, авыл жирендә егерме яшь—нәкъ тормышка чыгар вакыт. Шәһәрдә саналса да, Рәйсәнә дә аның иске өлешендә, үз йортлары белән яшәде бит... Өлгергәч, җиләкне дә өзәләр, юкса ул кибеп корый башлый... Кайдадыр чит-ят җирләрдәге солдатны, мәхәббәт дип, ярату дип көтеп яту—җүләрлек. Сугыш вакыты булмаса да, хәрби техника, утлы корал белән эш иткәндә төрле хәвефле хәлләргә юлыгуы, мәтәвеккә әләгүе дә мөмкин (абыйлары авызыннан ишеткәне бар), димәк, синең утырып калуың да ихтимал. Өч ел эчендә егет күңелендә ни-нәрсә кайнаганын кем белә? Әгәр тегендә, мөмкинлек чыгып, берәр әрсез нәрсәгә ияләнсә, эшкә яки солдаттан кайткан егетләр әйткәнчә «макаронник» булып тагын хәрби хезмәткә калса? Кайткач та, сиңа өйләнәме әле ул, әллә юкмы? Чөнки артта яшьрәк, чибәррәк, чаярак кызлар буй җиткезә...

Уйлана торгач, егет, Рәйсәнә рәвешенә үк кереп, әнә шулайрак фикер йөртте. Аннары, яшь тән иркәләү-назлау тели. Бу—табигать кануны. Ташып-тулып торган дәрт-дәрманны кая куясың? Яшьлек чоры бер генә бит. Заяга узсынмыни? «Яшь гомерләр ике килми, сулар үргә акса да...»

Габделнур үзен Рәйсәнәнең ире белән янәшә куеп карый: ул кем дә, ире—кем. Күрәсең, хирург булгач, ире инде институт бетергән, аягында нык басып тора. Яше дә кызныкыннан кимендә өч-дүрт яшькә олырактыр (артыграк булмаса). Безнең халыкта гадәттә гаилә шулай корыла бит... Кыскасы, егет үз урынын ярыйсы ук чамалады: чагыштыру аның файдасына түгел иде...

Кисәк кенә ул үз-үзен орышып алды: «Нәрсә син һаман пычкы чүбен кисеп утырасың, ул бит инде киселгән—узган гомер кебек. Булган—беткән!» Ә юк, бетмәгән икән шул: әнә генә Рәйсәнә утыра бит... Рәйсәнә... Ничә ел гомер үтсә дә ул бер дә үзгәрмәгән, нәфислеген дә җуймаган... Роза чәчкәсе яныннан узып китсәң, кабат аны эзләмә, диләр. Әйе, ул—матур чәчәк, ләкин тиз шиңә. Габделнур Рәйсәнәне шул чәчәккә тиңли иде бит. Ә нишләптер ул бер дә чибәрлеген югалтмаган, һаман шул килеш. Бәлки шагыйрь хаклыдыр: ана булу аңа гүзәллек кенә өстәгәндер?!

...Күпме вакыт үткәндер, Габделнурның очы-кырые булмас кебек тоелган газаплы минутларына, берәмтекләп исенә төшергән хатирәләренә нокта куеп, репродуктордан хатын-кыз авазы яңгырады.

—Мәскәүгә очучы пассажирлар игътибарына...

Мәскәүгә игълан булгач, берничә пассажир урыннарыннан кузгалды. Рәйсәнә белән ире дә балаларын, әйберләрен күтәреп, беренче катка төшеп киттеләр. Габделнур җиңел сулап куйды. Бераздан ул, торып, бөтен диварны биләгән тәрәзә каршына килде. Очу кырына күз салды. Менә ак очкыч, юлчыларны утыртып (шул җөмләдән Рәйсәнәне дә), ерак сәфәргә әзерләнде...

Зур самолет сызгыра, усалланып үкерә, гүя кемдер, нindидер көчле куллар аны җибәрмичә тотып тора, ә очкыч отыры үҗәтләнә, усаллана һәм, ниһаять, кузгала... Гайрәтләнеп, гүләп күтәрелеп киткәндә әйтерсең лә җир тетри: тәрәзә пыялалары селкенә, зыңгылдый, дерелди. Юк, бу пыяла гына дерелдәме, ә егетнең йөрәге дә шулай сулкылдый икән... Көтү залындагы кайбер юлчыларны да уятырлык булып очкыч тавышы белән бергә аның йөрәге кага икән...

Егет, тәрәзәнең салкын пыяласына кайнар башын терәп, бинһая ярсулы йөрәге түреннән ингән аваз чыгарды: «И-их!» Нindидер үткен әйбер бәгырен телгәләп уздымыни?! Һәм шул мизгелдә үк күзеннән ике тамчы сытылып чыкты. Ул аларны тоймады да хәтта. Чөнки уйлары әле

генә күтәрелгән очкыч канатына сарылган иде. Аңа тагын очрармы Рәйсәнә кебек гүзәл фәрештә?.. Кисәк кенә Энже исенә төште, мөнәсәбәтләре күз алдына килде. Һәм беренче мәртәбә аның сөйгән кыз түгел, ә фәкать... йөргән кыз гына икәнен тәгаен аңлады. Бу гайре табигый булып тоелса да, күңелне, тойгыларны алдап булмый икән шул...

—Хәерле юл сиңа, яшьлек дустым!—дип эндәште Габделнур күккә карап һәм авыр физик эш эшләгәндәй арып-талып урынына барып утырды.

Тынлык. Ләкин күзенә йокы керми. Истәлекләргә бирелеп, егет залга карый. Ул ничектер бөтенләй бушап калган сыман. Югыйсә кеше күп. Әнә, эшләпәле башын артка ташлап, бер ир гамьсез йокыга чумган. Кызык, үзе йоклый, үзе тезендә ятучы баласын тоткан. Сабый исә изрәгән. Залда сирәк-мирәк креслолар шыгырдый, гырлау авазлары да ишетелә. Идәндә сумкалар, чемоданнар, балалар ботинкасы һәм сандалилар аунап ята. Такыр башлы абзыйның авызы ачык; бер хатын уянды һәм, торып, сабыеның өстенә япты... Әйе, залда кеше күп. Хатын-кызлар да бар. Ә Рәйсәнә юк...

Ә очкыч инде һавада... Мәскәүгә ашыга. Рәйсәнәне башкалага алып бара. Кая юл тотулары икән? Шунда гына туктарлармы, әллә ары китәләрме? «Күрәсең, ире отпускыга чыккандыр (Рәйсәнә тагын бәби белән утырадыр) һәм ял итәргә китүләредер».

Мәскәү дигәч, Аля исенә төште. Анысы кайда йөри икән хәзер? Нишли икән? Хәер, төнлә юньле кеше нишләсен инде, йокы симертәдер. Үзе генә микән? Ай-һай... Ятар алдыннан, аркаларын мендәргә терәп, һәр кич Гомәр Хәйямне укыйлар микән? Бәлки бүтән шагыйрьнедер...

Егеткә кинәт ниндер ямансу булып китте, йөрәге урыныннан кузгалгандай тоелды. Кирәк бит: башта Рәйсәнәне күрде, соңра Аля исенә төште. Нәрсәгә кирәк инде күңелен алгысытып? «Кичтән тулай торакка кайтып кына китәсем калган икән, —дип уйлады ул.—Иртән иртүк килеп житкән булыр идем. Әллә нишләп каласы иттем бит. Дөрес әйткәннәр шул, күрәчәкне күрмәенчә, кереп булмый гүрләргә дип...»

Яшьлек мәхәббәтен очратасын күңеле сизгәндер шәт, туасы көннең нинди булачагын, жир тетрәү кебек зилзиләләрне алдан тоемлаучы кош-корт, киек жәнлек кебек... Йә, күрде. Шуннан ни булды? Берни дә. Дөнья үзгәрдеме? Юк. Ул хәзер кеше кешесе, балалары бар. Ике уйлап, бер төшенә дә кермидер армиягә озаткан егете... Хәер, Габделнур үзе дә аны еш искә алмый бит инде. Кияүгә чыгуын әйтеп язган хатын алганнан соң күңеле катты, фотосын да ертып атты. Анысы яшьлек дуамаллыгы булды, билгеле. Торсын иде шунда альбомда, ашарга сорамый иде бит. Юк, ачудан тураклады, күземә күренмә, янәсе. Ә шулай да ул кыз күңел түренә кереп урнашкан, аякларын бөкләп дигәндәй утырган да һич кенә дә чыкмый... Беренче мәхәббәте—сары чәчле, зәңгәр күзле түбән оч кызы шикелле. Мәскәү дигәч, тегесе искә төшә... юкса, булган-беткән дип кенә әйтәсе. Ә юк, алай гына түгел икән, жиңел генә котыла алмыйсың икән бер бәйләнгән, багланышка кергән кешеләрдән. Хәтергә килеп, башыңны катыралар икән әле алар...

Габделнурның йокысы качты. Үзе уңга-сулга карый, кешеләрне күзәтә кебек, ә күңеле... Ул ничектер югалып калды. Гүя бокс уйный торган дүртпочмаклы, канатлар белән әйләндереп алынган рингка чыккан. Көндәше кисәк кенә һич көтелмәгән яктан, «сул ыргак» алымы белән аның башына бәргән һәм ул нокаут алган. Хәер, эш аннан язуга ук барып житмәгән икән әле: ул фәкать нокдаунда исәңгерәп ята. Чөнки хөкемдарның бер, ике, өч... дип саный башлаганын ишетә, үз акылында, зиһене—аек, аягында басып тора. Ә хөкемдар—Габделнур үзе... «Әһә, димәк, тормыш дигән спорт мәйданына—рингка чыккач, нокдаунга гына түгел, нокаутка

да эләгүең һәм салкын идәнгә чалкан төшүең ихтимал. Сак кылан, егет һәм... барысына да әзер булып тор. Шуңа да, «тормыш—ананңы ормыш, диләр аны. Тормыш—куласа...»

Кисәк кенә майның егермесендә кояш тотылуы исенә төште. Шунда ул, бәлки үземә кагылышлы берәр әһәмиятле вакыйга булыр, дип тә шикләнгән иде бит. Шушыңа булды микәнни? Бүгенге хәлләргә... «Ярар, җыен юк-бар белән баш катырмыйк әле»,—диде егет һәм гәзитенә капланды. Әмма... чуалган зиһенен сүтеп очына чыгарлык, бер-бер артлы агылган уйлар ташкынын туктатырлык түгел иде инде. Уйлана торгач, икенче төрлерәк тә фикер йөртә башлады.

Әгәр Рәйсәнә белән ара өзелмәгән булса, язмыш сукмагы кай тарафка таба кереп китәр иде икән? Анын янына кайтса, озын-озакка сузмыйча өйләнер иде. Бала туар... Укуы нишләр? Ул хакта онытып торырга туры килер идеме? Бәлки вакытлыча гына. Гаилә мәшәкатьләре җайга салынгач, көйләнгәч, ул турыда да уйлап карарга булыр иде. Бәлки шул тирәдәге берәр уку йортына тәгаенләр иде. Әгәр анда вуз булса... «Кызык икән бу тормыш, шул хәяттагы синең язмышың,—дип уйланды егет.—Юллар күп. Унга китсәң—бер төрле язмышка дучар буласың, сулга борылсаң—бөтенләй икенчеләй. Кызык, нәрсәгә бәйле икән ул? Моны кеше үзе хәл итәме, әллә шартлармы? Икесенең дә катнашы бар шикелле. Ә аны алдан белеп буламы? Авылда, безнең өйгә кергән бер чегән карчыгы миңа, читкә китәсең, дигән иде. Миңа ул чакта унөч булгандыр. Ундүрт яшемдә мин сәфәр чыктым—туган йортымнан китеп бардым... Шуннан бирле беркайчан да багучыга кулымны тоттырганым булмады. Бирмәм дә. Хәзер нәрсә әйтерләр иде икән? Язмышыңны алдан белү кызык түгелдер мөгаен... Тик шулай да адәм баласына гомер бер генә бирелә. Ни кызганыч, ул аны кабатлый һәм төрлечә яшәп карый алмый. Фәкать бер генә тапкыр һәм бер генә төрле итеп гомер сукмагын уза... Ни аяныч...»

## XV

Икенче көнне иртән, сигезенче яртыда, аңа да бәхет елмайды: кечкенә самолетка утырып, Габделнур туган якларына юл алды.

Габделнурның уйлары үзе утырган самолет очышы кебек—тигезле-тигезсез агыла. Кичә яшьлек мәхәббәтен күрү аны бик нык дулкынланырга мәҗбүр итте һәм шул очрашу тәэсиреннән әле һаман айный алмый. Бер уйлаганда бу очрашу егет кеше тормышында гап-гади вакыйга булырга тиеш иде кебек. Ә юк, алай булып чыкмады шул. Күрәсең, бик озак вакытлар тинтерәтәчәк икән әле аны Рәйсәнә хакындагы уйлар.

Аны да самолет алып китте. Ләкин ул утырган очкыч Габделнурларныкы ише генә түгел—зур иде, пассажирларын «кукурузник» кебек селкетеп-борчып интектермәгәндер. Алар йомшак креслоларда тыныч кына утырып, һич югы тирбәнеп кенә барганнардыр. Рәйсәнәнең йөрәге дә Габделнурныкы сыман ашкынып-ярсып типмәгәндер—егетне бөтенләй күрмәде бит. (Дөресе—егет үзенең шул ук залда икәнен аңа белгертмәде.) Бәлки мәхәббәт, сөю-сәгадәт мәсьәләсе хәзер аны борчымыйдыр да—дөньясы түгәрәк: янәшәсендә, карчыклар әйтмешли, никахлы ире—таянычы һәм нарасыйлары—юанычы; берсе һичшиксез анын алдында ятып баргандыр.

Әгәр кичә сөйгәнен күрмәгән булса, егет тыныч кына туган төбәгенә юнәлгән булыр иде. Әлбәттә, яшь күңел буш торуны өнәми, соңгы вакытта анда Казан кызы урын алган. Бүген исә—икәү булдылар. Әйе, егет күңелендә үлмәс кош Феникс кебек янә Әлмәт кызы калкып чыкты. Хәер, калага кайткач, Рәйсәнә акрын-акрын онытылыр, аның нурлы йөзе тоныкланыр, ак күлмәкле сылу гәүдәсе ак томан эченәрәк керә барыр да шунда эреп

югалыр. Чөнки Казан кызы да зифа, төскә-биткә дә ярыйсы. Ләкин... ул—башка, ул—серлерәк, егеткә тәмамысы ачылып та бетмәгән шикелле, аның белән мөгамәлә бүтәнчә, аның холкы-фигыле, тәрбиясе үзгәрәк, кызның егеткә булган карашы да икенчерәк—үзен өстен итеп күрергә гадәтләнгән. Ә Рәйсәнә андый түгел иде һәм бүген ул үзенең бөтен гүзәллеге, инсафлыгы белән егет күңелендә кабат пәйда булды.

Габделнур, мончу уйларыннан арынырга теләп, түгәрәк салкын пыялага кайнар маңгаен терәде һәм аска таба бакты. Ә анда күзеңне алалмаслык, карап туйгысыз гаҗәеп манзара: яшькелт болын-кырларга киң җәелеп, бормалы-бормалы булып агып ятучы зур елга суы кояшта көзгедәй ялтырый; үз артыннан үрдәкнекедәй чөй сыман эз калдырып йөзүче баржаларның рубкалары елык-елык килә; су өстендә хәрәкәтсез калган бәләкәй генә көймәләр шәйләнә... Аларны югарыдан да ямь-яшел булып күренүче урманнар алыштыра. Саргылт иген басуының арышы егып ташланган ахры—тигезле-тигезсез покослар ята, арырак—гүя шырпы капларын тезеп куйганнар—салам эскертләре...

Рәйсәнәгә бәйле рәвештә Габделнур үзенең бала чагын, борынына ис керә башлаган көннәрен хәтерендә янартты: түбән оч, таллык, мал саклау, кичке уеннар...

Шунда беренче тапкыр кыз баладан:

—Минем белән йөрисеңме?—дип сорады бит.

Ул мөрәҗәгать иткән кыз түбән очта яши иде. Сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, күпереп торган матур алсу иренле. Әлбәттә, Габделнур—алтынчы класска күчкән малай—әле аны ни өчен ошатуын (яратуын дип әйтергә иртәрәктер) юньләп аңламагандыр да. Хәзер, инде байтак еллар узгач, шактый гына дөнья гизеп, кыз-кыркын белән аралашкач, уйлап куя: ни өчен ошатты икән? Мөгаен, иң беренчесе—төс-бите өчендер (гәрчә, үсмерләр әниләренә охшаган кызларны сайлыйлар дисәләр дә, бу очрак ул кагыйдәгә сыешмый, әнисе—кара чәчле), икенчесе—яхшы укыганы өчендер, өченчесе—чаңгыда шәп шуганы өчендер? (Ә кем белгән аны кемнең кемгә ни өчен ошаганын?!) Ул кыз Габделнурлар белән түгел, ә параллель класста укый иде.

...Алар—берничә кыз—сыер саклыйлар. Аның өстендә зур гына бишмәт, аягында күнитек (абыйсыныкы булды микән), башына җылы яулык бәйләгән.

Габделнур аның кулыннан тотты да:

—Минем белән йөрисеңме?—дип сорады.

Кыз ике уйлап тормады, җавабы катгый булды.

—Юк.

Бала-чага дими, ни дисең инде.

—Нишләп?—дип сорады малай.

—Белмим.

Кыз кулын ычкындырды да торып йөгерде. Малай аны куа башлады, җиңеннән эләктерде. Кыз тагын кулын тартып алды. Ләкин бу юлы еракка китмәде, кырт борылып, кабат элекке урынга—үзләренең сыеры янына кайтты. Ә анда кызлар чыр-чу килеп бөтен болынны яңгыраталар, чөнки бүтән малайлар да кызлар белән куышалар иде...

Алтынчы-җиденче классларда мәктәптә оештырылган әдәби кичәләрдән соң кызларны капка төпләренә хәтле озату гадәткә кереп китте.

Борыннарына иртәрәк ис керүнең сәбәбе—алар белән ике-өч яшькә өлкәнрәк малайлар укуда булгандыр, мөгаен, берсе хәтта дүрт яшькә олы иде бит.

Ни өчен яшь аермасы шулай зур булган?

Ул заманда балаларны сыйныфтан сыйныфка күчермәү кебек яман кагыйдәгә буйсыну бар иде. Ә ни өчен укучыларны, авылча әйтсәк, икенче елга утыртып калдыралар? Чөнки кайсының белеме түбән, кемнеңдер тәртибе мәктәп кысаларына сыешмый, ә күпчелек очракта—күпләп дәрес калдырган өчен. Соңгысы исә ачлык-хәерчелектән, сугыштан соңгы мохтаҗлык-фәкыйрьлектән килеп чыга: ни тамак туклыгы итәргә ризык юк, ни өскә кияргә кием юк—бала-чага, бик теләсә дә, мәктәпкә юньләп йөри алмый. Нәтиҗәсе аяныч—күчми калу—димәк, унике-унөч яшьлек үсмерләр белән янәшә унбишен-уналтысын тутырган «җиткән җегет»ләр дә укый. Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, олыраклар мисалы—бәләкәйләргә үрнәк—зурдан кубып кызлар белән йөрмәкчеләр... Ә Габделнур кемнән ким?..

...Габделнурның бу кайтуы маҗарасыз, тынычрак үтте. Дусты Касыйм өйләнгән, аңарда хәзер, кем әйтмешли, клуб кайгысы юк—хәләл җефете янында гына. Хәер, механизатор өчен вакыты да ул түгел—уттай урак өсте.

Беренче көнне үк зиратка барган иде, кәефе кырылып кайтты: исерек баштан тракторы белән капланган бер чордашының каберен күрде (ул фаҗигане Габделнур ишеткән иде инде). Әмма аның гүр иясе булганын үз күзләре белән күрү бик авыр тәэсир калдырды.

Икенче көнне кунак ныклап эшкә тотынды, чөнки әтисе әбисенең өен янарту хакында ике авылдашы белән килешкән. Аларның берсе бик күпләрне өйле итеп куандырган өлкән яшьләрдәге балта остасы, ә икенчесе Габделнур солдаттан ялга кайткач үзенең «Дружба» пычкысы белән Галләм абзыйның утынын турап биргән Шәйхетдин иде.

...Өченче көн көндезге аштан соң, осталар тәмәке пыскытканда Габделнур алар янында утырды: олылар сүзенә колак салды, үзе дә әңгәмәгә кушылды. Кичә, чалкан төшеп, ишегалдындагы чирәмгә ятты да күк йөзенә карады: ул чип-чиста, зәп-зәңгәр, очсыз-кырыйсыз—фәкать аның туган авылында гына шундый матурлык буладыр төсле тоелды. Кайчагында аксыл болытлар агыла—алар әллә нәрсәләргә охшыйлар, самолет эз салып узып китә. Вакыт сыйдырса, ул шулай сәгатьләр буе, хозурланып, туган авылының тансык саф һавасын сулап, күңелгә-җанга таныш авазларга колак салып, озаклап-озаклап назланып дигәндәй ятар иде. Әмма... эш итәктән тарта: осталар, тәмәке төпчекләрен сүндереп, акрын гына кузгала... Бүген исә, урамга чыгып, ике калын таш өстенә сузып салынган кыска юан бүрәнәгә утырып тора иде. Габделнурның әбисе янына күрше карчыгы кереп килә. Егет торып басты, исәнләште. Карчык капкадан тиз генә кереп китмәде—әйтер сүзе бар икән.

—Үскәнем, сина рәхмәтләр яусын инде, отпускыга кайтып, ял итмичә, осталарга булышып йөрисең.

Егет сүз озайтып тормады, елмайды, мактауны колагы яныннан гына уздырды.

—Түти, үзегез ни рәхәтләрдә яшәп ятасыз?

—Бер көе, үскәнем. Әле Әзәрбайҗаннан кызым кияве белән кайтып киттеләр, рәхмәт төшкерләре. Баламны бик сагынганыем, әзрәк күңелем басылды.

—Шулаймыни? Күптән кайтканы юк иде бугай. Аның хәлләре ничек соң?

—Ничек дип, апаем, чит җирләрдә тилмереп ята инде. Алты баласы бар. Тагын табар инде. Анда корсак төшерү юк икән бит, өй саен ишле бала ди.

Күрше карчыгының ул кызы Габделнурдан бер яшькә генә олы иде.

«Уналтыда кияүгә чыкты бугай. Ай-яй,—дип үзалдына баш селкеп куйды егет.—Ел саен бер бәби алып кайткан түгелме соң? Хәер, анысы алар эше».

—Анда жылы як бит, рәхәттер.

—И апаем, чит жирдә—эшлисен, үз жирендә—яшисен ди торган иде минем ирем. Ул да синен атаннар белән бер-ике ел шахтада эшләп кайтканые. Читтәге рәхәтлекне әйтмә инде...

—Әле телен онытмаганмы соң?—дип сорады Габделнур.

—Югын-юк та... Мин үлгәч кайтмас та инде... Балалары безненчә белми, ди. Каян белсен. Аналары да алар белән татарча авыз тутырып сөйләшә алмый бит. И апаем, никләргә генә киткәндер инде жәһәннәмгә?! Монда да яшәр иде әле матур итеп. Кызым бик эшчән, кайткач та тик утыра белмәде, бөтен эшемне ул эшләде, рәхмәт төшкере.

Габделнур, күрше карчыгының чиста өс-башына карап, элек-электән аны белгәнлектән, анын үзенен дә бик унган кеше икәнен искәрде.

Күрше карчыгы, эшләгән кешенен кадере бар хәзер, дип, мисаллар китереп, кызынын авылда калган чордаш-ахирәтләре ничек яшәгәнне санап үтте.

—Әнә дус кызы авылда калды, сыер сава, ире комбайнда. Жир жимертеп эшлиләр, уч тутырып акчасын, күрәп дигәндәй ипиен алалар. Әле генә иренә орден бирделәр, чүт кенә герой исеме эләкмәгән, ди, анысын күрше авыл комбайнерына биргәннәр, ди.

Ул турыда Габделнур да газетадан укып белде һәм бик горурланган иде.

Аннары карчык авыр сулап, әйтеп куйды.

—Ходайдан узып, берни эшләр әмәл юк, ризык йөртә бәндәне, ризык кайда—бәндә шунда.

—Түти, сез яшь чакта да безнен авыл кызлары шулай еракка, чит кавемнәргә китәләр идеме?

—Булды инде. Бер дус кызым төркмән егетенә чыкканые. Мары дигән шәһәрдә торалар. Ничә елдыр инде, хәтерләмим, бер кайтканые, гел алар кешесе булып беткән—кара чутыр, теле дә көтекләнеп беткән.

—Түти, ә сез кияү белән ничек анлаштыгыз сон?—дип сорады егет.

Күрше карчыгынын жыерчыклы йөзенә елмаю чыкты, кеткелдәп тә алды.

—Ул үзенчә пупалый, мин үзебезчә әйтәм, анламаганын кызым төшендереп бирә.

Аннары карчык өйгә кереп китте.

Нибар әрнүләрен әйтеп бетермәсә дә, тугыз бала үстереп, хәзерге көндә берьялгызы каңгырып яшәүче ана кешенен хәлен яхшы анлый иде кунак егет. Дөрес, ана кызын табаламый, үзе каршында үзе гаепле сыман, язмышына буйсынып яши.

## XVI

Күк йөзе түбәнтен генә агылучы янгыр болытлары белән капланган. Көчле, аяусыз жил аларны зур тизлек белән көньяк-көнбатышка куа, зифа талларны, нәзек камышларны жиргә кадәр индерә. Яшь тупыл агачы, арган кеше кебек, башын түбән ия дә, аннары күкрәк киереп сулар өчен күтәрелмәкче була, әмма усал жил аны шундук кире бөгә, агач як-якка чайкала, селкенә, карыша, тик турая гына алмый. Рәхимсез жил хәтта алабута һәм үләннәрне дә кызганмый.

...Авылдан килгәч, Габделнур, көне-сәгате белән дигәндәй, Мәһрүсә апаларына китте. Әнисе биреп жибәргән күчтәнәчләрне исән-имин,

күптин-күп сәламнәрне түкми-чәчми тапшырды. Бераз вакыт чәй янында Мәһрүсә апа, кызы—өчәүләшеп гәп кордылар. Габделнур сеңлекәше өчен бик сөенеп утырды. Чөнки кыз техникумда укуын да әйбәт кенә алып бара, өй эшләрен дә үзбелдеге белән җиренә җиткереп башкара, әнә әнисенә подъезд юышырга да булыша. Мәһрүсә апа, пенсиядә булса да аңа карап тик утырмый: иш янына куш булыр дип, идән юарга алынган.

Алардан кайтышлый егет Энҗеләргә сугылды. Ләкин ул өйдә юк икән.

—Ял йортына китте шул,—диде чуар күлмәк өстеннән яшел камзул кигән әбисе.—Кер, улым, өйгә кер.

—Ярар, ул булмагач, кереп тормыйм инде.

Габделнурга һәрчак ачык йөзле, хәерхаһлы әбекәйнең егетне ишек катыннан гына җибәрәсе килми иде, күрәсең.

—Чәй эчеп китәрсең.

—Рәхмәт.

—Атаң-анаң таза-саулармы соң?

—Әйе.

—Ярар алай булгач. Үзең исән йөре,—дип карчык аңа хәерле юл теләп калды.

Төшенке күңел белән тулай торагына кайткан егет менә хәзер, урамга карап, бүлмәсендә утыра. Ирек эштә күрәсең, Габделнур аэропорттан кайтканда өйдә юк иде.

Август ахырына һич кенә охшамаган ямьсез көн. Бүлмә салкын. Җил тәрәзә рамнарына хәтле селкетә, шак-шок бәрә, эре панельле йортның әллә кай җирләреннән тишекләр таба—өйгә үтеп керә; куллар, аяклар туңа.

«Кызык икән бу тормыш: кайчагында һәр эш-гамәлең тоташы белән уңай—майлаган арба тәгәрмәчедәй шома гына бара, ә кайвакыт дегет әсәре күрмәгәндәй шыгырдый—бөтен нәрсә синң кире ягы белән борыла,—дип уйлады Габделнур томан аша чак кына күренгән шәһәргә—Энҗе яшәгән бистәгә таба карап.—Ял йортына китеп барган. Сиздереп тә куймады югыйсә. Яна торган путевка булды микәнни?»

Менә тәрәзәгә кыйгач яңгыр тамчылары килеп бәрелде, өлгедә сызыклар хасил булды. Алар бер генә яклы түгел, ә төрлесе-төрле тарафка караган—өзек-өзек—штрих кебек. Кайбер тамчылар шул килеш кала: таралып та китми, аска таба да агып төшми.

«Сөйсәң—әрәм, ташласаң—җәл, дустым, сине нишләтим?» Кичке уенда кызлар шаяртып шулай дип җырлыйлар иде. Әйе, кайчагында кеше шундыйрак хәлләрдә дә, ягъни, аптыраашта да кала торгандыр мөгаен. Нишләмәк кирәк...

Яңгыр тамчылары, күбәйгәннән-күбәеп, берөзлексез пыялага бәрә һәм, кеше битендәге күз яшьләре кебек эз калдырып, түбәдән дә шап-шоп коела. Соңгыларына җиргә төшәргә ирек бирмичә җил аларның юнәлешен үзгәртә һәм ачу белән калайга китереп бәрә.

Туган авылында үткәргән ямьле, кояшлы көннәрдән соң шушы мәхшәргә тап булуын егет җылы комлы ярдан салкын сулы ярсу диңгезгә килеп кергәндәй хис итте: менә-менә дәһшәтле, таудай дулкыннар өстенә авар шикелле...

Яңгыр булуга карамастан, һавада түбәнтен генә күгәрченнәр оча. Малайлар футбол уйный торган урын тоташ суга әйләнеп яктырып киткән. Анда бер үсмер велосипедта чаба. Ә каршыдагы (алар йортыннан читтәрәк) бәрәңге бакчасында кызыл яулык бәйләгән, өстенә көзге пальто кигән бер апа, чүгәләп, яшь бәрәңге сайлый ахры: уң кулының бармакларын җиргә батыра да сул кулына тоткан чиләгенә үрелә, аннары янә җирне кармаларга,

актарырга тотына (Габделнурнын әнисе дә уллары кайтса яшь бәрәнгегә чыга торган иде); әллә ява янгыр, әллә юк—ана өчен барыбер, чөнки гаиләне сыйлыйсы-ашатасы бар...

Әйе, көйлеме ул, көйсезме—тормыш дәвам итә. Сиңа да, егеткәй, алҗыган кешедәй кул кушырып, боегып утырасы түгел. Җаның сыкравын сыкрар инде, монысы бәхәссез, аннан беркая да качып котыла алмыйсың, ләкин Энҗе өйдә юк дип кенә яшәеш тукталмый бит әле. Җәһәннәмдә түгел: кайтыр, күрерсең, сөйләшерсез, анлашырсыз да кабат матур гына йөреп китәрсез—очрашуларны янартырсыз. Башбирмәс кыз белән бәйләнгәнсең икән—һәрнәрсәгә, аның һәр капризына әзер бул.

Кайсыдыр бүлмәдән музыка агыла башлады. Көчле итеп радионы ачканнар булса кирәк: скрипка ниндидер моңлы көй суза, аңа калынрак тавышлы виолончель елап-шыңшып кушыла.

—Нәрсә мәлҗерәп утырам соң әле мин?!—дип сикереп торды да Габделнур караваг астыннан баянын тартып чыгарды.

Егетнең кәефе начар, күңелсез, бигрәк тә ялгызын булсаң... Хәтта сердәше-баяны да нигәдер туктап калды...

Кинәт кенә егет уйлап куйды: «Кайсы ял йортында икәнен сорамадым бит. Бәлки якын-тирәдә генәдер. Янына барып кайтыр идем. Хәер, әбекәй белмидер дә кая киткәнен, исеме дә хәтерендә түгелдер мөгаен. Аннары, артыннан эзләп йөргән шикелле була түгелме? Ошатамы әле синен килгәненне, юкмы—билгесез».

Яңгыр тамчылары җиргә туры гына төшә алмый, көчле җил аларны үзе белән әләктереп алып китә дә кар бөртекләредәй һавада очыртып йөртә. Яңгыр көчәйгәннән-көчәя, җил дә улый.

Август ахырында мондый күренеш сирәк күзәтелә торгандыр. Һәрхәлдә, Габделнур хәтерләми. Аның да бит язмышында бүгенгедәй хәлләр сирәк иде, бәлки әле бөтенләй дә булмагандыр. Аэропортта Рәйсәнәне күргәч егеткә әллә нәрсә булды. Күңел төшенкелегеме бу, яшьлек дустын сагынуымы, аның белән кавыша алмавына үкенүме—тәгаен гына әйтеп бирүе дә кыен. Ни генә дисәң дә бу аның өчен гадәти халәт түгел. Исенә төште: сөйгәненең соңгы хатын алгач, шулай авыр булган иде. Гаскәри хезмәттәше Иозас Заранка белән клубка танцыга баргач, Рәйсәнәгә ачу итеп, Зояга ияреп китте, шунда беренче тапкыр чын ирләрчә хатын-кыз назын татыды...

Хәрби хезмәт турында уйлагач, тагын бер әйберне искәртте: туган якларына ялга кайтып килгән солдатларның гаскәри тормышка кабат күнегеп китә алмыйча ничек интегүләрен, җәфа чигүләрен күз алдына китерде. Хәзерге минутларда ул үзе дә шундыйрак халәттә иде ахрысы...

Һәм ул, күңеле вәсвәсәгә, юк-бар уйларга бирелмәсен өчен, китапларын барлый башлады. Чөнки аны алда бихисап имтихан-зачетлар, контроль эшләр, семинарлар көтә.

Кичен соң гына Ирек дежурстводан кайтты. Күрештеләр. Ул кием алыштырып, юынып кергән арада Габделнур чәй кайнатты, авыл күчтәнәчләрен чыгарды.

—Нихәлләр?—дип сорады дустының суырылып калган йөзенә карап.—Әйдә, утыр.

—Берәү, ... кыл да сыймый, балта сабы буш, дип әйтеп әйткән ди. Шунын шикелле, безнең дә утырып торырга вакыт юк, көне буе чаптык. Бөтен бүлек аяк өстендә.

—Ни булды?

—Кичә ике инкассаторны бәргәннәр.

—Кайда?

—Воровскийда «Көз» кафесы бар бит әле...

—Әйе.

—Шуның каршында. Пистолетлар белән коралланган ике егет, тегеләрне атып үтергәннәр дә, алтмыш мең акчаны эләктереп качканнар.

—Ничего себе! Алты «Волга» машинасы бит ул!—дип баш чайкады Габделнур.—Тоттылармы соң?

—Юк. Бик чиста эшләгәннәр, әлегә эзләренә төшә алмыйлар.

—Мондый хәлнең күптән булганы юк иде бугай?

—Әйе.

Шул хакта бераз сүз куерткач, шәхси мәсьәләләргә күчтеләр.

—Үзеңдә ниләр бар? Мәхәббәт фронтында...

—Анда бер көе. Яңалык әйтимме?

—Әйт. Яхшымы, начармы?—дип елмайды Габделнур.

—Мине оператив бүлеккә кодалыйлар.

—Оһо! Ризамы соң?

—Әйе. Иртәгәдән күчәм.

—Йолдыз да бирәләрме?

—Әлегә бераү генә.

—Житеп торыр. Микро булса да—майор бит.

Икесе дә рәхәтләнеп көлделәр. Уку, эш, авыл, кызлар турында сөйләшә-сөйләшә бер «акбаш»ның да башына життеләр. Соң гына яттылар.

...Габделнур эш урынына—жир асты коммуникацияләре участогына килде. Хезмәттәшләре белән күреште, прорабскига кереп, ялдан чыгуын белдерде.

Шул вакыт участок башлыгы да күренде. Ул будкадагыларның барысы белән исәнләште дә телефон төбенә утырды. Аның авыр гәүдәсеннән урындык ыңгырашып куйды. Өлкән прорабның кыяфәте төксе, йөзе ачулы, салынган кашлары тагы да аскарак төшкән кебек, ачудан тешләрен шыгырдата, бүлмәдә хатын-кыз булмаса, аты-юлы белән сүгенүдән дә тартынмас иде.

—УМ-1 ме? Начальник кирәк! Юкмыни?..

Ул трубканы шапылдатып оясына ташлады. Алдындагы кәгазьгә нидер яза башлады, ләкин кисәк кенә аны читкә тибәрде. Янә трубкага үрелде һәм төзү идарәсенә шалтыратты.

—Кызлар, телефонограмма кабул итегез әле. Әйе, «УМ-1 башлыгына. Строймеханизация тресты управляющиена. Бульдозер номер 15-06 ике көн эшләми, тракторист исерек. Трубоукладчигының механизаторы эшкә чыкмаган. Уналты тонналы кран номер 15-53 трубоукладчик булмаганлыктан ике көн тик тора. Алар аркасында монтажниклар бригадасы эшсез утыра. Колонналар китертә алмыйбыз.

Идарә башлыгы һәм баш инженер». Әйе, шулай дип языгыз. Алар исеменнән китсен.

Трубканы куйгач, ул башта прорабка мөрәжәгать итте, агымдагы эшләр хакында сөйләштеләр. Аннары хоздесятницага бригадирларны чакырырга кушты.

Участок башлыгының электрикка әлегә йомышы юклыгын күреп, Габделнур ишеккә таба атлады. Урамда аны мастер туктатты. Өлкән прорабның зәһәренә эләкмәс өчен ул бая ук шыпан-шыпан чыгып ычкынган иде.

—Сиңа мастер фондыннан премия яздык,—диде ул.—Барып ал.

—Рәхмәт.

—Рәхмәт—сыек әйбер түгел, авызга салып булмый,—диде мастер һәм көлеп жибәрде.—Шаярттым гына. Ялдан чыккан кешегә ярап торыр.

—Әйе, дөрес әйтәсең.

Мастер бүген башкарыласы эшләр, якын көннәрдә бригадаларга кирәк буласы электр җиһазлары турында сүз башлады.

Шулай итеп, Габделнур атналар, айлар буена сузылачак эшенә-вазифасына кереште.

## XVII

Габделнур гражданкада, ягъни тыныч тормышта, өченче Яна елын каршыларга әзерләнә. Тыныч тормыш дигәнен куштырнаклар эченә алу дөрес булыр иде, чөнки аның мондагы яшәеше гаскәри хезмәттәгенә караганда да тынгысызрак—бер минут та дияргек буш вакыты юк. Атнасына алты көн хезмәт—анысы мәҗбүри, шуның өстенә төрле җыелыш, фәлән-төгән—җәмәгать эшләре. Коммунист булгач алардан да баш тартырга хакың юк, сылтау табып качып та китә алмыйсың. Тагы да мөһимрәк вазифасы—уку. Анысы да конвейерга салынган кебек: әле генә җәйге сессия бетте, кышкысы—борын төбендә. Декабрь уртасында латин теленнән зачет «эләктерде», ай ахырында—КПСС тарихыннан һәм немец теленнән. Гыйнварда археология нигезләрен «кимереп» имтихан тотасы, СССР һәм ТАССР тарихыннан зачет бирәсе. Иншалла, ерып чыгар төсле—кулыннан китап төшми.

Ә Яңа елны барыбер кешечә каршыларга кирәк. Тик нигәдер бу арада күңеле тыныч түгел. Ул еш кына тәрәзә каршына баса да Энҗе яшәгән якларга күз сала, озаклап карап тора. Менә бүген дә кичке сәгать тугызлар тирәсендә, карашын шулай алга төбәп, уйланып тора. Егет яшәгән йорт иң кырыйда, аннан соң сазлык, болын башлана. Монда кайчандыр урман булган булса кирәк: әле хәзер дә түмгәкләр калкып күренә, камышлар, таллар үсә; элегрәк торф та чыгарганнар. Соңгы елларда исә кешеләр, бакча ясап, бәрәңге, яшелчә үстергәннәр, кайберәүләр карлыган, алмагач та утырткан. Һәм, әнә шуларны кысрыклап, Восстание урамы ягыннан берничә йорт салганнар, бу урамны Коллективная дип атаганнар.

Габделнурның хәтерендә: җәй көне монда бакчада эштән кайткан ир-атлар, хатын-кызлар кайнаша иде, көзен кичке ашка бәрәңге алып кера башладылар. Егетнең күңеленә хуш килгән бер кыз еш күренде: кызыл свитер, көрән итәк кигән, әтисе казый, ул иелеп бәрәңге чүпли. Габделнур аны буй-сыны белән Энҗегә охшата һәм ничек эшләвен озаклап карап торырга ярата иде. Ә менә Энҗенең шулай бәрәңге җыеп йөрүен күз алдына китерә алмый. Аннары карашы алга, еракка төбәлә, чөнки анда йөргән кызы яшәгән бистә. Ә арырак Казансу елгасы, аның артындагы калкулыкта чал Кремль, Бауман һәм Совет районнары территориясе.

Кайчагында егетнең башына шундыйрак хыялый уй да килә: аучылар, балыкчылар (алар Казансуда да эчкәрәк кереп кармак салалар) кия торган озын кунычлы резин итекләр белән лачтор-лочтыр сазлык ерып, Энҗеләр яшәгән йортка хәтле барып чыгасы иде. Нәрсә дияр иде икән? Көлеп кенә куяр, әллә ни исе китмәс...

Ләкин хәзер бу тирәләр шактый үзгәрде, тормыш-яшәеш кебек туктап тормый, гел алга бара. Беркөнне, уң кул якта, бакчалардан читтәрәк, тракторлар күренде. Алар торба суза башладылар.

Ул көнне Энҗе Габделнурда кунакта иде. Кыз аптырап:

—Алар нишләмәкче була?—дип сорады.

—Сезнең бистә аша Казансуга торба сузып, су кудырачаклар.

—Нигә? Монда су болай да житәрлек бит. Артыгы белән...

—Ул—комлы-чуерташлы су. Бу тирәдә йортлар булачак,—диде егет бик белдекле кыяфәт белән.—Балчыкны, комны машиналар белән ташуга караганда елгага земснаряд кую арзангарак төшә. Монда әле юл да, күпер

дә булачак: Совет районы белән Ленин районы тоташачак.

—Ә син боларны каян беләсең?—дип сорады Энҗе ышанып җитмичәрәк, ә күзе үзләренең йортын эзләде; тик күпме генә караса да таный алмады.

—Беркөн механизаторлар белән сөйләшеп торган идем,—дип җаваплады егет һәм бераз хыялга бирелеп алды.—Менә күрерсең: үтәр еллар, сезнең тирәдә үз йортлы кешеләр калмаячак, барысын да күчереп, анда биек таш пулатлар салырлар...

—Һи, әле ул кайчан була...

Кем белгән аның кайчан буласын, Габделнур да әүлия түгел, шәһәр башлыгы кәнәфиендә дә утырмый. Эш дәвам итә: башта кечкенә чокырны тутырдылар,—вак таш белән комны бульдозер этә торды, аннары, зур бульдозер килеп, күпсанлы куыш-сарайларны җимерә башлады. Дөрес, моны, ягъни трактор киләсен, хуҗалары белгән булырга тиеш: кайсылары такта куптарырга кереште, кайберәүләр, этләргә калмасын, беркемгә дә тәтемәсен, диптер инде, ут төртә башладылар, бер абзый, төбе тирәли казып, алма агачы суырып чыгарды.

Габделнур (җиргә күмеләсе үсентеләрне җәлләп) түзмәде, тиз генә аның янына чыгып, рөхсәт сорады.

—Берсен алсам ачуланмассызмы?

—Ал, ал, миңа бу да җитә,—диде абзый.—Мә кирәк.

—Рәхмәт.

Егет бер яшьрәк агачны казып алды.

—Их, әрәм булалар,—диде агай йөрәк әрнүенә түзә алмыйча һәм егет кирәкне кире биргәч, агачын күтәреп, китеп тә барды.

Габделнур алмагачны шул сәгатендә үк Энҗеләргә илтте, чокыр казып, бөтен шартын китереп, утыртып та куйды.

Яшьлектә шулай булырга тиештер инде, күрәсең: ни генә уйласа да егетнең фикер сөреше чуалган кызына таба борыла, аңа барып тоташа. Әнә хәзер дә, тәрәзәгә карап торганда да, уйлары һаман Энҗе тирәсендә бөтерелә бит.

...Жир өстеннән сазлык буйлап торбалар суздылар һәм су катыш ком, чуерташ ургылып-ургылып ага башлады. Юан торбадан аккан бу ташкын төнлә дә гүләп торды, нәкъ авылдагы язгы ташу кебек шаулап акты. Торбара су күтәрелде, ерак-еракларга җәелде.

«Су күбрәк булган саен чокырлар тизрәк тула. Минем дә күбрәк укыган саен белемем арта бара бит. Күрәсең, шулай булырга тиештер—табигать кануны,—дип уйлады егет әлеге галәмәткә карап.—Дөрес, бер профессор әйтмешли, университет белем генә бирә, ә акыл бирми. Ләкин белем өсте-өстенә өстәлә барган саен кешенең аң дәрәҗәсе дә элекке хәлендә калмыйдыр бит инде. Бәлки галим моны шаяртып кына әйткәндер? Яисә бу зиһен төшенчәсенә кагыладыр. Кайбер нарасыйларга кечкенә чагыннан ук, бу—зиһенле бала, диләр бит».

...Торбаларны отыры алгарак суздылар һәм, бульдозер алагаем зур үткен пычагы белән комны читкә этәрә торды. Декабрь азагында туктадылар. Су өсте юка боз белән капланды, малай-шалай тимераякта шуа, кәшәкә белән хоккей уйнап мәш килә башлады.

Габделнур, боларга карап, үзенең ачлы-туклы, ләкин гамьсез балачагын сагынып искә төшерә: алар да буа өстендә шулай әвәрә килә, тау-калкулыкларда бәләкәй һәм ат чаналарында җилдерә, басу-кырларда үзләре әмәлләгән чаңгыларда узыша иде бит.

Бүген төнлә кар яуган. Түбәндә аяк эзләре күренә; йорт янында гына гараж бар, аңа бер гарип кеше «Москвич» машинасын ябып куя. Гараж түбәсендә кар ята. Сузылган торбалар караеп күренә, әйтерсең лә бик озын

бүрәнә, тик ул чатлы, П хәрефен хәтерләткән кыска агачларга салынган. Төнлә җил көнбатыштан искән ахрысы, ком өемнәре чүлдәге барханнарга тартымрак—кире якка таба бераз сузылганнар.

Яңа елны дүртәү—Ирек белән йөргән кызы, Габделнур һәм Энҗе—каршыларга исәпләп торалар иде. Ләкин кайчакта исәп хисапка туры килми—син бертөрле уйлыйсың, тормыш үзенчә хәл итә—Ирекне утыз бере кичендә дежур торуга билгеләделәр. Шуңа күрә Габделнурга үз җаен үзе кайгыртырга туры килде: совет шампаны, «Столичный» юнәтте, прокат пунктыннан телевизор, савыт-саба, шул исәптән, рюмка-фужер кебек вак-төяк алып кайтты. Баяны—карават астында, пионер шикелле—һәрвакыт әзер. Азык-төлек хәстәрен дә алдан ук күрде, кыскасы, буйдак тормышына ямь өстәрлек, килгән кеше алдында йөзе кызармаслык булды.

Бераз күчтәнәчләр алып Энҗеләргә барды. Кинотеатр янышнан узышлый афишага күз салды: көндез «Солдат Иван Бровкин» булган икән, ә кич—«Юлдан язган». Өйдәгеләрне бәйрәм белән тәбрик итте.

Энҗе киенеп-ясанып чыгып китешли әнисенә шыпырт кына:

—Мин иртәгә иртән генә кайтырмын,—диде.

Тәгъзимә апа, ризасызлык белдереп, нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, кызы аны тыңлап та тормады, тизрәк чыгып шылды.

Алар җәяүләп кенә Химиклар сараена таба чыршы карарга киттеләр. Бу тирәне кичәге солдат биш бармагы кебек белә: кремльдәге казармадан чыгуга Ленин районы военкоматына юл тотты бит. Ә ул әнә генә—каршыда. Мәдәният сарае Оргсинтез хезмәтчәннәре өчен әле быел гына корылды. Аны Габделнур эшләгән трест төзеде. Ул бик матур урында: тирә-ягына биек-биек наратлар, төрле куаклар ямь биреп тора. Төзүчеләр шулхәтле сак кыландылар ки, кайбер агачлар зур мәһабәт бинага терәлеп диярлек торалар. Мәдәният сарае артында бала-чаганы куандырырлык төрле-төрле шугалаклар, әкияти вак-вак тәбәнәк өйләр, таганнар...

Ерактан иң әүвәл чыршы очындагы кызыл йолдыз күренде дә ул кинәт юк булды. Аннары биек яшел агач башыннан аска таба сузылган утлар берәм-берәм кабынды: яшел, сары, зәңгәр, кызыл. Янә зур йолдыз кабынып, анардан нурлар сибелде, йолдыз сүнгәч, биек бинаның бөтен буена ярымтүгәрәк рәвешендә берничә рәт куелган лампочкалар янды. Ә уртада—Кыш бабай рәсеме. Халык күп: зурлар, яшьләр, бала-чага. Әнә бер кыз әнисенең кулыннан тарта:

—Якынрак килик.

Моны күреп торган Энҗе егетнең кулына үрелде һәм көлеп:

—Әйдә без дә чыршы янына барыйк,—диде.

Габделнур бик теләп риза булды.

—Киттек. Белеп тор: «абзаң» бизәгән чыршы булыр бу.

—И мактанчык!—диде кыз, ә үзе егеткә сыенды.

Чыршы тирәсен тәбәнәк койма әйләндереп алган, фанералардан әмәлләнгән ул корылмага төрле әкият персонажларын тасвирлаган рәсемнәр ясалган.

Киногa килүче яшьләр дә чыршыга җитәрәк туктап калалар, кызыгып карап торалар. Габделнур исә кызына сокланып һәм горурланып караштыргалый. Алар янында Энҗе үзенең буй-сыны белән дә, киеме белән дә аерылыбрак тора. Аның өстендә күк ак төлке якалы яңа пальто, якасы төсендәге затлы мул бүрек, аякларында озын кунычлы кара сапожки, кулында күн перчатка. Егетнең үз киеме гадирәк: шәл якалы кыска ярымпальто, солдат пилоткасына тартымрак «Москвич» дип аталган бүрек.

Бераздан, Энҗенең үзен генә калдырып, Габделнур кассага китте,

исәпләре—кино карап чыгу иде. Егет, билет алып, почмактан борылуга (касса бинаның уң ягында, кеше күзеннән читтәрәк урнашкан иде) кызының бер ир-ат белән сөйләшеп торуын күрде. Кисәк туктап калды, артка чикте. Түзмәде, үрелеп унга карады. Ир-ат үзен бик иркен тота: Энжегә кагылып-кагылып ала, кулына үреләә, башын ия төшеп колагына нидер әйтә. Кыз исә уңайсызлана булса кирәк: алан-йолан карана, Габделнур киткән якка да күз салгалый, гәүдәсен читкәрәк авыштырырга тырыша.

Егет, берникадәр вакыт качып торгач, почмактан бина артыннан чыкты. Аны күреп алган Энже ир-атка нидер әйтте ахры һәм тегесе җәһәт кенә урыныннан кузгалды, читкә китеп барды.

—Кем иде ул?—дип сорады Габделнур төксе генә.

—Бергә эшлибез,—диде кыз, әмма егеткә туры карамады.

—Ә-ә, алай икән. Булды, билет алдым.

...Кино карап чыккач, җәяү генә Коллективная урамына таба юл алдылар.

Табын әзерләүне Энже үз кулына алды. Габделнурга да йомышы төшә торды. Эш арасында бер-берен җинелчә генә иркәләү-назлауны да онытып бетермәделәр. Ниһаять, җыйнак кына хәстәрләнгән өстәл янына утырыштылар. Берәр рюмка тотып куйгач кәефләр тагы да күтәрелде, телләре ачылды, сүз иярә сүз чыкты.

Габделнур:

—Күптән түгел Бальзак турында бер китап укыдым,—диде.—Мескен, үләренә берничә ай калгач кына өйләнгән булган.

—Дөнья рәхәтеннән мәхрүм калган икән дисеңме?

Кыз егеткә карап елмайды, соргылт күзләре белән аны иркәләгәндәй яратып карады. Сүзнең ни хакында барганын икесе дә аңладылар.

—Әйе.

—Нигә аңа исең китте? Бөекләр арасында буйдаклар байтак. Чайковский өйләнеп унтугыз көн генә торган. Бик күп галимнәр, әдәбият-сәнгать әһелләре беркайчан да гаилә кормаганнар: Бетховен, Лист, Ньютон, Гоголь, Лермонтов...

—Ну, Лермонтов Тукай яшендә һәлак булган—егерме җидедә. Дуэльдә атып үтермәсәләр, мөгаен, ялгыз калмас иде. Ә тегеләре... Юк, мин алай яши алмас идем. Башлы-күзле булу кирәк инде...

—Син даһи түгел шул,—диде кыз, ләкин шундук, ялгыш сүз ычкындыруын абайлап, сөйләшүне икенче якка борып җибәрде.—Ярый ла уңсаң.

—Әйе, өйләнү—уен эш түгел. Гаилә—пулемет расчеты кебек.

—Кызык. Нәрсә соң ул расчет?

—Пулемет расчеты ике кешедән тора: беренче һәм икенче номер.

—Син пулеметчымыни?

—Әйе. Кронштадтан безне Ленинград тирәсенә өйрәнүгә җибәрделәр. Миндә РПД[1] пулеметы иде.

—Син—беренче номер?

—Әйе.

—Ул нишли?

—Пулеметка тулысынча ул хуҗа, аның өчен җавап та бирә.

—Ә икенче номер?

—Аның вазифасы—беренче номерга булышу, һәрчак кул астында булу.

—Өйләнешкәч син ничәнче номер буласың инде?

—Билгеле,—беренче!

—Ә мин икенчеме?

[1] РПД — ручной пулемет Дегтярева.

—Әйе.

—Әгәр теләмәсәм?

—Менә бөтен бәла дә шунда шул. Күп гаиләдә икесенен дә беренче буласы килә. Ә ул—мөмкин эш түгел. Тылны кем тәэмин итәр—анысын уйлаган кеше юк.

—Синеңчә, гаиләдә кемдер гел беренче, ә кемдер икенче булырга тиеш инде.

—Бүтәнчә була алмый.

—Ә бездә—әни беренче.

Габделнур аларда әтиләренә әллә ни сан югын сизенә иде.

—Беләм. Син дә шул рольгә дәгъва кылачаксыңмы?

Энже—акыллы, зиһенле, үткен кыз—тынып калды. Бик тирәнгә керүен шәйләп алды. Су төбен аягы белән тоймас хәлгә җиткәнче туктарга кирәк иде. Һәм ул шулай эшләде дә.

—Бик күнелсез темага кереп киттек,—диде кыз.—Әби әйтмешли, тумаган колыннын билен сындыра күрмик. Җыр тыңлыйк әле.

Ул, үзе алып килгән кассетаны куеп, магнитофон уйнатып җибәрде. Аннан бер хатын-кыз ниндидер дәртле җыр башкара иде: гарәп, төрек көйләренә тартым.

—Бу кем?—дип сорады егет.

—Долида.

—Кем соң ул?

И-и, шуны да белмәскә, дигән сыман, Энҗе егеткә бераз мыскыллы караш ташлады.

—Франция җырчысы. Ләкин үзе Египет кызы. Җиде телдә җырлый. Бик чибәр.

—Әллә синнән дә матурмы?

—Белмим,—диде Энҗе хәйләкәр елмаеп һәм Габделнурны танцыга чакырды.

Егет үзе Энҗе белән бии, ә үзе кыз белән ике арада булып алган әңгәмәне дәвам иткән кебек уйлана. Әйе, аның сизгер күнеле бу чибәркәйне үтәли күрә башлады кебек. «Сиңа, дускай гынам,—диде ул үз-үзенә,—аның көенә генә торырга кирәк булачакмы? Бу—баш бирмәячәк. Өйдә генә әле бер хәл... Өстеңнән йөрергә дә күп сорамас... Аннары инде сөяркәсенең хуҗалык буенча урынбасары булып яшәргә генә каламы?..»

—...Ярар, ярар, син беренче булырсың,—диде кыз баягы сөйләшүгә кире әйләнеп кайтып һәм аңа нокта куйгандай уенга борып әйтте.—Синең янында мин ничәнче булырга да риза.

Һәм иркәләнеп егет кочагына керде.

Егет эчтән генә уйлап куйды: «Кызганыч, мин беренче түгел шул инде.—Монысы пулемет расчетына түгел, ә Энҗенең кызлык намусына кагыла иде.—Ихтимал, соңгысы да булмам...» Ләкин бүген ул турыда кабат исенә төшерәсе килмәде. Бүген—бәйрәм. Иртәгә, киләчәктә ни буласын тормыш үзе күрсәтер.

Аннары соңгы вакытта бик популярлашып киткән «Кукарача» җыры яңгырады. Мексика киносындагы бу җырны бер атаклы музыкант-аккордеонист башкарды. Аны Высоцкийның карлыккан, көчәнеп тамак төбеннән чыга торган тавышы алыштырды. Аңа да алмаш табылды—телевизордан «Зәңгәр ут» тапшыруы...

Алар Яңа елны матур гына каршыладылар: шампан атылды, бенгаль утлары яндырылды, тостлар әйтелде—Яңа елда яңа бәхетләр юралды—теләкләр теләнде, Мәскәү кремле курантлары белән бергә бокаллар чыңлады, җыр-музыка өзлексез агылып торды. Соңгы елларда популярлашып киткән

«Орера», «Добры молодцы», «Песняры» кебек вокаль-инструменталь ансамбльләр башкаруындагы җырлар кызның күңеленә аеруча хуш килә иде. Мөслим Магомаевның «Матурлык королевасы» һәм «Ашыкма» җырын тыңлагач, Габделнур әйтеп куйды.

—Анын әбисе татар икән.

—Шулаймыни? Чыңгыз Айтматовның да әнисе татар дип ишеттем әле мин. Шагыйрьләр Василий Жуковский белән Константин Бальмонтның да аналары татар кызлары булган. Ләкин аларны турчанка дип язалар...

Караваt астыннан чыгып егет тезенә үрмәләгән баянга кушылып, дәфтәрдән карап булса да, парлап татарча җырладылар, дәртле көй янгырагач кыз биеп тә күрсәтте. Борчучы, комачау итүче булмады. Ахырда Энже, чишенеп, койкада аны көтеп яткан Габделнур кочагына ауды...

Йокыдан торгач, кунак озак юанмады, тиз-тиз киенде, чәй-мәйдән дә баш тартты.

—Озата барма, үзем генә кайтам,—диде ул һәм, егетне кочып, иреннәреннән суырып-суырып үпте.—Рәхмәт.

—Үзеңә рәхмәт.

Кызны подъезд төбенә хәтле озатып кергәч, Габделнур тәрәзә каршына килде.

Күк йөзе төрле төстәге алама болытлар белән капланган, алар—алсу, көрән, аксыл. Кояш болытлар арасыннан карый, арадан сузылган кызыл багана шәһәр өстенә төшә: сул яктагы, агачлары агарган ял паркына, эреле-ваклы йортларга... Аэропортка таба түбәнәеп төшеп килүче дүрт моторлы зур очкыч әйтерсең шул кызгылт баганага килеп бәреләчәк. Юк, бәрелмәде, очкыч үз юлы белән китте. Бетон полосага төшеп утыргандыр.

Габделнур кисәк кенә үзен һәм Энҗене әлеге очкыч белән кызгылт баганага (чын булмаса да) тиңләде. Болар «бәрелешмәде». Ә бит тормышта ул багана чын булачак. Кайсы самолет та, кайсысы багана икәне мөһим түгел. Әмма бәрелеш булачак. Ул чагында икесенә дә һәлакәт яный. Чөнки алар, гәрчә бер университетта укысалар да, «тормыш университет»ларын икесе ике төрле шартларда үткәннәр...

Менә бераздан, кояш болытлар арасына кергәч, теге куркыныч кызгылт багана юкка чыкты.

Төрлесе төрле биеклектәге торбалардан авыр болытларга җитәрдәй булып сузылып төтен күтәрелә. Бөтен җирне ап-ак кар каплаган.

—Әйдә, егет, бүген генә булса да борчулы уйларыңнан арынып тор әле, дөнья ул кадәр үк ямьсез түгел бит,—диде Габделнур үз-үзен юатып һәм тынычландырып.

Ул арада ишектә дусты Ирекнең йолдызлы бүреге һәм погонлы зәңгәр шинеле күренде...

## XVIII

Завод эчендә завод булачак, дип сөйләнүләр—имеш-мимешләр чынга ашар төсле: бүген полиэтилен комплексының яңасын кору башланачак. Шул уңай белән халык төзелеш мәйданына—комплекс булачак урынга—тантаналы митингка җыелды. Трестның берничә төзү идарәсе берьюлы бу олы һәм җаваплы, ике-өч елга сузылачак катлаулы эшкә керешәчәк иде.

Габделнур да йөзләгән кеше арасында басып торды. Монда төзелешкә мөнәсәбәте булган барча һөнәр иясе төзүчеләр, генподрядчы ролен үтәүче трестның управляющиеннан алып әле яңа гына институт бетереп килгән мастерга хәтле—бик күп инженер-техник хезмәткәрләр басып торалар. Алар белән янәшә профсоюз комитеты рәисе, партком һәм комсомол секретарьлары. Комплексны коруда катнашачак субподрядчы оешма

башлыклары да биредә. Аерым кастаны заводныкылар—заказчылар тәшкил итә. Алар башкарылган эшләрне, монтажланган җиһазларны гына кабул итеп калмыйча, акча капчыгы ролен дә үтиләр. Төзелеш оешмаларының матди хәле аларга бәйле—процентовкаларга алар кул куя. Республиканың һәм шәһәрнең партия-совет органнары җитәкчеләре үзләренә нинди мөһим бурыч йөкләнгәнен белеп-аңлап, киләчәккә планнар коралар. Чөнки объектны вакытында тапшыруны төзүчеләрдән генә түгел, алардан да таләп итәчәкләр. Мәскәүдәге төзелеш министрлыгыннан килгән могтәбәр түрәләр зур дәрәҗәләрен саклап, башны югары тотып гәп коралар. Илкүләм чарадан гафил була күрмик, дип радио-телевидение һәм гәзит-журнал хәбәрчеләре җыелган.

Сөйләүчеләр—сүз боткасы пешерүчеләр күп. Һәр чыгыш күтәренке рух белән сугарылган. Нотык беткән саен озакка сузылган алкышлар бөтен мәйданны тутырды. Ул авазлар янәшәдәге, инде эшкә «җигелгән» корылмалардан, ерактагы урманнан кайтаваз булып яңгырады. Бүтән вакытта зәңгәр күк йөзен иңләп, төзүчеләрне сәламләп, баш өстеннән генә очучы кошлар бүген читтәнрәк, әйләнебрәк үтәргә тырышалар.

Кешеләрне, шул җөмләдән Габделнурны да, бәйрәм тантанасы, илкүләм әһәмиятле эшкә катнашың булу тойгысы биләп алды. Нур өстенә ямь өстәп, соңыннан концерт булды. Мәскәү түрәләре үзләре белән танылган җырчыларны, музыкантларны һәм нәфис сүз осталарын да алып килгәннәр икән. Аларга җирле сәнгать әһелләре дә кушылды.

Митингта башланган шатлык-куаныч, җанлылык, рухи күтәренкелек әле халык таралганда да сүрелмәде: сүз һаман булачак зур төзелешкә әйләнеп кайта, аның тирәсендә чуала иде. Телдән кычкырып әйтмәсәләр дә бу хезмәт хакы, тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуга өмет белән дә бәйләнгән. Чөнки «Мәскәү абзый» социаль объектларга, шул исәптән, торак төзүгә дә акча бүлеп бирә. Балык тирәнлекне ярата, ә кеше—яхшыракны, дигән кебек, бу дөньяда һәркемнең адәм рәтле тормышта яшисе килә.

Тантана мәйданыннан китеп барышлый Габделнурның күзенә еракта, дүртенче төзү идарәсе егетләре арасында, бер таныш йөз чагылып китте. «Булмас, ул түгелдер,—дип уйлады егет һәм үзен тынычландырыр өчен көлемсерәп өстәде.—Кем әйтмешли, атаңа охшаган урыс күп булыр ул». Чөнки әлеге кеше бер генә күренеп алды да үзе кебек үк эш киеменнән булган төзүчеләр арасында юкка да чыкты, дөресрәге, тегеләрдән берикесе аны каплады: алар, җанланып, кулларын бутый-бутый сөйләшәләр, нәрсәдәндер кызык табып шаркылдап көлешәләр, әледән-әле урын күчәләр. Шуңа күрә Габделнур нихәтле генә текәлеп караса да кабат теге таныш чырайны күрә алмады. Бермәл, ул, юктыр, берәрсенең йөз чалымы гына аны хәтерләтәдер, дип, тынычланган кебек тә булды, аннары, янә күңелле алгысып куйды, башына кереп оялаган уй аңа тынгы бирмәде.

—Мин тиз генә бер җиргә барып килим әле,—диде ул үзе белән янәшә атлаучы, участокта бергә эшләүче электрик егеткә.

—Кая?—дип сорады тегесе.

—Әнә теге егетләр янына,—дип кулы белән уңгарак төртеп күрсәтте Габделнур.—Бер служакны очраттым бугай.

Үзе дә армиядә булган һәм андагы дуслыкның ни-нәрсә икәнен яхшы белгән иптәше каршы килмәде.

—Бар, бар. Мин будкада булырмын. Иркенләп йөр.

Габделнур, кешеләрне аралап дигәндәй, әмма күрше идарә егетләрен күздән ычкындырмыйча, алга карап китте. Үзе бара, үзе уйлана: «Неужели? Ә нәрсәсе бар аның искитәрлек? Нигә гаҗәпләнергә? Бик мөмкин. Ул бит әллә каян җәһәннәмнән түгел иде, Казан артыннан гына. Кайткандыр, монда

зур төзелеш барганын ишетеп белгәндер һәм... килгәндер. Син килгәнне нигә ул килмәскә тиеш? Әлбәттә, киеме бүтән, үзе—шул сыман».

Егет, тегеләрне куып җиткәч, капыл гына барып эндәшмәде. Кыен хәлдә калуың да мөмкин. Бервакыт, ул Декабристлар урамында, троллейбус тукталышында тора иде. Кинәт кемдер арттан аның күзләрен каплады: йомшак, кайнар, нәзек кенә куллар. Габделнур башын унга-сулга борырга итенә, юк, куллар ирек бирми. Менә бераздан куллар ычкынды. Артына борылып карaса, ике кыз тора, әмма берсе дә таныш түгел. Кызлар, ялгышуларын аңлап, кып-кызыл булдылар, кат-кат гафу үтенделәр һәм көлешә-көлешә шундук китеп тә бардылар... Менә шулай ояткa калмас өчен, ул төзүчеләргә ияреп берничә адым барды, инде тәмам инангач, ялгышуы мөмкин түгелен аңлагач кына, аларны кызу адымнар белән, озын-озын атлап, узып китте дә кырт борылды.

—Хөрмәт!—дип кычкырып җибәргәнен үзе дә сизми калды.

Биш-алты егет кисәк кенә туктадылар. Шик юк, аларның берсе Габделнурның гаскәри хезмәттәге дусты иде. Ул да танып алды.

—Габделнур!

Ике таза егет, бер-берсен кочаклап, аркаларыннан кага-кага күрештеләр.

—Син ничек монда килеп эләктең?—дип сорады Габделнур, дустының хезмәттәшләренә кул биреп, күрешеп чыккач.

—Абый чакырды. Ә син?—дип үз чиратында сорау бирде Хөрмәт.

—Безгә «сатып алучы» килгән иде. Вербовщик була инде. Мин бит соңгы ике ай ярымны Казанда хезмәт иттем...

Һәм алар, егетләрдән берничә адым арткарак калып, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә хәл-әхвәл белешә башладылар. Чөнки соңгы елны хат алышу ничектер өзелгән иде.

Хөрмәт өч елын тутырганчы шул бер частьта булган. Дембельдән соң, Казанга килеп, абыйсы янына балта остасы булып урнашкан.

—Без бит авыл малайлары, балта-чүкеч тота беләбез. Монда әллә ни осталык кирәк түгел, күбрәк опалубка ясыйбыз. Сиңа таныш инде. Механизаторлар кирәк түгел икән.

—Ярaң ничек соң?

—Төзәлде.

—Борчыймы?

—Әллә ни түгел. Көрәшеп кенә булмас, пожалуй. Теге хайван мәйданга юлны кисте...

—Үчен кайтара алмадыңмы?

—Ничек кенә әле... Берчак, җаен туры китереп, эздем мин аны. Ай буе кан косып йөрде, ахырда комиссовать иттеләр үзен... Ну минем дә хәзер көрәшер чама юк...

—Анысы начар икән,—диде Габделнур һәм, бу хакта озаклап сүз куертып тормас өчен, уенга борды.—Юкса, сабантуйда бөтен кызның күзе синдә булыр иде.

—Болай да караучылар табылыр әле.

—Безнең эше ашап-эчеп, дөресрәге, эчеп-ашап йөргән егетләргә, диген. Да, кстати, кызың турында сорарга онытып торам.

—Түү-түү,—диде Хөрмәт ачы елмаеп.—Очкан.

Һәм ул аңлатып бирде: кызы кияүгә чыккан, Хөрмәттән өч яшькә олырак авыл егетенә.

—Күз күеге булып тормас өчен, аны да, үземне дә газапламас өчен, китеп бардым,—диде ул авыр сулап.—Әни дә каршы килмәде, абый да чакырды...

Габделнурга, әйе, шулай инде, дип баш кагып җөпләп, өч ай Кронштадтта

карантин узып, солдат шулпасының әчесен-төчесен бергә татыган хезмәттәшенең кайгысын уртаклашудан башка чара калмады. Күрәсең, армиягә алынган авыл егетләренең күпчелеген шул көтәдер: үзе дә, Ирек тә шундый язмышка дучар булдылар бит. Кызларны да аңлап була: әйләнеп кайталармы егетләр, юкмы, кайткач, аларга карыйлармы, чөнки үкчәгә басып яшьрәк сылулар үсеп килә...

Кызлар темасын шуның белән ябылган санап, авырткан ярасына кабат кагылмас өчен, тормыш-көнкүреш хәлләренә күчте.

Хөрмәт Жилплощадкада яши икән, биш катлы тулай торакта. Габделнур да үзенең кайда торуын, адресын әйтте, кунакка чакырды. Ул дустын күрүгә чын күңелдән шат иде.

Күрешмәүләренә биш елдан артык гомер үтсә дә Хөрмәт әллә ни үзгәрмәгән: йөзе бераз тартылган тартылуын, ияк-яңаклары зәңгәрләнеп тора (элек ул әле юньләп кырынмый да иде), әмма куллары әүвәлгечә таза, бармаклары көчле; аның елмаюы да шул килеш калган: иреннәрен очлайтыбрак бөтен бите белән елмая, элек тә кечкенә, кысыграк күзләре тагын да йомыла төшә. Гомумән, җәлпәграк борыны да, бөтен алгы тешләрен күрсәтеп ихлас көлүе дә—барысы да таныш. Дөрес, ул буйга берникадәр калыккан шикелле. Ләкин монысы гәүдәсен төз тотып йөрүдән киләдер, ябыгып киткәнгә шулай күренәдер. Хәер, өч ел каеш буып йөрү анарда да эзсез калмас инде.

Эш киеме булса да өсте-башы чиста. Бу да гаҗәп түгел, алар яшь сугышчы курсын үткәндә үк бу яктан да төшеп калганнар рәтендә йөрмәделәр, һәрчак үрнәк булдылар.

Сөйләшеп сүзләре бетәрлек түгел иде, шуна күрә, хатирәләр янарту өчен, егетләр, бер-берсен кунакка чакырышып, аерылыштылар.

## XIX

...Кичен Габделнур кызы янына китте. Трамвайдан төшеп, аларга таба барганда, егетнең очлы күзе урамның теге ягында Энҗене күрде. Алар—өч кыз—култык астына кәгазьгә төрелгән әйберләр (туфлиләр булса кирәк) кыстырып, очынып баргандай бик җанланып сөйләшә-сөйләшә киләләр иде. Алар ягында да, Габделнур барган якта да тротуарда кеше булганлыктан, кызлар аңа игътибар итмәделәр. Яшьләрнең карашлары алга төбәлгән, уйлары белән кызлар инде кайдадыр еракта-еракта, ниндидер шатлык-тантана, күңел ачу вәгъдә иткән тарафта. Шуны сиземләп, егет дәшмәскә булды, үзен белдермәде һәм ары китте. Аннары туктады, артына борылды. Бераздан кузгалды, өйләренә барып киләсе итте.

—Киногa киттеләр,—диде әнисе.—Әле яңа гына.

—Алай икән.

—Әйдә кер. Нишләп чит кеше кебек ишек төбендә генә торасың.

—Рәхмәт.

Бәләкәй капкадан урамга чыгышлый исенә төште: кызлар кинотеатр ягына әйләнеп тә карамыйча үтеп киттеләр бит. Димәк... Егет уйга калды: «Әнисе белеп әйтми микән, әллә аңа да бөтен серләрен чишеп бетермәделәр микән?..»

Эштә бер ир-атның әйткәне келт итеп хәтерендә яңарды: «Егетләр исегездә тотыгыз: ана кеше беркайчан да баласын сатмаячак. Үземнең баштан узган. Кызы ире өстеннән йөрсә дә әбекәй моны кияүдән яшерәчәк...» Габделнур башын чайкап куйды, үз-үзе белән сөйләшкәндәй әйтте: «Кызык дөнья бу: гасыр яшә, гасыр буена өйрән, җүләр булып үләрсең». Әлбәттә, бу фикер укуга гына кагылмый, белем алуга гына кайтып калмый, аның мәгънәсе тирәнрәк.

Һәм ул китеп барды. Ләкин түзмәде, шактый вакыт үткәч, зәңгәр күк йөзенә ай калыккач, йолдызлар җемелдәшә башлагач, янә бу өй тирәсенә килеп, ак һәм зәңгәр төсләргә буялган бизәкле наличниклы тәрәзәләргә ерактан гына күз салды. Яран һәм аңа таныш булмаган бик күп гөлләр (Энҗе гөл үстерергә ярата) аша эчкә күз салды, малай-шалай кебек урамнан карауны килештермәсә дә өйгә кермәде. Озак торды, ләкин ут яктысында Энҗе күренмәде. Бу юлы инде егет бөтенләй өметен өзде.

Икенче көнне тагын таныш сукмакка эз салды. Энҗене чакырып чыгарды.

—Кичә килә алмадым,—диде Габделнур кызның таушалган чыраена карап.—Гафу ит.

Күзләрен чет-чет йомгалаган Энҗенең йөзенә ризасызлык галәмәте чыкты.

—Ә мин сине көттем,—диде ул, ә үзенең күз карасы кинәйгән, кашы күтәрелә төшкән иде.

Габделнур бер тын дәшми торды. «Өзәргә кирәк араны, моңарда ышаныч юк,—дип уйлады.—Алга-артка карамыйча качарга кирәк бу тирәдән». Шулай да уенны дәвам иттерәсе килде. Тагын нәрсә уйлап табар икән. Егет кызның кулын тотты—ул тирләгән иде.

—Ә мин кичә сездә ике рәт булдым. Син кинода иден.

Кызның ирен читләрендә чак кына елмаю чагылды.

—Әйе шул,—диде ул күзен дә йоммыйча, болай булгач аның хәле җиңеләйде—аңлатып торасы, сүз озайтасы юк.

Монысы инде Габделнурны чыгырыннан чыгарды, ары табан түзеп тора алмады, камчы белән сыдыргандай кисәк кенә әйтеп салды.

—Син—актриса!

—Ничек?

—Син кинода түгел, башка урында иден!

Егет аларны күрүен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бу рәвешле «дивар»га китереп терәгәч, кызның барыр юлы, дөресрәге, алга таба да алдашырлыгы калмады. Ялганы фаш ителгәч, ул, май ашап тотылган песи кебек, башын аска иде. Янәсе, ярамаган гамәл кылды, бик нык үкенә, билгеле. Иелгән башны кылыч кисми бит. Шуңа күрә егет белән килешкән атлы кыланды.

—Әйе. Гафу ит.

Кызның соңгы сүзләре тукран тәүбәсе генә икәнен яхшы белгән Габделнур:

—Син—Клеопатра!—диде.

«Кызганыч, син Юлий Цезарь түгел,—дип уйлады кыз ирония белән.—Хәер, син Эндимон[2] да түгел». Ә үзе мыштым гына торуында булды, янәсе, әйдә, егет, сайра, сине «бик бирелеп» тыңлыйлар.

Габделнур аңа шактый озак тугрылык, мәхәббәт, ике арада аңлашылмаучылык, яшерен сер булмаска тиешлеге хакында мораль укыды. Кыз акланмады, башын иеп, каршы эндәшергә базмыйча тыңлап торды. Һәрхәлдә, тыштан караганда аның күндәм генә басып торуыннан шулай дип уйларга була иде. Ә күңелендә ни-нәрсә—монысы егеткә караңгы иде. Ул, ни өчен элек йөргән кызлары белән аерылышуның сәбәпләрен әйтеп, үз тормышыннан да берничә мисал китерде.

Аннары, әле татулашырга нияте барлыгын исбат итәргә теләп:

—Мин сиңа хатлар күрсәтмәкче булам,—диде.—Әйдә безгә.

—Ярар,—диде кыз юаш кына.—Мин дә сиңа армиядәге егетемә язган хатны күрсәтмәкче идем.

[2] Эндимон—борынгы грекларның дини әкиятләрендә матурлык һәм яшьлекне чагылдыручы егет.

Өйгә керделәр. Энҗе ана әле генә язган, конвертка салынмаган хат тоттырды. Үзе киенергә дип, кече якка кереп китте. Габделнур күз йөртеп чыкты. Әллә ни искитәрлек нәрсә юк иде ул хатта. «Күрәсең, бу моны юри шулай коры язган, махсус миңа күрсәтер өчен»,—дип гөман кылды егет. Әмма ләкин эчендәген тышка чыгармады, чөнки дөнья аны уйларын яшерергә өйрәткән иде инде. Сүзең көмеш булса, дәшмәвең—алтын, диләр бит.

Энҗе бизәнеп-ясанып чыкканчы ул таныш бүлмәне караштырып утырды. Тыштан караганда авыл өе кебек булса да, аның эче шәһәрчә җиһазланган-бизәлгән: киң диван, зур шифоньер, өч көзгене берләштергән трельяж, түрдәге өстәлдә «Балтика» радиоалгычы белән магнитола, бер як диварга «Кызыл Октябрь» пианиносы терәлеп тора, түшәмдә биш чатлы люстра, идәндә зур палас, диван турысында бизәкле келәм. Егет бигрәк тә бер гөлгә сокланды. Монда килгән саен аңа карамыйча түзә алмый. Бу гөлнең исеме дә бар икән—«Яшь килен». Ул вак-вак түгәрәк яфраклы, күп ботак-чатаклы, чәчкәләре йолдыз кебек биш чатлы, әмма ак төстә. Нык чәчкә атса—бөркәнчекле кәләш кебек—ап-ак булып утыра.

...Ишек бикле. Ирек өйдә юк икән. Габделнур, кесәсеннән ачкыч алып, бүлмәне ачып керде. Кунак тәрәзәгә якынрак артлы урындыкка утырды. Хуҗа тәкъдим иткән чәйдән баш тартты.

—Мә алайса конфет, тик торганчы бер эш булыр,—дип елмайды егет.

—Син миңа хатлар күрсәтәм диген идең, кая, бир.

—Ә мин юри генә әйттем,—диде аның каршына баскан Габделнур.

—Ялганчы.

Егет теманы үзгәртергә булды. Кызы янына утырды да өйләнешү хакында гәп корып җибәрде. Кайда тору мәсьәләсенә тукталды. Төрле вариантлар санап үтелде. Энҗе ышанып җитмәде. Ләкин егетенең җитди йөзенә карагач, икеләнә калды.

—Кулыңны күтәр, бармакларыңны аер.

Габделнур моның ни өчен таләп ителгәнен белмәмешкә салышты, торып басты, кызның әмерен үтәде. Энҗе, аның кулы калтыравын күреп, сүзләренең ихласлыгына ышанды. Килештеләр. Һәм ул, торып, егетнең кочагына ташланды...

...Университетның «химкорпус»ында, йөзенче аудиториядә, Габделнур тузанлы, ачык зур тәрәзәгә карап утыра. Алгы планда кызыл кирпечтән салынган биек иске йорт почмагы күренә, котельнаяның тимерчыбыклар белән тарттырылган озын юан торбасы ишегалдындагы яшелгә төренгән агачлардан да биек булып кукраеп утыра. Ике-өч катлы иске йортларның кызыл калай белән ябылган түбәләрендәге күпсанлы моржалар, антенналар якындагы Пассажның түгәрәк куполын, ерактагы кремльнең ак төстәге Спасс башнясын һәм кызгылт Сөембикә манарасын каплап бетерә алмыйлар. Ә еракта-еракта, томан эчендә сыман күренгән Икенче җылылык-электр станциясенең үтә биек торбаларыннан төтен чыга. Ленин районы өстенә аксыл томан төшкән.

Егетнең дә үз тормышы билгесезлек, куе томан эчендә кебек. Энҗе белән ара инде ялганды дигәндә генә янә өзелде. Икесе дә моңа әллә ни игътибар бирмәгән сыман кылансалар да, чынлыкта исә алай булып чыкмады: асылда икәве дә моны бик авыр кичерделәр.

Габделнур диалектик материализмнан лекция тыңлый. Тик доцентның сөйләгәне бер колагыннан керә, икенчесеннән—чыга. Хәтта сүзнең ни турыда икәнен төшенергә дә омтылыш ясап карамый, әйе, колагы—аудиториядә, уйлары—Энҗе янында, (ул бүген юк, авырый, диделәр), күзләре—урамда. Ә аннан бала-чага авазы, мотороллер, машина тавышлары,

эт өргәне ишетелә, ниндидер кош сайрый: чут-чут-чут...

Кояш баеп килә, тәмам җиргә төшә язган, эссесе сүрелгән. Аның нурлары тәрәзәдә чагылып күзгә бәрәләр, әйтерсең лә кемдер күзгә уйната. Энҗе белән дә шул ук хәл: карасаң әле һаман күз чагыла, тик элекке кебек җылы гына бөркелми... Күк йөзе аксыл-зәңгәр төскә кергән, беленер-беленмәс кенә җил исә, хәер, ул бөтенләй исмәгән дә кебек, хәтта агач яфраклары да аңа бирешергә теләмиләр, андый гына тымызыкка бик исләре китми. «Синең дә исең китмәсен,—ди егет үз-үзенә.—Мондый хәлгә юлыгуың беренче мәртәбә генә түгел ич. Күңелеңә якын алма, йөрәгең кага башлар. Ничек җырлыйлар әле: «Илдә матурлар бетәрме?..» Әйе, бетмәс. Ләкин җырның азагы да бар бит: «...Җан сөйгәнгә җитәрме?»

Аудитория диварына, хатын-кызларның башларына кояш төшә. Беренче тапкыр күргәндәй, егет аларның прическаларына игътибар итте: әйтерсең лә казык башына элеп куелган чүлмәкләргә баеп килүче кояш нурлары төшә, чөнки күбесе чәчләрен баш түбәсенә өеп куйганнар. Ә Энҗенеке андый түгел, аныкы—бүтәнчә. Гомумән, ул үзе дә башка... Читтән торып укучылар арасында да яшь кызлар бар, ярыйсы гына чибәрләр дә. Ә менә күңел һаман Энҗегә тартыла... Эштә дә матур, яшь кызлар җитәрлек...

Укытучы һаман сөйли дә сөйли. Тыңлыйлармы аны, юкмы—монысы аңа кагылмый да шикелле. Аны студентлардан бигрәк почмактагы Володя Ульянов (ярты гәүдәле бюст кына булса да) игътибар белән тыңлый булса кирәк. Һаман сөйли... Арлы-бирле очып йөрүче чебен-черки дә авызына керми...

«Әллә бүген барып карарга инде,—дип уйлады Габделнур дивардагы экранга, кызылга буялган тактага бәбәкләрен терәп, йокымсырап утырган иптәшләренә күз салып; аның үзенә дә эссе, эчәсе килә иде.—Пожалуй, шулай итәргә кирәк... Ә иртәгә генә барсам?..»

Шулай үз-үзен кая куярга белмичә көнозын җаны уйнап, икеле-микеле уйлар белән йөрде, киногa барып кайтты. «Костер» кинотеатрында «Барысы да истә, Ричард» исемле фильм иде.

Телевизордан хоккей карады, яраткан командасы кубокка уйный иде. Алар оттыргач, күңеле төште. «Ярар, Энҗе янына бүген бармам инде»,—дип үз-үзен тынычландырды.

Эше тыгыз булганлыктан, ике көн рәттән укырга бара алмады. Борчуы йөзенә чыкты.

—Синең бүген кәеф юк ахры,—дип сорады контроль эш язып утырган Ирек, ул да җәйге сессиягә әзерләнә иде.

—Шулайрак. Энҗе янына барам әле. Соң булса да.

—Әйләнеп кайт.

Ирек дустының мәхәббәт маҗараларын яхшы белә, ләкин кысылмый. Бала-чага түгел, үз башы бар, дип кенә карый иде. Габделнур да аның, сәясәтчеләр әйтмешли, «эчке эшләре»нә тыкшынмый.

Габделнур кафега кереп тамак ялгады. Кыз укудан кайтасы вакытка тукталышка барып басты, арлы-бирле йөренде. Өенә сугылмакчы булды, ләкин бармады. Занятиедәдер шикелле тоелды.

Нишләптер бүген көн салкынча иде, кичкә таба тагы да суынды. Егетнең өстендә яшел төстәге, җилбәгәй җибәргән болонья плащ, аның эченнән пиджак кигән, күк төстәге лавсан күлмәктән, кыска, нечкә кара галстук таккан, озын яшькелт чалбардан. Ул билен кысып, тәненә сыланып тора, тез туры тар, ә балаклары матросларныкы кебек киң—клеш—һәм очлы башлы кара ботинкасының биек үкчәсен каплап торалар.

Урамда кеше күп. Габделнур яшеренебрәк басып торды. «Октябрь» кинотеатры каршына барып килде. Башын күтәреп, урамдагы сәгатькә

карады (үзенеке ремонтта иде)—унынчы ярты. Инде китәргә уйлабрак кабат тукталышка килде. Почмакта каршына Энже килеп чыкты һәм чак кына егеткә бәрелмәде, танымыйча узып китте.

—Энже!

Үзенә дәшкәнгә кыз борылып карады. Шатлыгы йөзенә чыкты.

—Ничек монда?

—Күрәсең...

Бергә атлап киттеләр. Габделнур Энженең портфеленә үрелде.

—Авырмы?

—Юк,—диде кыз, ә үзе бик теләп йөгеннән арынды.

Хәл-әхвәл сорашып, уку турында гәпләшеп, кайтып җиткәннәрен сизми дә калдылар. Капка төбендә туктадылар.

Кыз яланбаш, өстендә төймәләре каптырылмаган сары болонья плащ, ул кыска һәм Энженең йомры тез башларын күрсәтеп тора. Гадәттә аның эченнән ул йон кофта кия, итәге алдан да, артта да ерылган һәм төймәләр тезелеп киткән булыр. Тыгыз балтырлы төз аякларында эре парчалы үтә күренмәле ак оеклар һәм биек үкчәле туфли. Ул болай да озын гәүдәле, зифа буйлы, әнә шул биек үкчәле туфлиләрен кисә, егет белән бер буйда диярлек була. Шуңа күрә Габделнур аның янына барганда һәрчак калын табанлы ботинка кия.

—Туңасыңмы?

—Юк.

—Керәсеңме?

—Хәзер.

Ләкин икесе дә беләләр: берсенең керәсе килми, икенчесенең китәсе. Ниһаять, озак кына дәшми торганнан соң Энже басынкы тавыш белән йомшак кына сорап куйды.

—Нигә килдең?

Сер бирәсе килми иде егетнең.

—Болай гына.

Кызның күңеле мөлдерәмә чиләктәй—менә-менә суы түгелер кебек.

—Минем күз яшьләрен күрәсең килдеме?

—Юк.

—Син бит, килмәм, дигән идең.

—Ярар алайса, башка килмәм. Соңгы визит.

Бу сүзләрне ишеткәч, Энже, керергә теләп, капкага таба борылды. Ләкин ул бикле иде. Шуннан кыз күршеләрнең бәләкәй капкасыннан керде. (Бик тату яшәгәнлектән, ике ихата арасында тәбәнәк кенә рәшәткә-койма һәм кечкенә капка да бар иде). Ләкин аны япмады. Портфелен җиргә төшереп, капка баганасына яңагын куеп тора башлады. Пышылдап кына нидер әйтте. Габделнур ишетмәде, чөнки читтәрәк коймага сөялеп тора иде. Кыз тагын нидер әйтте, әмма егеткә бу юлы да аермачык ишетелмәде.

—Ишетмим,—диде ул.

—Якынрак кил.

Энженең соңгы сүзләрен Габделнур ишетте һәм аның каршына килеп басты. Шактый вакыт сүзсез генә бер-беренә карашып тордылар. Энженең соры чәченең бер учмасы кыеклап маңгаена төшкән, ләкин күзен капламый. Кечерәк кенә, аңгәмәдәшенә һәрчак туры караучы соргылт күзләре дымлы, сагышлы. Хәер, егетнең дә гадәттәге кырыс чыраенда борчылу галәмәте чагыла иде. Алар бер-берсенә ияләшкәннәр, ярты сүздән аңлау, бер карауда кичереш-тойгыларны сиземләү дәрәҗәсенә җиткәннәр иде инде.

Егет башыннан төрле уйлар йөгереп узды. Болай тору да уңайсыз иде. Ул кузгалып китмәкче дә булды. Ләкин инде күптәннән үзенә якын булган

ягымлы йөздән күзләрен алалмады, кызны бу хәлендә калдырып, читкә таба атлый алмады. Киресенчә, сакланып кына тулышып торган яңакларын тотты. Алар кайнар иде. Түзмәде, әкрен генә Энҗенең башын үзенә таба якын китерде. Беренче мизгелдә кыз тартылырга теләде. Әмма каты куллар аны кысып тоткан, тик авырттырып түгел, ә яратып, якын итеп. Кызның әнә шул көчле кулларга һәрвакыттагыча буйсынасы, үзен алар ихтыярына куясы, иркәләтәсе килде. Күзләрен йомды... Бөтен тәненә ут капты, эссе йөгерде... Сабыры төкәнде... Моннан ары да түзеп тора алмады һәм егеткә таба омтылды, гәүдәсенең бөтен кайнарлыгы, хисләренең ташкыны белән аңа сыенды...

Габделнур бертуктаусыз аның яшьле күзләрен, тулышып торган сусыл иреннәрен үпте, колагына ятышлы иркәләү сүзләре пышылдады. Кыз да аны бөтен барлыгы, дәрте белән назлады...

## XX

Эштән иртәрәк «ычкынып», Габделнур туп-туры университет китапханәсенә ашыкты. Үзенә кирәкле китапны алып, залга кереп утырды. Әйләнә-тирәсенә күз салды: Энҗе икенче почмакта утыра, ахры. Егет су эчәргә дип чыгып керде һәм кызның монда икәнлегенә тәмам инанды. Утырды, укый-укый яза башлады, башын күтәреп тирә-ягына карап алгалады.

Бераздан кыз янында урын бушады, егет шунда күченде. Әкрен генә сөйләшә, көлешә башладылар, шул ук вакытта уку-язуны да онытмадылар. Энҗе кирпеч калынлыгы «Капитал»ны конспектлый иде. Сигез туларга егерме минут кала ул бер сүз дә әйтми чыгып китте.

Тугызынчы яртыда Габделнур да китапханә белән саубуллашты. Истфак каршындагы бакчага кереп утырды, тәрәзәләргә карады. «Күтәргәме, юкмы?» Торып, сул кул якка таба аска төшеп китте. Матбугат йорты каршындагы троллейбус тукталышына килеп басты. Янә уйга калды. Җәяү атлады. Кире килде.

Троллейбуска утырды да үзенчә фикер йөртә башлады: «Күпердә төшәрмен. Юк, «Рабочая» тукталышында төшеп калырмын да кире килермен».

Троллейбусның тәрәзәләре ачык. Казансу елгасы ягыннан җылы җил исә, балык исе борынга бәрелә, әнә балыкчылар да күренә. Яшь-җилкенчәк су коена. Баганаларда утлар яна, район эмблемасы колач җәеп юмартлыгын күрсәтеп, кунаклар чакырып тора. «Рабочая»да төшмәде, чираттагысы да артта калды—ары китте.

Ул фәкать «Волгоградская» тукталышында гына троллейбустан төште һәм түбән таба торып йөгерде. Тулай торакка кайтып, иненә пиджагын элде, бик кадерләп кәгазьгә бер әйбер төрде, кабаланып чыгып чапты. Троллейбуска утырып кире китте. Вакыт егерме минутны күрсәтә иде. «Чистопольская»да транспорттан төшеп калды. Каршы якта, кибет янында, туңдырма саталар икән. Ул чатка кире килде, урам аркылы чыкты һәм кызның кайту юлы буйлап китте. Каршыга Энҗенең иптәш кызы килә иде. Исәнләштеләр.

—Кая барасың?—дип сорады күрше кызы.

—Аны көтәм. Ә син?

—Иптәш кызларга. Иртәгә куна барабыз. Эштә, чирли, дип әйтергә кирәк. Хәлләр ничек?

—Әйбәт.

—Уку ничек? Ял итәсеңме?

—Тиздән имтихан. Иртәгә һәм берсекөнгә укыйм.

—Ни пуха, ни пера!

—К черту! Рәхмәт.

Кыз йөгерә-атлый үз юлында булды. Габделнур да кире борылды, тукталышка китте. Газета укып алды, тагын китте, тукталышта көтә башлады. Троллейбус үткән саен тәрәзәләренә текәлеп карады.

Уртадагы трамвай юлын аркылы чыкканда бер адәм егылды. Почмакта ике милиционер тора иде, берсе сыбызгы сызгыртты. Тегене күтәреп торгыздылар, ләх исерек икән.

Габделнур, кулындагы төргәген саклык белән генә тотып, тупылга сөялеп тора иде, янә троллейбус килде һәм Ул күренде. Энҗе дә аны абайлады булса кирәк, ләкин төшкәч ары киткән булды. Әмма бер-ике адым атлагач туктады һәм егеткә таба килә башлады.

Янәшә атлап киттеләр.

—Нигә көтмәдең?

—Өйгә кайттым.

Кыз ышанмады.

—Алдама.

Габделнур уйлап куйды: ул бит көндез пиджак кимәгән иде, игътибар итми микәнни?

—Чын әйтәм.

—Ә кулыңдагы газетаң?—дип төпченде кыз.

Егет, тотылдым, дигән сыман, юри көлде.

Энҗеләр урамына кайтып җиттеләр дә каршы йорт капка төбенә килеп бастылар. Бераздан кызның әнисе чыкты.

—Энҗе, озак торма,—диде дә бәләкәй капка артында юк булды.

Берникадәр вакыт сөйләшеп, үбешеп торгач:

—Мин керим инде,—диде кыз.

—Күзеңне йом.

—Нигә?

—Йом инде.

Габделнур, кулындагы төргәкне сүтеп, газета эченә яшерелгән әйберне Энҗенең кулына тоттырды.

—Ой, нәрсә ул?

—Роза.

Фәкать шуннан соң гына кыз күзләрен ачты һәм кычкырып җибәрде.

—Ой, нинди матур! Ап-ак!

Егет аны эштә пенопласттан үзе ясаган иде...

... Габделнур белән Энҗе иртән сәгать унда очраштылар. Чәчәк алырга дип сөйләшкәннәр иде, чөнки бүген немец теленнән сынау бирәсе. Өченче көн егет зачет тапшырды—кырык мең билгене. Ике ел дәвамында, тырыша торгач, ул хәтсез генә сукалый да башлады. Күптән түгел завод поликлиникасында (эштә сул кулының уч төбенә отвертка белән ялгыш кадаган иде) бер немец инженеры белән вата-җимерә булса да гәпләшеп тә алдылар. Белгеч полиэтилен комплексын җиһазларга килгән дә, бераз сырхаулап тора икән. Габделнур тегенең үз телендә әйтә, ә немец—урысча. Шулай итеп берникадәр вакыт сөйләшеп тордылар. Немецчә өйрәнүнең тагын бер сәбәпчесе бар—участокта саф немка эшли. Аларның гаиләсе, сугыш башлангач, Идел буеннан Себергә куылган булган. Кызый шунда туган. Унны бетергәч, укырга керү нияте белән Казанга килгән, әмма конкурстан узмаган. Озак уйлап тормыйча төзелешкә урнашкан. Ләкин биредә тоткарланмас шикелле: бик белемле, үзалдына зур максатлар куеп яшәргә өйрәтелгән. Кызый бик тәртипле, пөхтә, пунктуаль, эшен дә җиренә җиткереп башкара. Габделнурга ул хөрмәт белән карый һәм аның белән ана телендә сөйләшергә тырыша: бердән, үз телен ихтирам итеп онытмаска

тырышса, икенчедән, егеткә практик күнегү бирермен дип уйлый иде.

Имтихан уңышлы үтте: Энҗе бишлегә бирде, ә Габделнурга дүртлесе дә бик җиткән. Ресторанда урын белешкәннәр иде, вакытында бара алмадылар, бер кызны күтәргә туры килде. Укытучы теге студентка өч куйган. Белеме шулай гына булгандыр инде, бик гадел укытучы иде югыйсә. Ә теге моңа риза булмыйча тагын билет сорап алган, янәсе, бишкә, һич югы дүрткә бирә. Кичке бүлектә укучыга ни пычагыма кирәк инде ул?

Энҗе һәм тагын берничә курсташы укытучыны аудиториядән чакырып чыгардылар, ашыгуын үтенделәр.

—Юк, мин аның белән эшне төгәлләмичә китә алмыйм,—диде укытучы.—Дөрес, мин аңа барыбер өчледән артыгын куймыйм, зачетын да көчкә генә биргән иде. Шулай да күтәргә туры килер.

Ниһаять, берникадәр вакыттан соң Бауман урамындагы «Казан» кунакханәсенә киттеләр. Билгеле, укытучы да алар белән барды.

Урамда, ишек янында, швейцар үтенече буенча бераз көтеп торырга туры килде. Чөнки ул иңнәренә фотоаппаратлар аскан, кара күзлекле, ак киемле өлкән яшьтәге кешеләрне эчкә үткәрде. Болар—хатын-кызлар чалбардан, ә ир-атлар шортыдан—берәр теплоходтан төшкән чит ил туристлары иде. Үз-үзләрен тәртипле, итагатьле тотуларыннан һәм ят телдә сөйләшүләреннән Габделнур шулай дип фараз кылды. Алар мрамор вестибюльдә тукталып тормыйча, парадный баскычтан өскә, икенче катка—Кызыл һәм Зәңгәр залларга менеп киттеләр.

Габделнурлар исә беренче каттагы, халык телендә «Яшел кафе» дип йөртелгән залга урнаштылар. Тыштан кергәч тә сул яктагы, тәбәнәк түшәмле, матур итеп бизәлгән залда кеше күп, җыр-музыка яңгырый. Өерелеп килеп кергән студентлар чуар иде: урта яшьтәгеләр генә түгел, яшь кызлар да байтак. Ресторандагы егет-җилән, ир-атлар аларга караштыра да башлады. Озак та үтмәде, бер әрсезе Энҗене танцыга да чакырды. Кыз бик теләп риза булды, Габделнурдан рөхсәт сорау түгел, әйләнеп тә карамады. Хәер, алар танышлар иде, ахрысы. Бик якын кешеләр кебек, авызга авыз куеп сөйләшә-көлешә дә башладылар, Энҗе тәмамысы аңа сыланып бетте. Кызның сул кулы ир кешенең җилкәсендә, башы иң өстендә, салмак кына агылган музыка уңаена биепме бииләр. Тора-бара кыз дөньясын онытты бугай: бераздан боларның чәчләре чәчкә «бәйләнеп», аерылмас хәлгә килделәр, бер-беренең кочагына кереп беттеләр... Моны күреп утырган Габделнур гарьләнде, ачуы чыкты. Энҗенең өстәл янында калган иптәш кызы егетнең кәефе үзгәрүен сизенде.

—Син нәрсә, аңа гына үпкәләмиләр инде. Подумаешь, танцыга чакырганнар...

Габделнур дорфарак эндәште бугай, теге тәмам чыгырыннан чыкты һәм Энҗе килеп утыру белән егетне хурлый башлады. Янәсе, ул «юнылмаган», һаман шәһәр тормышына гадәтләнә алмый... Энҗе—хәйләкәр нәрсә—егетнең үзен биергә чакырды. Габделнур баш тартты. Кыз ялынып тормады, кабат уртада бөтерелә башлады...

Кайтканда Габделнур текәп-текәп Энҗегә карады һәм үзенчә фикер йөртте: «Ничектер жәл бу кызый, ләкин башкача булмас ахры. Ул үзе дә шуны тели сыман. Әнә бит ничек турсайган...»

Әнисе ишек ачарга чыкты. Габделнур итагатьле генә исәнләште, Энҗегә исә:

—Котәм,—диде.

Кыз кереп китте дә янадан чыкты. Ләкин сөйләшүнең ата-анасы булмады. Һәм Габделнур, саубуллашып, әкрен генә китеп барды. «Ул кызганыч...—дип уйлады егет кайта-кайтышлый.—Пожалуй, соңгы тапкыр

атлавымдыр ике елга якын тапталган сукмак-юлдан...»

...Бүген Габделнурның бер минут та буш вакыты булмады: эштә дә әле бер нәрсә, әле икенче нәрсә дигәндәй килеп чыга торды, ә будкада, өстәлдә, ачып куелган китабы көтеп ята. Ни өчен дигәндә, КПСС тарихыннан сынау бирәсе бар.

«Бегемот»та курсташларыннан берәүне дә очратмагач, ул университетның төп бинасына йөгерде. Ни гаҗәп, анда да кеше юк. Ленин урамы буйлап кире килде. Көтәргә булды. Ниһаять, укытучы пәйда булды, өч курсташы килде, бераздан аларга тагын берәү өстәлде. Билет алгач, егетнең эченә җылы керде, бөтен борчулары таралды: сораулар таныш һәм ул аларны биш бармагы кебек белә иде. Озак утырмады, өченче кеше булып җавап тотты. Озын буйлы, ябык чырайлы укытучы артык җәфаламады. Хәтта соңгы сорауга җавапны сөйләтеп тә бетермәде.

—Житәр.

Кош тоткандай сөенеп коридорга чыккач, ике курсташы зачеткасын тартып алдылар һәм, андагы билгене күргәч, бердәм кычкырып җибәрделәр.

—Оһо! Бишле! Тәбрик итәбез!

—Рәхмәт.

—Карале, Гаделҗанов,—диде бер сабакташы тавышын баса төшеп һәм аның учына дүрткә бөкләнгән кәгазь төртте.—Мә, Зайцевага кертеп бир әле. Ул еларга җитешеп утыра. Берни белми.

—Ничек керергә соң?—дип сорады имтиханнан котылу шатлыгыннан әле һаман зиһенен җыя алмаган Габделнур аптырап.

—Берәр нәрсә калган диген.

—Ярар.

Габделнур тәвәккәлләде. Аудитория ишеген ачуга укытучының кылыч борыны аңа таба борылды.

—Нәрсә бар?

—Әйберем калган.

—Кер.

Егет әле генә үзе торып киткән өстәл астын караган арада кулындагы кәгазьне авыр хәлдә калган курсташ хатынга ташлап өлгерде. Һәм чак кына укытучыга эләкмәде: теге, урыныннан торып, аңа таба килә башлаган иде. Бәлагә юлыкканчы егет чыгып ычкынды.

Аны ишек төбендә дүрт күз белән көтеп торган сабакташына:

—Булды,—диде.

—Рәхмәт.

—Чүт кенә «янмадым».

Көлештеләр. Габделнур, иптәшләрен коридорда калдырып, чыгып китте.

Урамда кояш, җылы. Кремль сәгате кичке җидене күрсәтә. Егет Спасс башнясы астындагы ачык капкадан таркау гына атлап килүче ике солдатны күрде. Әйе, аның да болар кебек гамьсез чаклары бар иде. Ә хәзер... берөзлексез чатыр чаба. Ул баскычтан түбән таба төшеп китте. Урна өстеннән сикерде. Җиңел, рәхәт иде аңа, әйтерсең лә иненнән тау төшкән. Үтеп баручы өч кыз, чүп савыты аша сикерүче «тиле»не күреп, шырык-шырык көлделәр. Ә ул—шат, көлмәгәйләре тагы...

...Энҗеләр бүген сынау бирделәр. Ләкин бу юлы Габделнур аның янына бармады. Чөнки унысы көнне ТАССР тарихыннан үзе имтихан тотарга тиеш иде. Шулай да күңеле тыныч түгел. Һәм ул, максатын үзе дә анык белмәстән, нигәдер шәһәргә китте. Чернышевский тукталышында төшеп калды. Бауман урамыннан бара башлады. Алга табан—урамның теге ягына

караса—Ул килә. Беренче уе—каршына чыгу иде. Ләкин Энже аяк киеме салонына кереп китте. Габделнур, аның тиз генә чыкмасын чамалап, авторучкага паста сала торган мастерскойга барып килде һәм баягы урында көтә башлады.

Менә Энже, салоннан чыгып, өскә таба менеп китте. Егет аны «Спутник» кинотеатрына бара, ахры, дип уйлаган иде. Ләкин кызый ары китте һәм бер ишегалдына керде. Керер алдыннан артына, як-ягына каранды.

Егетнең исенә төште: кызый анда элек тә барып йөргән иде...

...Сынау биреп чыккач, гадәттәгечә шатлык кичерде, үзендә ниндидер жиңеллек тойды—гүя канатлар куйганнар. Көне дә гаҗәп матур бит. Аның бөтен вөҗүден куаныч биләп алды. Менә ике курс тәмам. Алда—калган өчесе. Әлбәттә, җиңел булмаячак. Ләкин... «Тәвәккәл таш яра, диләр бит, тырышырбыз,—диде Габделнур үз-үзенә нык ышаныч белән.—Башланган эш—беткән эш».

Егет киосктан аяк киеме чистарта торган крем алды. Бер сум биргән иде, китеп бара икән.

—Сдача ал,—диде киоск хуҗасы.

Тулай торакка җитәрәк бер йортның икенче кат балконыннан сигез-тугыз яшьләрдәге бер малай почмаклап бөкләнгән кәгазь самолет очыра иде. Аны җирдән алып, Габделнур өскә, тегеңә төбәп җибәрде.

—Истребителеңне тот!—дип кычкырды.

Малай да елгыр нәрсә булып чыкты—момент эләктерде. Кулын алга табарак сузып, олы абыйсына эндәште.

—Тот.

—Шаярма. Кабат сиңа җибәрмим. Үземә алып калам.

—Ә-ә, хәйләкәр.

Икесе дә елмаештылар.

—Рәхмәт.

Малайга каршы чит абый да кул изәде.

—Хәзергә.

Куанычы эченә сыймаган Габделнур кайта-кайта уйлап куйды: «Кешенең яшәеше шулай корылган инде—һаман алга барырга кирәк. Әгәр велосипедка атлангач, чылбырын-педален әйләндермәсәң—авасың. Димәк, тормышта да син үзеңне һәрдаим велосипедка утырган кеше кебегрәк хис итеп яшәргә тиеш—алга омтылып».

## XXI

Габделнур мунчадан чыкты. Бераз тын алды. Эссе мунчадан соң кичке саф һава күкрәккә бертөрле рәхәтлек биреп гүя үзе кереп тула иде: сулаган саен сулыйсы килә. Әйләнә-тирәдә ник шылт иткән аваз ишетелсен—авыл жиремени! Хәер, бу бистә чын авылны хәтерләтә бит. Шуңа күрә дә егетне бу якларга аяклары үзләре алып килә. Юк, аяк кына түгел, моны күбрәк йөрәк хәл итә.

Куе зәңгәр күк йөзенә, анда җемелдәгән йолдызларга, бер кичне карасаң түгәрәк ипи кебек тулышкан, ә аннан күпмедер вакыттан урак кебек кенә нечкәреп, кыяфәтен алыштырып галәм гизүче айга карап, сокланып торды.

Таш җәелгән (аны түшәүдә Габделнурның да кул көче кергән иде) тар сукмактан өйгә таба атлады. Өйалды баскычына меним дигәндә генә эчтә кешеләр сөйләшкән аваз колагына керде. Егет туктап калды һәм таныды: ана белән кыз әрепләшә икән.

Калынрак тавыш сорады.

—Нигә аларга бардың?

—Кунакка кайтты бит.

Анасына җавап итеп моны йомшаграк тавышлы Энҗе әйтте.

—Нәрсә калган сиңа анда? Оныт аны!

Анасының кискен итеп әйткән сүзләренә бу юлы кызы да шундый ук тонда җаваплады.

—Мин ничек аны оныт ыйм! Ул минем беренче мәхәббәтем!

Рөхсәтсез кеше хатын укуны өнәмәгән, гайбәт сөйләүне җене сөймәгән егет, боларның сүзен читтән, үзләренә күренмичә, качып-посып дигәндәй тыңлап торуны яхшысынмаса да сүзнең үзенә дә кагылышлы булачагын тоемлап, урыныннан кузгалмады, мыштым гына басып торды. Әйтерсең, ботинка табаннары ишек төбенә җәелгән резинага ябышты.

—Беренче мәхәббәт имеш?! Беренче тапкыр астына яткан егетем диген. Оятсыз!

—Ул мине ярата.

—Ә нигә алайса син корсакка узгач өйләнмәде? Койрыгын сыртка салды, ә?

Энҗе нидер әйтте. Тавышы зәгыйфь, тонык чыкты. Сүзләре әрнеп әйтелгән сыман тоелды. «Ярама тоз салма!» дигән кебегрәк ишетелде.

Тагын Тәгъзимә апа тавышы.

—Сине тугач та йөзтүбән әйләндереп яткырасы калган икән. Унбиш яшеңнән себерелә башладың.

—Анысы синең эш түгел.

—Мин—анаң! Күпме күз яше түктем синең өчен кайгырып... Кеше күзенә күренергә оялып йөрдем. Ә син...

—Колак итемне чәйнәдең инде... Бер мин генәмени? Кызларның күбесе шулай итте.

—Кеше коега да сикерер... Габделнур сизсә тегенең янында кунганыңны?

Бу юлы ананың тавышы йомшады. Бу инде усалланып түгел, ә борчылып әрләү иде. Әлбәттә, кызы язмышы өчен.

—Каян белсен ул аны? Син—әйтмисең. Аның башына да кермәс. Ул—авыл гыйбады.

Бу җавап Тәгъзимә апага ошамады. Сүрелә башлаган «учак» янә дөрләп кабынып китте.

—Нәрсә син ике сүзнең берендә, авыл гыйбады, авыл гыйбады, дип кеше кимсетәсең? Булса соң?! Дастуен җегет. Төтен өрми, тиктомалга аракы чөмерми. Тагы ни кирәк сиңа?! Бөтен эшкә кулы ятып тора... Булмаган үгезне көтеп бозаудан мәхрүм калма...

Энҗенең тавышы көчәйгәннән-көчәя, кызганнан-кыза барды. Ул истерикага тартым халәткә җитеп килә. Бу—Габделнур өчен яналык иде.

—Ул хәерчегә чыгып, мин хәзер тулай торакка, аның янына күчимме?

Анасының да тоны үзгәрде, ләкин киресенчә—йомшарды, үгет-нәсыйхәт биргәндәй тынычланды. Хәтта, әрләшүләрен дә онытып, беренче тапкыр Энҗегә, кызым, дип мөрәҗәгать итте.

—Кызым, байлык чиләк белән тулмый, тамчылап тула. Эшләрсез, фатир да алырсыз. Ул бит стройкада, ә анда квартир бирәләр. Башта үзебездә торырсыз. Кооперативка да акча җитәрлек. Алып бирәм...

Энҗе әнисен ярты сүздә өзде, үзенең тавышы киселде, әрнеп-еламсырап әйтте.

—Ә аның бу хакта ишетәсе дә килми. Мин кылын тартып караганыем, иптәш кыз кияүгә чыкты, ире аның янына күчеп килде, дип. Ул ничектер җирәнеп, ямьсез итеп әйтте.

—Йортка кергәнче, б... кер, дигәндер. Ызначит, үзенә ышана,—диде анасы басынкы тавыш белән.

Кооператив фатир алырлык кына хәлләре бардыр. Монысына Габделнур шикләнми. Чөнки бер мәртәбә Тәгъзимә апаның өстәл янында тиен акча санап утырганына тап булды. Димәк, хезмәт хакыннан тыш чумара да керә, дигән сүз.

Озаклап, керер-кермәс, шымчы сыман ишек артында торуны килештермәде егет. «Имәндә икән чикләвек, «Мадрид сараеның серләре» ачыла,—дип уйлады да, тавыш чыгармаска тырышып, сак кына басып, мунча юлына таба кире китте.—Ә мин юләр... Акыллы һәм көчле кешеләрнең бер йомшак ягы бар—аларның ышанучанлыгы, дип юкка гына әйтмиләр шул. Хәер, монда нәрсәдер бар, эшләр чиста түгел, дип шикләнә идем аны...»

Ул, ишеген чак кына күтәрә төшеп, акрын гына ачты да шыпырт кына мунча алдына керде. Анда озак юанмады, ишекне каты итеп ябып, тышка чыкты, тамак кырды, төчкергән булды. Аның бу хәйләсен күреп-күзәтеп торучы, утыз көн үткән саен кыяфәтен үзгәртүче айга карап, егет елмайды, бармак янады. «Менә шулай, ай дус, син генә түгел, бөтәннәр дә кыяфәт алмаштыра: еланнар кабыгын сала, җәнлек-җанвар йонын коя, хамелеон төсен үзгәртә, ә кешеләр... аларны әйткән дә юк инде—барысыннан да мәкерле һәм хәйләкәррәк, хәтта елына дүрт тапкыр каурыйларының төсен алыштыручы Шотландия кошлары—грауcларны да (егет алар турында кайсыдыр журналда укыган иде) уздырып җибәрәләр.

Бу юлы юри каты басып болдырга менде. Янә тамак кырды. Ашыкмыйча гына ишекне киереп ачты. Өйалдында кеше юк иде инде. Ул кухня ролен үтәүче кече якка узды. Ана белән кыз берни булмагандай мөлаем чырай белән өстәл янында утыралар иде. Гүяки әле баягынак кына пәрмә-пәр талашмаганнар да, әрепләшмәгәннәр дә.

—Хуш рәхмәт мунча хөрмәтенә,—диде Габделнур якты йөз белән баш кагып, аны әбиләре кечкенәдән шулай әйтергә өйрәткәннәр иде.—Бик әйбәт булды: пары да шәп, себеркесе дә хуш исле, суы да кайнар...

—Салкын су җиттеме соң?—дип сорады озын җиңле күлмәк кигән, яулыгын чөеп бәйләгән Тәгъзимә апа егетнең байлар төсе кергән таза, чиста йөзенә сокланып.

—Җитте, әле калды да.

—Кызым, Габделнурга сөртенергә зур сөлге бир, алдына җәяргә—кечкенәсен.

—Сые бар—хөрмәте юк, дип әйтмәсен дисеңмени? Булыр аңардан, гаеп-кыегыңны эләктерергә генә тора.

—Кая инде,—дигән булды егет. Энҗе биргән алъяпманы тез өстенә салып,—син бөтенесен үзең белеп эшлисең бит.

—Ярар, ярар, теленә салынма.

—Кызым, Габделнурга чәй ясап бир.—Аннары хуҗа хатынның тулы битле чырае кабат егеткә таба борылды.—Мунча яккан саен сиңа рәхмәтләр укыйм инде: электр керттең, утынын кисештең, ярып бирдең. Әйдә, берәр рюмка саласыңмы?

—Юк. Кирәкми. Рәхмәт. Хотя Суворов, мунча чыккач актыкны портянкаңны сатып булса да бер чәркә тот, дигән.

Аның уйнап әйткән сүзләрен хуҗабикә чынга алды.

—Шулай булгач...

—Болай гына әйтүем. Рәхмәт. Без армиядә шулай шаярта идек.

Энҗе тәрттереп алды.

—Салып бирәләр идеме соң?

—Анда кем бирсен,—дип елмайды егет кызга карап.—Старшина чираттан тыш өч нәрәт бирсә генә инде. Командирдан гауптвахта гына көтәргә мөмкин.

Энже төче елмайды. Бизәкле халатының өске төймәсен каптырмаган иде, чәй биргәндә юри иелде—егетне ымсындырып алды.

—Әйдә утыр, солдат, ашарсың да. Суворов, щи да каша—пища наша, дип тә әйткән бугай ул. Алары юк, бигайбә. Өчпочмак ярармы?

Кызның кинаясен аңлаган Габделнур:

—Ярамаган татарга каз ите,—дип көлеп җибәрде, урындыкка чөмәште.—Эт корсагына сары май килешер микән, дип әйтүең түгелме?

—Нәкъ шулай...

Энже чүмәләкәй тулы коштабакны егет каршынарак куйды, сай тәлинкә дә бирде. Тәгъзимә апа аны шелтәләгәндәй итте.

—Кызым, телең ни әйткәнне колагың ишетсен.

—Ә ул үпкәләми,—диде елмаеп кыз һәм егеткә күз кысты.—Әйеме, майн либен[3]?

Монда эшен беткәнгә санап, кыз алгы өйгә кереп китте.

Күрәсең, анасы төп мәсьәләне бүген хәл итәргә ният кылган: өстәл астыннан бер шешә тартып чыгарды, ике стакан тутырып салды. Һәм, бер тын икеләнеп, уйга батып утырды да, беренче тапкыр Габделнурга гадәттәгечә исеме белән коры гына түгел, ә ягымлы тавыш белән, ничектер бик үз итеп дәште.

—Әйдә, кияү, тот әле. Мин дә бүген бик арып кайтканыем.

—Ә абый?—дип сорады егет күзгә-башка бүтән чакта да бик сирәк күренүче, әллә ни тавышы чыкмый торган йорт хуҗасын—Тәгъзимә апаның ирен истә тотып.

—Ул үзенә тиешлесен «кабып» ятты инде. Иртүк торасы бит. Арып та кайта.

Габделнур бераз аптырашта калса да «булачак әби» эһ тә итмичә стаканын бушаткач, ык-мык итеп тормады—«җегетлек» күрсәтте—ике тында эчеп куйды.

—Менә булдырдың,—диде табын хуҗасы сул кулындагы өчпочмакны шактый мулдан кабып.—Тамагыңа аша.

—Рәхмәт.

Һәм Габделнур дөрес фаразлаган булып чыкты: сүз тормыш-көнкүрештәге вак-төяктән башланып, көнүзәк мәсьәләгә—ике яшь йөрәкнең кавышуына табарак авышты.

Өчпочмакны озак сузмыйча хәл иткәч, хуҗа хатын, авызын электр самавыры янындагы ак шадра тастымал белән сөртте, бал савытын «кияү»гә табарак этәрде, үзенә чәй агызды.

—Син инде бала-чага түгел, әрмис шулпасын да эчкән, кайтканыңа да өч ел тула... Энҗенең дә яше бара. Укуын бетерсә дә була иде югыйсә... Бер-берегезне яраткач нишлисең инде...

Гәрчә аңардан әле кызын сорап килүче булмаса да, (буйлы ыштанының бер балагын сызганып яки читек өстеннән чыгарып куйган яучы карчыкны да җибәрүче юк) «әбекәй» әнә шулай, «ялындырыбрак» фатихасын бирде.

Әлбәттә, егет аш белән атканга таш ыргыта алмый—бу мәгънәсезлек булыр иде. Сый-нигъмәт тулы өстәл янында, бигрәк тә кыз өендә, юк, өйләнмим, фәлән-фәсмәтән дип, кәҗәләнеп, сүз озайтмады, «булачак әби»сенең кәефен кырмады—җаена гына торды. Әле бераз иртәрәк икәнен искәртеп, әмма нияте барын белгертте, чөнки хәзерге мәлдә кирегә сукалау, бәхәс куерту файдасыз иде.

—...Тагын салыйммы?—дип шешәгә үрелде бу сүзләрдән бик канәгать калган «булачак әби».

[3] Майн либен — мой любимый (нем.).

«Кияү» стаканын читкә этәрде, зиһенен чуалтасы килмәде.

—Юк. Рәхмәт. Мунчадан соң иң тәмлесе—мәгрүшкәле сөтле чәй.

—Үзеңә кара.—Аннары Тәгъзимә апа алар янына чыккан кызына дәште.—Габделнур бүген бездә генә кунар, урынны икегезгә бергә җәй.

Энҗе, чын әйтүеңме, дигәндәй, анасына текәп карады. Алар берсен-берсе күз карашларыннан аңладылар һәм икесе ике төрле сөенделәр: кызын һәрдаим сагалап йөрүдән гарык ана, ниһаять, аны «олактырачагына» өмет итсә, кыз исә моннан ары кайда туры килсә шунда егеткә бирелергә мәҗбүр булмаячагына шат иде. «Иртәгә үк таныш юлдан больницага барып, төшереп кайтам,—диде кыз өйгә кереп барышлый күңеленнән һәм авызын кыйшайтып көлеп куйды.—Чиста килеш кияүгә чыгам». Чөнки аның тагын буенда бар иде. Егет күңелендә шик-шөбһәгә урын калмаслык булсын. Сәбәпләрен кыз үзе генә белә...

«Әби»нең әйтер сүзе, «фәлсәфә»се бетмәгән икән әле—теле ачылды. Кияүне кулга ияләштерү процессы дәвам итте.

—Син хәзер инде безгә чит кеше түгел,—диде Тәгъзимә апа урындыгын егеткә якынрак күчереп.—Кызыма да, безгә дә бик ошадың.

—Рәхмәт.

—Без, олырак кешеләр, тормыш уфалласын күбрәк тарткан, нужа суын күбрәк эчкән. Беренче елларны оя коруның читен яклары хәттин ашкан була. Бигрәк тә авылдан килеп төпләнгәннәргә. Торырга үз куышың булмау кимсетә, җитмәүчелек җелеккә төшә, барып сыенып кешең юклыгы... Безнең, шөкер, хәзер дөнҗабыз җитү, бөтен кайгыбыз, тапканыбыз—балалар өчен... Алар өчен дип дөнҗа көтәбез. Сездән берни дә кызганмабыз...

Һәм Тәгъзимә апа, кызының бая әйткән сүзләрен исендә тотып, егетне үпкәләтмәскә, аның мин-минлегенә кагылмаска тырышып, ләкин бик кыенга килсә ярдәм кулы сузачакларын, ягъни мәсәлән, фатир ягын хәл итүне үз өстенә алачагын да җай гына төшендерде. Әмма ул моны,—анның кына маялары барын,—Габделнурның хәтерен калдырмаслык итеп әйтә алды.

Монысына, турыдан ярып әйтмәвенә, егет рәхмәтле калды.

—Уйлашырбыз,—дию белән канәгатьләнде.

Икесе дә бу әңгәмәдән разый иделәр. Ана кеше үз сүзен бик ансат кына үткәзә алуына, егетне җиңел генә ризалатуына чын ихластан сөенде. Димәк, олы хәсрәттән котылачак, иншалла, егет кире чикмәстер...

Ә Габделнур болайрак уй йөртте. «Ни өчен хәзерге мизгелдә юкка бәхәс куертып, үзе әйтмешли «унбиш яшьтән себерелә башлаган» сөекле кызын «бөтен эшкә кулы ятып тора» торган асыл җегеткә сыларга маташкан кайгыртучан ананың кәефен кырырга? Бигрәк тә инде «кияү» дип ычкындыргач. Әйдә, миннән булсын яхшылык»,—диде үз-үзенә эссе мунчадан һәм куәтле хәмердән соң күңеле шактый күтәренке Габделнур. Ул, рәхмәт әйтеп, табыннан кузгалды һәм бераз һава сулап керергә булды.

...Иртәгесен, гадәттәгечә таң белән торып намаз укый торган әбисе, гыйбадәтен тәгәлләп, намазлыгын җыештырып, дисбесен бәбәй итәкле озын күлмәк кесәсенә салып, сәгатькә карап алды да олы якка чыкты.

—Энҗе, кызым, тор, эшеңә соңга калма,—дип кечкенә бүлемнең чаршавын этәргән иде, өнсез калды.—Әстәгъфирулла!

Карчык тизрәк үз бүлмәсенә ашыкты. Чөнки Энҗе урын-җирен караваттан идәнгә төшереп яткан. Тик кортканың сөйкемле иркә оныгы үзе генә түгел, ә егет белән. Кыз башын аның киң күкрәгенә куеп, изрәп йоклый иде әле...

...Туйдан соң дөмбер бәрмәс өчен Габделнур кыз белән ара өзүне озакка сузмаска булды. Чөнки ул аны «чистарынырга» үзе илтеп куйды. Әгәр аннан

кайткач очрашулар тагын элеккечә дәвам итсә, кызның кабат ул тарафка бармаячагы көн кебек ачык иде. Димәк, ана кагылмаска кирәк, юкса, бишмәт итәге белән күз яшенне сөртергә калмагае. Ләкин кызга сиздермичә, алдын-артын нык уйлап эш итәргә кирәк. Әмма иң мөһиме—вакытында ычкынырга! «Финита ла комедия!»—диде егет латин теле дәресендә отып калган хикмәтле гыйбарәне хәтеренә төшереп, ягъни, кәмит уены тәмам. Аерылышу әллә ни үкенечле булмастыр сыман. Авылда бер агай болай дип җырларга ярата иде: «Булмасам дагын туенда, күп йокладым куенында». Әйе, үкенерлеге калмады егетнең. Хәер, кыз да чиләкләп күз яше түкмәстер шикелле.

Шулай да кыз белән аерылышуны ачуланышмыйча, гаугасыз, җайлап-майлап кына хәл итәсе килде. Тик моны ничек башкарып чыгарга? Уйлый торгач, башына бер фикер килде. Ул аны озын-озакка сузмыйча тормышка ашырырга да ниятләде.

Беркөнне Энҗене тулай торакка чакырды. Бераз утыргач:

—Хат килде,—диде.—Сиңа энекәш сәлам әйткән.

—Рәхмәт сәлам китергән кешегә, дип әйтә минем әби. Ниләр яза соң?

—Әллә ни искитәрлек сүз юк. Мә, укы.

Егет, тумбочка тартмасыннан алып, аягын аякка атландырып өстәл янында утырган Энҗегә дүрткә бөкләнгән шакмаклы кәгазь бите сузды. Алдан корган план нигезендә бу «хат»ның караламасын үзе әзерләп, Габделнур эштә бер иптәш егеттәннән акка күчертеп яздырган иде. Астыртын гына Энҗенең реакциясен күзәтте.

Кыз укый башлады һәм... аптырап калды, Габделнурга күтәрелеп карады. Аның соргылт күзләрендә зәһәр очкын кабынды.

—Бу бит энеңнән түгел!—дип кычкырды ул күзен егетнең күзенә терәп.

Габделнур башын юләргә салды, янына килеп «хат»ны кулына алды.

—Ә кемнән?—дип әйләндергәләде

—Бер кыздан! Сиңа!—диде Энҗе һәм «хат»ны тартып алды.

—Ә-ә, гафу ит, ялгышлык миндә. Кая, бир әле анысын, мә монысын,—дип тумбочка тартмасыннан икенчесен алып сузды.

Кыз, дулап, атып бәрде.

—Кирәге бер тиен!—дип чыгырыннан чыкты һәм балавыз сыгарга тотынды.

Габделнур кызны юата башлады, тезенә утыртып, яшьле күзләрен, битен үпте, дәртсез генә иренәнә дә кагылып алды.

—Йә инде, үпкәләмә... Дөньяда андый хәлләр була инде ул... Безнең авылның бер кешесе заманында Минзәлә театрында эшләгән. Хатыны да шунда артистка икән. Артист халкын беләсең инде—чуар йөрәкле—апа бер егет белән шаярган.

—Ничек шаярган? Нигә?

Габделнур кызның татарча сүзләрне аңлап бетермәвен сизеп, көлеп җибәрде һәм тәфсилләп бирергә мәҗбүр булды.

—Ну, йөргән инде, ире өстеннән йөргән. Шуннан, бервакыт апабыз үзе генә санаторийга китә һәм икесенә дә хат яза. Ләкин конвертларын бутый, ялгышлык белән, билгеле.

—Ни белән бетте соң?

—Аерылды безнең абзый, театрдан да китте. Хәзер Казанда, икенче хатын белән яши, Бауман урамындагы банкта бухгалтер булып эшли.

—Син моны әле яңа гына уйлап чыгардыңмы?—дип сорады йомшый төшкән Энҗе.

—Юк инде... Кызлары бар иде бик чибәр, безнең авылга бабаларына

кайтып йөри иде...—Габделнур беравык тын торды, уйчан гына әйтеп куйды.—Әэнекәшнең хатын зерә укымадың. Анда бер бик җитди мәсьәлә бар: миңа авылга кайтып китәргә кирәк.

Бераз ипкә килә башлаган Энже, әле һаман турсайган авызын чак кына җыя төшеп, сүзләрен теш арасыннан сөзеп чыгарды.

—Кайчан? Ялгамы?

—Тиздән. Бөтенләйгә.

—Ничек?

—Шулай кирәк,—диде егет авыр сулап һәм, тегенең аңа иярмәсен белгән хәлдә, юри сорады.—Китәсеңме минем белән?

Кызның күзе шар булды. Егетнең тезеннән сикереп төште, каршына басты.

—Син нәрсә?! Нигә шушылай озак минем йөрәгемне газаплап йөрдең?!

Китүенең сәбәбен сорарга да башына килмәде. Чөнки авылда яшәп тормыш итәргә дучар булу ихтималы зиһенен шултиклем томалады ки, ул берни уйламас, егетнең сүзләренә аек акыл белән җавап кайтара алмас хәлгә килде. Аның кояшка янган кадерле йөзе чит тоелды. Югыйсә, егет кыз күңелендә бөтенләе белән үзләшкән кебек иде ләбаса. Хәзерге минутларда кызның бөтен барлыгы диңгез дулкыннарыдай чарпалана, гасабилана иде.

—Син нәрсә, мине декабрист хатыны дип белдеңме әллә?! Синең арттан Себергә дә китәр дип уйладыңмы? Ялгышкансың...

Тагын беркавым холыксызланып, гарьләнеп эчен бушаткач, Энже, соңгы мизгелдә соргылт чәчле башын горур тоткан хәлдә ишекне шапылдатып ябып, чыгып та китте.

Кыз китте.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Ләкин егет канәгатьләнү хисе кичермәде. Аның бәгыренең кайсыдыр өлешен өзеп алып киттеләр шикелле тоелды.

Габделнурның кайдадыр укыганы бар иде: «Сөю—риза булу, йомшаклык күрсәтү, ярамаган якны күрмәү, гафу итү дигән сүз ул». Димәк, ул да Энҗенең үзенә ошамаган якларын, аның кыланышларын күрмәмешкә салынырга, аңа юл куярга тиеш... Ю-ук, андый тормышның барыбер рәтечираты булмас иде... Ә кызның холкын өйләнешкәч үзгәртергә тырышуга килгәндә... Юктыр, булмастыр ахры, бу иркә шәһәр баласына—май өстендә йөзгән кукәй сарысына—егетнең теше үтмәстер шикелле. Күптән түгел комсомол райкомына эшкә күчкәч, кыз тагы да эреләнә төште. Шуңа күрә китүе хәерле... Китү дигәннән... «Поезд китеп барганда соңгы вагонга көч-хәл белән эләгә алган пассажир хәлендә түгел бит әле син,—диде егет үз-үзенә.—Әле син утырасы поезд алда...»

Йөрәген корт кимерсә дә, котылдым бугай, дип уйлады Габделнур бераздан җиңел сулап, әмма берничә елдан Энже белән бөтенләй икенче шартларда кабат очрашасын әле белми иде...

## XXII

Ир-атлар өчен Җилплощадкада тагын бер тулай торак бинасы өлгерткәннәр икән, Коллективная урамындагыларның күбесен шунда күчерделәр. Габделнур исә Восстание урамындагына эләгә алды, ә Ирекка Кызыл Байрактагы йорттан урын табылды. Шулай итеп, аларның юллары аерылды. Яшерен-батырын түгел, дусты анда озак тоткарланмас—башлыкүзле булырга йөри. Үз куышлары юк, вакытлыча кеше почмагына барып сыенырлар инде.

Габделнур күченгән тулай торакның икенче катында шактый зур

аерым бүлмә бар—кызыл почмак. Кайберәүләр аны ял бүлмәсе дип атый, кичәге солдатлар шаяртып, Ленин бүлмәсе (чөнки һәр хәрби подразделениедә шундый бүлмә бар), дип йөртә. Ләкин эш анын исемендә түгел, ә җисемендә—биредә үткәрелә торган чараларның асылы бер—ул яшьләрне тәрбияләү өчен хезмәт итә. Анда телевизор да бар, теләсән кайсы вакытта кабыз да кара; сирәк-мирәк концерт та куйгалыйлар; төрле истәлекле вакыйгаларга, бәйрәмнәргә яисә халыкара хәлләргә багышлап лекция-докладлар да укыла; шахмат-шашка уйнарга һәм газит-журнал караштырырга да була.

Әмма бүген кызыл почмакта Габделнур моңарчы күрмәгән-белмәгән чара билгеләнгән—ачык хөкем утырышы. Бәлки егет анда кермәс тә иде, ләкин күпмедер күләмдә үзенә дә кагылышы булгач, катнашмый чарасы юк.

Зал егетләр белән тулды диярлек. Ул бүген мәхкәмә йортына охшатып җайлаштырылган—җиһазланган: алда—гадәттәге президиум өстәле артында—моңарчы таныш булмаган кешеләр: хөкем итүче, гаепләүче, яклаучы. Өстәл белән егетләр утырган арадагы бушлыкта ялгыз урындык—гаепләнүченеке. Залга арты белән утырган егетнең ябык аркасына карагач, Габделнур аны тагын бер мәртәбә җәлләп куйды. Ләкин, бер уйласаң, үз бәхетенә үзе төкергән ул адәмне кызганырлык та түгел иде.

Хөкем вакытында үтәлергә тиешле процедураларның бөтенесе дә төгәл башкарылгач, эшкә керештеләр.

Ыспай гәүдәсенә ятып, килешеп торган, үзенә җитди кыяфәт биреп торучы костюм кигән кырык биш—илле яшьләр тирәсендәге хатын-кыз судья бүген каралачак эшнең нидән гыйбарәт икәнен кыскача аңлатып бирде.

Хәрбиләрчә тегелгән киемле утыз биш-кырык яшьләрдәге, тулы, ләкин төз буйлы гаепләүче торып басты. Залга күз ташлады, йомшак кына тамак кырып алды һәм, әйткән бер сүзен, үзле балчыкны коймага китереп чәпегәндәй, яңгыравыклы, үз-үзенә нык ышанган тавыш белән сорау бирде.

—Бу җинаятьне эшләргә сезне нәрсә мәҗбүр итте?

Зал тын калды.

Егет беркавым дәшми утырды, аннары авыз эчендә ботка пешереп алды—нидер мыгырдады.

Залдагыларның беренче рәттә утырганнары да аның сүзен аңламадылар, хөкем иярәренә дә барып ирешмәде.

Бераздан олы яшьтәге, күзлекле, чал башлы, ак пиджаклы яклаучы урыныннан калыкты.

—Иректә ни белән шөгыльләндегез?

—Силикатныйда эшләдем.

—Нигә аннан киттегез?

—Прогул өчен кудылар.

—Ә кайда яшәдегез?

—Фатирда, кеше почмагында.

Яклаучы чокчынуын дәвам итте.

—Өч ел түзгәнсез, тыелып торгансыз. Ә нигә гомер буе булдыра алмадыгыз? Нәрсә этәрде. 1956 елда сез яшь булгансыз, илле жиде-алтмышынчы елларда эшләгәнсез һәм... урлашу.

Адвокат гаепләнүчене төрле яклап капшап карый, сорауларны әзлекле рәвештә генә бирми.

—Гаделжанов белән ничек таныштыгыз?

—Очраклы гына.

—Ә нигә урладыгыз?

Егет дәшмәде.

—Сезне эшкә урнаштырдылармы? Урнаштырдылар. Аванс биргәннәр. Сезнең гомумән иректә булырга теләгегез бармы?—дип сорар итте адвокат аптырагач.

—Бар. Мин теләдем дә. Ләкин кая гына барсам да ерткыч җанварга караган кебек карыйлар.

Яклаучы түзмәде, ачуланып дәште.

—Алай әйтергә бернинди дә нигез юк. Бер белмәгән-күрмәгән егетләр сезне тулай торакка алып кайтканнар, ашатып-эчерткәннәр, урамда калдырмаганнар, төзү идарәсендә дә сездән йөз чөермәгәннәр: эшкә алганнар, аванс язганнар.—Ораторның ачуы сүрелә төште, тавышы йомшарды.—Сезнең үтенечегез нидән гыйбарәт? Суд нәрсәне искә алырга тиеш? Тәүбә, үз гаебеңне эчкерсез тану, иректә булу теләге—шуларнымы? Кайсын?

Гаепләнүченең мин-минлеге кузгалды бугай—бөтенесен шаккатырды.

—Теләгем: чыкканда акчам булырлык итеп төрмәдә эшләргә.

Егетнең бу сүзләрен ишеткәч, зал бермәл аптырашта калды, аннары гөжләп алды. Мондый җавапны берсе дә көтмәгән иде, күрәсең, өстәл башындагылар да бер-беренә карашып алдылар. Судья залны тынычландырырга мәҗбүр булды. Аннары хөкем шаһитлардан сорау алуга күчте.

Тегенең белән бер бүлмәдә яшәүче озын буйлы, ябык гәүдәле, яшь егет торып басты.

Бүлмәдәш егетләрнең тагын берсе җавап тоткач, чират Габделнурга житте.

—Получка алдык,—дип сүзен башлады ул торып баскач.—Ял көнне бер иптәш белән шәһәргә чыктык. Бу колхоз базарында тора. Кыяфәте бик кызганыч. Үзебез белән иярттек, ашаттык. Безнең бүлмәдә төн кунды, чөнки бер карават буш иде ул кичне. Аннары, икенче көнне, үзем эшли торган идарәгә алып киттем, кадрлар бүлегенә кертеп калдырдым. Шулай итеп, ул эшкә урнашты...

Тулай торакта политрук булып эшләүче юантык бәләкәй гәүдәле ир кеше, сөйли башлаганчы, сул кулы белән күзлеген төзәтеп куйды.

—Бер атнадан соң, бүлмәләрне карап йөргәндә, санитария кагыйдәләренең үтәлешен тикшергәндә, шифоньер артыннан аның пиджагы килеп чыкты... Аны буфетта әллә ничә мәртәбә бушлай ашаттылар, егетләр акча түләделәр...

Трестның кадрлар бүлеге башлыгы чыгыш ясады, аны тулай торак коменданты алыштырды.

Прокурор үзенең гаепләү нотыгын артык озынга сузмады, аның таләбе каты һәм конкрет иде.

—Ул РСФСР җинаять һәм гражданлык кодексының йөз дә кырык дүртенче маддәсенең икенче кисәге нигезендә җавапка тартылырга тиеш...

Аңардан соң мәхкәмәче адвокатка сүз бирде.

—Урлашу—хәзерге вакытта сирәк күренеш,—дип башлады нотыгын адвокат һәм аны озакка сузды.—Бу—гадәттән тыш вакыйга...

Габделнурның хөкем процессында тәүге мәртәбә катнашуы иде. Шуңа күрә мондагы һәр нәрсә аңарда кызыксыну уятты, ул һәр чыгышны игътибар белән тынлады. Ләкин яклаучының сүзләре аңа аеруча нык тәэсир итте. Чыгышы озынга сузылды сузылуын, авыл картлары әйтмешли, дилбегә буе булды, күрәсең, шулай кирәктер. Чөнки ул мәсьәләне тирәнтен аңлап,

белеп сөйли һәм жай белән генә бу байгышны ничек тә акларга тырыша, бу бәладән (яңадан утыртылу, төрмәгә озатылу ихтималыннан) йолып калырга омтылуы сизелә. Шулар һәм үз-үзен тотышы да Габделнурда соклану тойгысы уятты, һичнәрсә аның игътибарыннан читтә калмады. Бер уйлаганда, кем инде ул гаепләнүче урындыгында утыручы егет өлкән яшьтәге адвокат өчен? Беркеме дә түгел. Кемгәдер ялыктыргыч тоелган нотыгын кыскарак тотса да аны гаеп итә алмаслар иде. Ләкин, әле утызы да тулмаган, ә шулай да күпне күргән, дөньяның әчесен-төчесен шактый татыган, сәламәтлеге нык какшаган кешене күрәләтә кабат тормыш упкынына ыргытмаска тырышу, жәлләү, аны туры юлга бастырырга омтылу, язмышы өчен борчылу—яклаучыга өстән-өстән генә сөйләмәскә, залдагы егетләр кебек жинел генә түгел, ә төптәнрәк уйлап, мәсьәләнең асылына төшенергә тырышу ниятен уяткандыр. Адвокат, вазифасы буенча жинаятьчене якларга, дөресрәге, жәзаны киметергә тырышса да (кануннарга таянып, билгеле), аның гаебен дә инкарь итми. Ләкин, аның күңелен үсендерергә теләп, аңа төзәлү мөмкинлеген дә калдырырга тырыша. Нотыгының менә шул төшләре Габделнурның күңеленә аеруча хуш килде. Әле яклаучының сүзе бетмәгән икән. Габделнур, уйларыннан арынып, янә бөтен игътибарын сөйләмчәк адвокатның сүзен тыңлауга туплады.

—Яшьләр үзләренчә аңа тәэсир итәргә телиләр. Бу аңлашыла... Хөкем уртача чаралар күрергә тиеш. Ул инде өченче тапкыр прокурор һәм адвокат речьләрен тыңлый. Бертөрле жинаять. Аны куркыныч жинаятьчеләр белән бертигез күреп булмый, ул рецидивист түгел. Аңа йөз дә кырык дүртенче маддәнең икенче кисәге буенча иң югары жәза билгеләмәвегезне сорыйм, сәламәтлеге начар икәнне дә искә алуыгызны үтенәм. Аңарда гражданлык намусы уянды, дип саныйм, үзенең дәшмәве белән ул, моннан ары андый эшкә бармам, андый юлга басмам, дип әйтергә тели.

Яклаучының ахыргы сүзләре генә түгел, гомумән, бөтен чыгышы ниндидер күтәренке пафоска корылган иде. Кирәк чакта, урындыкта бөкрәеп, йөткеренгәләп утырган гаепләнүчегә бармагы белән төртеп күрсәтеп, кайчагында, эмоциональ рәвештә башын чөеп, залга мөрәжәгать итеп, хөкем рәисеннән, каты жәза билгеләмәвегезне үтенәм дигәндә, аның күзләренә керердәй булып, туры карап сөйләве Габделнурның күңелен нечкәртте. Хәер, бер аныкын гына микән.

Баштарак, бик исе китмичә, юньле кешеләрдән читкә тибелгән ачы язмышына битараф булып, үзенең бүгенге хәле белән килешкән сыманрак, тырпуланыбрак утырган егет тора-бара ничектер тагын да кечерәеп, мескенләнеп калды, күптән тарак күрмәгән, киезләнеп беткән житү чәчле башы салынып төште. Судья тарафыннан үзенә соңгы сүз бирелгәч, ул беренче мәртәбә кылган гамәленә чын күңелдән үкенде бугай. Һәрхәлдә, Габделнурга шулай тоелды.

—Миңа карата шундый карашыгыздан мин күп нәрсәне аңладым... Мине иректә калдырыгыз... Киләчәктә төзәлермен...

Ялынып-ялварып сорамаса да аның бу сүзләренең ихлас икәнлегенә, чын йөрәктән әйтелүенә кызыл почмактагы халык та, күпне күргән һәм байтак жинаятьчеләрне төрле срокларга зинданга озаткан судья да ышанды бугай...

...Залдан чыкканда Габделнур әйберләре урланган егетләр алдында үзен гаепле кебегрәк сизде. Дөрес, аңа беркем дә бармак белән төртеп күрсәтмәде, кырын күз белән карамады, авыр сүз әйтмәде. Шуңа да карамастан, аңа кыен иде. Чөнки бу күренексез бәндәне—Захарны ул ияртеп кайтты бит, эшкә алып барды, янәсе, игелек кыла... Менә нәтиҗәсе: ит—яхшылык,

көт—явызлык. Һәм аңа бу эссе, бөркү залдан киләчәккә сабак булырдай ниндидер авыр тойгы ияреп чыкты сыман тоелды.

Ай-һай, бу хөкем процессы гына аңа сабак булыр микән? Аңа карап кына, үз файдасын күзәтмәстән, кешеләргә яхшылык кылырга, кемгәдер булышырга омтылу гадәтен ташлый алыр микән?! Чөнки ул сыйфатлар малай чагыннан ук аның канына сеңгән, бала-чага һәм карт-корыга илтифатлы булу, ятимнәргә һәм фәкыйрь-фокраларга мәрхәмәтле, ярдәмчел булу оеткысы күңеленә салынган иде бит. Хәтерендә, ул бәләкәй чакта алар авылына еш кына саилчеләр килгәли иде: сәләмә киемле, иң аркылы аскан киндер букчалы, чачакланып торган иске чабаталы, олыларга ияргән бала-чага чебиләп беткән ялан аяклы. Әйе, алар үзләре мескен, киемнәре эт талагандай (юкка гына, эт талаган хәерче кебек, димиләр бит) теткәләнеп беткән, әмма, шундый ямьсез кыяфәттә, ач булсалар да алар урлашмыйлар, кеше әйберсенә тимиләр иде. Шуңадыр, әнисе Гөлзифа түти бу кызганыч Алла бәндәләрен беркайчан да буш кул белән чыгарып җибәрми иде. Арада күрше-тирә авыллардан да, ерак җирләрдән дә килүчеләр бар. Аларның милләте дә төрлечә була иде. Берчакны, Габделнурның анасы әйткән сүз малаеның хәтеренә уелып калды: «И Ходаем, үзең урыс бул, үзең хәерче бул...» Ә бервакыт, чегәннәр кергәч, әбисе, аларны бик өнәмичә (ул корырак холыклы иде), барыгыз, бар, йөрмәгез, үзебезгә дә ашарга юк, диде. Чегән хатыны аңа карап кына баскан җиреннән кузгалмады һәм әйтте: «Бабушка, ты скоро умирал». Гомерендә бер авыз сүз урысча сөйләшмәгән әбисе (һәрхәлдә, Габделнурның ишеткәне булмады): «Чуртым знаешь»,—диде дә, комганын тотып, мунча янына таба китте. Каенанасы күздән югалуга, Гөлзифа түти аяксыздан-к...сез ике кара малай җитәкләгән чегән хатынына ярты шишара ипи чыгарып бирде...

Әтисе Галләм абзый да юлда очраган берәүне дә калдырып китми, кул күтәрсәләр дә, күтәрмәсәләр дә машинасын туктата торган иде. Габделнурның исенә төште: бер салкын көздә, олы юлдан читтәге шактый ерак авылга китүчегә әтисе үзенең бишмәтен биреп җибәргән иде. «Абый, мин моны сиңа ничек кайтарыйм соң?»—дип сорады аптыраган адәм. «Шуфирыгызга бир, ул мине белә, Мамадышта автошколада бергә укыдык,—дигән иде Галләм абзый шул чакта.—Юлда очрашмый калмабыз».

## XXIII

...Көне нинди бит: язгы нурларын мул сипкән кояшлы, җылы, шатлык-сөенечләр вәгъдә итә торган. Һәм ул Габделнур өчен дә шулай булып чыкты да.

Көндез эшкә барып кайтты. Кайтышлый, китап кибетенә сугылып, берничә китап сатып алды.

Тулай торакта абыйсы Гатуф көтеп тора иде. Озак юанмыйча, киенеп, шәһәргә чыгып киттеләр. Бераз тамак чылатып, ашап-эчеп дигәндәй, ял иттеләр.

Абыйсы:

—Сессия вакыты бит, сынауга әзерләнәсе бар,—дип китеп барды.

Ул авыл хуҗалыгы институтының механика бүлегендә читтән торып укый иде. Армиядән кайткач, энесе Газиз дә институтка кергән иде. Ләкин педагог булырга теләмәде, ахры, ярты елдан укуын ташлады һәм үзенең яраткан һөнәре буенча эшли башлады.

Габделнур тулай торакка юл алды. Троллейбустан төшкәч, җәяүләп, Восстание урамы буйлап түбән таба төшеп китте.

Ул әкрен генә кайта иде. Арттан бер кыз куып җитте. Тигезләште.

Бертигез кайта башладылар. Кыз сул яктагы өйнең диварына бик якын, кирпечләргә тиеп диярлек атлый.

Габделнур түзмәде.

—Акка ышкыласыз бит.

Кыз гади генә әйтте.

—Юк, ул буялмый.

Егет сүзен сүз итте.

—Барыбер. Уртадан кайтыгыз, күкрәк киереп. Мин тешләмим.

Кыз көлеп җибәрде. Ләкин һаман шулай кайтуын дәвам итте. Габделнур исә теленә салынуында булды.

—Төрле кешеләр бар: берәүләр, мин кем, диеп, тротуарның уртасыннан йөри, икенчеләр—кырыйдан... Тормышта да шулай: кемдер вакыйгаларның эчендә, үзәгендә кайнарга ярата, кайсылары—читтән генә карап, күзәтеп тора...

Ниһаять, кызның да теле ачылды.

—Кемнең нинди гадәт инде.

Егет элеп алып китте.

—Гадәт—икенче холык, диләр.

Кыз да җавапсыз калмады.

—Кешенең табигате—характер формалаштыра...

Шулай сөйләшә-сөйләшә кайтып та житкәннәр икән. Баксаң, күршеләр булып чыктылар: йортлары янәшә генә, аларның да биш катлы кирпеч йорт, урамга буйлай салынган. Тукталдылар. Кызның да керәсе килми, ахры. Шуны тоеп, Габделнур дилбегәне үз кулына алды.

—Әзрәк йөреп килик.

Кыз, башын күтәреп, күк йөзенә карады.

—Мин өйгә кереп кенә чыгыйм.

Ни өчен икәнен әйтмәде. Хәер, егет төпченмәде. Саубуллашмагач, чыгаргадыр исәбе, дип кенә фараз кылды.

Кыз йөгереп кереп китте дә бер минуттан әйләнеп тә чыкты. Бая аның аягында туфли иде, бу юлы—кыска кунычлы боты.

Егетнең моңа игътибар итүен сизеп, кыз:

—Ни булмаска,—диде.

Чөнки күк йөзе болытлы, вак яңгыр сибәли башлаган иде. Жил дә исә. Дымсу юеш һава. Ләкин яңгыр утырып яумады, бераздан туктады.

Урамнан бая кайткан юл белән кире киттеләр. Ибраһимов проспектына чыгып, унга борылдылар. Кыз һаман йортлар янынанрак бара. Сөйләшү һава, яз турында иде.

—Тизрәк агачлар яфрак ярсын иде инде,—диде кыз күкрәктән чыккан ягымлы тавыш белән.—Болай—шыксыз. Җәй көне рәхәт. Кыш бик озын, көз—ямансу. Табигатьнең кешегә тәэсире бик көчле.

—Анысы—дөрес,—диде егет килешеп.

—Мин тыныч урамнарда йөрергә яратам. Узган ел Мәскәүдә булдым. Ерак туганнар шунда тора. Анда кеше күп, машиналар исәпсез, тавыш. МГУда булдым, бик биек, үзе матур, сокланып туя алмадым.

—Минем дә анда булганым бар. Әйе, сез хаклы—бик матур,—дип кенә әйтте егет үзе юньләп белмәгән башкала турында бик җәелеп китмичә.

—Тагын жыенам. Ленинградка барасы килә. Анда әнинең бертуган сеңлесе яши, әле быел гына тора башлады, кияүгә чыкты, икенче иргә.

Габделнур, үзенә таныш шәһәр телгә алынуга шатланып, кызга Ленинград турында үзе белгән-күргәннәрне сөйли башлады. Үзе яннан кызга карый иде.

Кыз уртача буйлы, ябыграк йөзле, борыны да озынчарак, уң ягында

миңе бар. Конгырт чәчле, чәче алда мангаена, ике яктан күз тирәсенә төшебрәк тора, башында яулык, өстендә яз-көз кия торган юка пальто. Ул егеткә сирәк карый, ә Габделнур—еш. Аннары сүз спорт темасына күчте. Сүз моннан чыкты: кыз, тиздән Соцгород паркы ачыла, анда күнелле, диде.

—Еш барасызмы?—дип сорады егет.

—Юк. Әллә нигә бер.

—Үзәк паркка барасыздыр?

—Юк. Ял итәргә бармыйм. Мин анда тренировкага йөрим.

—Нәрсә белән шөгыльләнәсез?

—Җиңел атлетика.

Шуннан инде сүз спортка күчте. Егет Игорь Тер-Ованесян турында, аның берничә төрдән мастер нормасын үтәвен әйтте.

—Төп шөгыле—озынлыкка сикерү. Ләкин биеклеккә сикерүдә дә, йөз метрга йөгерүдә дә—СССРның спорт мастеры. Ә сез цирк артисты Вальтер Запашныйны беләсезме? Менә ул гимнастика, акробатика һәм штанга күтәрү буенча спорт мастеры. Фәкать көчле булуы аркасында гына исән кала.

—Ничек?

—Аренада ул юлбарыс авызына башын тыга торган була. Бервакыт, юлбарыс авызын яба. Циркач, моның яңакларын каерып, көчкә башын чыгара. Индиядән кайтарылган бу хайван кешеләргә һөҗүм иткән, бер адәмне ашаган да булган. Ерткыч җанвар, әгәр бер мәртәбә кеше итен татып караса, түзә алмый икән... Юлбарысны сатучылар аның нинди икәнен әйтмәгәннәр...

Бу сүзләрне ишеткәч, кызның тәне калтыранып киткәндәй булды. Шуңа күрә ул теманы үзгәртте.

—Мин фигуралы шууны яратам. Ева һәм Павел Романовлар профессионалга иртә чыктылар.

—Бу елларда күпләр китте, чехлар гына түгел, безнең Белоусова белән Протопопов та...

Аннары сүз хоккей, гимнастика турында барды. Икесе дә спорт белән шөгыльләнгәч, аны яраткач, уртаклык, сөйләшер нәрсә күп иде. Кыз еш кына сүз арасында табигать матурлыгына соклануын да белдерергә җай таба.

—Нинди матур яңгыр ява иде, туктады. Ә яңгыр кирәк, юып төшерергә...

Шәһәр җирендә дә табигать уяну чорына аяк баскан: яз исе килә, яшел үлән баш төртә. Юеш асфальт читендәге куакларда эленеп калган яңгыр тамчылары бу кичкә сихри ямь өстәп җем-җем итә. Каршыга очраган, әкрен генә атлаучы парлылар, сәлам биргәндәй елмаеп, бер-беренә юл саба, ялгызаклар карашында да мәрхәмәтлелек сизелә.

Габделнурның искәргәне бар: бәйрәм, олуг тантана көннәрендә халык, гомумән, бер-беренә ягымлырак, җылы карашлы, юл куючанрак һәм теләктәшлек белдерүчәнрәк була. Кайбер кешеләр табигатендәге усаллык, явызлык кебек тискәре күренешләр дә күпмедер вакытка читләшеп тора, аларның да тупасланган күңелләре нечкәрә, хискә тартыла.

Тимер юлга күтәрелеп, бераз киткәч, унга борылдылар һәм озакламый Соцгородка барып җиттеләр.

—Цирк турында искә төште: украиннарныкын караган идем, клоуннары ошамады, ә мәскәүлеләр—яхшырак,—диде кыз афишалар яныннан узганда.—Кобзон киләсе икән.

Бакчага керделәр. Анда кеше-кара юк. Шәрә агачлар арасындагы салкынча һава постаментларга мендерелгән спортчыларның гипстан ясалган

ак сыннарын да капшап йөри. Бераздан юл өзелде: канау казылып, алар бара торган сукмакны кырт кискән, унга барып, урап кына юлга чыгарга була. Егет кызның кулын алды һәм ул яннан, балчык өеме өстендәге сукмактан бара башлады. Аннан, юлга чыккач та, Габделнур кызнын кулын җибәрмәде, җинелчә генә кысып тотты, кыз—карышмады. Кайту унаена чыктылар, трампарк каршындагы сквердан уздылар.

—Элек кешеләр ничектер хисле булган,—диде кыз бераз дәшми-тынмый атлагач.—Дөньяны таный белү, аңлау һәм кабул итү дәрәҗәсе икенчерәк дип әйтимме, тәрбия һәм әйләнә-тирә мохите дә үзгәрәк... Иҗат әһелләре, югары катлау...

—Эшче дә табигатьне аңларга мөмкин, иҗат кешеләре генә түгел.

—Билгеле,—диде кыз һәм, күрәсең, аңа яз үзенең сулышы белән сихер өргән иде, әйтеп куйды.—Минем Парижга барасым килә. Луврны, Эйфель башнясын күрергә хыялланам... Яз көне...

—Ә Пушкин көзне яраткан,—дип сүз кыстырды егет.—Ул көз көне бик актив иҗат иткән.

—Аның җаны шагыйранә, лирик. «Онегин»да бик күп урыннар шул хакта сөйли. Чөнки үзе шундый булган. Ә Есенин яз көне язган. Менә тыңлагыз:

Проплясал, проплакал дождь весенний,
Замерла гроза...

Аннары кыз уйчан гына әйтеп куйды.

—Хәер, ул көз турында күбрәк тә язган бугай әле.

Закружилась листва золотая
В розовой воде на пруду,
Словно бабочек легкая стая
С замираньем летит на звезду...

—Бик матур юллар,—дип килеште егет.

—Аның Пушкинга багышланган шигыре дә бар. Ул аңа сокланган, аны хөрмәт иткән һәм ахырын болай тәмамлаган: «Чтоб и мое степное пенье Сумело бронзой прозвенеть».

—Ә минем тальян гармун турындагы шигырьләрен укыганым бар,—диде Габделнур әңгәмәне дәвам итеп.—Үзе уйнаганмы, юкмы—анысын әйтә алмыйм...

Шулай сөйләшә-сөйләшә киткән юлдан кире әйләнеп кайттылар. Алар китеп барганда бер фатирның ачык форточкасыннан җыр авазы ишетелә иде. Һаман да утыралар булса кирәк.

—Туй яисә туган көндер,—диде кыз башын кыңгыр салып, өске каттагы бер якты тәрәзәгә карап.—Элек туйдан соң бер ай сәяхәт иткәннәр, хәзер булмый... Минем иртәгә иртәрәк торасым бар, занятиегә.

—Ә безнең—ял. Кайда укыйсыз?

—Җинел промышленность техникумында. Ә сез?

Егет әйтте.

—Бездә дә тарих махсус предмет,—диде кыз.

Аннары сүз эш, уку турында булды. Бер эскәмиягә утырдылар. Җиләс, салкынча булганга бераздан торып киттеләр.

—Ә сезнең техникум кайсы төштә? Ишеткәнем юк.

—Кабан күле буенда. Кыш көне без анда чаңгы шуабыз. Җәй көне бик матур. Ул бит—серле, борынгы.

—Ә сез беләсезме Болак күперләренең исемнәрен?
—Юк. Аларның исеме дә бармыни?
—Әйе,—диде егет һәм санап күрсәтте.—Кабан күле белән ике арадагысы, үзәктәгесе—Булачный, аннары менә болай: Батуринский, Дегтяревский, Романовский, Лебедевский, Ложкинский, Жарковский...
—Кызык,—диде кыз.—Белмәгән идем.
—Тунмыйсыңмы?—дип сорады егет подъезд каршында туктагач.
Кыз дәшмәде. Габделнур уң кулын җиңелчә генә аның җилкәсенә салды һәм кысып тотты. Кыз бер сүз дә әйтмәде. Тәне каты, куллары да; ул егетне бик якын җибәрмәде. Үзе дәшми. Егет ана карап елмайды, кыз да җавап кайтарды. Икесе дә елмаеп беркавым торгач, кыз кузгалды.
—Керим инде.
Очрашырга сөйләштеләр. Габделнур сагызланмады.
—Өйгә дә керергә була, әти-әни усал түгел,—диде кыз, аннан уйчан гына өстәде.—Әле бу көннәрдә аралары бозылып тора... Хәер...
—Нәрсә?
Егет төпченмәкче иде, ләкин кыз, өендәге «чүп»не тышка чыгарып селкергә ярамаганын истә тотып булса кирәк, кисәк кенә әйтте.
—Хәер, бусы сезгә кирәк түгел...—Аннары сүзне икенчегә борды.—Үскән саен кыенрак икән. Элек спорт белән даими шөгыльләнә идем. Хәзер алай түгел. Кичләрен чыгасы килә. Әни чыгара. Ләкин әйтеп, әлбәттә, озак тормаска куша.
—Озак... Бу төшенчәне төрлечә аңлап була.
—Уникеләргә хәтле.
—Сиңа ничә яшь?
—Унсигез. Җәй көне унтугыз була.
Кыз читкә карады, ишеккә кагылгалады. Аны ачкач, сузып кына:
—Хәерле төн,—диде.
—Сиңа да,—диде егет. Һәм үзенең исемен әйтте.
—Ә мин—Тамара,—диде кыз кереп барышлый.
Тулай торак бүлмәсе. Дүрт карават. Берсе—буш. Өчесендә егетләр йоклый. Габделнур шыпырт кына йөрде. Аннары, китап-дәфтәрләрен алып, кухняга чыгып утырды. Ул диаматтан кыш көне котылган иде, хәзер тарихи материализмны тапшырасы бар. Фәнни атеизм нигезләрен «кимерергә» кирәк.

## XXIV

Биш катлы йорт көндезләрен бушап калса, кичләрен ыгы-зыгы белән тула. Ә получка-аванс көннәрендә тагын да җанлана төшә: тамак чылату аркасында еш кына шау-шу куба, ызгыш-низаг чыга, тукмашу-тунау китә. Акыл утырткан өлкәнрәкләр тавыш-тынсыз гына салып, әңгәмә корып утырса, яшь-җилкенчәк тәмамысы тугарыла—азына-тузына кәеф-сафа сөрә.
Габделнур һәм тагын ике егет бүлмәдә өчесенә бер яртыны «сындырып», гәпләшеп утыралар иде. Кинәт ишек ачылды һәм күрше егете атылып килеп керде: күзе-башы тонган, күлмәге умырылган, чәче тузгыган.
—Абыйлар, коткарыгыз!—дип сөрән салды да сорап-нитеп тормастан кергән уңайга түргә үк узды.
Егетләр, ярдәм сорап ялваручыга карап, бу ни хәл дип уйларга өлгермәделәр, аның артыннан ук икенче яшь егет кереп җитте. Анысының борыны канаган, ә кулында пәке.
—Суям!—дип акырды ул һәм урындык өстенә үк менеп баскан теге бичарага таба омтылды.

Ләкин Габделнур житезрәк булып чыкты—аяк чалып өлгерде. Егет исенә килгәләгәнче, юлбарыс житезлеге белән сикереп, өстенә менеп тә атланды. Бүлмәдәшләре дә сикерешеп тордылар һәм, исерекнең бармакларын каерып, кулыннан пәкесен тартып алдылар.

Ул сүгенә-сүгенә торды да бөтен ачуын әүвәл кергән егеткә төбәп:

—Мин сиңа күрмәгәненне күрсәтермен әле!—дип жикеренде.—Барыбер чыгарсың.

Чыннан да, кеше бүлмәсендә озак кала алмый бит инде, бераздан теге яшүсмер дә чыгып китте.

—Ну яшьләр!—дип баш чайкады бүлмәдәшләре прораб Шәмсун.

Кирәк бит, егетләр өстәл яныннан кузгалуга бу бүлмәдә дүртенче кеше булып яшәүче яшь егет кайтып керде. Ул да салмыш иде. Ишек катында ботинкаларын калдырды да, чишенеп тә тормыйча койкасына ауды. Бүлмәгә тирләгән аяк исе таралды.

Габделнур аңа:

—Ваня, киеменне салып ят,—диде.—Аңарчы оекбашларыңны юып куй. Юкса, скунска әйләнерсең.

Әле былтыр гына урта мәктәп бетереп килгән шапшак егет аның сүзенә колак салмады. Шуннан Габделнурның жен ачуы кузгалды.

—Мин сиңа ике тапкыр әйттем бит инде: оекбашларыңны көн саен юа торган бул дип. Ә син өченче мәртәбә әйттерәсең. Без синең сасыңны иснәргә тиешмени?

Йөзтүбән капланып яткан егет, башын да күтәрмичә, бәйләнмәле дигәндәй кул гына селтәде.

—Ах ананны... Әле син шулаймы?!

Габделнур укый торган китабын атып бәрде дә сикереп торды һәм Ваняны, кай жире туры килде шуннан эләктереп, күтәреп идәнгә томырды.

—Ы-ы,—дип ыңгырашкан аваз гына чыгара алды егетең.

—Бар ычкын! Юып кер!—дип кабатлады Габделнур ярсуын баса алмыйча, аның куллары дерелди иде.

Бүлмәдәшләре, аның болай кискен эш итүен жөпләп, баш кагып куйдылар.

Озынча ябык гәүдәле яшүсмергә, көчкә сынын жыеп, торып коридорга юнәлүдән башка чара калмады.

—Аңа мин дә әйткәнием инде,—диде өстәл жыештырып маташучы Миргаяз.—Саңга сукмагач, үзенә үпкәләсен.

Кич белән Габделнур, урынга яткач, күрше караватта тыныч кына йоклаучы Ваняны жәлләп тә куйды. Хәер, имгәнгән-сынган төше юк иде шикелле. Аннары, бу сансыз малай аркасында үзенең дә ярамаган эш эшләп ташлавын искәрде. Яшь чагын, Алабугага укырга килгәч, тулай торакта бер өлкән егетнең үзен карават астына тотып атуын хәтерендә яңартты. Теге сары кашлы юлына басты түгелме соң үзе дә? Дөрес, анда сүз чираттан тыш тагын идән юдырту турында бара иде. Ә монда... Шулай да булсын ди. «Ә синең ни хакың бар тиктомалга кеше баласына кул күтәрергә?—Менә шунысы бәгырен кимерә иде.—Әйт идең тагы бер кат. Егетләр дә әйтсен иде. Сиңа гына бөтенесеннән күбрәк кирәк...» Икенчеләй уйлаганда, Ваняга бу хәтеренә сеңешлерәк, озакка житәрлек, гомерлек сабак булыр: тәнеңне, киемеңне чиста-пөхтә йөрт, тирәңдәгеләр белән санлаш, олылар сүзен аяк астына салып таптама. Әле алда гомерең булса, күпне күрерсең...

Тамара Габделнур белән берничә мәртәбә очрашты.

Аның тормышында бу арада тетрәндергеч вакыйга булды: әтисе белән әнисе аерылыштылар, өч бүлмәле зур фатирларын икегә бүлделәр, Тамара әнисе белән яңа урынга күчте. Әтисез калгач (ә ул үзен шулай ярым

ятим хис итте, ничектер юашланды, боекты, ятим бала уйчан булыр, дип белми әйтмәгәннәр), ул бу егеткә тагы да ныграк тартыла төште. Ул аны хәтта үзенең таянычы кебек тоя башлады. Аның көчле, яклаучы булырдай кеше икәнлегенә бер вакыйгадан соң кыз тәмамысы ышанды, ана булган ышанычы, өмете бермә-бер артты. Дөрес, бу хәл әле Тамаралар яңа урынга күчкәнче үк булган иде.

...Ял көне.

Габделнур кызны өй янында көтеп алды да алар, житәкләшеп, урам буйлап киттеләр. Проспектта унга борылдылар һәм Тамараның яраткан урынына—бакчага таба атладылар. Байтак вакыт, юк-бар сөйләшеп, аллеяларда йөрделәр, ял итәргә килүчеләрне күзәттеләр, стадионда, футбол кырының читенә басып, спортчы егетләрнең туп типкәнен карап тордылар.

—Менә боларның эше шәп,—диде Габделнур елмаеп.—Аларның берсе безнең төзү идарәсендә дә исәпләнә, ай саен килеп акчасын гына алып китә.

—Бездә профессионаллар юк дигән булалар тагы.

—Әйе,—диде егет килешеп.

Аннары алар, кулга-кул тотынышып, кайту ягына борылдылар. Ләкин Воровский күпере тирәсенә житкәч, Габделнур тәкъдим ясады.

—Әйдә, өскә менәбез дә, тимер юл белән китәбез.

—Кая? Мәскәүгә хәтлеме?—диде Тамара көлеп.

—Анда бүген барып житеп булмас... Левченко поселогына таба бераз барырбыз да кире борылырбыз.

—Әйдә.

Һәм шулай иттеләр дә: шпалларны санап дигәндәй, батып баручы кояшка карап, алга таба киттеләр. Монда тыныч. Сул якта йортлар бар-барын, ләкин алар юлдан ерак, ә уңда сәнәгать предприятиеләре: трампарк, тимер-бетон әйберләре һәм силикат кирпече заводлары, машиналар хуҗалыгы, жылылык электр станциясе; аларның корпуслары, эстакадалары, краннары һәм башка жиһазлары күренә, ә электр станциясенең төтенләп утыручы юан торбалары исә әллә кайларга күккә ашкан.

Бераздан кире борылдылар. Габделнур, алга карагач, эчке сизгерлек белән сагая калды: сулда, тимер юл салынган үрдән түбәндә, биш-алты егет сөйләшеп тора. Бая алар юк иде. Каян килеп чыкканнар? Нинди уй, нинди максат белән йөриләр? Якын-тирәдә бүтән жан иясе күренми. Каршыга яисә арттан товар-йөк поездлары да килми. Ул, кесәсенә кулын тыгып, һәрвакыт үзе белән йөртә торган пәкесен чыгарды, аны ачып, кире кесәсенә тыкты.

Тамара, моны күреп, гажәпләнде.

—Ни булды? Нәрсәгә ул?

Егет алга ымлады. Кыз да тегеләрне күреп алды.

—Әйдә йөгерәбез,—диде ул Габделнурның кулын кысып тотып.

Үзенә һәм Тамарага нык ышанса да, хәзерге ситуациядә аларны житез аяклары да коткара алмас иде. Бердән, шпаллар өстеннән йөгерү бик җайсыз, икенчедән, астагы төркемгә куркуыңны күрсәтү булыр иде. Аннары, ерткыч жанварларга беркайчан да аркаңны күрсәтергә ярамаганын егетнен кайдадыр укыганы бар иде.

—Юк, өлгермибез. Каушама. Үзеңне тыныч тот.

Ул моны юкка гына әйтмәде, чөнки бер егет, өердән аерылып, әкрен генә өскә күтәрелеп килә иде. Ул ике рельс арасына, шпалга басты. Аякларын аерып куйган. Кулында әйбер-кара күренми. Габделнур сулга күз салды. Иптәшләре нишли? Әлегә тик торалар, ләкин барысының да күз карашы

бу якка—югарыга төбәлгән. «Күрәсең, тегеңәрдән сигнал гына көтәләр булыр, хәзер менеп җитәрләр»,—дип фараз кылды ул.

Егет белән кыз тегенең каршына килеп туктадылар. Тамара чытырдатып Габделнурның сул беләгенә ябышты. Ә аның уң кулы кесәсендәге пәкене сабыннан тоткан иде.

—Тартырга бармы?—дип сорады уртача буйлы егет.

—Юк, тартмыйм,—диде Габделнур коры гына, ә үзе тегенең кулларына янә күз төшерде: алар—буш.

Кыска чәчле, борын асты каралыбрак торган (әле яна гына мыек чыккан) яшь егет кабат сүз катты.

—Шырпы юкмы?

—Юк.

Габделнурның тавышы бу юлы да үз-үзенә нык ышанган кешенекедәй тыныч иде. Берничә секундка пауза барлыкка килде. Егет каш астыннан сөзеп, сынап карый, Габделнур да аңа төбәлгән.

—Ну, беттеме сораулар?

Егет дәшмәде.

Габделнур кызына таба борылды.

—Әйдә киттек.

Алар, янәшә атлап, тегене әйләнеп үттеләр. Кыз адымын кызулатмакчы иде, юлдашы сул кулын кисәк тартты һәм аны тыеп барды. Үзе арка тамырлары, умырткасы белән тоярга теләп, арттагы тынлыкка колак салырга тырыша иде. Юк, әлегә ул-бу сизелми. Иптәшләре дә күтәрелми, тик торалар. Ләкин монысының арт яктан кастет-фәлән белән чәпәве бик ихтимал иде. Габделнур колагын шомрайтты.

Бөтен тәне калтырый башлаган Тамара, ун адым чамасы киткәч, өзгәләнеп:

—Йөгерик!—дип ялынды.

—Юк!—диде егет шактый кырыс тавыш белән.—Тыныч кына бар.

Бераздан Габделнур артка борылып карады һәм күрде: астагылар баскан җирләрендә торалар, ә теге үрдән төшеп бара. «Узды шикелле, котылдык»,—дип уйлады ул. Әйе, хәзер арттан китереп бәрү куркынычы янамый. Дөресен генә әйткәндә, Габделнур үзе өчен түгел, ә сөйгәне өчен курыккан иде. Әгәр аны пычак белән кадапмы яки башына сугыпмы һуштан яздырсалар, кыз аларга каршы тора алмаячак. Шик юк, Тамара спорт белән шөгыльләнгән, алай тиз генә бирешмәс. Ләкин тегеләр күбәү, ә ул—берүзе...

Күпергә җиткәч, икесенең дә эченә җылы керде. Кыз туктады, башын Габделнурның күкрәгенә куюга авызы ыржаеп китте һәм елап җибәрде. Аның йөрәге дөп-дөп типкәнне Габделнур тәне белән генә тоймыйча, колагы белән дә ишетә иде.

—Йә, йә, бетте, тынычлан.

Бушангач, күз яшьләрен сөртеп, Тамара аны кочаклады һәм иреннәренә үрелде...

Кызның егеткә булган уңай карашы тагын да ныгый төште. Ул аңа элек тә ошый иде. Хәзер бу егетнең үзенә терәк булырдай кеше икәненә ул тәмам инанды.

...Тамара әтисенең алардан аерылып китүен бик авыр кичерде. Әтисен бик ярата иде кыз. Кечкенәдән үк аларның «серләре беректе»,ул мәктәптә булган бөтен яңалыкны әүвәл аңа сөйли иде: бәләкәй чакта—тезенә утырып, үсә төшкәч—сыенып кына... Әтисе дә кызын бик ярата, ләкин үзенчә, аны сынап, тикшереп тора, ни-нәрсәгә сәләтле икәнен дә чамаларга тырыша иде. Спорт белән шөгыльләнә башлагач (әтисе аны җиңел атлетика секциясенә яздырды), аларның уртак «серләре» тагы да күбәйде. Чөнки әнисе спорттан

ерак кеше, эшләве—бер заводта ОТК контролеры.

Баштарак әти-әнисе ярыйсы гына тату яшәделәр шикелле. Һәрхәлдә, Тамарага шулай тоелды. Ләкин соңгы елларда араларыннан кара мәче узды, ир белән хатын тыныша алмый башладылар.

Тамара берөзлексез диярлек әтисе турында уйлана. Ничек итеп үзен кечкенәдән спортка тартуы... Шуңа бәйле рәвештә, әтисенең кем булуы, кайда эшләве, ничек яшәве хакында да...

Аның әтисе фехтование буенча тренер. Еш кына команда белән ярышларга, чит шәһәрләргә китә иде. Ул югында әнисе эштән соңга калгалап кайта торган булды, авызыннан аракы исе дә килгәли иде. Кыз элек боларга игътибар итмәде, уку белән спортны бергә бәйләгәч, вакыты да юк иде: иртә—китә, кич—кайтып ава...

...Әтисенең алардан китүе кызның бәгырен сыкратты. Ата белән яшәгәндә Тамара ардаклы бала иде—кадерле, газиз. Ә хәзер? Баштарак бу хәл бөтен фаҗигасе белән аңына барып җитә алмады, аның мие томаланды. Беренче көннәрне үзеге өзгәләнде. Әтисенә үпкәләгән минутлары да булды кызның. Ул аптырауга төште. «Нигә китте? Ни өчен?» Һәм әтисе белән әнисе арасында булган низаглар, җәнҗаллар, шул чакларда ишетелгән өзек-өзек сүзләр хәтеренә килде. «Күрәсең, бу бер бүген генә килеп чыккан хәлнең нәтиҗәсе түгелдер,—дип уйлады кыз.—Әкертен генә кеше организмын эчтән кимергән авыру бер көн килеп тышка бәреп чыккан кебек, алар арасындагы мөнәсәбәт тә, айлар-еллар узгач, гаиләнең җимерелүе белән тәгәлләнде».

Никадәр генә сер сынатмаска тырышмасын, анасы да пошаманга төште. Кызын бу тиклем кайгырыр дип уйламаган иде. Хәер, үзе дә еш уйлана башлады ана кеше: кайда, кайчан ялгышты соң ул? Уйларының очына чыга алмаган, аптыраган-йөдәгән мәлләре күп булды. Ләкин соң иде инде... Үз-үзен тыя, мәҗбүр итәрдәй ихтыяр көче таба алмады шул, кеше сүзенә ышанды...

Ире ярышларга киткәч, ул әүвәлге елларны аны бик сагынды, юксынды, аннары көнли башлады, кайткач, җәнҗал куптарды. Чөнки ярышта—кызлар, ә ире аларга хуҗа—тренер. «Базар хәбәрләре» дә килеп җиткәләде. Кем белә, бәлки юри ишеттергәннәрдер яшь хатынга. Аларның мул тормышларына, тату яшәүләреннән көнләшеп, хөсетләнеп әйткәннәрдер. Бөтен нәрсәгә җитмәүчелек заманда ире чит шәһәрләрдән (бигрәк тә союздаш республикалар башкалаларыннан) чүпрәк-чапрак та, затлы ризыклар да алып кайтты, шунлыктан кием-салымга, азык-төлеккә кытлык кичермәделәр. Дөрес, ул аларны потлап-капчыклап ташымады, кирәк кадәренчә генә, ләкин гаиләне киендерергә, ашау-эчүгә җитәрлек күләмдә иде.

Ә хатынның хезмәттәшләре, ахирәтләре моны күреп-белеп тордылар, үзенең дә теле сөяксез—авызында сүз тормый, холкында бераз һавалану галәмәте дә бар иде. Билгеле инде теге усал телләрне көнчелек корты кимергәндер... Ә ул, кеше сүзе—кеше үтерә, дигән әйтемнең асылына төшенә алмады. Аннан, бер дә бер көнне үз-үзенә сорау бирде: «Нигә мин яшь гомеремне әрәм итәм?» Һәм хатын бер яшь «нәрсә» тапты. Бозык хатынның ишек төбе җәнҗалсыз булмый, дип белми әйтмәгәннәр. Хәзер хатын, үзенең йөргәнен сиздермәс өчен, ире кайтып керү белән аңа бәйләнә, тавыш чыгара торган булды, көнләшә, янәсе. Вакыт-вакыт «сулга каеру»дан туктап та карады, әмма, ире киткәч, тагы иске сукмакка баса иде, күрәсең, күнел азуы чиргә, «аш төрләндерүгә» гадәткә әйләнгәндер.

Билгеле, андый ямьсез хәбәр, сонлап булса да, гәрчә халыкта, бөтен урамда бер ире генә белми, дип әйтелсә дә, иренә дә килеп ирешә. Ул хатыны белән төрлечә сөйләшеп карады: тәмле тел белән дә, каты кул белән дә. Әмма файдасы тимәде, кара тун юу белән агармаган кебек, хатын игә килмәде. Ире соңга калды, ахрысы, ертыкны алданрак күреп, вакытында

ямау салып өлгермәде.

Бер-берсеннән читләшү, гайрәт чигү шул чиккә барып житте ки, ниһаять, ул мона нокта куярга булды. Ләкин кызын искә төшергән саен, аңа караган саен бу уеннан кайтып торырга мәжбүр булып, ул көнне тарта-суза кичектерде. Кызына никадәр авыр буласын да, ата-ананың аерылышуы бала күнеленә жәрәхәт саласын һәм психикасына сугасын да, тормышның матди ягын да, башкасын да уйлады. Тамара өчен атасыз калу—каладан салага калу белән бәрабәр икәнен ул яхшы аңлый иде. Ә иң мөһиме—ул кызын бик ярата иде. Тик, күпме генә сузылмасын, тартылган кыл бер өзелергә, утка куелган тулы савыт кайнап ташырга тиеш иде. Менә, быел тәвәккәлләде. «Инде үсеп житте, үз көнен үзе күрерлек булды»,—дип уйлады ата кеше.

## XXV

Кызганычка каршы, күрше йортта да (моторлар төзү заводы тулай торагында) ашханә эшләми икән. Габделнур «Фукерман»га юл алды. (Кызыл Байрак һәм Гагарин урамнары чатындагы ашханәне шулай атап йөртәләр иде.)

Ашап кайтканнан соң, урамдагы автоматтан Тамарага шалтыратты. Трубканы кыз үзе алды.

—Сәлам.

—Исәнме.

—Хәлләр ничек?

—Әйбәт,—диде кыз йомшак, ягымлы тавышы белән һәм, бер тын дәшми торганнан соң, үпкәләбрәк сорады.—Нигә шалтыратмадың?

Габделнур бер генә секундка пауза ясады, трубканың авыз каршындагы башын уң кулы белән каплап, тамак кырып алды да, тавышына көрлек галәмәте чыгарып, җавап кайтарды.

—Мин шалтыраттым. Җавап бирүче булмады.

Тамара, кайчан, сәгать ничәдә, дип төпченеп тормады. Трубкада янадан баягы йомшак, ягымлы аваз ишетелде.

—Ярар, ачуланмыйм.

Габделнур, булдыклы кыяфәтен күзгедә күргәндәй, будка пыяласына карап, үзенә-үзе баш селкеде, канәгатьлектән күңеле ташып, сул күзен кысты һәм, инициативаны үз кулына алды. Чөнки бу мәлдә акланып тору—егетлек түгел, ә сүзне читкәрәк, бүтән юнәлешкәрәк алып китү кулайрак.

—Әле нишлисең?

—Телевизор карыйм. Кино.

—Үзең генәме?

—Әйе.

—Килимме?

—Кил.

Егет җинел сулап куйды: «Үтте, ахры, жил-давыл купмады». Автобуска утырып, «Телевышка» тукталышына хәтле барды. Төште. Кичке һава, жил булмаганлыктан, бик бөркү, жылы. Өйләре янына килде. Ун минут чамасы көтте. Кыз чыкты.

Өйгә керделәр. Тамара ишекне бикләде. Габделнур, туфлиен салып, бүлмәгә узды. Анда тоныК кына ут яна—бәләкәй лампочка борылган. Өйләрендә үрнәк тәртип, бөтен нәрсә «ялт» итеп тора.

Телевизордан чыннан да кино күрсәтәләр икән. Тамара диванга утырды.

—Кил,—дип үз яныннан егеткә урын тәкъдим итте.

Кыз алдына тәлинкә куйды һәм сары төстәге төче чия капты.

—Аша.

Габделнур бу җимешнең ни икәнен белми иде, сорарга кыюлыгы

житмәде, горурлыгы да рөхсәт итмәс иде. Шулай да ят ризыкны алды. «Төше дә бар, чиягә тартым нәрсә икән»,—дип нәтиҗә ясады. Экранга карады: кино үтереш турында, шуны тикшерү.

—Нигә шалтыратмадың?

Габделнур баягынак бик җиңел генә котылса да, монда да бу сорауны көткән иде. Чөнки хатын-кыз, уена килгән әйберне энәсеннән җебенәчә төпченмичә, ир-атның җелегенә төшмичә калмый. Бередә акылның катнашы юк, бу—аларның табигате, шуның сөреше. Тамара гына аерым балчыкка камырдан әвәләнмәгән бит! Шуңа күрә егет кызга телефоннан шалтыратканчы ук бу турыда уйланган һәм җавабын да әзерләп куйган иде.

—Сишәмбе, чәршәмбе һәм бүген шалтыраттым, җавап бирмәделәр,—диде егет һәм кулын кызның җилкәсенә куйды.

Нәкъ шулвакыт түрдәге телевизор начар күрсәтә башлады. Хуҗа туташ, торып, аны боргычлап азапланды.

—Син кергәч, бозылды,—диде ул, артына борылып, елмаеп.

—Сездә дә яхшы күрсәтмәгәч инде, телевышка каршыда гына бит.

—Шәмнең яктысы астына төшми.

Бермәл Габделнур, әллә көйләп бирим микән, дип тә талпынган иде, ләкин ул уеннан кире кайтты: «Кеше әйберсе... бәладән баш-аяк».

Урыныннан кымшанмыйча калуының икенче сәбәбе—кызның читтәрәк торуында да иде. Чөнки Тамараны бу хәлендә күргән егет-җилән аңа сокланмыйча булдыра алмас, гәүдәсенең сылулыгына битараф калмас иде. Бигрәк тә аулакта, икәүдән-икәү генә калган шушындый бәхетле мизгелдә. Габделнурның да, торып, аны арттан кочаклап аласы, куенына сендерәсе килде. Ләкин ул сабырлыгын җуймады.

Телевизорны көйләгәч, кыз диванга утырды. Егет сул кулы белән аны кочаклады, уң кулын калку күкрәгенә куйды. Аның кайнар тәненә кагылуга кино кайгысы бетте егеттә.

—Кино карыйк инде,—диде Тамара йомшак кына.

Ләкин Габделнур моңа игътибар итмәде, кызның башын үзенә якынрак китереп, берәм-берәм күзләреннән үбә башлады, аннан битен һәм, ниһаять, иреннәрен...

—Син чәнечкеле,—диде кыз пышылдап, әмма үзе дә егетне муеныннан кочты.

Габделнур уң кулы белән аны биленнән алды. Ләкин шул мизгелдә тагын экрандагы сурәтләр бозылды. Кыз, моны күреп, торды, барып көйләде дә, кабат элекке урынына утырды.

—Укуларың ничек?—дип сорады Габделнур.

—Әйбәт. Тәгәлләп киләм. Ә синең?

—Минем дә бара. Бүген иртән университетта булдым.

Егет аны янә коча, үбә башлагач, Тамара торып китте һәм телевизор янына барып басты.

Габделнур да торды. Өй эченә карады. Аның бу фатирга әле беренче керүе иде. Залда җиһазлар байтак: телевизор куелган тумбочкадан тыш бер як диварда савыт-саба белән тулы сервант, икенче якта өстәл, идәнгә зур гына чәчәкле-бизәкле йомшак палас җәелгән, түшәмдә биш чатлы люстра асылынып тора.

—Сезнең ничә бүлмә?

—Ике.

—Ничә кеше торасыз?

—Әни белән икәү генә.

—Ул кайда?

—Кинода. Иптәш хатыны белән китте.

Егет ачык ишектән күрше бүлмәгә күз салды—койкалар бар. Кыз янына килеп, башын кочты, аннары күтәреп алырга теләде. Телевизор өстендәге антенна идәнгә төшеп китте. Кыз көлеп җибәрде, антеннаны рәтләп куйды.

Габделнур Тамараны кисәк кенә күтәрде дә йокы бүлмәсенә алып кермәкче булды. Ләкин кыз каршы килде, тыпырчына башлады.

—Кирәкми!

Егет, кире уйлап, аны диванга алып барып салды. Тәне—ут, халаты ачылып киткәч, кояшта янган ялангач аяклары күренде. Габделнур Тамараны берөзлексез коча, үбә башлады, кыз үзе дә аны кайнар куллары белән урап алды. Ләкин ботына кагылгач:

—Кирәкми!—диде.—Хәзер әниләр кайтыр.

—Өлгерербез әле.

—Юк, юк,—диде кыз, үзе дә еш-еш сулап, күрәсең, анын да сабыры төкәнеп килә иде инде, шулай да ул ихтыяр көчен югалтмады.—Иртәгә. Мин сиңа әйттем бит, алар җидегә киткән иде, кайтып җитәрләр... Иртәгә ул Ульяновскига китә.

Егет ирексезләмәде, суынды.

Кыз, аны кочаклаган хәлдә, көлеп (каян шәһәр баласының теленә килгәндер):

—Синең йөрәгең чабыш атныкы кебек тибә,—диде.

Габделнур, Тамараны алдына утыртып, янә иркәли-назлый, үбә, тырпаеп торган тыгыз түшләрен кыса, умачлый башлады.

Ә телевизорда фильм дәвам итә. Полиция комиссары бүлмәсе, аны атарга йөриләр, ахрысы, берәү ишек шакый бу репортер белән утырганда...

Күзе экранда булса да хәзер Габделнур өчен кинонын кызыгы бетте.

Кыз да дивардагы сәгатькә карап алды.

—Хәзер кайтырлар инде,—диде ул йомшак тавыш белән.—Сине күрмәсеннәр.

Егет торды. Алгы бүлмәгә чыкты. Аягына киде.

Тамара аңа сыенды, күзләренә карады.

—Иртәгә минем туган көн.

—Ярый. Хуш.

Кочаклашып, озак итеп үбештеләр.

—Иртәгә кайчан шалтыратасың?—дип сорады кыз.

—Биштән соң.

—Ярар. Сау бул.

Ул ишекне ачты. Өске каттан бер ир белән хатын төшеп киләләр иде. Габделнур чыгып ычкынды. Тамара тегеләр белән исәнләшеп калды.

Габделнур тулай торакка кайтты. Берүзе. Радио тынлады: спорт хәбәрләре, виолончель концерты.

...Икенче көнне дә җылы, кояшлы иде. Егет университетка занятиеләргә барып кайтты. «Россиядә профсоюз хәрәкәте» дигән темага махсус семинардан зачет «эләктерде». Тагын бер сынау (СССР тарихы) бирәсе калды. Анысы—июнь ахырында.

Кичен, егетләр белән бергәләп, туйга киттеләр. Куллары буш түгел: чәчәкләр, бүләкләр.

## XXVI

...Туйдан иртән генә таралдылар. Габделнур, трамвайга утырып, тулай торакка кайтырга чыкты. Ул үзе генә калды: егетләр кайсы-кая кызлар озата киттеләр. Калтырча шикелле шалтыр-шолтыр булса да, трамвай үзенекен иткән—егет йокыга талган һәм үз тукталышын узып киткән иде.

Трамвайдан төшеп, бер квартал түбән таба атлагач, ул Кызыл Байрак урамына борылды. Егет уң яктан бара иде. Ә сул якта янәшә ике тулай торак бинасы, икесе дә кызларныкы... Кирәк бит: аскы катта бер тәрәзә ачык һәм анда бер чибәр кыз елмаеп басып тора икән. Ник елмаймасын ул, бик елмая, чөнки үзе—чибәр, көне—матур, кояш инде күптән чыккан, каршыдан карамаса да җылысы һәм нурлары күрше йорт түбәләренә һәм агач башларына таралган, ә алардан—кызның ягымлы йөзенә нур бөркелә. Урамның каршы ягыннан, тротуардан, озын буйлы, матур гына егет тә атлый, тик бу якка гына карамый. Әһә, әнә сизде...

Габделнур, үзендә кемнендер күз карашын тоеп, шып туктады. Сулга карады. Күрде, һәм үзе дә ирексездән әлеге кызга елмайды. Аларның күз карашлары очрашты. Бу шулкадәр табигый булды ки, Габделнур, урам аркылы йөгереп тә чыкты, бер сикерүдә тәрәзә аша бүлмәгә очып кына дигәндәй килеп тә төште. Гүяки шаһзадә... ак аты гына юк...

Мондый тәвәккәллекне һәм җитезлекне көтмәгән кыз башта куркып калды, аннары, риясыз елмаеп торган егеткә карап:

—Болай ярамый бит инде,—диде.

Габделнур тәрәзә тупсасына артын терәде дә бүлмә уртасына күчкән кызга:

—Курыкма,—диде.—Мин әле айнып җитмәгән. Туйдан кайтам. Хәзер чыгып китәм.

Кызның өстендә кыска җиңле җәйге күлмәк, чәчләре бөдрәләнеп тора, җилкәсенә таралган, алсу иреннәре менә-менә көлеп җибәрер төсле, коңгырт-кара күзләре мөлаем, үзе—яшь, карашы—самими.

—Нинди туйдан?—дип телгә килде ул, ниһаять, егетнең угры түгеллегендә шиге калмагач.

—Иптәш егеткә камыт кидердек.

—Өйләнү—начар эш түгел инде. Мәҗбүри өйләндермәгәннәрдер бит? Әллә кызы ябышып чыктымы?

—Юк та. Ни әйтсәң дә, үз иркең белән камыт кию инде ул. Әле иртәрәк иде, без—икебез бер елгы. Ат алсаң, арба кирәк, хатын алсаң, бар да кирәк. Торыр җирләре дә юк... Без тулай торакта яшибез, Восстаниедә...

Шулчак бүлмә ишеге ачылды һәм утыз-утыз биш яшьләрдәге бер хатын-кыз керде. Ул иске генә халаттан, тапочкадан, чәчен баш түбәсенә өеп куйган, кулында агач саплы таба, аның өстенә кәстрүл капкачы каплаган. Бүлмәгә кыздырылган бәрәңге исе таралды. Габделнурны күргәч, чак кына кулыннан табасы төшеп китмәде. Ул чәрелдәвек тавыш белән кычкырып җибәрде.

—Сез кем? Нишлисез монда?

—Гафу итегез, менә сенелкәш янына кергән идем.

—Тәрәзәдәнме?—Теге зәһәрле күз карашын яшь кызга текәде.—Кемен ул?

Аның төксе чыраен күреп, коелып төшкән бичаракай алдаша алмады.

—Беркемем дә түгел. Беренче күрүем.

Тегенең карашы егеткә юнәлде, тавышы—боерулы.

—Барыгыз, чыгыгыз!

—Хәзер,—диде Габделнур карышмыйча, ләкин үзе яшь кызга сокланып каравында булды, урыныннан кузгалмады.

Аны мондый усал чырай белән генә өркетеп булмый иде. Теге, мөгаен, шуны аңлап, табасын өстәлдәге шакмаклы такта кисәгенә шапылдатып куйды да җәлт кенә чыгып та китте.

Бераздан, куркуы сүрелә төшкәч, кызый телгә килде.

—Карт кыз ул. Үзе дә йөрми, безнең янга егетләр килгәнне дә өнәми.

—Алар халкы шулай инде,—дигән булды Габделнур белдекле кыяфәт белән һәм теманы үзгәртте.—Ә синең егетең бармы? Минем шикелле «чибәр»ме?

—Әйе,—диде кыз көлеп, аннан ул да сүзне икенчегә борды.—Туй шәп булдымы соң?

—Чукынып китсен туйлары, бер тамагым туймады, дип әйткән ди берәү. Чәй эчертмисеңме?

—Юк. Үзем инде әллә кайчан эчтем.

—Саран икәнсең. Юри генә әйткән идем, ышанды. Кайткач, үзем самавыр куярмын.

—Тулай торактамы? Анда нинди самавыр булсын?! Алдакчы...

Габделнур, чыгарга кирәген дә онытып, уен-көлке белән шаяртып гәп коруын дәвам итте. Юк-бар сөйләшү, егетләр белән кызлар арасында була торган гадәти тел чарлау иде бу. Аннары ул ишек катына килде һәм, ишеккә арты белән торган хәлдә, борчуы өчен кыздан кат-кат гафу үтенеп, чыгарга җыенды. Ләкин шулчак аның артында ишек ачылды һәм, ул борылып өлгергәнче, җилкәсенә саллы гына ир-ат кулы кагылды.

—Гражданин...

Габделнур борылып караса—милиция сержанты тора: озын буйлы, калынча гәүдәле.

—Исәнмесез,—дип әйткәнен сизми дә калды егет һәм кисәк айнып китте.

—Әйдәгез минем белән!—диде сержант коры гына.—Нишләп тәртип бозасыз?

—Гафу итегез, минә таныш кызлар янына кергән идем.

—Тәрәзәдәнме?—дип сүз кыстырды карт кыз.—Без аны бөтенләй белмибез, иптәш милиционер. Беренче күрүебез.

—Ачыкларбыз,—диде дә, ишекне каерып ачып, тәртип сакчысы «хулиган»ны үз алдыннан үткәреп җибәрде.

Урамга чыккач, Габделнур янәшә барган сержантка җайлап кына кичә бер дустын өйләндерүләрен, әле иртән генә туйдан кайтуын, югары уку йортында читтән торып укуын, үзенең дә өч ел армия хезмәтендә булуын, хәзерге вакытта төзелештә эшләвен һәм кызлар янына явыз ният белән кермәвен искәртте. Ничек итсә итте, әмма сүзе үтте. Үзе дә әле күптән түгел солдаттан кайтып, милициягә эшкә кергән сержант, ана үз тиңедәй карапмы, артык каты бәрелмәде.

—Кайда, кем булып хезмәт иттең?—дип сорап куйды.

Габделнур бәйнә-бәйнә, мөмкин хәтле тәэсирле итеп, тәфсилләбрәк юл буе сөйләнде. Дусты Ирекне дә телгә алды, фамилиясен дә әйтте. Сержант андый милиционерны хәтеренә төшерә алмады. «Монысын юкка гына әйттем,—дип уйлады «тәртип бозучы».—Мескенләнү генә булды».

Ул әле сержантның аны кая алып барганын белми иде. Кай тарафка юл тотуларын белмәсә дә, йортлар арасыннан «Комсомолец» клубы яныннан үтеп, бер-ике минут баргач, Габделнур кая килеп чыгуларын аңлады һәм шул мәлдә үк үзенең әле коммунист икәнен дә исенә төшерде. Чөнки алар айныткыч ишеге төбендә тукталдылар. Моны Габделнур дивардагы язулы элмә тактадан укып белде. Егетнең моңарчы, шөкер, бу учреждениегә эләккәне юк, аның кайда икәнен дә белми иде. Баксаң, янәшәдә генә икән. Һәм егет вәсвәсәгә төште.

Сержант, кулы белән ишарә ясап:

—Уз,—диде.

Подвалга төшәсе икән.

Габделнур (соңыннан андый уйның ничек күңеленә килүенә сөенеп бетә

алмады), башын юләргә салып, әйтте.

—Юк инде, иптәш сержант, сез алдан узыгыз. Мин армиядә ефрейтор гына идем. Сез—өлкәнрәк. Безне анда беренче көннән үк югары чиннарны ихтирам итәргә өйрәттеләр.

Һәм... кызыл погонына аркылы өч сары тасма таккан беркатлы адәм баласы аның такылдавыннан эреп киткән иде, ахрысы, үзе алга чыгып, баскычтан түбән төшә башлады. Габделнурга шул гына кирәк тә: ул, сулга таба каерып, бөтен көченә торып йөгерде. Артына борылып карамады да, чөнки йөз метрга йөгерүдә частьта иң осталарның берсе санала иде бит. Әле дә аякларының җитезлеге кимемәгән. Ике атлап, бер сикерүдә дигәндәй, Ибраһимов проспектын аркылы үтте һәм, Восстание урамына чыкмыйча, биш катлы йортлар арасыннан гына үзенең тулай торагына томырылды. Вахтер янында гына адымын акрынайтып, дүртенче катка да очып кына менде...

## XXVII

Габделнур бүлмәне ачып керде, ишек бикле, егетләр өйдә юк иде. Ул бераз хәл алды. Аннары, бил тиңентен чишенеп, юынып-кырынып керде, чиста кием киенеп, кызның туган көненә дип алган бүләген кесәсенә салып, Киров районына китте. Кичә, телефоннан шалтыратып, аңа бүген киләсен әйткән иде.

Сәгать сигезләр тирәсендә Тамара яшәгән өч катлы кирпеч йортка килеп тә житте. Подъездга керде. Алар фатирының кыңгырау төймәсенә басты. Җавап бирүче, ишек ачучы юк. «Йоклый торгандыр»,—дип уйлады егет һәм урамга чыкты. Берничә минут өйтүр бакчасы янында басып торды.

Көн җылы, иртәдән үк кояш кыздырырга ниятли. Җил-фәлән юк—өрәнге яфраклары селкенми. Җан-тәнеңә ниндидер рәхәтлек вәгъдә итә торган җәйге тылсымлы көн.

Бераздан кыз да чыкты. Габделнур дөрес фаразламаган—Тамара йокламый икән. Йөз-кыяфәте бер дә әле яңа гына җылы урын-җирдән күтәрелгән кешегә охшамаган: йөреш-хәрәкәте салмак, ләкин таркау түгел, кызгылт иреннәре күпереп ымсындырып тора, кыйгач кашлары астында озын керфекле коңгырт күзләре нур сибә; өстендә җиңсез күлмәк, аягында туфли, матур итеп, уртадан юл ярып таралган чәче, күкрәкләрен каплап, алдына ишелеп төшкән, йомры иңбашларын күрсәтеп тора.

Егетнең янына ук килеп исәнләште.

—Иртә бит әле,—диде ул Габделнурның күзләренә яратып карап.—Бездә кеше бар. Хәзер бераз сабыр ит, күршеләр чыксын инде. Алар гел шулай шалтыратырга кирәләр.

—Ярар.

—Ачуланма, яме,—дип, үз итеп елмайгач, Тамара подъездга кереп югалды.

Каккан казык кебек бер урында басып тормас өчен Габделнур йорт буйлап китте. Аргы башына барып җиткәч, туктап калды. Урамның теге ягында, тыкрыкта, икешәр катлы сары йортлар, очлары киселгән юан агачлар тезелеп киткән. Егет сулга борылды. Автобус тукталышын үтеп, чатка барып җитте. Каршыда өйләр юк, шактый җир бетон койма белән әйләндереп алынган, сулда, ул беткән төштә, тимер юл рельслары күренә.

Ә арырак—яшеллек. Бу инде Казанның бер чите. Урман эченнән узучы олы юл белән бераз барсаң, данлыклы Аккош күленә тап буласың, фәлән йөз чакрымнар ары китсәң ерак шәһәрләргә барып чыгасың: Горькийга, Мәскәүгә...

Чаттан борылып, кыз өенә таба килгәндә егет телевышка турысында

туктап калды. Беренче күргәндәй, башын күтәрде. Алар авылы тирәсендәге һәм ул армиягә киткәнче эшләгән төбәктәге нефть вышкаларыннан дүрт-биш мәртәбә биек иде төрле юанлыктагы торбалардан корылган һәм әллә кая биеккә ашкан манара. Кем әйтмешли, очына карасаң, бүрегең төшеп китәр. Аның аскы өлеше һәм шактый мәйдан койма белән әйләндереп алынган, капка да бар. «Күрәсең, моны саклыйлардыр әле,—дип уйлады элекке гаскәри.—Стратегик объектлар исәбендәдер».

Беркавым торгач, ул кабат таныш йортка әйләнеп кайтты. Баягынак килгәндә өй каршындагы бакчада эскәмияләр буш иде, хәзер берсенә олы яшьтәге ак чәчле апа чыгып утырган. Ул монарчы бу тирәдә күзгә чалынмаган озын буйлы ыспай егеткә карап алды. «Син кем? Изге ният белән йөрисеңме?»—дигән сыманрак шикләнеп, сынап караган төсләрәк тоелды аның карашы. Подъезд ишекләре ачыла-ябыла башлады: кешеләр уянып чыгалар һәм кайсы тиз-тиз, кайберләре әкрен генә китеп баралар. Күрәсең, кемдер эшкә ашыга, икенче берәүләр—кибеткә. Хәер, бу дөньяда һәркемнең нинди дә эш-шөгыле, йомышы-вазифасы бар... «Менә мин дә таң тишегеннән чабып килдем бит,—дип үзалдына елмаеп куйды егет.—Мине яшьлек дәрте йөртә».

Күп тә үтмәде Тамара чыгып аны өенә чакырды.

—Кер әйдә.

Кыз ишекне эчтән бикләгәч, алгы бүлмәдә тукталдылар.

—Туган көнең белән!—диде Габделнур һәм бүләген бирде.

—Рәхмәт,—диде кыз күнеле булып һәм, ачып карагач, сөенеченнән кычкырып җибәрде.—Ой! Нинди матур!

Әллә ни кыйбат булмаган муенсаны да шулай кабул иткәч, егеткә дә рәхәт булып китте.

—Кая барабыз?—дип сорады Тамара Габделнурның каршына басып.—Пляжгамы?

Егет иңнәрен сикертеп куйды.

—Белмим. Әйдә.

—Иртә бит әле,—диде кыз аңа туры карамыйча гына.

—Соңрак алайса,—диде егет аның белән килешеп.

Кыз үзе бергә-бер калырга курка, ахры. Егет аның акрын һәм калтырабрак чыккан тавышыннан, шикләнебрәк караган күзләреннән шуны абайлады.

Кыз күлмәкчән. Юка күлмәгенең итәге тезләрен чак кына каплый. Коңгырт төстәге йомшак чәчләреннән хуш ис килә. Чиста йөзенә иннек-кершән якмаган. Бит очлары алсуланып тора. Ул анык кына бер карарга килә алмый, икеләнә, ахры. Уйчан күзләре, бөтен торышы шул хакта сөйли иде.

Берникадәр вакыт дәшми торгач, ниһаять, Тамара:

—Әйдә, уз,—диде.

Бүлмәгә керделәр. Габделнур бизәкле келәм эленгән диварга терәп куелган киң диванга утырды. Аның гәүдәсе астында пружиналар шыгырдады. Егетнең үлеп йокысы килә, хәле юк. Ләкин үз-үзен җинеп, күзләрен йоммаска тырышты.

Кыз да, кыяр-кыймас кына, диванның читенә генә, аның янына утырды. Ул аякларын бер якка авыштырыбрак, йомры тез башларын бер-берсенә нык терәп утыра. Егеткә бик якын килмичә, кулларын тез өстенә куеп, карашын каядыр читкә төбәп уйчан гына утыруыннан Габделнур аның киеренке халәттә икәнен аңлады.

Кыз әкрен генә сүз башлады; тавышы боек, чырае караңгы иде аның бу минутта.

—Кайда булдың?

—Абыйлар белән төне буе апаларда салып утырдык,—дип ялганлады егет, чөнки ул туйга барасын әйтмәгән иде.

Кыз тагын үзалдына йомылды. Башта турсаебрак торды. Чөнки кичә ул аны бик зарыгып көтте... Булдыра алганча мул итеп табын әзерләде, душ астында коенып чыккач, чәчләрен тарап, бик аз гына «Прелесть» лагы сиптерде, битенә чак кына поляк кремы сөртте, бизәнеп-ясанып үзен рәткә китергәч, яңа матур күлмәген киде. Чамасын белеп кенә кулланган француз ислемаеннан бүлмәгә хуш ис таралды... Менә килер, менә килер, дип өзлексез дивар сәгатенә карады. Телевизорны тоташтырса да андагы вакыйга-хәлләр кызны ныклап җәлеп итә алмадылар. Чөнки ул Аны көтте. Ул килмәде. Кыз аңа бик нык үпкәләде... Ләкин бүген, үзен күргәч, ачуы кайтты. Тыштан күрсәтәсе килмәсә дә, асылда ул аңа озаклап үпкәли дә алмый. Егет аның бөтен вөҗүден биләп алган иде инде: кая гына барса да, ни генә эшләсә дә Ул аның күз алдында, Ул аның уенда... Һәм бераздан Тамара Габделнурга яратып, ягымлы һәм җылы итеп, якты нур чәчеп торган күз карашы белән карады. Үзенең ачулана, үпкәли алмавына көрсенсә дә, болар аның көченнән килә торган гамәл түгеллегенә хурланса да, чынлыкта ул берни дә эшли алмый, йөрәк тибешенә буйсынудан гайре чарасы юк, монда мәсьәләне акыл хәл итми, бу авыр халәттән котылу юлы да юк иде инде.

Кызның хәлен бер күрүдә үк чамалаган егет бу үзгәрешне сизеп алды. Үзенчә, башта каты торса да, ахыры йомшак булачак, дип дөрес фаразлаган икән. Шуңа күрә ул килеп керү белән аңа кагылмавын, кирәк-кирәкмәс чакта иркәләү-назлау белән мавыкмавын, үзенең хисләре хакында сүз катмавын дөрес булган гамәл дип санады. Менә «көн» ачылып китте, «болытлар» таралды. Хәзер... ярый.

Габделнур, торып, кыз каршына килде, иелә төшеп аның башын кочты, йомшак чәчләрен сыйпады.

—Сагындым.

Алкасы бар икән.

—Колагымны авырттырма,—диде кыз чак кына ишетелерлек итеп.

Егет аны җиңел генә күтәреп алды. Күзләрен, иреннәрен үбәргә кереште. Аннары колагына назлы сүзләр пышылдый башлады. Кызның тәкате бетте, буыннары сыекланды, моннан ары да каршы тора алмаячагын аңлады, зиһене томаланды. Дөресен әйткәндә, аның каршылык күрсәтерлек, сөйгәненең теләгенә карышырлык хәле дә, уе да юк иде инде. Ул Габделнурның муенын кайнар куллары белән кочып алды. Үзе дә, күзләрен йомып, аның иреннәрен эзләде... Егет аны җайлап кына күтәреп диванга салмакчы булды.

—Юк, кирәкми,—диде кыз пышылдап.

—Теге яккамы? Койкагамы?

Кыз башын селкеде, дәшмәде.

Габделнур аны йокы бүлмәсенә алып керде. Анда ике карават бар иде, берсе—җыелмаган. «Димәк...»—дип тиз генә үзенчә фикер йөртте егет. Шунда илтеп салды.

—Күлмәкне бөгәрлисең.

—Сал.

—Юк.

Егет аны янә кулына алды, аягүрә бастырды, күлмәген салдырды. Күзләре йомык Тамара лифчик белән трусиктан гына калды. Тәне ут кебек кайнар, көйдереп ала торган. Егет аны кабат койкага салды. Үзе дә исерек кеше хәлендә иде, башына кан йөгерде. Тиз-тиз генә чишенеп атты. Кыз күзләрен ачмыйча гына пышылдады.

—Карама.

Егет анын күкрәкчәсен дә салдырды, берөзлексез үбә, коча башлады. Габделнурның кулы аягына тигәч, калтырап китте кыз.

—Кирәкми! Кирәкми!

Ләкин егет аңа карамады, ай-ваена куймыйча, үз эшен эшләде: карышкан кулын алып, икенчесе белән бергә үзенең сул кулына тотты, уңы буш иде... Тамара тыпырчына, йөзен егетнең башы астына, муенына яшерә. Габделнур берөзлексез үбә, назлый торгач, кызның түзәр әмәле калмады: егетне кочаклап алды һәм... кычкырып җибәрде.

—А-а-а...

Урамда тавыш ишетелде, һавада очкыч гүләве булса кирәк. Беренче тапкыр ир-ат кочагында беркаян бернинди ярдәм көтә алмаслык хәлдә ялгыз калган һәм ул ярдәмне кирәксенмәгән дә саф кызның кычкыру авазы самолет гөрелтесенә күмелде...

...Кыз үзе елый, үзе сөйләнә.

—Син—беренче... Мин сине кичә көттем... Бер ярты кызыл шәраб алган идем, яртысын эчтем!..

Габделнур аны юатты, чәчләрен сыйпады, үпте. Беразга гына тынып торды да кыз тагын елый башлады.

—Әнигә ни әйтермен!..

Аннары ул, торып, егеткә карарга кыймыйча, бүлмәдән чыгып китте.

Габделнур кузгалды. Җәймәдәге кызыл тапны күрде. Шулай да шикләнде. Шифоньер өстендәге шешәне, яртылаш кына калган кызыл шәрабны, кулына алып, бөкесен ачты да чак кына җәймәгә тамызды: аерма бар иде. Шәраб шешәсен урынына кунаклатты... «Димәк, алдамый»,—дип фикер йөртте.

Тамара (ул халаттан иде) кереп, җәймәне алып чыгып китте. Габделнур анын артыннан ваннага керде. Кыз сулкылдый-сулкылдый елый иде. Үзе берөзлексез кабатлый.

—Әнигә ни әйтермен? Нишләдем мин?!

Егет аны кочаклады, булдыра алганча юатты, назлы сүзләрен җәлләмәде.

***

...Сәгать уникеләрдә комлыкка киттеләр. Көнозын кызындылар. Кайтырга чыктылар.

—Кинога барыйк,—диде кыз.

—Ярый, керик.

Алар, «Звездочка» кинотеатрына кереп, «Ловко устроился» дигән фильм карадылар. Америкада төшерелгән әлеге комедияне караганда Тамара тәмам тынычланды, бөтен тәне белән егеткә сыенып утырды, анын беләген, кулын бер генә секундка да кулыннан ычкындырмады. Егет тә аны кочагында (алар иң арттагы рәттә утырганнар иде) тотты...

Кайтып киттеләр. Тамаралар йорты белән янәшәдәге азык-төлек кибетеннән ашарга ипи, сыр һәм башка ризык алдылар.

Өйгә керешли Тамара почта тартмасын карады. Анда телеграмма ята икән.

—Ульяновскидан әни җибәргән,—диде кыз һәм алгы бүлмәдә үк укый башлады.—«Кадерле кызым! Сине туган көнең белән тәбрик итәм! Сиңа бәхет телим!»

Котлауны укыгач, ул янә балавыз сыгып алды.

—Кичә әтидән килгән иде. Ул да Казанда түгел.

—Ярышка киткәннәрмени?

—Әйе.

Кыз ашарга пешергән арада Габделнур черем итеп алмакчы булды. Баягы караватка ятты. Бүлмә эченә күз салды... Шүрлектә китаплар... Өстәлдә көзге... Тәрәзә төбендә чәч... Күзләре йомылды...

Күпмедер вакыт үткәч, Тамара аны сак кына уятты. Капкалап алдылар. Бераз телевизор карагач, йокы бүлмәсенә керделәр. Яттылар.

—Кирәкми, авырта,—дип ялынды кыз.

—Бер генә...

—Түз инде зинһар...

Ләкин егетнең сабырлыгы җитмәде, барыбер үзенекен итте: ташы кызган иде... Кыз тагын күз яше түкте... Бераздан кемдер шалтыратты: коридордагы кыңгырау аваз салды. Тамара, торып, өстенә халат киеп, ишек янына барды, сорады.

—Кем бар анда?

Тыштан җавап бирделәр. Кыз ишектән тайпылды.

—Кем ул?—дип шыпырт кына сорады торып аның янына чыккан Габделнур.

Кыз да, сул кулының имән бармагын иреннәренә куеп, тавышын күтәрмичә генә, егеткә карап:

—Күрше абый,—диде.—Тагын телефон кирәк булган.

Ул әле һаман елый, сулкылдап тора иде.

—Ачма,—диде егет һәм тиз-тиз киенә башлады.—Хәзергә, сау бул... Шалтыратырмын... Ярар, мин киттем.

Ул, кызның кочагыннан арынгач, кухняга чыгып, тәрәзәсен ачты һәм йортның арт ягындагы бакчага сикереп төште. (Бәхете, Тамаралар фатиры беренче катта гына иде.) Артына да борылып карамыйча бу өй тирәсеннән гаип булды. Ул кухня тәрәзәсен ябып азапланучы Тамараның аңа кул изәгәнен дә күрмәде.

## XXVIII

Октябрь ахыры.

Күк йөзе аксыл, салкын, җил.

Кичә кичтә яңгыр яуган иде. Бүген төнлә көчле салкын булган һәм агачларга боз ябышып каткан. Алар, тук башакларын күтәрә алмыйча иелгән арыш сабаклары кебек, көчле җилдә дә селкенмичә моңсу гына утыралар.

Кояш чыккан.

Җир өсте ап-ак. Үләннәр, әрем, сарут сабаклары, куаклар һәм агачлар көмеш сыман ялтырый башладылар.

Әнә шул хозурлыкка хәйран кала-кала Габделнур участокка бара. Ул иртән электр цехына кереп чыкты, Митрохинны, рәссамны күрде, йомышларын төгәлләгәч, җәяүләп эш урынына китте.

Агачлар, бозга төренгәч, бик тиз сыналар икән: бер нечкә ботакны сындырып карады да бүтән кагылмады—җәлләде. Басуда тар сукмактан барганда тагын шуны күрде: кыл нечкәлеге үләннәр дә, бәс катып, агачның нәзегрәк ботаклары кебек юанайганнар, алар аякка-тезгә килеп бәреләләр, шыбыр-шыбыр, чылтыр-чылтыр, шылтыр-шылтыр килеп төрле авазлар чыгаралар. Әйтерсең лә пыяла торбалар арасыннан барасың һәм аларның бер-берсенә бәрелеп ниндидер көй чыгаруын тыңлыйсың...

...Эштән бушаган араларда Габделнур төзелеш объектларына карап торырга ярата. Биналарның күпчелеге тимер-бетон плитә-панель-блоклардан җыела, кайберләрен кирпечтән күтәрәләр.

Бүген дә ул, участокны әйләнеп, хуҗалыгын барлап чыккач,

ташчыларның кирпеч тезгәнен карап торды. Яна корпусның икенче каты биеклегенә күтәрелгәннәр, әмма аларның ничек эшләгәне аермачык күренә: житез, көчле кул белән кирпечне үрелеп алулары, як-ягына измә сылаулары, тезгәннәре янына җайлап кына яткырулары, калай кельма белән шак-шок бәргәләүләре, артык измәне тышкы дивардан сыпырып алулары... Измә салып җаяләр дә янә кирпечкә үреләләр... Көнозын шулай... Кайберәүләр шулхәтле житез эшли, бер үк хәрәкәтләрне өзлексез кабатлый—автомат диярсең. Хәер, озак еллар эшләгәч кул да, күз дә ияләнәдер шул инде. Ярдәмче эшче хатыннар измә белән кирпечне житкереп кенә өлгерсен...

Әйе, матур эшлиләр, кем әйтмешли, хезмәт җимешләренә дә, үзләренә дә сокланып туя алмассың. Әмма, ни кызганыч, шул осталарның кайберләре өйдә җәнҗал кубара; аларның гаиләдә үз-үзләрен ничек тотуларын ишетү—сискәндереп җибәрә.

—Төш турында ташчылар бригадасында җыелыш,—диде мастер будкадан башын тыгып.—Син дә кереп утыр. Син коммунист бит.

—Кем икәнемне син искәртмәсәң дә беләм,—диде Габделнур салкын гына.—Керермен.

Үзе партиясез булгангамы (заманында трест парткомында кандидатурасы узмаган диләр) бу мастер җае чыкканда гел шулай төрттерергә, чеметеп алырга ярата иде. Югыйсә Габделнур ул әйтмәсә дә участокта үтә торган чараларның берсеннән дә читтә калмый...

Аш—ашка, урыны—башка, дигәндәй, эш һәм укудан тыш тагын мөһим бер шөгыль—мәхәббәт мажаралары да аны биләп алган иде бит.

***

Габделнур Тамараларга әле тагын бик күп мәртәбәләр—ике ай буе килгәләде, әлбәттә, ата-аналар кунакка—яшьләр җыела аулакка, дигәндәй, кызның әнисе югында гына. Ә күпчелек вакыт ул Тамараны егетләр булмаганда үз бүлмәсенә алып кайтты. Кыз аңа карусыз бирелә иде. Чөнки ул инде егеткә тәмамысы ияләнеп җиткән һәм язмышын шуның белән бәйләргә әзер.

Беркөнне, Габделнур аны озата килгәч, ул егеткә сарылып, ихлас ярату белән күзләренә карап, әйтеп куйды.

—Әйдә, керик тә, әнигә әйтик.

—Нәрсәне?

Бу араларда татлы уйларга йотылып йөргән кыз әле үзенен күнелендә генә саклаган эч серен әйтеп бирде.

—Безнең өйләнешергә җыенуыбызны.

Егет бермәл багана кебек катып калды: анын Тамарага, өйләнәм, дип өметләндергәне, гомумән, бу хакта сүз кузгатканы, булыр-булмас нәрсә лыгырдап, авыз чайкаганы юк. Шуны әйтергә кирәк: кызнын да моңарчы телдән бу уен белдергәне булмады. Күрәсең, бу теләк кызның күнелен күптәннән биләп алган, үзеннән-үзе шулай хәл ителергә, ахыры шуның белән тәмамланырга тиешле нәрсә, дип уйлый. Кияүгә чыгу—буй житкән һәр кыз баланың хыялы; аларны табигать шулай яраткан, ул шуңа әзерләнә; анын ир хатыны, ана буласы бар. Бу җәһәттән караганда Тамара гына башкача фикер йөртүче кыз түгел иде. Андый момент килеп житкән чакларда кыз бала эш-уку гамәлләрен дә оныта, чолгап алган мохитнең дә әһәмияте бетә, әйләнә-тирәсендәге кешеләр сүзе дә аңа керми, хәтта ата-ана үгет-нәсихәте дә үз көчен югалта—бер колагыннан керә, икенчесеннән—чыга, аларның аек акыл белән әйткән уй-фикерләре мие томаланган кыз баланың аңына барып житми... Менә хәзерге кебек

ике арада булган хәлләрдән соң бигрәк тә... Тамара Габделнурга кыз балада саклана торган иң кадерле әйберсен—гыйффәтен бүләк итте: үзе теләп, аны яратып, аңа өмет баглап һәм ышанып бирелде. Чөнки ул хәзер кызның төп терәге: әтисе урынына да, егете урынына да. Әтисе киткәч, газап йотып йөргән көннәрдә Габделнур аңа таяныч булды. Кыз аны, үзе дә сизмәстән, язмышына хужа буласы кеше—ире итеп күрде, аны фәкать шулай күз алдына китерә иде. Ышанмаган, яратмаган, якын тоймаган кешегә кыз бала иң кадерле нәрсәсен алай тиз генә бирми. Әгәр ул үз теләге белән шушы адымга бара икән, аңлашылса кирәк, бу инде мең кат уйланылган...Чөнки Тамара моны аек баштан, аңлы рәвештә эшләде. Әгәр теләмәсә, аны Габделнур да, бүтән берәү дә—берсе-бер тел белән генә түгел, көч белән дә ала, бу адымга барырга мәҗбүр итә алмаслар иде. Кыз спорт белән нык шөгыльләнде, үзендә физик көч барын да белә, ихтыяры һәм рухи ныклыгы җитәрлек икәнен дә яхшы тоя иде. Ләкин дәрте, үзенә иш булырдай буй-сынлы бу егетне якын итүе, йөрәге кабул итүе өстенлек алды һәм... ул хәл булды. Тамара бу турыда бик күп укыды, үзе әйтмешли, теоретик яктан нык чарланган иде. Иптәш кызларының да берничәсе шулай эшләде. Икесен генә мәҗбүр иттеләр—көч белән алдылар...

Шул хәлләрдән чыгып фикер йөрткәндә аның Габделнур белән чәч бәйләргә теләве үзеннән-үзе аңлашылса кирәк.

Сөйгән егетенең тыныч холык-фигыле дә, кылтаймыйча җитди һәм урыны белән юмор кушып сөйләшә белүе дә, сүзләренең үтемле һәм төпле булуы да, тәмәке тартмавы һәм хәмер белән мавыкмавы да, эше белән укуының бергә үрелеп баруы һәм алда ниндидер перспективага, үсешкә өмет тотуы да—барысы да кызның ихтирамын бермә-бер арттыра иде. Аларның һәрчак уртак темалары да табылып тора. Тормыш сукмагыннан янәшә, кулга-кул тотынышып атлаганда бу да мөһимдер кебек тоела кызга.

Иптәш кызлары белән аралашудан, сер бүлешүдән ул шундый нәтиҗә дә ясады: бу егет ир-ат буларак аны тулысынча канәгатьләндерә. Ир хатыны булгач, монысы да бик мөһим икән. Юкка гынамы ана җәнлек-җанварлар иң гайрәтле иркәккә өстенлек бирәләр, үзләренә пар итеп иң көчлене, алар өчен орышта җиңгәнне сайлыйлар! Егет бу яктан да сынауны уңышлы үтте. Шулай булгач, инде вакыт җитте кебек. Дөрес, Тамара үзендә бернинди дә үзгәреш сизми әлегә. Ләкин еш очрашуларның, бернинди дә саклык чаралары күрелмәвенең ахыры ни-нәрсә белән бетәчәген ул аз-маз чамалый.

Тик менә егет—Габделнур—әле гаилә корыр вакыт җитте, дип уйламый, үпкән-кочкан—җилгә очкан, дип тагын бераз йөрергә ниятли иде. Бердән, аңа әле егерме алты гына, яшьлегенең кадерен белеп, ни кыланса—шул килешә өйләнмәгән егеткә, дип типтереп калу форсатын кулдан ычкындырасы килми. Ут—утыннан, күз караудан туймас, диләр бит. Бигрәк тә шәһәр җирендә, чат саен чибәр кызлар очрап, куенына керергә әзер торганда кулыңны бәйләү—юләрлек булыр иде... «Яшь гомерләр ике килми, сулар үргә акса да»,—дип юкка гына җырлаганнармы?! Икенчедән,—монысы иң мөһиме—аның бу авыр йөк-вазифаны әле шушы араларда гына җилкәсенә саласы килми иде. Әйе, ул тормыш коруны, кечкенәдән үк, авыр вазифа, дип уйларга күнекте. Чөнки гаилә өчен һәрчак аның башлыгы—ир заты җавап бирә. «Ир—баш, хатын—муен»,—дигән әйтем канына сеңгән. Хәлбуки, кайбер хатын-кыз: «...Муен кая борылса...»—дип тә җибәрә. Ләкин баш уйламаса, муен да борылмаячагын егет яхшы аңлый. (Хәер, моны укучы балалар да белә.) Үз-үзен хөрмәт иткән ир мөстәкыйльлеген югалтмаска, һәрдаим үзен гаилә башлыгы итеп тоярга һәм тотарга тиеш. Хатын-кыз сүзен тыңларга, әмма аның кубызына биемәскә. Моның өчен

исә һәр яклап әзер булырга тиеш ир заты. Шуңа күрә, арбаны дегет тота, хатынны егет тота, дип тә әйтәләр бит. Әйе, авыл малае буларак, ул шулай тәрбияләнгән: йорт-җир һәм каралты-кура торгызу, акча һәм азык-төлек табу, мал-туар асрау, өс-баш һәм кирәк-ярак юнәтү—барысы да үз-үзенә ихтирамы булган ир-егетнең төп һәм изге бурычы. Бу—борынгыдан килгән. Аннары соң, шул кадәресе дә бар бит әле: әгәр өйләнәсең икән инде, бетте, шабаш, элеккечә әйтсәк, ярәшкән кызың белән торырга тиешсең. Кыз балага да кияүгә чыкканда, «төшкән җирендә туфрак бул», диләр бит. Димәк, дип зиһен йөртте егет, ике якка да таләпләр бердәй тигез куела... Шуңамыдыр, Габделнур бу мәсьәләгә бик җитди карый иде. Хатын аерып йөрү кебек ямьсез гадәт-күренешләр аларның кан-кардәшләре арасында булмаган. Хәтта ике хатын белән торучыны да ишеткәне юк Габделнурның. Югыйсә ерак бабалары хәлле генә кешеләр булганнар... Димәк, алар, ике кызны сөй, иллә-мәгәр, берәве белән гомер ит, дигән кагыйдәне тотып яшәгәннәр. Ә ул—Габделнур атлы егет—үзен шушы ишле, абруйлы агай-эне, нәсел-ыруның дәвамчыларыннан берсе дип күзаллый, атсыз-затсыз итеп тоймый иде. Юкка гынамы, берәр гаеп-кыек яки ярамаган гамәл кылыну ихтималы күренсә, әтисе, Галләм абзый, һәрчак, нәселдә булмаганны, дип кенә җибәрә иде. Бу сүзләр үз балаларына гына түгел, ә сеңелләренең угыл-кызларына карата да әйтелә иде. Шуңа күрә Габделнурның туганнан туган ага-энеләре дә нинди генә булса җитди адым ясарга, олы һәм җаваплы эшкә керешер алдыннан аның әтисенә киңәшкә киләләр иде.

Әйе, үзе уйлаганча, Габделнур әле башлы-күзле булырга әзер түгел. Чөнки мәшәкате муеннан: укып бетерәсе бар, алда—башланмаган ике ел, дүрт семестр дигән сүз, исәп-хисапсыз семинар һәм контроль эшләр, зачет-сынаулар... Бала б...на батса, укуының рәте-чираты китәчәген ул бик ачык күзаллый. Чөнки курсташларының күбесе гаиләле һәм ул аларның ничек интеккәннәрен әйбәт белә. Бу җәфа чигүдән котылу өчен укуын ташлаучылар да булды... Өйләнү—түгел сөйләнү, дигәндәй, әле кайдадыр яшәргә дә кирәк бит. Фатир мәсьәләсе дә бүген-иртәгә генә хәл ителәчәк түгел. (Дөрес, чират бара баруын.) Кыз, бәлки, үзебездә яшәрбез, дип уйлый торгандыр. «Әзер ояга йомырка салуы җиңел, әлбәттә»,—дип уйлады егет. Ә андый юлга Габделнур гомердә дә бармаячак: йортка кермәк—җан бирмәк. Бу вариант—аның өчен кулай түгел. Безнең халык йортка керүне өнәми, бу эш егет кешене бизәми. Хәер, бүтән халыкларда да ул хупланмый. Казанда бергә хезмәт иткән дусты Гена, мордва егете, бервакыт, сүз иярә сүз чыгып, кияүнең хатыны өендә яшәве—хурлык, ул әбисе өендә елына биш тапкыр гына булырга тиеш, дигән иде. Әйе, ул хакта уйлану гына да Габделнурның эчен бора башлый... Йөрерсең аннары, урамда—май чүлмәге, өеңдә көл чүлмәге булып... Берсеннән котылды бит инде. «Әби»сенең башта бездә торырсыз, аннары кооператив квартир алып бирермен, дип алтын таулары вәгъдә итүен һич онытмый... Димәк... «Эшләр тыгызга киткәнче чабуны җыярга, койрык бозга катканчы ычкынырга кирәк»,—дип фикер йөртте егет кыска гына вакыт эчендә дәшми торган, тынлык урнашкан мизгелдә.

...Ләкин аның, киләчәген уйлап, татлы уйларга йотылган бу гүзәлнең кәефен кырасы килмәде һәм ул күңелләндәгеен кызга әйтмәде.

—Алай кисәк белдерү ярап бетмәс,—диде ул ягымлы гына һәм Тамараны кочагына алды.—Башта загста белешик, гариза бирик. Әниеңне дә бераз гына әзерләргә кирәк. Алай бик капыл гына килеп чыкмасын. Аннары әйтсәк тә була. Без аның белән таныш та түгел бит әле.

—Ул сине белә, каршы килмәс.

—Шулай да... Бүген түгел. Өстә дә гадәти генә кием... Әйтәләр бит: киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар. Минем аның күзенә

юньлерәк кыяфәттә күренәсем килә. «Кыз катына барган чакта бүркең камалы булсын!» дигән безнең бабайлар. Бәлки... иртәгә әйтербез?

—Ярар,—диде кыз юаш кына.

Яратуы, егеткә булган ышанычы шултиклем көчле иде ки, үз сүзендә торырга батырчылыгы җитмәде. «Иртәгә дә көн бар бит... Ул ничек әйтсә, шулай булыр»,—дип өметләнә иде. Шуңа күрә күңелен боектырмады, кешеләргә явызлык эсти белмәгән гөнаһсыз җан Габделнурга чын күңеленнән ышанды. Соравын яңадан кабатларга, катгый рәвештә таләп итәргә базмады, үтенеченең аяк астында калмаячагына өметләнде.

Дөресен генә әйткәндә, бик җиңел генә үз теләгенә ирешү дә егетне бераз шиккә салды, итәгемме, җиңемме, шушы минем тиңемме, дигән кебек, сагайта калды. Ул бит артык каршылык күрмәде. Әлбәттә, кызның аны яратуы, аңа ышануы монда зур роль уйнагандыр. Ләкин... барыбер ул болай тиз бирелүе белән егетнең күңеле суынуга, күңеле кайтуга үзе сәбәпче иде түгелме соң? Пакь кием кадер арттырыр, диләрме әле? Мондый эшләр фәкать туй узгач кына эшләнергә тиеш түгелме соң? Шуңа күрә дә кызлар ул көнне (дөресрәге, төнне) курка-өркә, шик-шөбһә тулы уйлар белән көтеп алалар. Никадәр генә яратмасыннар, егет куенына вакытыннан алда кермәскә, буй бирмәскә тырышалар... Ә монда намус пәрдәсе бик җиңел ачылды...

Дөрес, бу урында шаять, җаена сала белсәң, энә дә суда батмый, дигәндәй, Габделнурның «булдыклы»лыгын, сүзен сүз итә, эшен эш итә белүен дә, кызның көенә генә торуын, бөтен ихтыяр көчен, мөмкинлекләрен аны яулап алуга туплавын да онытырга ярамастыр. Аның кылган һәр гамәле исәпле, һәр сүзе уйланылган, бөтен омтылышы бер ноктага юнәлгән иде. Көнең килеп җиткәнне сабыр гына көтү—үзе егетлек.

Саф кыз... Кырыкта булса да кыз булсын, дигәнгә, кыз дип кызыкма, бер көн хатын булыр, дип тә әйтәләр әйтүен. Ләкин... әйе, тормышның әнә шундый «ләкин»нәре дә бар бит әле аның. Ул соңыннан сиңа—парына, аккош кебек тугрылык саклармы? Бу сыйфатлар аңа ана сөте белән кергәнме? Ефәк тузып, югычка да ярамаслык хәлгә килмәсме? Хатын-кызның башын әйләндерердәй тасма телле, зиһенен чуалтырдай төс-кыяфәтле берәүнең тезенә җиңел генә утырмасмы? Икене, өчне ияртә торган кәҗәгә әйләнмәсме?

Пионер, комсомол, партия сафларында чын атеист булып тәрбияләнсә-чыныкса да Габделнурга аны авылга алып кайтырга, әти-әнисенә, әбиләренә, менә сезгә килен алып кайттым, дип тәкъдим итәсе дә бар бит әле. Аларны үзләренә кунакка дәшәсе булыр. Нәрсә белән сыйлар, нинди ризык пешерер килен балакай каенана белән каенатайга? Кода-кодагыйларның кунак-кунак «уйный» торган гадәте дә бар бит. Алар иркенләп гәп корып утыра алырлармы? Саный китсәң, шактыйга җыела икән телдән әйтелмәсә дә күңел түренә сеңгән, табу урынына йөри торган ул «ләкин»нәр...

Шуларны уйлагач, Габделнур ирексездән көлеп куйды. Егет кызның әти-әнисенә кем дип эндәшергә тиеш булыр иде икән?.. Ул үзләренең өендәге хәлләрне, үзара мөгамәләне күз алдына китерде: апасы Гөл-сылуның ире Насиф Галләм абзыйга, бабай, ди, ә Гөлзифа түтигә, әби, дип эндәшә. Өлкәннәр дә Насифны яраталар, кияү, дип өтәләнеп торалар. Кыскасы, борынгыдан килгән гореф-гадәт саклана, дәвам итә. Ә Габделнур Тамараның ата-анасына, дедушка, бабушка, дип әйтә алмый бит инде. Алар әле яшьләр,—дөрес анламаслар, аннары бу Габделнур белән (кияү булган суратттә) алар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне—туганлашуны да дөрес чагылдырмаячак. Ә бала тугач нишләргә? Кем дип исем кушарга? Һәр ике

як та тезгенне үзенә таба тартырга маташачак. Димәк...

Әнисенең бер сүзе гелән генә Габделнурның колак төбендә ишетелеп тора сыман.

Ялга кайткач, алар өйдә икәве генә чагында, Гөлзифа түти ачуланмый-сүкми, тавышын күтәрми, әмма кистереп дигәндәй әйтеп куйган иде.

—Улым, йөргән кызларыңны бер дә безгә белгертмисең. Алай да, килен буласы кешегә тарысаң, кода-кодагыйлар белән иркенләп чөкердәшеп сөйләшеп утырырлык булсын, яме.

Анасының сүзләрен малае уенга борып, көлеп кенә куйды.

—Ярар, әни, юк өчен борчылма.

Әмма ананың фикер сөреше улына барып житте, күңел түренә кереп оялады.

Матур хатын—ир күрке, диләр. Сүз дә юк, Тамара ярамаслык түгел: коеп куйгандай буй-сыны дисеңме, егет-җилән күзе төшәрдәй төс-бите дисеңме, аек акыллы холык-фигыле дисеңме—барысына да һич шикләнми кул куярлык. Әмма... Егет, чабышта үз-үзен тыярга мәҗбүр булган юртак аргамак кебек, ашыкмаска, сулу алырга тырышты. «Чапаланма,—диде ул катгый итеп.—Сабыр бул. Ахырдан үзеңнең дөя түгеллегеңне исбат итә алмассың! Әйтергә таба түгел, кыз—шәп! Ниндидер сөйкемле сөяге дә бар шикелле. Ләкин... Һава хәленә, карына карап мазь сайлаган чаңгычы кебек, кат-кат тикшер, төрле вариантлар булуын онытма. Тормыш атлы чаңгын көйле барырлык булсын...»

Егетнең күңеленә шик төшергән тагын бер нәрсә бар иде. Тамара бөтен нечкәлекләрен әйтеп бетермәсә дә, егет аның әнисенең әтисе өстеннән йөргәнен, салу мәсьәләсендә дә нәфесен тыя алмаучы хатын икәнен аңлады. Димәк, анасына карап, кызын кочарга кирәк... Авылда картлардан ишеткәне бар иде Габделнурның: «Сыер алсаң, тоягына кара, хатын алсаң, ыруына кара». Әйе, әйтүе җиңел. Ә чынлыкта? Хәер, авыл җирендә нәсел-нәсәбен тикшерү кыен түгел, чөнки анда борын-борыннан халык бер-берсен җиде буынына кадәр белә. Әйтик, фәләннекеләр бер кардәш-ыруны тәшкил итә, төгәннекеләр—икенчене. Хәтта зиратта да һәр агай-энә, туган-тумачаның үз урыннары бар... Шуңа күрә кемгә кем кулайрак туры килә, кемне килен итеп төшерергә, кемне кияү итеп түр башына утыртырга—болар әллә ни катлаулы, чишә алмаслык мәсьәлә түгел. Авыл шартларында таләпләр егеткә дә, кызга да бердәй куела: тормыш алып баруы, эш рәтен белүе, кул осталыгы, тәртип ягы, уңган-житез булуы, бер-беренә тугрылык саклавы, гаиләдә әхлак-тәрбия мәсьәләләренә караш—барысы исәпкә алына, һәркайсы күз уңында тотыла. Дөрес, сала җирендә дә кагыйдәдән чыгармалар булгалый, яшь-җилбәзәк бөтенесен уйлап житкерми, иш-ишкә куш килү-килмәвен бөртекләп тормый: бер егеткә ошаган кыз фәлән нәселнеке булса ни дә, төгән ыругныкы булса ни—ошаган—өйләнә. Ник син аның башында тукмак тукымыйсың. Әле күрше-тирә авыллар да бар бит. Әйе, дөнья булгач, авылда да төрле хәлләр килеп чыга.

Ә менә шәһәр җирендә мәсьәлә бүтәнчәрәк тора. Кала—зур, яшәү—аерым, кешеләрне бик белеп бетермисең (еллар буе күрше-күлән белән дә аралашмаучылар бар), читләтеп кенә сораштырырга, өзек-өзек сүзләрдән үзенә чамаларга, нәтиҗә чыгарырга кала. Габделнур, яшь булса да, уйламыйча булдыра алмады. Тамара, әнисе... Димәк, ирне ир дип хөрмәтләү, олылау ул хатында җитәрлек микъдарда булды микән? Әллә, әүвәл—Алла, икенче—патша, өченче—ир, дигән төшенчә аңа ят микән?

Әлбәттә, кызын яраткач, анасы турындагы ямьсез уйларны, керләнмәс ак булмас, дип читкәрәк куып җибәрергә дә мөмкин. Бәлки шулай дөресрәктер дә әле. Даһи юлбашчы әйтмешли, балалар ата-аналары өчен җавап бирми

шикелле. Әмма монда кешенең нәсел-нәсәбе, дәвамы һәм, ниһаять, егетнең үз язмышы хакында сүз бара бит. Шуңа күрә Габделнур үзенең киләчәген күз уңында тотты.

Менә шул шик-шөбһәләр, башына килгән төрле уйлар да аны бимазалады.

Әлбәттә, егет болар хакында даими рәвештә уйланып йөрми, кем әйтмешли, башы яшь, алар төнге күк йөзендә сирәк-мирәк атылган йолдызлар кебек хәтер чоңгылында кабынып-кабынып кына китәләр һәм аны кирәк-кирәкмәс адым ясаудан тыеп калалар... әлегә. Ә алдагысын Алла белсен, дигәндәй, киләчәген тормыш үзе күрсәтер. Һәрхәлдә, ул моның шулай булачагына өмет тота. Ул белә: әгәр нигезе дөрес корылган булса, өй нык тора, ишелми-җимерелми озакка чыдый... Монысы—бәхет эше. Ә бәхет бөтен кешегә дә бертигез тәтеми. Борынгыларның, хатыннан уңсаң—казна, уңмасаң—каза, дигәне дә бар бит әле.

...Бу кичне дә әрәмгә җибәрәсе килми иде егетнең. Кыз бик теләмәсә дә, нәфесен тыеп тора алмады: өйләреннән читтәрәк, агачка сөяп кенә дәртен басты, күңелен хушландырды. Аннары, йорт янына якын ук бармыйча туктады һәм кыз белән мөмкин хәтле ягымлы кыланды: юка гәүдәсен сак кына назлады, чәчләрен иркәләп сыйпады, иреннәрен суырып-суырып үпте, төпләре сөрмәләнеп уелган (ни өчен икәнен егет үзе генә белә) күзләренә озак-озак итеп, сокланып карап торды. Кыз, билгеле, бу назлау-иркәләүгә эреп төште: бөтен барлыгы, кайнарлыгы, дәрте белән аңа сарылды, яңадан баягы сүзне кузгатмады.

—Мин сине яратам!—диде ул пышылдап.

—Мин дә.

—Бик яратам!

—Ярый, мин киттем,—диде Габделнур, ә үзе кызны назлавын дәвам итте.—Сау бул.

Егетнең китешли, башлап күргәндәгедәй озак карап торулары, сыйпаштырулары бу гүзәл затның төс-бите хәтерендә уелып калсын, озаграк саклансын өчен генә тырышудан гыйбарәт иде.

...Һәм ул аны хәтерендә генә калдырды, икенче көнне дә, өченче, дүртенче... кичне дә Тамара янына бармады, бәладән баш-аяк дип, шәүләсен дә күрсәтмәде, ул тарафка эзен суытты: бер кат ташлаган чабатаны кайтадан кимәскә булды.

Бу араларда ул, бер тишеккә генә ышанмаган акыллы тычкан кебек, еш кына күршедәге таныш егетләр янында озаклап утыра (гомер булмаганны кәрт суга, домино уйнап вакыт уздыра), бигрәк тә кызның тулай торакка килү ихтималы булган көннәрдә, бара-тора җепнең очы табылудан шикләнеп, үзләреннән чыгып сыза торган иде. «Нихәтле читтәрәк торсам, шулхәтле үзенә яхшырак булыр, күзенә чалынмам»,—дип гөман итә.

—Бүлмәсендә юк,—дип төшеп әйтәләр иде кызга аны чакыра менүчеләр.

Бүлмәдәш дуслары да һичкайчан аны сатмадылар, «пролетар теләктәшлек» күрсәттеләр. Аларның җаваплары төрлечә булса да, мәгънәсе бер, асылы шуна кайтып кала—аны яклау.

—Ул эштә.

—Ул укуда.

—Ул авылына кайтып китте...

Алар, кызның читкә кагылудан кимсетелгән, хәсрәт пәрдәсенә төрелгән йөзенә туры карап, күз дә йоммыйча алдыйлар, янәсе, үзләреннән мөннәт төшерәләр иде.

Әйе, алар, туган йортларыннан читкә китеп, ата-ананың, әби-бабайның

күз-колак булуыннан «котылган», тулай торак «тәрбиясе» алган егетләр, һичкайчан кыз баланың кәефен кырудан тайчанмадылар. Байтак гомерләрен горбәттә үткәреп, гөнаһ-мазардан куркудан узган, азау ярган бу зимагурлар әллә ни вөҗдан газабы кичермәделәр, ахрысы. Чөнки Тамара аларның кадерле апасы да, сөекле сеңлесе дә түгел... Үзләренең гаделсезгә рәнҗетелгән кыз туганнарының шулай тилмереп йөргәнен, аларның мөлдерәмә яшь тулы әрнү-сагышлы күзләрен күрсәләр, боек күңелләрен аңлый алсалар, бәлки егетләр икенче төрлерәк җавап биргән булырлар иде...

Инде бу кызны кабат күрмәм, дип уйлаган Габделнур ялгыша иде. Чөнки тау белән тау гына очрашмый бит...

## XXIX

Төн уртасы.

Габделнур иң соңгы кеше булып урынга ятты, күзләрен йомды.

Егетләр, тыныч сулап, изрәп йоклыйлар. Бүлмәдә дә, биш катлы кирпеч йортта да тынлык хөкем сөрә: караватлар да шыгырдамый, коридорда аяк тавышлары да һәм күрше бүлмәләрдән кеше авазлары да ишетелми, гүя әйләнә-тирә вә бөтен гавам тирән йокыга талган... Ә юк, әнә кемнәр өчендер тормыш-көнкүрешнең борчу-мәшәкатьләре төнката да тукталмый икән. Чөнки урамнан гөжләгән аваз инде—узып баручы ялгыз машина тавышы ишетелде...

Күпмедер вакыт чалкан яткач, Габделнур унга борылды, кулын баш астына куйды. Тик нигәдер йокы алмый. Көн буе уйланып йөргән башы, йөгереп тау төшкәндә кисәк кенә туктый алмаган малай кебек, тиз генә халәтен үзгәртә алмыйча җәфалана, ахры. Егет янә чалкан ятты. Шулай уңайрак: бөтен тәне, сөяк-санаклары тарала, ял итә. Ә менә ми күзәнәкләре... алар әле тиз генә тынычлана алмый, лотерея уйната торган пыяла барабандагы шарлар сыман бөтереләләр, куышалар, уйнаклыйлар, кыскасы, алар—өзлексез хәрәкәттә, тик үзләре күренмиләр генә. Әйе, тәне иркенләп, таралып, кыймылдамый ятса да, уйлары тынгы тапмый иза чигә...

Кайчагында ул үзен ике төрле тормыш белән яшәгән кебегрәк хис итә. Кайсыдыр журналдамы, әллә гәзиттәме параллель дөньялар турында мәкалә күзенә чалынган иде. (Әйе, атаклы галим Никола Теслага багышланган иде бугай ул. Аның: «Мин җир шарын урталай яра алам, ләкин теләмим»,—дигән үтә кыю һәм шик-шөбһә уята торган гаҗәеп сүзләре дә исендә калган.) Әйтик, без—кешеләр тормышы һәм янәшә генә тагын кемнәрнеңдер (алар, кеше, дип аталамы яки бүтәнчәме—анысы мөһим түгел) бердәй яшәеше бар икән. Егет үзен шулайрак хис итте. Менә бар бер дөнья—шау-шулы зур төзелеш ыгы-зыгысы—трест, идарә эчендәге вакыйгалар; бар икенчесе—аның үз тормышы, фәкать аңа гына кагыла торган яшәү рәвеше, уй-хисләре, хәл-әхвәле. Ләкин соңгысы кечерәк, таррак һәм масштаблы төзелеш кебек бөтен республикага, илгә шауламый. Алар өчен аның кирәге дә юк сыман. Әмма егетнең шәхси тормышы өчен һәр вакыйга әһәмиятле, үзенчәлекле—бүтән һичберкемнең яшәешен кабатламый торган. Менә аның өчен, гади бер электрик Габделнур өчен кайсы мөһимрәк? Әлбәттә, тегесе. Юкка гынамы шагыйрь: «Үзең турында уйлама, илең турында уйла, илең турында уйласаң, гомерең озын була», дип язмаган. Чөнки һәр кеше үзенең эшләре белән ил язмышын хәл итүгә күпмедер дәрәҗәдә өлеш кертә. Бу элек-электән шулай килгән. Борынгыларның, иле юкның икмәге юк, икмәге юкның түшәге юк, дигән сүзләрен истә тотып булса кирәк, шагыйрь аны Ватан язмышы кыл өстендә торган чорга карата әйткәндер. Әйе, шулай. Бәлки сугыш вакыты өчен бу

дөрестер. Ә тыныч тормышта? Кайчагында менә шундый мәзәк (кемдер, юләр, дияр) уйлар да килә иде Габделнур атлы егетнең башына...

Нигә дип андый уйлар килә икән? Җырдагыча: «Ник моңая безнең баш? Ник моңаймасын безнең баш, үзе ялгыз, үзе яшь», булгангамы? Ләкин егет андый «юләр» уйларны күп уйламаска тырыша, сирәк-мирәк килгәләгән чакларында да аларны куып җибәрү ягын чамалый. Чөнки ул үзен әнә шул зур төзелешнең бер әгъзасы итеп тоя. Ничек тә аннан аерылмаска (аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, диләр бит), иптәшләре, дуслары, хезмәттәшләре белән бер сафта атларга тырыша. Шулаен шулай, әмма шәхси тормыш—ул һәркемнеке аерым, һәр кешенең үзенчә сыйфатларга ия, үзенә генә хас төсмерләр белән бизәлгән. Урман аланы кебек: анда җиләге дә, чәчкәләре дә, чүп үләннәре дә бар. Күрәсең, бу шулай булырга тиештер дә. Гәрчә, Габделнур кебек гомуми торакта яшәүчеләргә андагы шартлар борынгы община строен-җәмгыятен хәтерләтсә дә—барысы да бөтенесенең күз алдында шикелле. Әмма тулай торактан чыгып киткәч һәркем үзенчә яши, гамәл кыла. Хәер, шәһәрдә генә түгел, һәркайда шулай. Ил, республика, район, авыл тормышы белән бәйләнеп яшәгән сала кешеләренең дә үз өйләре, үз тормыш-көнкүрешләре, яшәү рәвешләре.

Кызык, ә Африкадагы, дөньяда иң кыска буйлы пигмей кабиләләре (ир-атларның да буе йөз илле сантиметрдан артмый, диде этнография укытучысы) ничек яши икән? Аларның Габделнур яшендәге егетләре ни төрлерәк фикер йөртә икән? (Сүз уңаенда әйтик, анда, вакыты җиткәч, үсмерләрне җиргә сузып салалар да пычак белән тешләрен игиләр һәм шуннан соң гына алар «җегет кеше» саналалар икән.) Анда зур төзелешләр юк, алар шәһәрнең дә ни икәнен белмиләр. Ул гына да түгел, аларда хәтта кабилә башлыгы-юлбашчы, канун төшенчәләре дә юк. Аларны чолгап алган мохит—джунгли дип аталган, кыргый җәнлекләр мыжгып торган калын урманнар гына... Ә барыбер... үзләренчә гаилә коралар, балалар үстерәләр... Кызык... «Ярар, егет, алар инде күптән куышларында йокы симертәдер, иртәгә ауга чыгасылары бар. Сиңа да эшкә, йокла,—диде Габделнур үз-үзенә.—Күзеңә йокы кермәсә, сана: бер, ике... утыз... кырык...»

Кермәсә керми икән йокысы да! Һаман баягы уйлар тынгы бирми. Чүлмәк ташка бәрелсә дә, чүлмәккә вай, таш чүлмәккә бәрелсә дә, чүлмәккә вай, дигәндәй, инде башы шаулый башлады.

Менә ул, Габделнур, һәм тагын бик күпләр, буй җитмәстәй зур хыяллар белән, тормышны күпмедер дәрәҗәдә идеаллаштырып, Каверинның «Ике капитан» романындагы герой әйткәнчә, көрәшеп һәм эзләп, табып һәм бирешмичә яшиләр. Аларга илнең, төбәкнең, үзләре хезмәт куйган оешманың һәр уңышы—сөенеч. Ә бар шундыйлар... Әнә Каравай бистәсендә үз йорты белән торучы, монтажчылар бригадасында эретеп ябыштыручы булып эшләүче, юантык, тәбәнәк, симез гәүдәле абзый. Ул үз вазифасын биш бармагы кебек белә, әлбәттә, ярата, ләкин аннан да бигрәк... акча ярата—һәр минуты исәптә. Эштән соң калырга, ял көне чыгарга дисәләр, иң беренче сүзе—тияре күпме? Кемдер аны кызартырга теләсә, җавабы да әзер: «Циркта клоун бушка елмаймый да». Бәлки ул хаклыдыр: үз йортында яши, хуҗалыгы бар, хатыны өйдә ишле бала белән утыра. Абзый беркайчан да, бернинди дә җәмәгать эшләренә катнашмый, үзе әйтмешли, бушка койрык чәнчеп йөгерми, хәтта дружиначылар белән дә кичен чыкканы юк. Ул турыда ишетүгә үк кашы-күзе коела. Аны дөнья хәлләре дә кызыксындырмый.

Кичә Габделнур алар янына барган иде. Тәмәке тартырга, хәл җыярга

тукталган чаклары булды. Шунда халыкара хәлләр белән кызыксынучы монтажчы егет:

—Менә Гандураста хәлләр мөшкел икән әле,—диде.

Күбесе сораштыра башлады.

—Нәрсә булган?

—Кайчан?

Әлеге абзый исә:

—Ә син кашыма,—дип әйтеп салмасынмы.

—Нәрсәне?—дип сорады теге беркатлы егет.

—Кычытмаган җиреңне. Җаның тыныч булыр.

Бериш бригадирларны да белә Габделнур: алар—кулларына инструмент тотып карамыйлар, ярты көннәре прорабскида үтә. Ә бригадирларның күпчелеге—хезмәттәшләре белән янәшә торып, бердәй тир түгә.

«Кайсылары дөрес эшли? Кем дөрес яши?..»—дип уйлады Габделнур акрын гына йокыга китеп барышлый...

Инде генә йоклап киттем дигәндә тагын уяна: айный башлаган исерек кебек. Янә башында фикерләр кузгала...

Әйе, баягы уйлары хезмәт урыны, эш белән бәйләнгән. Әле бар бит фәкать шәхси тормышка гына кагылышлы яклар. Монда да чагыштырып карарлык, фикер җебеңне чуалтырлык нәрсәләр әз түгел.

Ул бит үзе ике төрле тормыш алып бара икән: яхшы һәм яман. (Бик примитив күзаллау, билгеле.) Дәлилләрме? Әйдә бераз фәлсәфәгә бирелик әле. Күрәсең, табигать тарафыннан адәм баласына туганда бөтен сыйфатлар да салына һәм, нинди мохиттә, ничек тәрбияләнүенә, яшәү шартларына карап, алар үсеш ала. Кемдер, гади генә итеп әйткәндә, үрнәк кеше булып үсә, ә икенче берәүдә тискәре сыйфатлар өстенлек итә. Югыйсә һәр сабыйның дөньяга аваз салуы бертөрле кебек: берсе дә мин—бандит яки мин—идеал булам, дип кычкырмый, фәкать яшәүгә лаек шәхес икәнен белгертеп кенә сөрән сала.

Менә ул үзе, Габделнур, кем? Бер яктан уйлап караганда, тел-теш тидермәслек чын асыл зат үрнәк иптәш сыман: эшли, укый, хезмәттәшләре һәм бүлмәдәшләре белән тату яши—үзара мөнәсәбәте әйбәт, ата-ананы хөрмәтли, туганнары белән аралаша, олыны—олы, кечене—кече итә белә, кеше малына кул сузмый—хөкем астында булганы юк... Кыскасы, бүген үк (хәзер соң инде, иртәгә иртүк) тот та Казанның иң биек җиренә (Кремль калкулыгы ук булмаса, Әмәт тавы да ярап тора) ак мәрмәрдән һәйкәл корып куй... Ә юк, бик кәпәренмә әле син, ашыкма, егет... Һәйкәлнең мәрмәрен түгел, юлга түши торган гади таштан куелганын да күпсенүчеләр булыр әле... Ни өченме? Син бит, бер бөек язучы әйтмешли, әйбәт начар кеше. Ничек инде ул алай? Әйдә, уйлап кара һәм хәзер яшертен генә (син аларын чит-ятларга бик белгертмисең бит) икенче яклап күз салыйк синең хәл-әхвәленә. Кара, бу бит бер дә пьедесталда басып торырлык ихтирамга лаек кеше түгел икән. Энҗене ике ел өметләндереп йөртте дә ташлап китте, Тамараны тилмертте (бәлки әле беренче мәртәбә Габделнур кочагына кергән караватта һаман балавыз сыгадыр), янәшә койкадагы яшүсмерне идәнгә тотып сылады... Саный китсәң, әле шактыйга җыеладыр кыек-мыек эшләрең... «Японнар, мине мактаган кеше—дошманым, ә тәнкыйть иткәне—укытучым, ди бугай. Мин үз-үземә дошман да, укытучы да булам микәнни?»—дип елмайды Габделнур аптырагач.

Җилсез яфрак селкенмәгән кебек, һәр нәрсәгә нидер сәбәпче була. Моны да истән чыгармыйк, агай-эне. Аны да бит гел генә көйләп-җайлап, иркәләп-назлап кына тормыйлар, тормышның ачы кырыс җилләре һәрдаим диярлек чәчләрен тузгыта, кемнәрнеңдер этлеге бәгырен телгәли.

Әйе, алдау-йолдауга юлыга, иң изге тойгы-хисләре җиргә салып таптала, кагылган-сугылган чаклар дисеңме—барысы да була бит... Боларын кая куясың? Шулар аркасында ул да, Нерон[4] кебек үк булмаса да, усаллана (аның урынында һәркем шул халәткә керер иде), тупаслана... Ыһы, болай уйласаң, ямаулыкка сүтек эзләсәң, һәр нәрсәне аклап була икән. Бәлки фикер сөрешен каршы якка юнәлтергә, йөз сиксән градуска борырга кирәктер һәм... Моңа чик куяргадыр? Әйтик, гел уңай сыйфатларны гына үзләштерергә һәм калку итеп үстерергә?! Ә тормышта алай булыр микән соң? Уң янагыңа суккан саен сулын куеп торсаң сине бөтенләй җиргә үк мәтәлдермәсләр дип кем гарантия бирә. Шул-шул менә. Кайда монда хакыйкать мизаны? Әйе, син рәнҗеткән кешеләр җәл. Ә синең үзеңне кем кызганыр? Әгәр кемдер кыерсытканда үз-үзеңне яклый алмасаң, үзеңә җайлысын-кулаен сайлап тормышыңны көйли алмасаң, соңыннан үзең үк үкенәчәксең бит. «Менә шулай, дускай гынам,—дип егет уй йөртә һәм нәтиҗә чыгара.—Әйе, һәр әйбер, һәр кылынган гамәл ике яклы: pro һәм kontra[5].

Ә сәгать уклары туктауны белмичә әкрен генә әйләнеш ясый: бер, ике...

Ниһаять, йокыга куера баруын тойган егетнең күз кабаклары авырая... Баш мингерәткеч уйлары каядыр еракка-еракка, караңгы бушлыкка таба агылалар һәм бераздан бөтенләй таралышып юкка чыгалар...

Кыш көне узган отчет-сайлау профсоюз җыелышында, Митрохин тәкъдиме белән, Габделнурны бертавыштан төзелеш комитеты әгъзасы итеп сайладылар. Дивар гәзите мөхәррире вазифасын ул булачак журналист егеткә тапшырды. Ә үзе баш-аягы белән яңа җәмәгать эшенә чумды.

Профкомда аны торак-көнкүреш комиссиясенә керттеләр. Аларның бурычы эштән буш вакытларда—кичке якта яки ял көннәрендә—төзүчеләрнең өйләренә барып, торак шартларын тикшереп, акт төзүдән гыйбарәт иде.

Әнә шундый кичләрнең берсендә, бакча аша кайтып барганда, ярдәм сорап кычкырган бер кызны коткарырга дип, агач арасына ташлангач, Габделнурның башына күсәк белән тондырдылар.

*Икенче кисәк тәмам*

---

[4] Нерон — бозыклыгы һәм кансызлыгы белән атаклы борынгы Рим императоры.
[5] Pro,kontra (лат.) — яклап,каршы.

Рифат
Җамал



# ҮТКӘННӘРДӘН КАЙТЫП КИЛӘМ...

***

**«Кырык яшем. Инде акыл кергән**
**Хисләрем дә әле китмәгән.**
**Әллә язым, әллә инде көзем**
**Һаман әле нидер җитмәгән.»**

**Диеп язган идем кичә генә**
**Инде алтмыш. Ешрак сулыймын.**
**Ә шулай да язгы ташкын кебек**
**Ярсу әле, тулы сулымын.**

***

*«Ярты-йортыларга ау башлыйм мин...*
*Миндә бүре каны! Мин—бүре!»*
Рүзәл Мөхәммәтшин

**«Мин дә—бүре!»—диеп сөрән салып,**
**Ау ачкансың «ярты-йортыга».**
**Тик бүренең казыйлыгы шикле**
**Кемнәр кертер аны йортына..**

**Бүре каны башны әйләндерә**
**Кемнәрнедер килә атасы.**
**Бүре өчен куян—ярты-йорты,**
**Тик ул да бит бала атасы.**

**Кемдер—бүре, кемдер—ярты-йорты,**
**Тик хакыйкатъ күпкә ачы ла.**
**Онытмасын бүре булмакчылар—**
**Бүрегә дә аучы табыла.**

Рифат ЖАМАЛ (1951)—*шагыйрь, ветеринария фәннәре докторы; Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. «Күңел сүрәләре», «Ташта үскән чәчәкләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Хыялларың вак булсалар
Тавык канаты кебек,
Күтәрмәсләр алар сине—
Урының булыр чүплек.
Тик күңелең тыныч булыр—
Һәрчак табарсың җимлек.

Хыялларың, өметләрең
Зуррак булса үзеңнән,
Эшкә ашмаслар да алар
Кеше көләр сүзеңнән.
Йөрәгеңә кан савар да,
Сагыш агар күзеңнән.

***

Урамнарда карлар ява
Тын гына, талгын гына.
Минем күңелем ак карлардай
Очар күк, талпын гына.

Талпындым, оча алмадым,
Янә җирдә калдым да
Аңладым—
Син юк, син юк пар канаттай,
Очар өчен янымда.

***

Сыным-буем кызлар өчен түгел,
Йөзем-битем коеп куймаган.
Тик шулай да яраттылар мине,
«Нигә?»—диеп күпме уйланган.

«Нигә?»—диеп күпме уйландым мин.
Ниләр белән үземә караттым?
Бер төн генә, бер көн генә булсын
Мин аларны үзем яраттым.

***

«Бар да уза!»—дип язылган
Сөләйман балдагына.
Үткәннәрдә бар да узган,
Узмаган алда гына.

«Бар да уза!»—дигән мөһер
Сөләйман бармагында.
Үткәннәрне онытмыйча
Алга бар, арма гына!
Алга бар, арма гына!

***

Синме икән соңгы януларым—
Кемнәр белә тормыш азагын...
Син бул!..
Булма!
(Ниләр диим?)
Минем соңгы газабым.

***

Шигырьләремне
Ошатмады җыен,
Бәлки
Азрак булган сыем.
Үземә дә ошамадылар—
Шунсы кыен.

***

*«Кайтып киләбезме үткәннән?»*
М.Мирза

Үткәннәрдән кайтып киләм—
Балачак, әти, әни...
Олыгайгач бөтен шатлыклар
Балачакта микәнни?

***

Кем яратмый мактаганны—
Үсенә моңа күңел.
Тик алданма, чын мактау ул
Үзең барында түгел.

***

Дуслар мактаганга
Китмәсен исең.
Дошманнан мактаттыр—
Булса көчең.

## Бер хатын әйткән иде

Бу дөньяда иң гүзәле
Хатын-кыз, ди барчасы да.
Чынында
Иң куркынычы да.

***

Кемнәр мал җыйган,
Кемдер аң җыйган...
Мал да калган,
Аң да калган.

## Парлар

Яшәү белән үлем,
Кояш баю, таң ату,
Егет вә кыз,
Сөю һәм югалту.

***

Бу дөньяда бушлык булмыйдыр,
Кояш баеса, Ай чыга.
Яхшылык, явызлык һәрдаим,
Тик кемнәр багына кайсына.

***

Уйланган кешегә кыен
Бу дөньяда яшәү.
Кайчак шагыйрь сүзеннән дә
Зуррактыр дәшмәү.

***

Атлар иярләмәдем,
Сөңгем булды каләмем.
Шуның белән яулап алдым
Синең серле галәмең.

## Бакча дәфтәре

Бер ягында кыяр-кишер,
Кайчан тишелгән икән...
Икенче яртысы—шигырь—
Сөю ишелгән көннәр.

***

**Мәчетләр күбәя,**
**Мәктәпләр азая,**
**Зиратлар зурая,**
**Авыллар кечерәя.**
**Бөкрәя ир-атлар...**

**Авылсыз зиратлар.**

***

**Еллар белән уйлар тирәнәя,**
**Хис диңгезе саегая...**
**Шул сай диңгездә булса да**
**Йөзәрлек каек кая?!**

***

**Ачтан үлмәс өчен бер кыерчык**
**Эзләгәндә меңнәр,**
**Бер капкорсак ябыгырга диеп,**
**Түли меңнәр...**

***

**Кем нәрсә эзли урманда?**
**Кемдер саф һава сулый.**
**Кемдер, тыңлап туялмыйча,**
**Тып-тын тынлыкны тыңлый.**

***

**Кемнәрнедер гел хурлыйлар,**
**Ә кемдер гел актан, гүя...**
**Ә бит рәсем ак-караны**
**Аралаштырганнан туа.**

***

**Кеше тынлыктан килә дә,**
**Тынлыкка китеп бара.**
**Күкрәп кал—кеше гомере—**
**Ике тынлык, бер ара.**

***

**Боз астында аккан инеш кебек**
**Тып-тын ага җаным. Ташымый.**
**Сез тимәгез аңа. Кайвакытта**
**Язгы дәрьялардай ярсу ул.**

***

**Әле җирдә яшәмәдем кебек,**
**Инде китеп барам... мөһаҗир.**
**Миннән калмас инде таш пулатлар,**
**Калса калыр бары моңлы җыр.**

**Редакциядән:**
***Каләмдәшебезнең бу айда юбилее. Аны ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!***



Гүзәл Әдһәм

# ӘТНӘБИ

ХИКӘЯ

Лиза, аякларын авыр сөйрәп, икенче катка күтәрелде. Кулындагы швабрасы, юеш чүпрәкләре белән «чәп-чеп» килеп, баскыч басмаларын санап, аңа иярде.

И-и, бар иде вакытлар! Мондый баскычлардан Лиза атлап та, йөгереп тә түгел, очып кына үтә иде! Очып кына... Каршы килүчеләр, аның белән очрашкач, үз-үзләрен белештермичә, каерылып артыннан карап калырлар иде... Үтте, үтте шул ул көннәр...

Коридордагы көзгегә күзе төшкәч, үз шәүләсен күреп тәннәре чымырдап китте.

Әстәгъфирулла! Улмы соң бу? Кайчандыр спорт чалбары вазифасын үтәгән, тезләре чыгып асылынган чүпрәк сәләмәсе белән юыла-юыла, нинди төстә булуы күптән онытылган футболка аламасы кигән, үкчәләре ашалып, икесе ике якка авышыбрак торган туфлиле бу хатын аңа бик чит һәм ... чиркангыч булып тоелды.

Хатын, ярсып, башындагы төссез яулыгын сыпырып төшерде. Озын авыр толым, иреккә чыгуына шатлангандай, буй булып сузылып төште. Тормыш бәсләреннән бүгенгә кадәр сакланып калган бу кара толым—Лизаның бердәнбер горурлыгы иде. Элеккеге Лизадан әле һаман «бәс сармаган» шул толым гына калды инде.

И-и, матур да иде соң Лиза! Ул сәхнәгә чыгып биегәндә күпме кеше, әсәренеп, сулыш та алмыйча аңа төбәлер иде. Чибәр түгел иде Лиза, матур иде! Матур иде! Жырларда жырлангандай, кашы да—«каләм», күзе дә «чем кара» түгел иде аның. Кара кашлары, шактый мул булып, берберсенә тоташып үскәннәр иде. Күзенең төсе дә бер караганда—яшел, бер караганда—зәңгәр, ә кайчагында соргылт булып тоела иде...

...Ходай яратканын сынар диләр. Ай-яй, сынады да соң тормыш Лизаны! Алтмыш биш яшең тулганда швабра өстерәп кеше артыннан жыештырып йөр инде! Бу эш табылуга сөенә-сөенә, житмәсә. Сөенмәссең! Картаеп

Гүзәл ӘДҺӘМ (Гүзәл Әдһәм кызы Шакирова)—*язучы, филология фәннәре кандидаты. «Наласа авылы көе» дигән бәяннәр һәм хикәяләр китабы авторы. Алабугада яши.*

килгәндә күзенә карап торучы унжиде яшьлек оныгың булса!

Лиза, Нуриясен искә төшереп, елмаеп куйды. Нурия... Нур иясе... Кыз быел мәктәпне бетереп институтка керергә хыяллана иде. Юк, институтка түгел! Сәнгать академиясенә! Факультеты да... Нинди әле? Тагын исеннән чыкты ләбаса. Ә-ә-ә... «Декоративно-прикладной»!

Улы Айдарны хулиганнар чәнчеп үтергәндә, оныгы Нуриягә әле ике генә яшь иде. Килене озак көенмәде, бер урыс белән тормышын бәйләде. Әй үртәлде дә соң Лиза оныгының Нуриядән «Нюрка»га әйләнүен күргәч! Күп тә үтмәде, шәһәр төзелешенә Рязаньнан килгән урыс үз якларына җыена башлады. Лиза аларның аяк астына егылып ялварды:

—Калдырыгыз Нуриямне! Минем аннан башка беркемем дә юк! Зинһар, аермагыз мине Нуриядән!

Урыс шундук ризалашты. Кулына ике яшьлек баласын тоткан, корсагы шактый түгәрәкләнеп килгән (тагын берне көтәләр!) хатынын көйләргә дә булышты хәтта.

Дөрес, тегесе башта елады. Аннары, вакытлыча гына, Нурияне калдырырга риза булды. Баштарак ике-өч айга бер хатлары килеп торса да, яши-яши алары да сирәгәйде. «Вакытлыча» калдырылган Нурия, шулай итеп, Лизада бөтенләйгә торып калды. Кызның унбиш яше тулгач төшкән фотосы салынган конвертның, «адресат выбыл» дип кире әйләнеп кайтуына да елдан артык вакыт узды инде...

***

...Лиза, яңа гына җыештырып чыгарган аудиториясенә карап, канәгать елмайды.

—«Кетер булды»...

Чынлап та, бүлмә ялт итеп тора иде.

—«Кетер итеп» юып чыгардым,—дип кабатлады ул тагын үз-үзенә.

«Кетер итеп» ... Бу сүзне ярата иде Лиза.

Нәфисә карчык сүзе... Аның Лиза сүзенә әверелүенә дә күпме вакыт үткән! Күпме соң? Йа, Раббем, кырык елдан артык! Ул чакта Нәфисә карчыкка да алтмыш биш яшь иде. Лиза яше! Лизаның хәзерге яше!

Әтнәдән бөтенләйгә күченеп киткәч тә Лиза Нәфисә карчыкны гел сагынып яшәде. Берәр эш башкарырга җыенса, «Нәфисә апай нишләр иде икән?»—дип күңелдән генә аның белән киңәшләште.

Нәфисә апай... Күни Нәфисәсе!

Беренче тапкыр аның белән очрашканда Лизага унсигез яшь кенә иде.

Унсигез яшь! Кемгә—ничек, ә Лизаның иң авыр, четерекле чаклары иде.

... Лиза әти-әнисен бөтенләй хәтерләми. Сугыш башланган елны татар авылына шәфкать туташы булып эшкә килгән аның әнисе. Чуаш кызы Анна... Күп тә үтмәгән, дөньяга Лиза аваз салган. Анна кызын бик яраткан диләр... Медпунктның бер бүлмәсендә яшәгән алар. Лизаның туган йорты да, беренче нигезе дә—шул медпункт булган. Кызчыкка ике яшь тулгач, Аннаны сугышка алганнар.

Лизаның икенче нигезе «детдом» булды. Татар авылындагы шул ятим балалар йортында Лиза унсигезен тутырды. Сугышырга, тырнашырга, үзен якларга өйрәнде.

Берлин өчен барган сугышлардан Анна әйләнеп кайтмаган. Аның гәүдәсе белән бергә «әти» дигән кеше турындагы серне дә җир үз куенына алган. Документта гына «әтисе» графасындагы «Лазарь» исеме, сергә уралып, бүгенгә кадәр яши бирә. Кем идең син, Лазарь? Татармы? Русмы? Әллә чуашмы?

«Лиза Лазаревна» дип дәшәләр иде аңа.

Беренче тапкыр шулай олылап директорлары Фәния апа атады. Атады да, кулына паспорты белән аттестатын тоттырды.

—Сиңа унсигез яшь, Лиза Лазаревна! Тормыш юлыңны хәзер үзең сайлыйсың,—диде.

Аннан, кинәт йомшарып, Лизаны кочаклап алды.

—Бәлки, калырсың, Лиза? Кечкенәләр группасына няня кирәк... Соңрак тәрбияче итеп урнаштырырбыз...

—Юк!—диде Лиза, катгый итеп.—Фестивальгә генә барып кайтам да,—укырга китәм... Мәскәүгә.

Казандагы фестивальдә Лизаны кат-кат сәхнәгә чыгардылар. Зал гөр килде. Әле «Әпипә»гә, әле «Калинка», «Лезгинка», «Краковяк»ка тыпырдады кыз. Битләр—алсуланды, аяклар —ут янды, йөрәге, күкрәгеннән бәреп чыгардай булып, дөп-дөп килде...

Баянчы егет Азатка әнә шул фестивальдә гашыйк булды ул. Житәкләшеп Бауман урамында йөрделәр. Идел буена төштеләр... Лиза шунда үз гомерендә беренче тапкыр туңдырма ашады... Беренче тапкыр үбеште... Ул бик бәхетле иде...

Ике атнадан кыз көтмәгәндә Казан вокзалында Азатны тагын очратты. Егетне күрүенә шатланып, үкси-үкси күз яшен түкте ул.

Башкала институтында Лизаны сайлап алу турында ук төшереп калдырганнар иде. Әти-әнисен югалту ачысын хәтерләмәгән кызга моннан да зур кайгы булуы мөмкинме соң?

—Сөрт яшьләреңне!—диде Азат кыю гына.—Киттек!

—Кая?

—Кая булсын? Әтнәгә! Мин анда музыка укытам. Сиңа да эш табылыр...

Азат бер кулы белән Лизаның кыршылып беткән чемоданына тотынды, икенчесе белән кызны житәкләп тә алды.

Мәктәп директоры Лизаны сәхнәдә күреп белә икән. Җәй уртасы булуга карамастан, кызны эшкә алды.

—Пока Каенсарда пионер лагеренда эшли торырсың, сентябрьдә—күз күрер,—диде ул.

Сентябрьдә алар Азат белән бергә тора башладылар. Авыл Советына барып язылышып кайттылар да—вәссәлам!

«Мәктәп квартирасы» дип аталган йорт «детдом кызы»на ожмах булып тоелды.

—Йомышың төшсә, Нәфисә апайга кер! Ул бик ярдәмчел хатын... «Күни»ләр нәселеннән...—диде директор, ачкычларны тапшырганда.

Йомыш шунда ук төште. Тамак ягын кайгырта башлагач, тоз юклыгы билгеле булды.

Лиза «Күни»ләргә юнәлде...

Иң элек тәрәз төбендә ут янып утырган кып-кызыл яраннарга игътибар итте ул. «Мин дә шундый гөлләр үстерермен!»—дигән уй сызылып китте аңында.

Өр-яңа ук булмаса да, шактый төзек тоелган йорт-жир гажәп күркәм һәм килешле күренә.

Детдом гадәте буенча баскычтан очып кына үтмәкче иде, кисәк туктап калды. Ышкып юа-юа ак сөяк төсенә кергән шоп-шома баскыч такталарына, түфлиләрен салган булса да, бармак очларына гына басып үтте ул.

Жыйнак кына веранда аша салкынча чоланга узып, өй ишеген ачып жибәрде. Күзе кояшка чагылып берни күрмәс булды.

«Сөбханалла!»

Бу сүзне Лиза үз гомерендә беренче тапкыр әнә шунда кулланды бугай.

Зур-зур тәрәзәләргә эленгән ап-ак челтәр пәрдәләре, караватта кукраеп утырган ап-ак мендәрләре, тиешле урынына бик белеп урнаштырылган шкаф-диваннары белән йорт эче нурга коенган иде. Исем-кушаматлар тырнап язылган, чуарланып беткән детдом мичен күреп гадәтләнгән Лизаны шундый да ап-ак мич булу мөмкинлеге гаҗәпкә калдырды.

Мич артында кыштырдаган тавыш ишетелде.

—Кеше бармы әллә?

Лиза, тавыш иясенең күренүен көтеп, тынып калды.

Ак чаршау салмак кына ачылды да, аннан, ак оекбашлары белән йомшак кына басып, йорт хуҗасы күренде.

Ап-ак яулыгын дүртпочмаклап таратып бәйләгән карчык үзе дә ак йөзле иде. Маңгай сырларының тирәнлеге язмышының бик шома булмавын дәлилләп торса, колакларындагы зур бөҗраны хәтерләткән алтын алкалары кайчандыр бай һәм бәхетле булган тормышның шаһите иде.

Лиза аны шул күрүдән үк яратты.

Хәтерендә әнисе образын тудырырга тырышып, аны күз алдына китерергә омтылган чакта, томан аша пәйда булган серле шәүләнең әлегә кадәр йөзебите шәйләнгәне юк иде. Шул билгесезлек, унсигез ел буе, кызның күнелен нәүмизләп, җанын сыкратып, күзен ачыттырып килде.

Лизага кинәт рәхәт һәм җиңел булып китте.

—Сез минем әниемә охшагансыз...—дип сулкылдады ул.

—Әниләр бар да шулай инде, бер-берсенә охшыйлар,—диде карчык. Лизаның «әни» сүзен беренче тапкыр әйтүен Нәфисә карчык ул чакта белми иде әле.

***

... Очарга өйрәнгәндә кош баласы башта үз оясы тирәсендә генә әйләнә диләр. Канатларын җилпеп читкәрәк талпынса да, оясын күздән югалтудан курка. Тик серле дөнья нәни кошны һаман ераккарак чакыра. Таныш түгел хәят, ымсындырып, үзенә әйди. Канатлары талып, хәлдән тайгач кына сабый кош үз оясын эзли башлый. Уңга карый, сулга борыла... Тик ни кызганыч! Тирә-якта—чит дөнья, чит хәят...

... Лиза шул сабый кош халәтендә унсигезен тутырды. Туган оясы булмаудан бу «кош»ның бәгыре телгәләнә, күнеле сыкрый иде.

«Күни»ләр гаиләсе ярым-ялгыз Лизаны үзенә сыендырды...

***

—Бу дөньяга алты кыз бала тудырдым,—дип кабатларга ярата иде Нәфисә карчык.

Бераз торгач, исемнәрен санап китә:

—Рәүшәниям... (Өлкән кызы Раушанияне ул, назлап, шулай атый иде).

—Надия белән Нуриям... (Бу исемнәрне атаганда, керфекләре арасыннан сытылып чыккан сыңар күз яше җыерчыклар арасына кереп югала. Йогышлы чир афәте бу ике кызны, сабый чакта ук, үз куенына алган).

—Кадриям... Иң кадерле йөрәк ярам...

—Лутсия белән Бинирам... (Люция һәм Венера исемнәрен шулай татарчалаштырып әйтә иде ул).

—Ялгыз башым дүрт кыз үстердем! Укыттым! Өчесе—укытучы, ә Бинирам—бырач!—ди ул, горурланып.

Дөрес, Венераның врач ук түгел, ә фельдшер-акушер гына булуын Лиза

белә иде. Хастаханәдә эшләүче ак халатлы бу «фәрештәне» «бырач түгел!» дип әйтергә авылда кемнең теле барсын ди!

Лиза (Нәфисә карчыкча әйтсәк,—«Илизау») акрынлап бу гаиләгә шул кадәр ияләште ки, андагы тәртип-гадәтләрнең сиздермичә генә үзенә дә сеңә баруын тоеп гаҗәпкә кала иде хәтта...

—Тормышны «кетер итеп» яшәргә кирәк...

Бу сүзне карчык еш кабатлый иде.

«Кетер итеп»...

... Өен—«кетер булсын», өс-башын—«кетер булсын», эшләгән эшең—«кетер булсын»! Бу кагыйдә гаиләнең язылмаган канунына әверелгән. Нәфисә карчыкнын дүртпочмаклап япкан ак яулыгы—«Күни»ләр нәселе кагыйдәләренең дөньяви һәм гамәли чагылышы булып хәтердә уелып калган.

Карчык гел «кетер» яулык кына япты шул...

... Алар нәселенә кагылышлы күнелсез хәлләрне дә Лиза күреп һәм сизеп килде. «Өендәге хәлне күршеңнән сора» дип юкка гына әйтмиләр лә...

Өлкән кызының утыз яшендә яман чиргә юлыгып, өч сабыена ятимлек куркынычы янавын, карчыкны тагын да бөрештереп, җыерчыкларын тагын да тирәнәйтүен күрше-тирә күрми-сизми дисеңме?

Язылмаган кануннарның икенчесе: «Күңелсез хәлеңне, чиреңне сөйләп кешене ялыктырма! Авызың тулы кан булса да—читләр каршында түкермә!»

Кичен, моржадан сыек кына төтен күтәрелеп, кызган майның тәмле исе тарала икән, димәк, карчык иртәгә, кызының хәлен белергә, Арчага җыена дигән сүз.

Тирә-күрше, көтү озатып, «биш минутлык иртәнге гайбәт»не башлаганда, «Күни»ләр капкасы тавышсыз гына ачылып, анда Нәфисә карчык пәйда була. «Кетер» яулыгы өстеннән ак затлы ефәк челтәр шәлен ябынган. Шәл читеннән зур алтын алкасы бөжраланып ялтырап тора. Эре бизәкле кара озын күлмәге, ак шәл чуклары белән уралып, арык кына ыспай гәүдәне шактый тулыландырып, ямьләндереп җибәргән. Баскан саен «шыгыр-шыгыр» җырлап торган затлы читеге карчыктагы алиһәләр рухын бәян итә кебек...

«Биш минутлык иртәнге гайбәт» «шып» туктый. Хатыннар яхшы белә: «Күни» Нәфисәсе үзе дә гайбәт сатмас, сатучыларны да жене сөймәс.

—Рәүшәниянә бездән дә сәлам әйт, Нәфисә апай...

—Рәхмәт, шулай итәрмен, Алла боерса...—Карчык, тәз атлап, Арча автобусына ашыга...

***

... Хатирәләр, хатирәләр...

Соңгы көннәрдә Нәфисә карчык Лизаның хәтеренә килә дә төшә, килә дә төшә. Институт бинасындагы һәр бүлмәне, һәр коридорны юып чыгаргач, Нәфисә апайча, «кетер иттем» дип шатланып куя ул.

Бу хатирәләр нигә шулай гел бимазалый аны? Югыйсә күрешмәгәнгә кырык еллап үтеп киткән! Кырык ел! Йа, Раббем! Кырык көн диярсен!

Барысы да хәтердә... Нәфисә карчыкның ачуланган чагы да исендә...

... Лиза, модага ияреп, чәчен кистереп, бөдрәләтеп кайткан иде. Көзгедәге сурәтенә карап, үзенә сокланып өнсез калды. Бигрәкләр дә килешә иде аңа бөдрә чәч!

Туп-туры «Күни»ләргә чапты. Нәфисә апай күреп шаккатсын әле!

Карчык бер сүз генә әйтте:

—Чүриле маржасы булгансың...

—Матур бит, Нәфисә апай...

—Тиле... Хатын-кызның бөтен күрке чәчендә... Толымны кисү бәхетеңне кисү белән бер ул!

—И—и—и, Нәфисә апай...

—И-ләмә! Кара минем кызларга!

Лиза белә: «Күни» кызлары озын чәчләрен өеп, бик матурлап йөртә иде.

Карчык ап-ак яулыгын башыннан сыпырып төшерде:

—Минем чәчне күрәсеңме?

Карчыкның юкарып, коелып бетә язган чәчләре арасыннан алсуланып баш тиресе күренеп тора. Көмеш чулпылы тасмага кушып үрелгән нечкә генә кыска ике толымы, зәгыйфь үлән сабагыдай, арык җилкәсенә салынган.

—Татар хатыны толымлы булып гүргә керә...

Лизаның үз гомерендә беренче тапкыр «Күни» Нәфисәсе белән әрепләшәсе килеп китте:

—Ә мин—татар түгел бит! Чуаш та, мари да түгел! Мин—советский!

—«Әстәгъфирулла» диген, балам... Син—татар! Синең ирең—татар! «Бисмилла»ны әйт. Бу дөньяда бисмиллалы эшнең генә—кадере, бисмиллалы тормышның гына яме булыр...

Үртәшәсе килү теләге һаман үсә барды:

—Ә синең кызларың? Алар дүртесе дә коммунист бит! Менә алар «бисмилла» әйтәме соң?

Карчык дәшмәде. Акрын гына борылып, сак кына мич артына керде.

...Лизага шулчак бик авыр булып китте.

Бугазына тыгылган төенне авырттырып йотып җибәргәндә, ике «юл», битне юешләп, түбән сузылды. «Рәнҗеттем, рәнҗеттем бит карчыкны,—дип сыкрады ул.—Әниемдәй якын кешемне рәнҗеттем...»

Лиза белә: мич артындагы ак чаршау белән бүленгән почмакта Нәфисә карчыкның Лизага моңарчы таныш булмаган үз серле дөньясы бар. Кыз, ак чаршауны бармак очлары белән генә әләктереп, шул серле почмакка күз атты.

Ярым караңгыда күзгә ташланган беренче әйбер—бизәкләп эшләнгән шәмаил булды (аның шулай дип аталуын Лиза шактый еллар үткәч кенә белде). Янәшәдәге шүрлектә читләре теткәләнеп беткән иске китаплар тезелгән. Шүрлек читендә эленеп торган тәсбихка (бу атама белән дә ул соңрак танышты) Лиза сәерсенеп һәм ятсынып карады. Иң гаҗәбе: идәндәге намазлык өстендә утыручы (ул җәймәнең шулай дип аталганын белмичә күпме еллар үткән!) «Күни» Нәфисәсе. Карчыкның пышылдап әйткән сүзләре, Лизаның колагын назлап, аңына барып иреште.

—Йа, Раббем, үз нәселен, ата-анасын белмәгән бу баланың гөнаһларын гафу кыл. Габдулла кызы Илизаның туачак баласына да, үзенә дә иман нуры иңдер! Амин!

Лиза, аяк очларына басып, шыпырт кына өйдән чыкты. Шәфәкъ нурына төренгән кичке һаваны комсызланып сулады.

Тиздән ана булачагын ул әле белми иде...

***

—Малай булмаса—роддомнан да барып алмыйм!—дип кырт кисте Азат, хатыны авырлы икәнне белгәч.

Лизаның әле генә изге серне пышылдаган иреннәре дерелдәде, күзләрен яшь пәрдәсе каплады. «Нәрсә ди бит! Нәрсә ди! Ходаем, әле яралып кына килгән җан турында, үз сабыең турында шулай диярга ярыймы!? Ничек җир йотмый аны?!»

Нәфисә карчыкның алдына башын салып, үкси-үкси елады Лиза. Азаттагы шушы миһербансызлыкка каршы көрәштәш иптәш булуына өметләнеп, башын күтәреп аңа карады.

«Ходаем! Әллә көлеп тора инде? Елмаюдан маңгай җыерчыклары да языла төшкән бит!»

Карчык кытыршы учлары белән Лизаның чәченнән сыйпады:

—Илизау, балам, тыңла әле, бер хикәят сөйлим үзенә...

***

*Нәфисә карчыкның беренче хатирәсе.*

...Кырыгынчы ел... Алтынчы авырымны күтәргән чагым... Төн...Чаршау артында без икәү...

Мөхәммәтҗан шыпырт кына колагыма пышылдый:

—Нәфисәү, монысы точно малай булачак!

— Белмим шул, Мөхәммәтҗан... Мин үзем дә алты кызның берсе бит... Ә син—алты бажайның өлкәне... Беләсең лә...

—Алтыны бәхетле сан диләр... Бер егет кирәк бит инде миңа да! Фермадагы бөтен хатын көлә үземнән... Апылый да көлә...

—Шулардан көлдереп торасыңмы?

—Юк ла инде... Болай гына әйтүем... Мин аларның утыз улларын Рәүшәниямнең бит очындагы бер бөртек сипкеленә дә алмаштырмыйм...

...Бинирам кырык бердә туды. Тагын кыз булганын белгәч, түшәмгә карап шактый яттым. Мөхәммәтҗанның нәүмиз күзләре миңа бага кебек.

Шул чакта күңелемнән генә ант иттем: «Малай булганчы табачакмын! Мөхәммәтҗанга бер малайны барыбер табачакмын, Алла боерса!»

Сабыйларны имезергә китерделәр. Бүлмәдәшем Зәйтүнә бишенче улын имезә. Ә минем кызым имчәкне кабарга теләми, теле белән этә дә чыгара, этә дә чыгара...

—Күр инде, Нәфисә, бу галәмәтне! Миңа—бишенче ул, ә сиңа алтынчы кызын бирде Ходай...

Мин дәшмим.

—Синең улны—миңа, ә минем кызны, ялгышып, сиңа биргән...

Мин дәшмим.

Шык-шык-шык... Шык-шык-шык...

Нинди тавыш дип тәрәзәдән карасам, Мөхәммәтҗанның тулган айдай балкыган йөзен күреп, каушап калдым.

—Нә-фи-сәү, Нә-фи-сәү... Улымны күрсәт!

Эсселе-суыклы булып киттем.

«Ул? Нинди ул»?

—Апылый әйткәч, йөрәгем ярыла дип торам! Шатлыктан кеше үлә микән, Нәфисәү? Йә, күрсәт инде «Күңи» нәселен!

Мөхәммәтҗанга текәлеп өнсез калдым! Карале бу Апылыйны! Ничек явыз шаярткан!

Иремнең озын какча йөзе, бераз гына кәкрерәк борыны, кояшта янган кара-кучкылт бите, хәтта авызындагы чите кителгән теше дә шатлыктан елмая кебек.

—Мөхәммәтҗан, малай түгел шул... Кыз туды...

Әле генә балкыган йөзе кисәк сүнде, кашы җыерылды...

—Барыбер... Күрсәт...

Мөхәммәтҗан тәрәз аша сабыемның йөзенә текәлде.

—Мөхәммәтҗан, Зәйтүнә бишенче малаен тапты...Кыз дип хыялланган булган... Бәлки...

Жыерылган кашлар дуга кебек бөгелде, күзләр—ут чәчте, йодрыклар—төенләнде... Ярый әле ике арада пыяла бар!

—Кешенеке алтын булса да, үз бугым кадерлерәк!

Шыгырдатып тәрәзәне ачты. «Юаштан юан чыгар» дигәндәй, мин куркудан жыерылып килдем.

Ягымлы, назлы тавыш белән сүзен дәвам итте:

—Нәфисәү, монысы бигрәкләр дә чибәр булган. Алтыны—бәхетле сан диләр... Дөрес икән... Бусы сиңа... Бәбәй бүләге...

... Мин, бер Мөхәммәтжанның ераклаша барган какча гәүдәсенә, бер тәрәзә төбендә яткан божралы зур алтын алкага карап, үзалдыма пышылдадым:

—Малай булганчы табачакмын! Мөхәммәтжанга бер малайны барыбер табып бирермен!

... Бер атнадан сугыш башланды...

***

...Лиза әле дә бик яхшы хәтерли. Нәфисә карчыкның төпчек кызы Венера Әтнәдә бер чибәр иде! Ходай аннан матурлыкны бер дә кызганмаган. Кыйгач каш, коңгырт күз, килешле борын һәм ияк, чиядәй ирен... Алсу бит уртасына кечкенә генә миң төртергә дә онытмаган хәтта. Озын һәм купшы чәче—нур өстенә нур диярсең... Матур йөртә иде Венера чәчен: әле күкрәгенә үреп сала, әле оста чәчтарашлар кебек әллә ниләр кыландырып өеп куя...

Шулай да иң сокландырганы—Венераның бәрхеттәй тавышы булгандыр. Башын бераз гына артка ташлап, колакны иркәләгән бәрхет тавышы белән көлеп тә жибәрсә! Мөгаен, ожмах фәрештәләре дә Венера кебек чибәр түгелдер...

Хәтерли Лиза, нишләп хәтерләмәсен? «Күни»ләр өе каршындагы куш өянке йөрәкләре телгәләнгән күп гашыйкларга шаһит. Әллә кыз артык сайландымы, әллә артык горур булды инде. Очрашырга өметләнеп килгән егетләр, ярты төнгә кадәр көтеп тә кыз күренмәгәч, төн караңгылыгына кереп югалалар иде.

Лиза үзе бәрхет тавышлы бу гүзәлгә сокланып та, кызыгып та карады. Айратны тапканда ул нечкә билле бу чибәрнең гажәеп оста «кендек әбисе» булуын күреп шаккатты.

Соклану һәм кызыгуга ихтирам дигән тагын бер хис килеп өстәлде...

***

Жәйге матур көннәрнең берсе иде. Улы Айратның йокысын саклап, ишек алдында китап укып утыра иде Лиза.

—Апа, бәби янына керим әле...

Башын күтәрсә, койма артында биш-алты яшьләрендәге нәни кыз басып тора.

Лиза, капканы ачып, кызчыкны эчкә үткәрде.

—Кер, әйдә, кер...

Нәни кыз сак кына коляскага кагылды, йоклаган сабыйга елмаеп карап торды.

—Синең энең-сеңелең бармы?—дип сүз башлады Лиза.

—Мин—үзем сеңел! Төпчек...

—Бәбәйләрегез юк икән... Күңелсездер инде...

—Булмаса ни... Минем апам, абыем бар!

Лиза нәни кызны үчекләүдән туктады. Кем кызы икән бу? Моңарчы күргәне юк иде.

—Кемнәрнеке син? Кунакка килденме?

—Мин—«Күни» кызы! Әтнәбигә килдем...

Лиза пырхылдап көлеп җибәрде. «Күни кызы» диме? Димәк, Нәфисә апайның Раушаниясенең төпчеге инде...

—Нигә «Күни кызы» дисең? «Күни»—кушамат бит ул!

—«Күни» кушаматмы...? Булса ни... Кушамат—начар була... Ә «Күни»... «Күни»—ул яхшы кушамат!

Нәни кыз зәңгәр күзләрен тутырып Лизага карады.

—Мин—«Күни» кызы!—дип кабатлады ул, башын горур чөеп.

...Кызчыкның «Әтнәби!», «Әтнәби!» дигән яңгыравыклы тавышы җәй буе ишетелеп торды ул елны.

***

Җиңү бәйрәмнәренең берсен Лиза яхшы хәтерли. Тәрәзәдән тышны күзләп тора иде. Урам буйлап кайтып килгән ак яулыклы Нәфисә карчык әллә ничек, бөрешеп кенә, күләгәдәй үз ишек алдына узды.

Бер-бер хәл булганмы әллә?

Лиза, шомланып, ашыга-кабалана «Күни»ләргә юнәлде.

Нәфисә карчык бик унайсыз итеп, башын иеп, бөкрәеп утыра иде. Тагын да кечерәеп, бөрешеп калган.

—Нәфисә апай, ни булды?

Карчык елый иде. Тимердәй нык Нәфисә дә елый белә икән!

Лиза карчыкның үзенә таба сузылган учына күз салды. «25 лет Победы в Великой Отечественной войне» дигән сүзләр язылган саргылт медальга төбәлеп, Нәфисә карчык телгә килде...

*Нәфисә карчыкның икенче хатирәсе.*

...Без—Хәерниса белән Баһаветдиннең уңган-булган алты кызы идек. Мин, Нәфисәбану,—иң өлкәне...

Миннән соң—Кәшифәбану, Зәйнәпбану, Камиләбану, Мәймүнәбану, Фәйрүзәбану туган...

Сугыш алтыбызны да тол итте... Мин—дүрт кызым белән, ә биш сеңелем—берәр бала белән ялгыз торып калды.

«Җиңү көнне Баһаветдин карт күз яшьләре белән кычкырып елаган диләр. Алты киявемне алды, Гитлер явыз! Алты кызымны тол ясады, нәләт!—дигән ди.

Бу сүзләрне Әтнәдә күпләр сөйләде.

—Әти, ялгышма! Мөхәммәтҗан—хәбәрсез югалган... Ул кайта бит,—дип, каршы төштем үзенә...

Кайтмавы булды, ахры...

«Малай табып бирәм!» дигән вәгъдәмне үти алмыйча калдым.

Сугышка киткәндә каерылып-каерылып артына карады Мөхәммәтҗан.

—Нәфисәү, кызларны укыт, укытучы булсыннар,—диде.

Рәүшәниямне чакырып алып, колагына нидер пышылдады. Серләре килешә иде үзләренең! Нәрсә пышылдаганын, күпме сорасам да, Рәүшәниям әйтмәде. Соңыннан, сугыш беткәч кенә, билгеле булды серләре.

—Әни, мин башка фамилиягә күчәм,—диде Рәүшәния.

—Ни сөйлисең? Нинди фамилия?—дип, аптырап, күзенә төбәлдем.

—Теге чакта әти: «Сугыштан кайтмасам, «Мөхәммәтҗанова» фамилиясен ал, кызым,»—дип пышылдады колагыма...

Ах, вәгъдәмне үти алмадым шул!

Кияүгә чыкса да, «Мөхәммәтҗанова» фамилиясен йөртте Рәүшәниям.

Кияү дә каршы килмәде, аңлады кызымны...

Бигрәк ярата иде Рәүшәниям әтисен! Серләре бик килешә иде аларның...

...Иң авыры—кырык бишнең августында булды...

...Ишек алдында Бинирамның «Әти кайтты! Әти кайтты!» дигән тавышын ишетеп, тәрәзәгә атылдым. Карасам, Бинирам, бер солдатны чытырдатып кочаклаган да, «Әти!»,»Әти!» дип кычкыруын белә.

...Тик солдат кына... Мөхәммәтҗан түгел иде шул. Шәрифулла исемле икән... Мөхәммәтҗан утырган машинага ничек бомба төшүен үз күзе белән күргән... Шуны сөйләде. Ул чакта мин аңа тамчы да ышанмадым. Ә Рәүшәниям—ышанган... Шәрифулланы озаткач, әтисенең серен чиште миңа... Фамилиясен «Мөхәммәтҗанова» дип үзгәртте...

...Илизау, Мөхәммәтҗанның кайтмавы хак булды, ахры... Вәгъдәмдә тора алмадым шул...

... Сары медальгә корыч Нәфисәнең күз яше тамды.

***

...«Күни»ләр нәселенең тагын бер язылмаган кануны «Тиккә вакыт уздырма! Кулың эш белсен!»

Бу йортта «кич утыру» гадәткә кергән. Бергә-бергә шәл бәйлиләр, җырлашып та алалар... Венераның бәрхет шаян тавышы барысын да шаккатыра:

...«Эй, моряк!

Ты слишком долго плавал,

Я тебя успела позабыть!»...

Кинодан кайткан саен нәкъ артистлар кебек кыландырып җырлый иде ул!

Нәфисә карчык, кызларының уңганлыгына, кулларының җитезлегенә соклана-соклана, оныкларына бияләй бәйли.

Лизага бишинә тотарга да ул өйрәтте. Йон язу, эрләү, кату серләре белән дә таныштырды . Улы Айратка бәйләгән иң беренче ап-ак нәни оекбаш әле дә күз алдында Лизаның. Бармак очлары кызарып чиләнеп, канап чыккан иде.

—Батыр ярасыз булмас!—дип көлде карчык.

Кулыңа бер тапкыр инә тотсаң, шәл бәйләргә дә өйрәнеп була икән! Уртасын бәйләүләре җиңел булса да, читендәге бизәкләре зур осталык сорый.

«Күни» кызлары исә, инәләрен «чек-чек» бәреп, әллә нинди бизәкләрдән шәл читенә матур сурәтләр тезә.

—Әни, син яраткан «чит»не бәйлим,—ди «бәрхет тавыш» Венера...

### *Нәфисә карчыкның өченче хатирәсе*

Болын-басу эшен бик ярата идем яшь чагымда. Җәйге печән өсләрен мәңге онытасым юк! Алдан, «тугызлы» чалгы белән, Мөхәммәтҗан бара... Аның артыннан, «бишле» чалгы белән, мин... «Бишле» чалгы иң кечкенәсе... Кайчакта үртәлеп тә куям: «Бала-чага кебек, «бишле» чалгы белән...»—дим, киреләнеп.

—Син үзең дә бөтерчек кадәр генә... Унҗиде яшьлек кызлар кебек—ыспай,—ди Мөхәммәтҗан, мине юатып.

Хатын-кызны кадерли белә иде ул. Үзе—сабый бала кебек хыялый тагын. «Ак тәлинкә сары май»ны (ромашка) зәңгәр чәчәкләр белән аралаштырып, тәкыя үрә дә, сиздермичә генә килеп башыма киертә.

Мин ачуланам:

—Кит, җүнсез, кеше көләр... Кырыкка җиткәндә... Кина түгел лә бу!—дим.

—Бәхеттән көләләр ди мени, юләр...

***

... Нәфисә карчык җыерчыклы куллары белән шәл читен иркәли.

—Бусы—мин бәйләгән көлтәләрнең арыш башаклары... Бусы—без чапкан болындагы зәңгәр чәчәк... Ә бусы—...

... Ах, бу хәтер дигәннәре! Лиза, күпме генә тырышса да, шәл читендәге бизәкләрне исенә төшерә алмады.

Онытылган... Онытылган бит!

Шул чәчәкнең исемен белсә, бизәген дә хәтерләр иде кебек.

«Нинди чәчәк соң? Нинди бизәк?»

Күпме шәлләр бәйләп сатты Лиза. Аннан күрмәкче Нуриясе дә кул эшенә өйрәнде. Сәнгать академиясендә укырга хыялланувы да тегү-чигүне яратканнан. Оныгына дип бәйли башлаган шәле, Лизаның хәтерсезлеге аркасында, ярты юлда туктап калды. Йә, нинди чәчәк соң? Нинди бизәк онытылган?

... И-и-и, ул Әтнә яклары... «Күни» Нәфисәсенең җыерчыклы ак йөзе... Искә килә дә төшә, килә дә төшә...

...« Бәрхет тавыш» Венера да, бөдрә чәчле кара егеткә кияүгә чыгып, күрше авылга китеп барды. Бәхете бар икән кызның.Эше Әтнә больницасында гына, әнисе өендә еш кунак була. Ниткән кунак?! Җинен сызгана да, «ә!» дигәнче бөтен дөньяны «кетер итеп» чыгара. Тукта, тукта! Нәни кызын ияртеп килеп, атна буе куна кала башлады түгелме соң? Әллә...? «Күни»ләр сер бирмәс, авыз тулы кан булса да, төкерүчеләр түгел!

***

... Азат эчкәли башлаган чак иде. Көн саен исереп кайта. Кайбер төннәрне кайдадыр кунып та кала.

Түзде, түзде дә Лиза, әйберләрен җыйнаштыра башлады. Кама буенда яңа шәһәр төзелешен ишетеп белә иде.

—Китәм! Күпме түзәргә була? Китәм!

Нәфисә апай ни дияр?

Карчыкның алдына башын салып, үксу-үксу елап эчен бушатасы, кызгандырасы килде аның.

Баскычларын очып кына үтмәкче иде, верандадагы тавышларны ишетеп туктап калды. Карчыкның иң кадерле кызы—йөрәк парәсе—елый:

—Түзәр хәлем калмады, әни! Тагын «ычкынды»... Өч көн буе айнымый... Чәй эчәргә чынаяк та калмады өйдә... Телевизор пыяласы да «чәлпәрәмә» килде... Тәрәзәләрне дә ватып бетерде...

Лиза белә: кадерле кызның ире кулыннан гөлләр тама. Белмәгән эше, булдырмаган кәсебе юк. Тик нишлисең? «Ычкына» торган гадәте бар...Ах, шул аракыны уйлап чыгарган явызны!

Кадерле горур кыз—мактаулы укытучы—кара янган эзләрне әллә ниләр сөртеп яшерергә тырыша. Авыл халкыннан яшерерсең, бар!

Әнә бүген тагын күз яшьләрен түгә:

—Әни, синең яныңа кайтыйм инде... Ризалыгыңны бир...Бәлки, ана да сабак булыр...

—Уйлама да!

—Әни, мин беләм бит... Венера инде атна буе синдә ята. Әйтмәгәч тә... Аңа ярый... Ә миңа?

—Син—малай анасы! Шуны онытма: әтисе янында үскән малай гына ир-егет булып җитешә! Малайларга хатын-кыз тәрбиясе генә җитми!

Кадерле кыз баскычтан төшкәндә Лиза верандага сыенып качып калды. «Күни» кызы капкага таба атлады. Башы иелгән, муены да кыскарып, иң башлары салынып төшкән. Менә ул капка келәсенә тотынды... Туктады... Купшы чәчле башын югары чөеп, инбашларын сикертеп куйды. Зифа гәүдәсе—грекларның таш сыннары кебек... Капканы ачты...

—Галимулла абзый, хәлләрең ничек?—дип, яңгыравыклы көр тавыш белән күрше картка сәлам биреп узды.

... Лиза өйгә кереп тормады. Сиздермичә генә чыгып китү ягын карады.

***

«Бу дөньяда берәүнен дә сандыгы буш түгел»,—диләр. Нәфисә карчыкның тагын бер ярасы—Лүтсиясе булды. Матурлыгы белән аерылып тормаса да, бар җире дә килешле иде кызның. Үзе тыйнак, акыллы. Нәфисәнең үзенә охшап—туры сүзле. Кулыннан килмәгән бер эше дә юк. Тик кыз утызын да, кырыгын да тутырды... Кияүгә чыгарга һаман ашыкмады. Чоланда шкаф өстендәге пар мендәрләр, горур кукраеп, туй кыңгырауларының чылтыравын юкка гына көттеләр...

Кер дә кунмаган ап-ак мендәрләр әле һаман да шунда утыралар кебек тоела Лизага.

... Лиза эшен тәмамлап килә инде. Коридорның теге башында гына юылмаган бер бүлмәсе калды. Ишек төбенә студентлар өелгән. Имтихан бара. Тәрәз төбенә тезелешеп утырган кызлар, Лиза килгәнне күреп, китапларыннан башларын күтәреп, кымшанышып куйдылар.

—Утырыгыз, утыр...Укуыгызны белегез...

Курчак кебек бер матуры дивар буена чүгәләгән. Кыска блузка белән чалбар арасындагы тәне, нәфис биле—шәп-шәрә. Арт йомрыларына кадәр беленеп, күренеп тора хәтта.

«Әстәгъфирулла! Нуриясе мондый кием кимәсен тагын! Кисәтергә кирәк»,—дигән уй сызылып үтте башыннан.

«Матур курчак» телгә килде:

—Иң проблемный укытучы—шушы доцент. Ни имтиханда күчертми, ни взятка да алмый, ичмасам...

Лиза колагын торгызды.

—Йомшак җирен барыбер таптым үзенең. Бик таләпчән кыланса да, кешене кызгана икән... «Әни онкологиядә ята, шуны сакладым»,—дип бер-ике бөртек күз яшемне чыгарган идем...

—Алдашып, «өчле»нне алдың бит инде! Комачаулама әле сөйләнеп,—дип, тәрәзә төбендәгеләр аның сүзен бүлде.

Матур кыз торайды: «Ну, пока!»—дип, кыланчык елмаеп, коридор буйлап китеп барды.

—Йөри шунда сөйләнеп,—диде икенчесе, аны өнәмичә. —Бөтен укытучы да шушы доцент кебек булсын иде әле! Лекциясен дә менә дигән итеп укый, темасын да ялт итеп аңлата... Бер сорауны да җавапсыз калдырмый.

—Шуңа күрә аның дәресенә бар студент та бердәм йөри...

Аудитория ишегеннән берәү чыгып: «Дүртле!»—дип сөенеп пышылдады. Башкалар аны сырып алды.

Лиза ишек ярыгыннан эчкә күз салды.

«Син мине күрмисең дә, ә мин синең турыда күпме белеп өлгердем!—дип уйлады ул.—Купшы чәчләрен матур итеп өеп куйган... Муены да шактый

текә... Затлы костюмы инбаш-аркаларын матур күрсәтә... Йөзе нинди икән? Күрәсе иде!»

Лиза кинәт үз өстенә күз салды.

«И-и-и, бигрәк инде... Нинди матур эш халаты карангы бүлмәдә шкаф тартмасында ята югыйсә...»

Лиза, «ялт» борылып, кинәт китеп барды. Ун минут та үтмәгәндер, коридордагы көзгегә күз салып узды. Кара толымын баш түбәсенә өеп куйган, зәңгәр эш халаты кигән ыспай хатынны күргәч, канәгать елмайды.

Коридор бушап калган. Лиза, чиләк-чүпрәкләрен алып, бүлмәгә керде.

***

Доцент хатынны ул бер күрүдә үк ошатты.

Менә син нинди икәнсең! Иллегә якынлашып киләдер... Талчыкканлыгы йөзенә чыкса да, зәңгәр күзләре бик нурлы күренә.

—Юа башласам ярыймы?

—Ярый, ярый... Хәзер, әйберләремне генә җыям да, иркенләп җыештырырсыз...

Бәрхет тавыш колакны иркәләде.

Доцент хатын, урындык аркасына элгән мамык шәлен алып, инбашына салды да, китапларын кулына алды.

—Ах!..

Лиза сыгылып төште.

—Нәрсә булды? Авырыйсызмы әллә?

—Әтнә шәле...—дип ыңгырашты Лиза.

—Әйе, Әтнә шәле!

Монысы—Нәфисә апай бәйләгән көлтәләрнең арыш башаклары... Бусы—болындагы зәңгәр чәчәк... Ә бусы... ?

Исенә төште бит Лизаның, исенә төште! «Мөхәммәтҗан үргән тәкыя бизәге!»

—Сез... Әтнәдәнме?

—Түгел... Әнием шуннан... Анда минем туганнарым яши... иде... Шәлне дә алар бәйләде... Соңгы бүләк...

—Сез—кем?

Доцент хатын башын югары чөеп, купшы чәчләрен төзәтеп куйды. Кинәт кенә бер ун яшькә яшәргәндәй тоелды. Зәңгәр күзләре балкып китте. Зифа гәүдәсе—грекларның таш сынын хәтерләтә...

—Мин—«Күни» кызы!—диде ул горур гына.

***

... Лиза, инәләрен «чек-чек» бәреп, Нуриясенә шәл бәйли. Күзләре көлә, иреннәре елмая... Горур башын кара толымы бизәп тора...

Бүлмәгә, ишелеп, ачык тәрәзәдән балаларның чыр-чуы килеп керде. Шәһәр шау-шуына кушылган бу эчкерсез авазлар арасында зәңгәр күзле нәни кызның «Әтнәби!», «Әтнәби!» дигән тавышы да яңгырап-яңгырап киткәндәй тоела...

# Рафаил Сираҗи

***

**Ий галимнәр! Сезнең сүзне танучылар**
**Сусаганнар фикерләрнең асылына.**
**Шәп фикердән жанга гыйбрәт табучылар—**
**Гыйззәт белән шифа ала сусынына.**

**Әмма, бар бит сүз мәгънәсен илтифатсыз,**
**Колак читеннән үткәргән гамьсез әһел.**
**Сүз тыңларга вакыт тапмыйдыр ул затсыз,**
**Малпәрәстлек[1] чире йоккан—комсыз**
**бәхыйль[2]...**

**Сарыф итмә юкка, асыл теләгеңне,**
**Бу кемсәгә үткәрим дип фикереңне—**
**Онытма син зур максатка кирәгеңне:**
**Хак ризалыгына юлла зикереңне.**

**Гыйлемлекнең кадере югалыр, дәхи,**
**Әгәр аны тыңлаучысы булса бәхыйль.**

***

**Сәясәтче! Кай тарафка карашларың,**
**Чикерткәдәй сикерәсең, боргаланып?**
**Мәсләгең ни, хәзер кая барышларың**
**Чапкан аттай, тыпырчынып, юргаланып?**

**Сәясәттә яман хәлдер фәхишәлек,**
**Кем хакимдар—бию шуның кубызына.**
**Хакимдарлык вазыйфасы—тиз кучмәлек,**
**Кулдан китә билгеле чор узуына...**

**Хаклык дигән олуг канун нигезендә**
**Йөзә алсаң хакыйкатьнең диңгезендә—**
**Булырсың син һәрчак гавамның күзендә;**
**Коръән тәгълиматын куллан син сүзеңдә.**

**Бүгенлекне генә яклау булса сүзең—**
**Бакыйлыкта оҗмах күрә алмас күзең.**

*Чүпрәле*

---

1 Малпәрәст—малга табынучы.
2 Бәхыйль—саран, карун.

**Печән базары**

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Фирүзә
Җамалетдинова

# КАРАК ҺӘМ АШКАЗАНЫ

САТИРИК ХИКӘЯ

Авыл өстеннән вертолет очып үтте. Коелары кипкән, чишмәләре корыган, әйләнә-тирәсен шайтан таягы басып алган авылның дүрт почмагында дөнья көтеп яткан дүрт ятимә карчык, намаздан соң дога кылырга дип, барысы берьюлы кулларын күтәрде.

Вертолет тикмәгә генә очмый ул! Аларның җирләреннән файдаланган Инвестор Өлкәннәр көне уңаеннан быел да берәр банка куертылган сөт һәм дә берәр шешә көнбагыш мае янына «Принцесса Нури» чәен куеп җибәрми калмас... Күктән генә исән-имин төшә күрсен... Ул-бу булудан Алла сакласын үзләрен! Әнә бит көн саен радиодан мәтәлгән самолетлар турында сөйләп кенә торалар...

***

Инвестор вәкарь белән генә вертолет тәрәзәсеннән бинокль аша кишер басуына карады. «Эшлиләр, димәк...» дип куйды ул үз—үзенә сөйләнгәндәй.

Анда, махсус киемнәр кигән сакчылар һәм берничә милиционер иске сырмалы бер агай артыннан кыр уртасындагы автобус янына куелган үлчәүгә табан атлый, ә агайның тишекле сеткасыннан эп-эре дүрт кишер күренеп тора иде.

***

—Дөрес үлчәмисең,—дип карышты Мансур.—Каян килсен монда бер кила! Дүрт кишер дип яз ылутчы... Йә тугыз йөз илле грамм диген... Ул кишер басуының үзле балчыгы үз итеп, яратып ябышкан фуфайкасын кагып-кагып алды. Башлары калҗайган сазлы күн итекләрен бер-берсенә бәргәләде. Өшегәндәй җилкәләрен җыерып-җыерып куйды.

—Син инде, туган, бабаңны тамак кырырга өйрәтмә. Бу эштә сакал агарган минем,—диде ярым горурлык катыш, үлчәү янында торучы шома

битле агай. Ул ике бармак арасына кыстырган тәмәкесенең утын күккә төбәгән көенчә ручкасына үрелде, үзе кыңгыр салган эшләпәсе астыннан күз чите белән генә Мансурга карап мыскыллы елмайды.

—Тәк-тәк, бер кила дип язабыз без моны.... Ә сине карак дип язабыз... Тәк-тәк...

Ул тишекле сетканың бер җебенә саннар язылган келәймәне беркетте дә каракка кире тоттырды, аннан автобуска табан ымлады.

—Бар, кереп утыр. Документын тутырырбыз. Соңрак кул куярсың...

Мансурның йөрәге жу итте. Битендәге төкләренә ут капты диярсең, һәммәсе чемер-чемер килә—аңа чынлап та уңайсыз һәм оят иде. Үз гомеренә энә дә урламаган зат һич көтмәгәндә угры дигән дан күтәреп, калтыранган аякларын буйсындыра алмыйча, бурлар белән шыплап тулган автобус баскычыннан менеп бара менә... Карашлары белән ул автобус эчен айкады: ни хикмәт—караклар һәммәсе тыныч иде. Тәрәзә пыяласына таба авышкан башларны күргәч, күнел дулкыннары бераз басылгандай булды. Ара-тирә гырлаган тавышлар ишетелә, автобус идәнендә пычрак сеткалар, яртылаш тулы капчыклар аунап ята иде...

Ир елмаеп куйды. «Кишерләрен түгел, үзләрен күтәреп чыгып качсаң да исләре китмәстер, мөгаен,—дип уйлады.—Пошмаслар күп лә бу дөньяда!»

—Болар барсы да кишер урлаганмы суң, братан?—диде Мансур шоферга моңсу караш ташлап.

—Караклар тыныч була ул. Борчылма, әйдә... Урлашучылар күп бүген... Море... Океан...—диде тегесе рульгә таянган көе генә башын яртылаш ир ягына борып. Мансур тамак кырды.

«Нишләп урлашыйм ди мин? Карак имеш... Инвестор минем җиргә дә кишер чәчә ич. Пайга дүрт кишер генә тиядер әле,—дип аңлатырга тырышмакчы булган иде дә тукталып калды.—Нинди пай ди инде? Гомергә бер дә түләгәннәре юк ич аны... Берәр закуны бардыр күрәсең... Эшләгән өчен дә түләмиләр әле менә. Былтыр кишер җыешкан өчен дә һаман бер тиен алмаган... Бу дүрт кишерне шуның өчен дип исәпләсәләр дә ярыйдыр югыйсә...»

Ирнең уйлары гүя хәерчелек сазлыгына батты. Бу мәлдә үзенең урлашкан булуына ул һич кенә дә ышана алмый, ә хак уйлар гына уйлаганга җанына шулкадәр дә рәхәт иде. Инде дулкынлануы да басыла төште кебек...

—Арылган,—диде Мансур сүзне икенче юнәлешкә борып.

Шофер дәшмәде. Радионы кабызып җибәрде.

Анда кемдер «Шалт Мөхәммәтҗан»ны җырлый иде:

> «Мөхәммәтҗан уңган кеше,
> Гөрләп кенә бара эше...»

Яшьлеге исенә төшеп китте. Бар иде лә җырлар! Урлашырга ярамый дип өйрәттеләр шул аны. Әбисе белән бабасы дин кушмый диделәр. Мәктәпкә кергәч, пионеры, комсомолы рөхсәт итмәде. Ышанды Мансур. Ышанылган да яшәлгән инде... «Хәзер инвесторлар ирек бирми. Безнең бабайлар гасырлар буена эшкәрткән бит бу җирләрне! Шуны җир күрмәгән инвесторлар алып бетерсен әле»,—дип ярсыды ул ачуын басарга тырышып. Кинәт умарта күче сарып алгандай бөтен тәне кычыта башлады. Кычытуны һәм нәфрәтен җиңәрлек башка берни булмаганга, үзе дә сизмәстән аяк астына үрелде. Бер кишерне сеткасыннан алып сүзсез генә мырлый-мырлый чалбар балагына ышкыды да шартлатып тешләде. Радио җыр сипте.

«Кай ара акча жыйган бит,
Дача салдырып куйган бит,
Шалт, Мөхәммәтҗан...»

«Уңган кеше...» дип мыгырданды ул шытыр-шытыр кишерен чәйнәп. Бу сәер заманда җыр шактый искергән булып күренде.

Шофер да шулай уйлады бугай—каналны күчерде.

«Н. шәһәрендә кала башлыгы миллиардлаган доллар акча үзләштерүдә гаепләнә», дип сөйләп китте радиодагы ягымлы тавыш.

—Урлыйлар, ә, братан,—диде Мансур шоферның аркасына төбәлеп. Үзе тагын сеткасына үрелде.

—Аның кадәрне ничек урлап булсын? «Үзләштерәләр» ди бит радио. Аның берәр аермасы бардыр инде...—диде тегесе төксе генә.

—Бардыр, бардыр,—дип кабатлады Мансур.—Әмма да ләкин без төзегән социализмны пыран-заран китерәләр бит... Безгә бер тиенен дә бирмиләр бит, братан...

—Йорт төзегән балтаны өйгә керткәннәрен кая күргәнең бар синең? Сарайга гына чыгарып ыргыталар шул аны, туганкаем...

Мансурның җен ачуы чыкты. Шул ачудан ул өченче кишерне учына гына сөрткәләп авыз эчендә әйләндерә-әйләндерә, һаман ач ашказанына озатты. Радио исә берөзлексез теге зур башлыкның чит ил банкларына күчергән миллионнарын санады. «Нигә кирәк инде шуның кадәр. Комсызлар! Гуҗлар!»—дип сүкте ир аларны эченнән генә.

Радио теге түрәнең йомшак кәнәфиен дә, йортын да дәүләткә тартып алу ихтималы барлыгын хәбәр иткәч, Мансурның эченә җылы йөгерде. «Гаделлек үлмәгән шулай да»,—дип сөйләнде дүртенче кишерен чалбарының бот турысына озаклап ышкый-ышкый. Ул инде үзенең ни сәбәпле автобуста утыруын да онытакан иде.

—Туя белмиләр, братан, ә?—диде ир янә шоферның киң җилкәләренә төбәлеп.

—Тавык кына ул бөртек чүпләп тә туя,—дип җаваплады тегесе. Каракларга карата шофер нигәдер үтә дә битараф иде. Мансурның ара-тирә сүз кушкалап алуыннан да арып китте бугай:

—Нарат сагызы булдың инде, тәмам,—дип өстәде.

—Карале, братан,—диде Мансур,—шоферның соңгы җөмләсенә игътибар итмәстән,—аны утыртканнармы соң?

—Кемне?

—Каракны дим.

—Кая?

—Өтерменгә инде, автобуска түгел...

—Акчалы кешене кем утыртсын?—диде тегесе бик хәбәрдар кешедәй.

—Ә ник сөйләп торалар алайса?..

—Син кишер урламасын өчен,—диде дә шофер башын артка ташлап көлеп җибәрде. Ихахайлап көлүдән башкалар да уянды. Кайсыдыр киерелде, кемдер кайда икәнлеген анларга тырышып тәрәзәгә төбәлде. Кишер турында сүз чыккач, Мансур аяк астына иелде. Анда балчыкка каткан буш сетка гына аунап ята иде. Ир аптырап китте. Ашап бетергәнме соң әллә ул дүрт кишерне дә? Инде хәзер нишләтерләр? Ир буш сетканы кат-кат селеккәләп карады да йомарлап чалбар кесәсенә тыкты.

—Карале, туган,—диде автобус шоферы.—Братан да братан дип сөйләшәсең. Каян өйрәндең син ул сүзне? Берәр нәрсә урлаган идең мәллә соң? Утырып чыктың мәллә моңарчы да?

Төрмә турында сүз кузгалгач, Мансур куырылып куйды. Бик әкрен тавыш белән:

—Күрше карчыгына шәһәрдән оныгы кайтып йөри. Ул шулай сөйләшә,—дип җаваплады.

Ул арада каракларны каядыр, шәһәрдәге милиция бүлегенә алып барасыларын хәбәр иттеләр һәм автобус кузгалып та китте.

—Өтермән имеш,—дип куйды ир сул як күкрәгеен угалап. Әйтерсең аның йөрәген тимер баулар белән бәйләгәннәр дә ул шулардан арынырга тырышып азаплана иде:

—Ходай кешене иректе итеп яраткан. Ирекле итәргә теләмәсә, аны ана карынынннан ук чыгармас иде... Әйе...—дип үз-үзенә сөйләнде ул.

Алар шәһәргә бик тиз барып җиттеләр. Чит илдә автобусларны да ясый беләләр инде, асфальтка чыккач, җилдәй очты гына тимер арба. Менә алар әллә нинди затлы йортның түбәсе генә диярлек күренеп торган биек таш койма янына килеп туктадылар. Ул арада милиционерлар, каравылчылар, мизанчылар машиналарыннан сикерешеп төштеләр дә баягы үлчәүне койма ягындагы асфальтка китереп куйдылар. Йокылы-уяулы кешеләрне тулы янчыкларын күтәртеп берәм-берәм чакыра тордылар... Чират Мансурга да җитте.

—Кишерең кая?—дип сорады аннан үлчәү янында торучы агай.

—Юк.

—Ничек юк?

—Юк инде... Әллә суң ашап бетердем микән мин аны... Озак тоттыгыз бит... Үтереп тамак ачты да... Әз иде бит ул, братан...

Үлчәү янында кәгазь тотыручы тәртип сакчылары каракны акларга җыенмыйлар иде.

—Бирермен мин сиңа братаныңны... Бу мөгаен шәһәргә бушлай килер өчен кереп утыргандыр,—диде берсе.—Милицияне алдамакчы була бит ә...

—Беренчедән—алдашкан өчен, икенчедән—кеше милкеннән бушлай, сораусыз файдаланган өчен, өченчедән—дәүләт органнарын санга сукмаган өчен штраф салырга кирәк,—диде юанрагы һәм башкаларга тотырылган кәгазьләр өстенә өр-яңасын тартып чыгарды да нидер яза башлады. Иң ахырдан исем-фамилиясен, адресын да теркәделәр. Аннан Мансурдан кул куйдырып, пичәтле квитанцияне кулына тоттырып автобустан төшереп җибәрделәр.

Мансур инвесторлар яшәгән шәһәр урамында як-ягына каранып шактый озак басып торды. Басып торуының сәбәбе шул: инде караңгы төшеп килә, ә кесәсендә өенә тиз арада кайтып җитәр өчен акчасы юк иде. Хәер, аның гомумән акчасы юк иде. Шунлыктан беркемнән берни өмет итмичә, җәяүләп тәпиләргә булды ул. Тап-такыр кыр юлыннан атлады да атлады. Йөгерерлек хәле калмаган иде. Вакыт-вакыт борыны юешләнде. Тукталып, кульяулыгын алмакчы булып кесәсенә тыгылды... һәм тартып чыгаргач аптырап китте. Теге сетка ич бу! Сеткага караклыкка дәлил—санлы келәймә ябыштырылган иде. «Их, дәлиле кесәдә генә булган бит! Бу кадәр штраф чәпәмәсләр иде бит дүрт кишер өчен»,—дип уйлап ир кырны янгыратып бер сүгенеп алды. Аннан сазлы буш сетканы кишер басуына атып бәрде дә юлын дәвам итте. Ә ашказаны һаман сулкылдап-сулкылдап көчен-җегәрен суырды. Авылга ул ачыгып, таң атканда гына кайтып керде.

Байларның, инвесторларның хәлен аңлады Мансур: барысына да ашказаны гаепле икән—чөнки кичтән эп-эре дүрт кишер ашап та тамагы бер генә тамчы да туймаган иде...

***

—Кая олактын суң син?—дип аңа иртүк Нуриәсма карчык килеп житте.

—Лапастан кәҗәмә печән төшерәсе бар ласа.—Аның артыннан ук ачык тәрәзә аша калтырана-калтырана Бибиҗамал карчыкның тавышы атылып керде:

—Әллә кая югалдың, Мансур, синнән башка кулсыз-аяксыз ла без... Әйдәле, базга бәрәңгемне салыйк әле, улым...

Авылның дүрт урамындагы дүрт карчыкның эшләрен бетереп кайтуга Мансур, хәләл хезмәт хакына алынган зәм-зәм суыннан изрәп, эчке тынычлык белән тирән йокыга талды.

Ә авылның дүрт почмагында көн итеп ятучы дүрт карчык бу мәлдә күктә очып йөргән Инвесторга озын гомер һәм саулык теләргә дип намазлыкка басты...

Алмаз Хәмзин

# ИМГӘК

Алкышлар, алкышлар, алкышлар...

Чәчәкләр, чәчәкләр, чәчәкләр... И-и! Бүген аңа күпме бүләк иттеләр аларны!.. Рәхәт! Бик рәхәт! Рәхәтлекнең чиге юк! Үбәләр, кочалар!...—Битенә ябышкан ирен эзләрен сөртергә дә вакыты юк аның. Хәер, каян белсен ул яңакларында ясалган иннек картиналарын, күрми бит. Күрсә дә сөртмәс иде. Ник, көнләшсеннәр! Менә ул нинди күркәм зат, менә ул нинди бөек шәхес! Ул бизәкләр аның кайчандыр хезмәт баскычларыннан өскә, югарыга күтәрелгәндә үпкән-ниткән гүзәлкәйләренең рәхмәт билгесе һәм киләчәккә тагын да зуррак өмет баглаучы татлы хыяллар күпере.

Күпләре картайды, ләкин яшьләре-чибәррәкләре бар бит. Үсәләр яшьләр, черт возьми! Карап бетерергә житешмисен... Әнә алар сәхнәгә менә—йөрешләре челтәр-чигешле. Ай, жаныкайларым!.. О-о! Бүләкләр! Коллегалар! Йомышлары үтәлмәгәннәр... Ул хәтле үк зурдан купмаска иде инде—машина дип... Кеше алдында уңайсыз, болай да әллә ниләр уйлыйлар...

Аның гәүдәсе халыкка чак күренә—ул юбилеена китерелгән бүләкләргә күмелде. Ул шат, чиксез шат! Ул үзен ким дигәндә президент итеп хис итте. Юк, юк, президент кына түгел!!! Аның бу минутларда күккә чөелгән башы Аллаһы Тәгаләгә ымланган рәвештә.

Элек кем иде дә, хәзер кем булды?!

...Аңа күбесенчә исеме белән түгел, «имгәк» дип кенә эндәшәләр иде. Нигә шулай дигәннәрдер, ул аны хәзер дә белми. Югыйсә эшләмәгән эше калмады, тыкшынмаган жире дигәндәй... Үсмер чакларында, Хрущевның «мин көтүчедән күтәрелдем» дигән сүзләренә мөкиббән китеп, ул көтү көтәргә хыялланды. Ләкин авылның данлыклы көтүчесе, инде халык малын егерме елдан артык көткән Гыймай һич урыныннан төшми интектерә—көтә дә көтә, көтә дә көтә. Бу да көтә аның киткәнен. Юк, Гыймай һаман көтә.

Менә берзаман Гыймайны колхоз көтүенә билгеләделәр. Дөресрәге, анда акчаны күп түләгәч, ул шунда күчте. Жае чыкты бит монаˌ Авыл жыелышында ул үзенең кандидатурасын куйды. Авыл халкы: «Башы да жүнләп эшләми, мәктәптә укуының да рәте булмады»,—дип, моны жәлләп, бертавыштан, көтүче итеп сайлап куйдылар. Ә нигә булмаска! Күптәнге хыялы бит. Безнең илдә барлык житәкчеләр дә түбәннән күтәрелүләре белән мактаналар, ягъни халык арасыннан. Ул да һичшиксез генсек булачак. Шул хыяллар белән ул икенче көнне иртүк, матур итеп киенеп, көтүгә чыкты. Бөтен кеше шаккатты: «Менә сина имгәк!—диештеләр.—Ярый, Аллага тапшырдык!» Бер кулында мәктәпкә йөрергә дә тәтемәгән шәп, яна портфель, эче тутырук конфет, шешәдә—сөт, ашъяулыкта ипи, суган. Тәмәке төрергә гәжит. Әле тәмәке тартканы юк-югын, өйрәнер. Ничек инде көтүче хәтле көтүче булып тәмәке тартмаска тиеш ди ул. Тартачак, кәнишне! Ләкин кибеттән анын кебекләргә әле махорка алу кыенрак. Ничава, болында кипкән куян бугы беткәнмени, йә булмаса коры яфрак—уасын да озын итеп гәжиткә төреп жибәрәсен! О-о! Төтене шәп! Авыздан төтен түгәрәкләре өрүне кем белми, менә борыннан һәм колактан чыгаруны өйрәнәсе бар.

Көтү артыннан ияреп авылны узу белән берничә сыер инеш буйлап, нишләптер, кире өйләренә чаптылар. Ул аларны күрмәде. Изге хыялларга чумып барганда ничек күрәсен инде аларны—генсек буласы кеше бит ул! Тагын бераз баруга унбишләп сыер әрәмә юлыннан унга каерылды. Каян күрсен ул аларны. Ул чагында анын уйлары биш ай көтү көтеп аласы акчалары турында иде бит. Их, жүнләп укыган булса тапкырлыйсы гына, югыйсә... Юк шул. Очына чыгар хәл юк. Күп инде, күп, дигән фикергә килде дә, татлы хыялларына чумган килеш йөз илле сыердан көтүдә калган егермесе артыннан бара бирде. Аңына килгәндә ул болын уртасында берүзе генә басып тора иде.

Шул ук көнне иртәнге сәгать тугызда үзе кайтканчы авыл халкы жыелышында аны бу эштән азат итү турында карар чыгардылар. Бу имгәккә көтү ышанып тапшырган без жүләр, дигәннәр.

Әй, аптыраган юк ла. Жүнле илдә чыпчык үлми, киттем бардым шәһәргә, диде дә, мәктәптә үзе төсле өчле-тугызлыга укыган дусты Жәүдәтнен милициягә урнашуын искә төшереп, шунда ычкынды. Яхшы эш тапканчы милициядә эшләр.

Әнә, Рәсәйне дер селкетеп торткан Дзержинскийнын ул хәтле белеме дә булмаган, мин анардан ким мәллә? Сыер көтеп йөрергә абзагызны кем дип белдегез, аны Гыймайлар көтсен, безгә югарыга үрмәләргә кирәк, ишетәсезме?!

И сөенде Жәүдәт дусты белән очрашуына. И сөенде! Мине гел жүләргә санап йөриләр иде, ярый әле син килден, ди.

Жәүдәтнен инде милициядә тәжрибәсе бар. Заданиеләргә бергә йөрербез, бер-беребезне сатмаска әйбәт булыр, ди.

Берзаман боларга кибет басалар дигән срочный хәбәр килә. Тиз генә пистолетларны кыстырып машиналарына утыралар да ычкыналар ике дус бандитларны тотарга. Ә шофер кая, кайсы кибеткә барасын белми. Ах, шайтан алгыры, кайсы кибет икәнен сорарга оныткannar бит. Инде байтак кителгән. Чурту матер! Менә сина бәла. Кире кайтып сорамакчы да булалар. Жәүдәт әйтә, инде борылмасак та була, безне эштән куганнардыр, ди. Әлбәттә, куарлар, бүтән бу имгәкләрне милициягә алмаска дигән карар да чыгарырлар. Ярар, Дзержинский булмасак та яшәрбез, безгә дигән бәхет безне көтеп торадыр, дип аерылышалар дуслар.

Нишләп имгәк булсын ул! Тавышы бар бит анын. Һәй, жәмәгать, жырга оста бит абзагыз! Бу яктан Илһам бер кырыйда торсын! Ходай бирсен

бирмәсә, икенчесен бирә ул! Җырлар өчен акыл кирәкми. Карагыз әнә, хәзер җырчылар күпме?! У-у, урыс әйтмешли: «Развились!... Хоть пруд пруди!» Фонограмма яздырасың да, китәсең ил буйлап. Дан, шөһрәт, популярлык! О-о! Акча—море, кызлар!.. Балдеж! Борис Николаевич булу—пүчтәк! Кирәкми президент урыны, просто кирәкми. Әтинең өч сыеры бар. Берсен сатып, җыр яздырабыз, икенчесенә—радио, телевидениеда әйләндерәбез. Акча дигәндә алар теләсә нинди җыр уйнаталар, күрсәтәләр дә. Түлә генә. Авылына кайтып ул әти-әнисен әлеге фикеренә күндерде. Үзләре дә өч сыер асрап туйганнар, ахрысы, сөт эчмәскә дигәндә рәхәтләнеп риза булдылар. Аның исәбе зурга китте. Шул хәтле расходланып яздыргач, Тукай премиясе дә алып булмас микән берочтан дигән уй борчый башлады. Шуңа күрә дә ул таныш шагыйреннән «Мин яратам сине, президент!»—дигән җыр язуын сорады. Шигырь шул хәтле әйбәт килеп чыкты. Бигрәк тә:

Мин яратам сине, президент,
Гөнаһларың белән яратам,—дигән җире.

Әлбәттә, мәгънәсенә колак салсалар, һичшиксез Тукай бүләгенен бирәчәкләр. Музыкасын язуны үзләренең авыл гармунчысы Сәлимгә тапшырды. Сәлим—искиткеч талант. Аның инде ике җыры бар.

Язды. Бик ошатты җырчыбыз һәм үзе дә җырны бик матур итеп башкарырга тырышты. Әзрәк тавышына Салават стиле дә өстәде. Болай булгач, премия бирми калмаслар, йөз процент! Ышанам. Шулай итеп бер сыерлык эш эшләнде. Икенче сыер акчасы телевизорда ике янгырап, радиода биш ишетелеп, «аллаһәкбәр» булды. Кая анда премия турында сүз кузгату. Әти-әнисе аңа бу юлы «имгәк» дип әйтеп тормадылар. Билгеле бит инде. Болай да... Әйттең ни дә, әйтмәдең ни...

Ай, малай, дөнья кая таба бара?! Беркая тыгылып булмый. Президентны мактап җырласаң да күтәрмиләр. Ике сыер гына аз шул.

Каян гына акча табып Вамин булырга? Суны саталар инде—хуҗалары бар. Нефтьнеке дә бар, газныкы да... Әһә, һаваны сатмыйлар бит әле. Һаваны! Нигә шуңа тотынмаска?! «Экология министрлыгыннан кредит юнәлтеп, тотыныйм әле бу эшкә»,—дип, кош тоткан кебек кереште ул әмәленә. Ышанасызмы, бирделәр. Чөнки сиздeләр. Мондый җаваплы эшләрне башкару өчен шундый имгәкләр кулай. Башлы кеше тотынамы соң мондый тәвәккәллеккә? Алай-болай бу хәвеф шырыкка китсә менә кемгә ягып куярга була ич кынгырлыкны. «Тик эшебез уртак булсын, табышың да... Эһем, эһем»... Килешенде, куллар бирешелде. Китте эшләр ходка. «Имгәк» дисәләр дә, бик җүләр түгел ул. Артта терәү бар, өстә—түбә. Тотынды имгәгебез урман һавасы сатарга. Алалар. Кырылып алалар. Чират. Ай, чиста, саф һавага сусаган халык. Ай, сусаган!

Нәтиҗәне «өстәгеләр» дә күргәннәр. Күптән түгел үзен әрәмәлек министры итеп билгеләделәр. Портфельле министр! Бүген юбилее! Түрдә, затлы бинаның алтын тәхетендә утыра. Рәхәт. Искиткеч рәхәт!

Менә инде ул тантана ахырына якынлашып килә. Аны котларга халык сәхнәдән өзелми. Ниһаять, аңа ахыр сүз бирделәр. Ул әйтер фикерен табалмый җәфаланды. Нәрсә әйтсен, һава сатудан башка җүнле эш кырганы юк бит аның. Шулай да микрофонны кочәйткәч аның авызыннан «Мин булдырам!..» дигән сүзләр сытылып чыкты.

«Далеко пойдет!—дип куйды тамашачы арасында тантананы төшереп йөрүче танылган урыс фотохәбәрчесе Шамил. Бу вакытта илдәге соңгы әрәмәлектә янгын чыгып, ул да янып бетеп бара иде.

...Алкышлар, алкышлар, алкышлар!..
Чәчәкләр, чәчәкләр, чәчәкләр!..
Үбеш, сөеш...

Рәфикъ
Юныс

# ЭШ КҮП ӘЛЕ!

**Киң тәрәздән бага берәү.**
**Эһем-кеһем йөткерә.**
**Күзе күпне күрә, башы**
**Олы гамьнән күперә.**

**Әле күпме бу дөньяны**
**Тәртипкә саласы бар!**
**Көтүдәге сыерларга**
**Номерлар тагасы бар.**

**Торналарның, тукраннарның**
**Сан исәбен алмаган.**
**Пошилар бар—савылмаган.**
**Тиресе туналмаган.**

**Түрәләргә этләр ырлый.**
**Мәчеләр никтер мырлый.**
**Тургай ни теләсә шуны**
**Тота да менеп җырлый!**

**Йомран-әрлән ояларын**
**Чыгасы бар актарып.**
**Бу—хөр-мөстәкыйль яшәүнең**
**Яшьрен ныгытмалары!**

**Җилләр әле исми һаман**
**Бары кушылган якка.**
**Күргән-ишеткәннәрен дә**
**Сөйләмиләр колакка.**

**Кояш әле тәртип белми—**
**Һәркемгә тигез төшә.**
**Күпме халык әле һаман**
**Үз телендә сөйләшә!**

---

## Конкурс дәвам итә

Бөек сатиригыбыз Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге һәм «Казан утлары» журналы редакциясе иң яхшы сатирик әсәрләргә үткәргән «Печән базары» конкурсына яңа хикәяләр (күләме 15 биттән артмасын), шигырьләр, фельетоннар, пьесалар, скетчлар, пародияләр, эпиграммалар, такмаклар һ. б. кабул ителә. Авторлар конкурста берничә әсәр белән берничә кат катнаша ала. Түбәндәге премияләр билгеләнде:

*I урынга—50000 сум (бер премия)*
*II урынга—30000 сум (ике премия)*
*III урынга—10000 сум (өч премия)*
*5000 сумлык ике кызыксындыру премиясе.*

Әсәрләр 2011 елның азагына чаклы кабул ителә.

Махсус жюри ясаган йомгактан тыш әсәрләрне журналдан укучылар—үз җинүчеләрен, матбугат ру.дан укучылар—үз җинүчеләрен билгели алачак (1-3 урыннар). Жюри бу нәтиҗәләрне дә искә алыр.

# НӘҖИП ҖИҺАНОВ ҺӘМ ТАТАР МУЗЫКА СӘНГАТЕ

Татарстанда Нәҗип Гаяз улы Җиһановтан башка олуг композитор һәм киң музыкаль-җәмәгать эшлеклесе булып танылган, үзенә аеруча тирән игътибар җәлеп иткән кешене табу кыен. Аңа багышлап уздырылган юбилей тамашалары, бәйгеләр, конференцияләр музыкаль сәнгатьне яраткан халыкны үзенә тартуы турында сөйли. Быел аның 100 еллык юбилее киң билгеләп үтелде. Вакытлар узган саен бу бөек шәхеснең музыка сәнгатенә бирелгән чын пәрвәрлеге ачыла бара.



Композиторның балалык һәм яшүсмер елларындагы язмышы җиңел булмый. Ул Уральскида туа, бик яшьли ятим кала һәм абыйсы Җәләл (Җәләл Садриҗиһанов) белән бергә ятимнәр йортында тәрбияләнә. 1928 елда Казанга килә һәм Көнчыгыш музыка техникумына укырга керә. Әмма бу уку йортын үзгәртеп оештырган вакытта ул Мәскәү музыка училищесын тәмамлап Мәскәү дәүләт консерваториясенең өченче курсына кабул ителә. Аның композиторлык иҗатының үсешендә, башка татар композиторларының да беренче буыны өчен остаз булган укытучы Генрих Ильич Литинский мөһим роль уйный.

Нәҗип Гаяз улы Җиһанов композитор буларак узган гасырның 30 нчы-40 нчы елларында өлгереп җитә. Әле Мәскәү консерваториясендә үк ул татар композиторларыннан беренче булып музыкаль сәнгатьнең прелюдия, сонатина, квартет һәм симфония кебек жанрларына мөрәҗәгать итә. 1936 елда Әхмәт Фәйзи либреттосы буенча композитор үзенең диплом эше итеп «Качкын» операсын яза.

1938 елда Татар дәүләт филармониясе төзелә һәм әлеге вакыйга Н.Җиһановның Беренче симфониясе белән билгеләп үтелә. 1939 нчы елда Казанда Татар опера һәм балет театры ачыла һәм бу көнне аның «Качкын» операсы куела. Шушы ук елда ул Татарстан композиторлар берлеген оештырып, аның җитәкчесе булып сайлана. 1945 елда композиторның тырышлыгы аркасында Казан дәүләт консервbooториясе ачыла һәм ул аны гомере буена җитәкли.

Нәҗип Җиһановның 1940-50 еллардагы иҗаты күп яклары белән уңышлы. Бу чорда композиторның төп әсәрләре–биш операсы языла. Алар арасында «Алтынчәч», «Түләк», «Җәлил», программ әсәрләрдән «Кырлай» симфоник поэмасы, татар халык темаларына язылган Сюита, «Нәфисә» увертюрасы, һ.б. әсәрләре бар.

1960 нчы еллар ахырыннан 1988 елларга кадәр сузылган чоры симфония һәм камера-инструменталь жанрны үзләштерүгә багышлана. Сәяси җылылык башлану сәнгать кешеләренең тормышка һәм иҗатка карата мөнәсәбәтләрендә билгеле бер үзгәрешләр китереп чыгара. Яңа фикерләр, яңа шәкелләр туу вакыты җитә. Философик мәсьәләләргә мөрәҗәгать итү, инструменталь формаларга таба омтылу, вакыт үзгәрешләренә карата бик сизгер булган композитор Нәҗип Җиһановка да кагыла.

Башка иҗатташлары арасында Нәҗип Җиһанов әсәрләренең аерылып торуын билгеләүче нигезнамәләр нинди, дөнья күренеше нидән гыйбарәт?

Барыннан да бигрәк Н.Җиһановның катлаулы тарихка һәм хәзерге героик темаларга игътибар баглавын күрсәтергә кирәк. Алгы сафка халыклар бәрелеше, туган ил язмышы хәл ителә торган кискен вакыйгалар һәм глобаль конфликтлар куела. Халык көнкүреше, эчке иҗтимагый проблемаларны гәүдәләндерүгә игътибар юнәлткән композитор Салих Сәйдәшевтән аермалы буларак, Нәҗип Җиһанов татар халкының чит ил яулап алучыларына каршы көрәшен сурәтли. Ул тарихта өйрәнелмәгән, музыкаль сәнгатьтә генә түгел, әдәби әсәрләрдә дә чагылыш тапмаган

фактларга игътибар бирә. Мәсәлән, 1941 елда Муса Җәлил либреттосы буенча язылган «Алтынчәч» операсында, 1945 елда язылган Нәкый Исәнбәт либреттосы буенча иҗат ителгән «Түләк» операсында болгарларның XIII гасырда монгол басып алучыларына каршы көрәше сурәтләнә. Моның белән берррәттән, тарихи вакыйгалар эченә халык легендаларын да кертеп җибәрү–композиторның яңа алымы.

Нәҗип Җиһановның хәзерге темаларга язылган операларында да зур иҗтимагый вакыйгалар чишелеше күз алдына бастырыла. Мәсәлән, 1917 елдагы инкыйлаб «Ирек» операсының нигезенә салына. Бөек Ватан сугышы вакыйгасы, шагыйрь Муса Җәлилнең батырлыгы, сугыштан соңгы җимерекләкне бетерү өчен көрәш аның 1942 елда М.Җәлил либреттосына язылган «Илдар», 1950 елда Ә.Исхак либреттосы буенча язылган «Намус», 1957 елда Әхмәт Фәйзи либреттосы буенча язылган «Җәлил» операсында чагыла.

Нәҗип Җиһанов татар музыка өлкәсендә драматик образларны барлыкка китерде. Аның геройлары фаҗигале язмышлы горур титаннар. Бер-берсенә каршы торучы халыкларның үзәк образлары белән берррәттән, аның әсәрләрендә йөрәк кичерешләре, бер-берсен сөя торган яшь геройларның лирик-психологик халәте гәүдәләндерелә. Социаль низаглар, шәхси драмалар халыкның көнкүреше, табигать, бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр, йолалар фонында үсеш ала. Драматургиядә күп планлылык–Нәҗип Җиһановның опера эстетикасына хас булган үзенчәлекләрнең берсе.

Аның операларында инструменталь чалымнар әһәмиятле роле уйный, һәрбер персонаж үзенең лейтмотивы белән сурәтләнә. «Алтынчәч», «Түләк», «Җәлил» операларында вокаль һәм инструменталь партияләр бертигез дәрәҗәдә. Бу–композиторның тагын бер казанышы.

Нәҗип Җиһанов әсәрләре опера формаларының үсешендә үзенә бер яңа чор. Элекке вакытларда музыкаль драма һәм опера үзәгендә соло–ялгыз җыр торса, Н.Җиһанов барлык опера формаларын бертигез дәрәҗәдә куллана.Фольклор рухлы традицион хор, катнаш, күмәк биюләр белән берррәттән, дан, мактау җырлары, пастораль җырлар, героик марш-җырлар, елау, зар-сагыш җырлары үсеш ала. Аның операларында ариозо, речитатив, ансамбль һәм хорлар бер-берсе белән үтә сыгылмалы чиратлашкан күләмле күренешләр өстенлек ала, аерым инструменталь эпизодлар зур роль уйный.

Композиторның симфонияләрендә образларның беркадәр башкача урнаштырылуы күзгә ташлана. Ул барлыгы 17 симфония язган. Болар арасыннан Икенче «Сабантуй» симфониясе 1970 елда СССРның Дәүләт премиясенә лаек була. Монда беренче планга халыкның тарихи язмышы турында фәлсәфи уйланулар чыгарыла. Яшьлек сиземләкләре, халык бәйрәмнәре, табигать матурлыгын күзәтүләрдән туган оптимистик кәеф күренешләрен көтмәгәндә көрәш-сугыш һәм кайгы-моң күренешләре алмаштыра. Үткәннең фаҗигаләре яңадан тантана һәм шатлык күренешләре белән чиратлаша.

Н.Җиһановның иң ачык казанышларыннан берсе–симфонияләрдә дә, операларда да полифоник техникадан гаять оста файдалану. Аның әсәрләрендә полифония, элек күрелмәгәнчә, үсешенең иң әһәмиятле принципларына әйләнә. Ул чорда оркестрны максатка ярашлы төзи белү бик аз композиторларга гына хас булган. Җиһанов бу эштә дә зур осталык күрсәтә. Ул консерваториядә үзе оркестровка дәресләрен алып бара, аны язу осталыгын гамәлдә куллана, тембр мөмкинлекләрен яхшы белә.

Аның эш стилендәге үзенчәлекләре белән бергә композиторның шәхси холкы турында да әйтми булмый. Кайсы яктан карасаң да, Нәҗип Җиһанов үз әсәрләрендәге геройлары кебек үк, гадәти шәхес кенә түгел. Ул трибун, табигате, характеры буенча юлбашчы, җитәкче. 28 яшендә үк Татарстан композиторлар берлеге рәисе, 34 яшендә консерватория ректоры. Берничә тапкыр ТАССР һәм СССРның Дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик хезмәт герое, СССРның халык артисты, Ленин премияләре буенча комиссия әгъзасы. Консерватория ректоры буларак, ул Казанга атаклы профессорлар–Г.И.Литинский, А.С.Леман, Г.М.Коган, Э.А.Монасзон, И.С.Дубининаны чакырып китерә. Студентларны танып белә, консерватория тәмамлаганнан соң да аларның тормышы белән кызыксынып тора, диплом эшләре, мөгаллимнәрнең диссертацияләре белән танышып бара, музыка өлкәсендәге яңалыклардан хәбәрдар, китапханәсе дә гаять бай була. Музыка сәнгатенең барлык өлкәләре белән дә даими элемтәдә тору гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә.

Н.Җиһановның гомере эш вакытында өзелә. 1988 елда Уфада татар сәнгате декадасы көннәрендә аның «Җәлил» операсы гаять зур соклану белән кабул ителә. Аны унөч тапкыр сәхнәгә чакыралар. Нәтиҗәдә дулкынланган композиторның йөрәге бу шатлыкны күтәрә алмый.

Н.Җиһанов һәрвакыт эш өстендә: конференция, пленум, съезд һ.б. шундый чараларны үзе оештырып йөри. Шундый вакытта иҗат белән шөгыльләнергә вакыт табуы–гаҗәеп! Татарстан җөмһүрияте симфоник оркестрының һәр концерт сезоны Җиһановның чираттагы симфониясе белән ачыла. Шул ук вакытта ул гаять таләпчән, һәрвакыт башкалардан аерылып тора торган фикере бар, алар үзенчәлекле һәм тормышчан. Аның сүзләреннән ни эшләргә кирәклеген төгәл, ачык анлавы, тирән фикерләве анлашылып тора. Барлык максаты, омтылышы үз халкының мәдәниятен үстерүгә, аны алга этәрүгә юнәлтелгән иде. Ул перспективалы яшьләр–студентларны, осталыклары ачылган иҗатташларын аерым күзәтеп бара, аларга ярдәм итә. Техник үзгәрешне белеп тора, вакытның яңа музыкаль юнәлешләрен үзләштерә.

Мәсәлән, романтик юнәлешләр Фәрит Яруллин, Рөстәм Яхин иҗатында күренсә, яңа стильләр Алмаз Монасыйпов һәм аның укучылары иҗатында чагыла. Үзенен үсешен норматив кагыйдәләр белән дәвам иткән классик юнәлеш заман рухына туры килми иде инде. Татар музыкаль стилен һәм чараларын актив рәвештә яңарту кирәклеге алга килеп баса. Моны композитор сизми калмады. Менә ни өчен аның иҗатында традицион классик закончалыклар белән беррәттән ниндидер башка стиль ориентирлар очрый башлый. Җиһановның төп иҗат чорында импрессион һәм романтик тенденцияләр әледән-әле күзгә ташлана. «Алтынчәч» һәм «Түләк» операсында әкияти-легендар образлар, «Җәлил» операсы монологик поэма жанрында язылу, фортепиано өчен прелюдияләре һәм романслар–моның ачык мисалы.

Импрессионистик тенденцияләр 1980 елда чыккан җиде пьесадан торган «Матюшин эскизлары» дигән фортепиано циклында да бар. Ачык сурәтле, лирик-шигъри һәм бию жанрындагы образлары калкып күренеп тормый, ә бәлки эскиз рәвешендә бирелә. Тагын бер соңгы романтик күренеш тенденциясе 70 нче еллардагы «Нҗери» (кызлар исеме) балетында да сизелә (Н.Җиһанов либреттосы). Сюжетның нигезендә җирне эсседән һәм корылыктан коткару хакына авылның иң матур кызын Аллага корбан итү турындагы африка халык легендасы ята. Әсәр ритуаль Африка фольклорын бүгенге көн аңлатылуында куллануы белән неофольклористик ысулның кайбер принципларын искә төшерә. Балетта классик һәм үзенчәлекле бию номерларын аерым традицион рәвештә бүлү, кире һәм уңай геройларны капма-каршы кую юк. Символик образлар, язмышның трагизмы, бер актлы күренеш, монотематик композиция–болар барысы да классик юнәлештән ерак торган билгеләр. Әсәр образларның экспрессив характеры, тирән психологизмы, саф инструменталь тематизмы симфоник үсешенең өзлексезлеге белән аерылып тора. Барлык бу яңа күренешләр Россия һәм Европа композиторларының 60-70 еллардагы бер актлы балетлары тәэсирендә барлыкка килгән.

Кыскасы, Нәҗип Гаяз улы Җиһановның иҗаты–татар музыкасында гаҗәеп зур колачлы, яңача һәм үзъяшәешле иҗат. Барыннан да бигрәк, ул–яңа этап ача. Композиторның иҗаты аерым иҗтимагый-сәяси шартларда яшәде һәм, һичшиксез, тарихи үсеш-үзгәрешләр белән бәйле булды. Иң мөһиме, Нәҗип Җиһанов яңа тема һәм жанрлар барлыкка китерде, милли музыкада классик опера һәм программлы симфонизмны тудырды, драматургиядә эпик-драматик типларны тәкъдим итте. Гармонияне, фактураны, оркестровка чараларын һәм тематик үсеш алымнарын бөтенләй башка биеклеккә күтәрде. Даими рәвештә яналыкка омтылу нәтиҗәсендә аның иҗаты туып торган һәм яңәшәдә булган башка төр стиль юнәлешләренең тәэсирен дә үзенә сыйдырды. Татар музыкасы өлкәсендә жанрларның күптөрлелеге, темаларның масштаблылыгы, эзләнүләрнең киңлеге ягыннан да аңа тиңнәр юк. Ә кайбер тенденцияләрнең каршылыклылыгы–композитор иҗат иткән вакытның-чорның каршылыклы булуы нәтиҗәсе.

Татар халык музыкасын яңа баскычка күтәрүче, аны үстерүгә бөтен гомерен багышлаган композитор Нәҗип Җиһановның исеме лаеклы рәвештә Казан дәүләт консерваториясенә бирелде. Ышанабыз ки, аның иҗаты әле озак вакытлар буе кызыксынучыларның игътибарын үзенә тартыр, яңа буыннар өчен үрнәк булып калыр.

**Аида АЛМАЗОВА,**
*сәнгать фәннәре кандидаты*



*Республиканың әдәбият-сәнгать вәкилләре «десант»ы Әлмәттә. Уңнан сулга – Шамил Рәкыйпов, Үзбәк Саттаров, Атилла Расих, Риза Ишморат, Нил Юзиев, Әхмәт Исхак, Рәисә Ишморатова, Айрат Арсланов, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Клара Булатова. 1971 ел.*



*Драматург Таҗи Гыйззәтне (1895-1955) Татар академия театрыннан соңгы юлга озату күренеше.*



*«Әдәбиятлар дуслыгы – халыклар дуслыгы». Мордва язучылары Александр Доронин һәм Григорий Агейкин республикабызның Лениногорск районында. Сулдан икенче – матур әдәбиятны пропагандалау бюросы директоры, язучы Рәфкать Кәрами. 1985 ел, сентябрь.*



*Демьян Фәтхи (Фәтхетдинов Касыйм Фәтхетдин улы) – шагыйрь (1906-43).*



*Акчурин Рәсим Сөләйман улы – хәрби эшлекле, генерал-полковник. Мәскәү шәһәре региональ татар милли-мәдәни автономия рәисе.*

Зиннур
Закиров

# ДИНЕБЕЗ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

*И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,*
*Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк,*
*Мәдәният мәйданында урын алыйк,—*
*Егла-тора алга таба атлыйк имди.*
*Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,*
*Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;*
*Диңгез якасында торып, без сусамыйк,—*
*Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.*

Габдулла Тукай. 1905 ел.

2008 елда Мәскәүдә, Согуд Гарәбстанының һәм Кытайның Казанда уздырылган мәдәният көннәренә багышланган концертлары булды.

Кытайлар шаккатыргыч бөеклеккә меңгәннәр: бүген югары сәнгатьтә аларга тиңнәр бар микән? Аерым башкаручыларның җырлавы, хор, опера, балет, оркестрның симфоник әсәрләре—барысы да искиткеч югары камиллек, дөнья стандартлары дәрәҗәсендә башкарыла. Шул ук вакытта югары сәнгатьләренең нигезендә миллилек сакланган: көнбатышны сукырларча кабатламыйлар. Аларның милли фольклорны саклаулары, бөтен дөнья халыклары сокланырлык камиллеккә җиткерүләре таң калдыра. Борынгыдан килгән уен коралларын ташламаганнар, киресенчә, башкару осталыкларын, кулланылышын тагын да үстергәннәр. Инде акробатика, цирк сәнгатенә килгәндә, бүген дөньяда аларга житүче бар микән?

Кытайларның бу чыгышларын караганда үзеңне зур елан алдында сихерләнгән куян итеп тоясың, хәтта куркыныч та булып китә. Шундый ук тойгылар Пекинда узган Олимпия уеннарын караганда туган иде. Бу ил, бу халык үз җирләренә генә риза булырмы, Җир шары белән идарә итәселәре килмәсме?

Гарәпләр фольклор ансамбле концерты һәм туй күлмәкләреннән, үзебезчә атасак, мода театры күрсәтте. Концертка килгәндә, ул унбишләп гарәпнең ике сәгать буе, бер чама ритмда барабан кагу астында, гади генә хәрәкәтләр белән бедуиннар (көтүчеләр) биюен башкаруы булды. Киемнәре бик гади, аякларында оексыз кигән төрле аяк киемнәре—көтү көткән җирләреннән генә алып киткәннәр шикелле.

Мода театры кәләшләрнең туй күлмәкләрен пәрәнҗә япкан кызларга кидертеп күрсәтте. Үз кызларын алып килмәгәннәр, бездәгеләрне яллаганнар. Күлмәкләре искиткеч затлы, матур итеп тегелгән, алтыннар белән чигелгәннәр, берсенә хәтта алты кило алтын киткән диделәр. Гарәпләрнең бөтен сәнгате шулдыр гына дип әйтәсе килми, ләкин министрлары катнашында зурлап күрсәтелгәч, башка шундыйрак уйлар килде. Бу ике илнең мәдәнияте арасында искиткеч зур аерма, диндәшләребез гарәпләр ким дигәндә 10 гасырга артта калган кебек тоелды.

Болай дөнья цивилизациясеннән артта калуның сәбәпләре нәрсәдә соң? Беренче итеп ислам динен атарга булыр иде, чөнки гарәп илләрендә ислам дине идеологиясе өстенлек итә, күбесе шәригать кануннары белән яшиләр. Ислам динен

гаепләр идек, күбесенчә мөселманнар яшәгән, бүген югары үсеш алган Төркия, Малайзия, Иран дәүләтләре мисалы бар. Бөек ислам тәгълиматы берничә гасыр буе дөнья үсешенә нинди зур өлеш керткән, күпме бөек галимнәр, математиклар, астрономнар, фәлсәфәчеләр, шагыйрьләр, инженерлар, дәүләт, хәрби җитәкчеләрен тудырган. Хәзерге Испания җирлегендә, ул вакыттагы ислам дәүләтенең Кордова университеты Европа халыклары өчен иң зур фән һәм белем алу үзәге булган, Европа «Янарышы»ның нигезен тәшкил иткән, әлеге кыйтгага цивилизация алып килгән.

Димәк, сәбәп 4-5 гасыр буе дөньяның бөек үсешен тәэмин иткән исламда түгел, ислам тәгълиматының, халыклар цивилизациясенең иҗтимагый фикер үсешеннән артта калуында, ислам дини әһелләренең аны үстерергә теләмәүләрендә. Ислам дине шигыйларга, сөнниләргә бүленә, һәр дин әһеле үзенең мәзһәбен булдыра, йөзләгән секталар туа, изге Коръәнне һәрберсе үзенчә аңлатып, төрле тәфсирләр, хәдисләр язалар. Бу гамәлләр ислам динебезнең дошманнары—кара көчләрнең дә «тырышлыгы»ннан башка эшләнми булыр.

Менә ислам диненең кайбер дәүләтләрдә шәригать кануннары аша идарә итүче дингә әйләнүе дә сәбәпчедер. Халыкны томаналыктан дөнья прогрессы юлына чыгармыйча, аның фани дөньядагы тормышы өчен кайгырмыйча: «Сез—мөселманнар, сезне мәңгелек Алла йортында җәннәт көтә»,—дип яшәтү бик унай шул. Коммунистлар да халыкны ачлы-туклы яшәтеп, бушка эшләтеп, йөз елга якын коммунизм белән алдадылар бит...

Аллаһы Тәгалә искиткеч камил дөньяны, унай, гүзәл табигатьле Җир шарын яраткан. Кешеләргә яшәү мәгънәсен аңлатырга пәйгамбәрләр, алар аша Коръән кебек аң-белем чыганакларын иңдергән. Мең ярым еллар элек, соңгысы итеп Мөхәммәд пәйгамбәр аша, Изге Коръәнне иңдергән. Киләчәктә кешелек үз алгарышын үзе тәэмин итәрлек дәрәҗәгә җиткәнлектән, ул соңгысы була. Кешеләрнең үсеш, аң-белемнәре югарылыгы, табигатьтәге урыны һәм башка изге тәгълиматларның асылына таянып, Коръән цивилизация үсеше куйган барлык сорауларга җавап табарга мөмкинлек бирә.

Ләкин гамәлдә кешелек дөньясының күп өлеше бу изге тәгълиматларның асылыннан тайпыла. Яһүдиләр Муса пәйгамбәр аша иңдерелгән изге Тора—Тәүратны Аллаһының сайлап алынган милләте, дөнья халыклары белән идарә итәргә хокукын исбатлый торган тәгълиматка әйләндерергә тырыша.

Гайсә пәйгамбәр аша иңдерелгән изге Евангелие—Инҗилнең дә асылыннан ерагаюлары шиксез. Христиан дине, бигрәк тә православие алтынга күмелде. Моны без Мәскәүдәге дини бәйрәмнәрдә йөзләгән кешенең миллионлаган сумлык алтыннан торган затлы киемнәреннән, алтынга күмелгән храмнардан күрәбез. Россия империясен милитар омтылышларга өндәп, башка халыкларның илләрен яулап алып юк итүгә керткән өлешләрен белгәч, аларның Аллалары кая микән, әллә аны алтын һәм чиксез властька омтылуга алышканнармы дип уйлый башлыйсың. Православие динендәге илләрнең дөнья үсешеннән байтак артта калуы, илдәге әхлакның бик түбән булуы яшәеш диңгезендә җилкәнсез калган көймәне хәтерләтә.

Изге Ислам диненә килгәндә дә шул ук хәлне күзәтәбез—ул хак динебезнең, җәмгыятьнең үсеш «җилкәне» булу вазифасын үтәми. Халкыбызның бөек затлары булган Утыз Имәни, Курсави, Зыятдин Камали, Әхмәтһади Максуди, Муса һәм Заһир Бигиевлар, Мәрҗани, Риза Фәхреддиннәр ислам дөньясын, ислам тәгълиматын, гарәп телен, мәдәниятен, тарихын, гореф-гадәтләрен тирәнтен өйрәнгән, аңлаган шәхесләр булганнар. Үзләренең бөек хезмәтләрендә Ислам динебезнең асылы, иң якты, иң мәрхәмәтле, җәмгыятьнең алгарышын, үзе яраткан адәм балаларына фани дөньяларында Аллаһы Тәгалә рухына туры килердәй, чиста, матур, бәхетле тормыш тәэмин итә алганын исбатлыйлар. Аның өчен шәригать кануннарының нигезендә Коръән, хәдисләр, кайчандыр бер килешенгән аңлатулар, чагыштырулар белән беррәттән, иҗтимагый тормыш чынбарлыгы, тарихи вакыйга сынаулары, тәҗрибәсе дә ятарга тиешлеген төшендерәләр. Ул заманнардагы мөселман дөньясының искиткеч артта калуына, ислам тәгълиматының дөньяви алгарыштан тайпылуына

каршы чыгалар, суфыйчылыкны киң таратып, халкыбызны алгарышка уяткан җәдитчелекнең нигезен салалар.

Болай да мең еллап үсеш алмаган шәригать кануннарына таянып, баш ватмыйча яшәп идарә итүче «мүкләнгән» дин әһелләре белән көрәшеп күтәрелә башлаган 20нче гасыр башы «Татар яңарышы» революциядән соң бөтенләй өзелә, большевиклар үз тәгълиматларын кертәләр, бөек затларыбызны, аларның хезмәтләрен юк итәләр. Уйнашчы әби патшаның ислам белән көрәшмәскә, аның белән власть куйган кешеләр аша идарә итәргә кирәк дигән сәясәтен истә тотып җитәкчелек итә башлыйлар, динне тар гына кысаларда яшәргә мәҗбүр итәләр. Миңа калса, ул кысалар бүген дә саклана шикелле.

Ике-өч ел элек Малайзия дәүләтенең ул чактагы премьер-министры Мөхәммәт әфәнденең бөтендөнья мөселман конгрессында сөйләгән, кайбер «дөнья хуҗалары» арасында зур тавыш куптарган чыгышын укыганым бар. Ул анда җаны көеп, 1,3 миллиард мөселман өммәтенең таркау, артта калулары аркасында башкаларның басып торуы, көрәш юлында алгарышны түгел, үзләренә күрсәтелгән гаделсезлеккә каршы террор юлын гына сайлавын ачынып сөйләде. Бүгенге дин әһелләренең еллар буе «мәчетләргә электр уты кертү шәригать канунына туры киләме» ише буш бәхәсләр белән шөгыльләнүе, изге Коръәннең асылына түгел, хәрефенә табынып, мөселман өммәтен дистә гасыр элеккеге гарәпләр тиңендә тотарга җыенуларын гаепләде.

Горурлыгыбыз булган мөселман өммәтенең дөньяда артуында, хак дин буларак ислам тәгълиматының кешеләргә «Алгарыш» кыйбласына әверелүеннән бигрәк, артта калган ярлы халыкларның югары артымы белән бәйләнгәнен онытмаска кирәк.

Бүгенге заманда Ислам дине, Ислам дөньясы зур сынаулар алдында тора. Аны кыргыйлыкта, наданлыкта, террорчылыкта гаепләү сәясәте бара, «кара көчләр» үзләренең бөтен байлыкларын, чиксез мәгълүмат тарату мөмкинлекләрен файдаланалар һәм бүген дөнья халыклары арасында күпмедер фикердәшләрен дә табалар.

Дөньяның биш миллиардлап халкының бүген бер миллиарды «алтын миллиард» санала. Алар дөньяны талап, үтереп, изеп, агулап үзләренә «җирдәге оҗмах» ясаганнар. Адәм балаларының тагын бер миллиарды бүген туйганчы ашый да, су эчә дә алмый—ачлыктан, ялангачлыктан шешенә, үлә, кара тормыш кичерә. Калган халыклар ничек кирәк шулай яраклашып, тормышын очын-очка ялгап яшәргә мәҗбүр.

Җир-анабыздагы шушындый гаделсезлеккә, алласызлыкка, ялганга корылган системага каршы бердәнбер көч булып бүген Ислам дине, Ислам тәгълиматы, алга киткән Ислам дәүләтләре генә тора ала. Шуңа да «кара көчләр» бөтен агуларын аларга юнәлтәләр.

Кайбер мисалларны китерәсем килә. Беренчесе—шәригать кануннарына, хәләлгә таянган ислам финанс системасы. Халыкларны талауга, алдауга көйләнгән, «кара көчләр» уйлап чыгарган, миллионнарны бер мизгелдә талаган көнбатыш финанс системасының соңгы кризисы ислам финанс системасына зыян китерә алмады! Шуңа да бүген ислам банкларын ачарга теләүчеләр бихисап.

Икенче мисал—Бангладештан Нобель премиясе лауреаты Мөхәммәт Юнисның яңа банк—кредит системасын булдыруы. Ул үзенең аз гына акчасы хисабына авылдашларына берничә долларлап кредит өләшә. Алар ул акчага йә берничә тавык, яки эш коралы сатып алып, азмы-күпме акча эшли башлыйлар, аларның өметсез тормышында нинди дер хәрәкәт башлана, күңелләре үсә, әкренләп аякка басалар. Шул гамәл аша миллионлаган Бангладеш халкы бүген төпле икътисад коруга ирешә, чөнки бу гамәлнең асылында изге Ислам кануннары ята. Ул банкларны америкалылар да бик кулай тапканнар.

Өченче мисал—төрекләрнең илаһи заты, бүгенге дөньяның иң атаклы философы Фәтхулла Гүлән. Ул үзенең гамәлләре белән изге Ислам диненең асылы булган бөек гуманизмны, кешелекне алгарышка этәрү бурычларын тормышка ашыра, мөселман өммәтенә якты караш тудыра. Дөньяның күп илләрендә, хәтта алдынгы көнбатышта,

Америкада да ачылган, искиткеч югары нәтиҗәләр белән эшли торган меңгә якын төрек лицейларының фәлсәфи нигезен булдырган дөньякүләм бөек шәхес. Тик без генә аларны саклый алмадык, «без булдырмадык»...

Минем уйлавымча, татар-төрки халыкларның шәригать кануннарында гарәпләрдән аермалылык булмыйча кала алмый. Әлбәттә, алар ислам дине нигезендә булырга тиеш. Безнен бабаларыбыз мең еллар буе Тәңрегә табынганнар—тәңре динендә булганнар, ә ул күп дин галимнәре аңлатмасында мәҗүсилек түгел, кешелек тарихында беренче бер аллалык дине булып тора. Тәңрегә табынып бабаларыбыз дистәләп бөек дәүләтләр төзегәннәр, Евроазия кинлекләренә һун-төрки цивилизациясен, мәҗүси европалыларга бер Аллага табынуны алып килгәннәр. Заманында безнең бабаларыбыз иң якты, чиста, халыклар тормышының ихтыяҗларына җавап биргән хак дин Исламны кабул иткәннәр. Тик меңнәрчә ел табынган, халыкларның яшәү рухына, рухи «матрицага» кергән тәңречелектән бөтенләе белән баш тартып, күбесенчә гарәпләр рухындагы ислам тәгълиматына гына күчү дөрес үк булды микән?

Минемчә, бүгенге көндә хак ислам тәгълиматының асылына таянып, аны үстерү максатында, татар-төрки мөселманнары биш мәсьәләне үзләренең тарихи хәтерләре нигезендә хәл итәргә тиешләр.

Беренчесе—тәңре диненең нигезендә булган әби-бабаларың рухы алдында җаваплылык, аларны рәнҗетерлек гамәлләрдән сакланып яшәү, алар алдында үзеңнең тормышың, кылган яхшы эшләрең белән мактанасы килү теләге, кылган начар эшләрең өчен оялу, алар рухыннан гафу үтенү—моннан да зур тәрбияви гамәл бармы? Бигрәк тә кешеләрнең фани дөньядан киткәч әти-әнисе, әби-бабалары, туганнары, гомер кичергән замандашлары белән күрешәчәкләрен, алар алдында да җавап тотарга туры киләчәген белү бүгенге яшәешне чистартмас идеме?

Бүген инде фән дә бөек галәм мәгълүмат кыры барлыгын нигездә таный. Мин шул кырда кешеләрнең рухын тәшкил иткән җаннары саклануына, аларның берберсе белән аралашу, исәннәрнең гамәлләрен күзәтүенә, лаеклы очракта аларның үз рәхмәтләреннән ташламауларына ышанам.

Икенчесе—Аллаһы Тәгалә яраткан искиткеч гүзәл табигатьле җир-суга, һәр халыкның үз тормышларында бәхетле тормыш кичерү өчен бүләк ителгән туган туфрагына изге хөрмәт. Юкка гына безнең борынгы бабаларыбыз ерак юлга чыкканда кесәләрендә һәрвакыт төркиләрнең изге туган җир кисәге булган дала әремен йөртмәгәннәр, аның туган җиргә алып кайту көченә ышанганнар. Моны мәҗүсилек дип атау белән килешеп булмый. Минемчә, без Тәңречелекнең бер нигезе булган бу изге төшенчәне бөек Ислам тәгълиматына каршы куярга да, югалтырга да тиеш түгелбез. Бүген фәнгә, һәр сулыкның, урманның, агач-куакларның, җан ияләренең, барлык тереклекнең үзенең нурланышы, тибрәнеше барлыгы билгеле. Кешеләрнең табигать белән гармониядә, изге мөнәсәбәттә булуы, аларның яшәешен, саклануын тәэмин иткән.

Тәңречелекнең бүгенге дәвамчысы утрау-дәүләт булган Японияда синтоизм исеме астында сакланып калган. Синтоизм бүгенге көндә дөньяда иң экологик дин дип санала, японнар иң бәхетле картлыкка ия булган халык, бездәгегә караганда 20ләп елга озаграк яшиләр. Нинди олы икътисади алгарышка ирешкән ил булуы белән бергә, үзләренең туган җирләренә, өлкәннәргә искиткеч карашлары белән дә аерылып торалар.

Аллаһыбызның яратып булдырган җир йөзен саклау безнең аның алдындагы олы бурычыбыз. Шуңа да җир-суларыбызның, табигатебезнең, тереклек дөньясының бүгенге аяныч хәле, аны саклау, яңарту—хак динебез, дин әһелләренең, барлык мөселманнарның яклавында торырга тиеш дип уйлыйм.

Чаллыдагы Әлфәс хәзрәт белән бер әңгәмә вакытында, Канадага безнең җәнлекләр циркы баргач, тимер читлекләре кечкенә булган өчен, аларга чыгыш ясарга рөхсәт бирмичә, читлекләрен тиешенчә зурайтырга мәҗбүр иткәннәрен, Скандинавия илләрендә, коллар хезмәтен кулланганга очсызрак булган Боливия кофесына байкот игълан ителүен сокланып сөйләгәч, аның, Исламның асылы шул инде, дигәне хәтеремдә.

Өченчесе—бүгенге ислам тәгълиматында милләтләргә, аларның саклануына, үсүенә булган битарафлык сизелә. Минемчә, беренче урынга милләтләр түгел, мөселман өммәте куела. Шуңа да дин әһелләренең бүгенге милли проблемалардан бик ерак торганлыгы күренә. Казаныбызның 40 мәчетендә кәсеп күрүче 60лап мулланың, меңләгән шәкертләребезнең, дәүләтебез, динебез җимерелүне искә ала, шәһит бабаларыбыз рухына дога кыла торган «Хәтер» көнендә, дөньяви пәйгамбәребез—изге Тукаебызны искә алу бәйрәмендә катнашмаулары, аларның фикер кимәле, тарихи, фәлсәфи, мәдәни үсешләренең түбәнлеген күрсәтә. Ә бит 90нчы еллар күтәрелеше заманында безнең дин әһелләребез халык белән бергә иде, милләт, динебез күтәрелеше өчен бергә көрәштеләр...

Шунысы аңлашылмый, бер-ике буыннан соң, татар телен, мәдәниятен белүче калмаса, аларның вәгазьләрен кем тыңлар? Урысчага күчәрләрме? Мөселман өммәтен киңәйтүгә генә омтылу, шул ук «Пролетарии всех стран соединяйтесь»ны хәтерләтмиме?

Бүген авыл саен бишәр мәчет ачсаң да, күркәм Кол Шәриф мемориаль-музееен төзесәң дә куркыныч түгел, төзе генә, ә менә милли мәктәп, төрек-татар лицее тотарга, милли университет төзергә—«не сметь». Бу хәлләр дә динебезнең милләт проблемаларыннан ераклыгын, югары даирәләребезнең максатына туры килгәнлеген күрсәтә.

Дүртенчесе—дәүләт, барлык хокук мәсьәләләрен аңлатучы мөселман сөннәтенең дә нигезенә күбрәк гарәп халыкларының тәҗрибәсе салынган. Нигә бүген көнбатыш илләрдә халыклары өчен хөррият, алгарыш китергән, гражданлык җәмгыяте, демократия төзергә мөмкинлек биргән кануннарны, халкыбызның үсеш югарылыгын истә тотып, үзебезгә яраклаштыра алмыйбыз?

Бишенчесе—Изге Коръәнне, пәйгамбәребезнең хәдисләрен, мөселман сөннәтен, күбесе гарәпләрнең гореф-гадәтләренә нигезләнгән шәригать кануннарын аңлатудагы, кешеләргә җиткерүдәге гафу ителмәслек торгынлык. Ничә йөз еллар буе, асылын, эчтәлеген дөрес аңлыйсы-аңлатасы урында, бер китаптан икенчесенә күчереп язу белән шөгыльләнәләр. Шуларның кайберләрен китермичә кала алмыйм.

«Ярым уяу, ярым йокы хәлендәге Адәм галәйһис-сәламнең сул як кабыргасын алып,аңардан Хәуваны бар иттеләр». Йөз ел элек бөек шәхесебез Муса Бигиев үзенең «Озын көннәрдә ураза» язмасында Коръәннең унлап аяте нигезендә моның дөрес түгеллеген, Хәүва анабызны, хатын-кызларны кимсетә, Коръәннең асылына каршы килә торган шөгыль, дип язган. Хәүва белән Адәмнең бер пар булып яратылуын исбат итә. Пәйгамбәребезнең шундый хәдисен китерә. Хатынының буйсынмавына зарланып ярдәм сорап кергән бер күршесенә: «Хатын-кызлар алар кабыргадан (кабыргадай кәкре итеп) яратылганнар, аның башыннан, иң кәкре җиреннән, шуңа күрә аларны төзәтергә азапланмагыз, сындырырсыз. Булганча кабул итсәгез ялгышмассыз, кешеләр белән шәфкатьле булыгыз»,—ди. Күргәнегезчә, нәзек, нәфис, катлаулы конфигурацияле кабырга сөяге белән чагыштыру гына бар. Тик һаман да иске аңлатманы сөйли, яза бирәләр.

«Язмыштан узмыш юк» психологиясен сеңдерү, кешеләрнең «винтик» кенә булуларына, алардан берни дә тормаганлыгы, алар өчен язмышлары инде күптән язылган булуы, кешеләрнең битарафлыгына, эшләгән тискәре гамәлләрен язмыш белән генә аңлатуга китерә. Бу тәгълимат та шул кешеләрне буйсындырып тоту өчен, фани дөньяда алгарышка, бәхеткә омтылучы затларның рухи иреген йөгәнләр өчен эшләнмиме?

Бүген дә хезмәт ияләренең өстен катлауга, хакимият ияләренә каршы көрәшүләре гөнаһ дип саналуы, явызлык эшләгәннәрнең бары тик Аллаһы Тәгалә каршында гына җаваплылыгы, хәзрәтләребезнең һәр вәгазьләрендә җитәкчеләргә буйсынырга тиешлегебезне тәкрарлау Изге Коръәннең асылына туры килә микән? Ә бит Аллаһыбыз кешеләрне рухи ирекле итеп яраткан, үзе алдында гына тезләнергә, аңа гына табынырга кушкан, изге Коръән китабы шуннан башлана. Сәясәтче Гейдар Жамал бу үгет-нәсыйхәттә, халык үзе сайлаган, кабул иткән, аның өчен игелекле гамәлләр кылучы, алгарышка алып баручы милләт лидерлары булган җитәкчеләргә генә буйсыну турында әйтелүен күрсәтә.

Гыйбадәт төшенчәсенә дә бер төрле мәгънә бирергә кирәктер. Һаман да китаптан китапка гыйбадәтне Ислам тәгълиматында каралган биш вакыт намаз, ураза тоту, мөмкинлек булганда хаж кылу һәм Аллаһы Тәгаләгә табынуның башка гамәлләре белән генә чикләү дөрес булырмы? Бүген дә дин әһелләренең кешеләрнең тормыш гамәлләрен шулар аша гына бәяләүгә омтылышы сизелә. Минемчә, бу мөселманнарга тиешле булган гамәлләр, кешеләрне изге Ислам диненең асылына китерү, кешеләрне изгелекләр кылып яшәүгә этәрү өчен каралган.

Шуның мисалы итеп 3-4 ел элек бер абзыйның газетада чыккан язмасын искә аласы килә. Анда ул үзенең ничек Ислам кушканча яшәве, бөтен шартларын үтәве белән горурланып яза. Аның өчен шатланабыз әлбәттә, тик аның бөек милләттәшләребез, бигрәк тә Рудольф Нуриев турында әйтелгән пычрак сүзләрен кабул итеп булмый. Ул анда югары сәнгатьне, балет сәнгатен күрмәгән, аңламаган башы белән, Р. Нуриевның дөнья сәнгатенә, тамашачыларына чиксез зур рухи байлык биргәнен, милләтебезнең даның күтәрүдә керткән өлешен белмичә, үзенең хөкемен чыгара, аны тәмугка билгели. Күз алдына китерү дә авыр—Фонтейн белән Нуриевны бер балет спектакленнән соң, ялгышмасам, бер сәгатькә якын, 76 мәртәбә бис белән чакырып алкышлыйлар, бу Гиннес китабына иң бөек казаныш булып кергән, Адәм затының нинди камиллеккә, югарылыкка менә алуын күрсәткән, кешеләрне барлыкка китерүче Аллаһы Тәгаләгә изге хезмәт.

Андый, башына түбәтәй киеп, яулык бәйләп алган, өч дога ятлаган «хөкемдарлар» күп очрыйлар. Берәүләре оҗмахка билет кына сатмый, икенчеләре исә каргый-каргый тәмугка «җибәрә»—Аллаһы эшенә кысылырга күп сорамыйлар, гөнаһтан да курыкмыйлар.

Азмы хәзер дин тирәсендә кәсеп ясаучылар?! Кайбер дин әһелләре хәтта кәсепчеләрне хәтерләтә. Олы кайгылар белән эшләре төшеп, дорфалыкка, кеше гозеренә игътибарсызлыкка тап булганнар азмы бүген? Үзебезне, халкы нинди, мулласы да шундый, дип кенә тынычландырсак инде.

Ике олы яшьтәге әби бар иде. Икесе дә бик укымышлы, догаларны, Коръәнне яхшы белүчеләр, гомерләре буе биш вакыт намаз укыганнар, үзләре белгәннән бирле ураза тотканнар, инде алар мәрхүмәләр, иншалла, урыннары оҗмахта булыр.

Тик алар икесе ике төрле иде. Берсе кырысрак, шаярган балаларны да «бисмилласыз ясалганнар» дип сүгүчән, җырлау, уен-көлке дә ярамый, каргарга да мөмкин иде. Ә икенчесе сәнгатьне дә аңлаучы, яратучы, кешенең хәленә керә белүче, гайбәтсез, ярдәмчел, ачык күңелле, бик сабыр иде. Мәрхүмәне озатканда да авыл халкы эч серләребезне аңа гына сөйли идек, якын киңәшчебездән башка нишләрбез инде дип елады.

Минемчә, төрле авырлыкларга, изелүгә түземлегебез артык чиксез булса да, безгә бүген кешеләргә, аларның гамәлләренә бәя биргәндә сабырлык җитми. Киресенчә булуы хәерлерәк, иманлырак булыр иде минемчә.

Кешеләрне тыеп торган гөнаһ төшенчәсенә килгәндә, фани дөньяда яшәгәндә без аның тулы мәгънәсен, җитдилеген аңлап бетермибез. Байтак язмышларны күргәнлектән, күп кешеләр үзләренең кылган гөнаһлары өчен җирдәге тормышларында ук җәзаларын алалар дип уйлыйм.

Тәңречелекнең дәвамы булган синтоизмда гөнаһ урынында оят төшенчәсе дә кулланыла. Анда гына түгел, башка байтак халыкларда, бигрәк тә протестантизм таралган илләрдә, оят төшенчәсенең универсал, бик тә үтемле, тормышчан булуы билгеле. Мәсәлән, хәерче булу оят, чөнки алардан ни Аллага, ни муллага, ни халыкка. Шул ук вакытта хәерче халык арасында бай булу, байлыгың белән мактану, купшылану оят. Надан, шапшак булу, үзеннең тарихыңны, мәдәниятеңне, бөек кешеләреңне, нәселеңне белмәү, милли телеңне, аның сәнгатен белмәү оят, динеңне санга сукмау оят.

Безнең халыкка да гөнаһ төшенчәсе белән бергә оятны кертү файдалы булыр иде: халыктан оят, кешеләрдән оят, күршеләрдән оят, авылдашлардан оят, әти-әнидән, туганнардан, балалардан, хатыннан, дуслардан, танышлардан,

укытучылардан оят, хәзрәттән оят һ.б, һ.б. Шушы оят хисе Амстердамның мэрын эшкә велосипед белән йөртә, дөньяның иң бай саналган Америка миллиардеры 1956 елда төзелгән зур булмаган йортта яши, гади киенә, гади туклана, бу аның саранлыгы түгел, яшәеше шулай. Табышының күп өлешен хәйрия фондларына сарыф итә.

Бездәге халыкның күзенә кереп торган, нәфрәтен уяткан, ике-өч кеше яши торган «хоромнар», вагон чаклы машиналар һәм башка байлыклар, шыксыз, байлыкка күмелгән кабинетлар, офислар тотуны гөнаһ төшенчәсе белән бәяләү авыр, аларның күбесе мәчетләр салганнарын да искә алыйк. Моны тик оятсызлык белән генә аңлатып, оятсызлык өчен генә гаепләнүе мөмкин.

Шулай итеп, Оят факторы кешеләр аңында тиешле урынын алса, үзен-үзе көйли, үзен-үзе төзекләндерә, үзен-үзе савыктырып яши торган җәмгыять була. Аллаһы Тәгаләбездән, пәйгамбәрләр җибәрүдән туктап, кешеләргә үзләренең җәмгыятьләрендә үзләренең үсешләрен, матур, бәхетле, тигез тормышларын үзләре тәэмин итү бурычы куелган бит.

Ислам дине тәгълиматын халыкка җиткергәндә һаман да шул 14 гасыр элеккеге мисаллар китерелә. Мәсәлән, оҗмах турында—анда сине хур кызлары көтеп торганы, искиткеч матур җиләк-җимешле бакчалар, саф, салкын сулы чишмәләр—болар барысы да, гомеренә хатын-кыз заты күрә алмыйча, үзләренең хуҗаларының гаремнарына кызыгып яшәгән, туйганчы ашарына булмаган, салкын чишмә суына тилмергән гарәп бедуиннары—көтүчеләре өчен мәңгелек хыял булгандыр, аларны мөселманлыкка китерүдә унай шарт булгандыр. Ләкин 21нче гасырда һаман шуларны сөйләү дөрес булырмы? Бигрәк тә хур кызлары турында. Бу бит ир белән хатын кыз арасындагы мөнәсәбәтне хайваннар түбәнлегенә төшерә. Нигә соң оҗмахта сез яраткан хатыннарыгыз, ирләрегез, сөйгән ярларыгыз, туганнарыгыз, дусларыгыз белән бергә булырга тиеш түгел? Бу очракта ул изге динебезнең асылына туры килер иде.

Тәмуг мәсьәләсендә дә дөрес итеп аңлыйсы, аңлатасы әйберләр бар. Мәңгелек тәмугта яндырылуны акыл иясе, дин галиме булган Муса Бигиев үзенең төпле хезмәтләрендә ачык итеп күрсәткән. Бер мизгел генә фани дөньяда яшәгәндә кылган гөнаһлары өчен кешеләрне мәңгелек тәмуг утында яндыруны чиксез мәрхәмәтле Аллаһыбызның, Исламның асылына туры килми дип исбат итә ул. Тагын бер ягы бар— бик көчле физик тәэсир булганда—олы имгәнүләр, янгыннан яки башка бик көчле эчке авырудан, кешенең тереклеген мөмкин кадәр саклау өчен каралган шок—аңын югалтып, баш миенең, гармональ системасының эшчәнлеген саклап калу механизмы бар. Мин моны табиб буларак та, үлеп бетә язган кеше буларак та ышандырып әйтә алам. Юкка гына «Мин сезгә үзегез күтәрә алмаслык авырлык бирмәм» диелмәгән изге Коръәндә. Тик фани дөньяда кешеләргә бирелгән искиткеч гуманлы чыдамаслык авыртудан саклау механизмы алар мәңгелеккә кучкәч тә сакланмасын, ди.

Ә менә ачы җан ярасыннан тилмерүгә андый механизм каралмаган. «Тән ярасына түзеп була, җан ярасына түзеп булмый» дип юкка гына әйтелми бит. Кылган гамәлләрен өчен үкенү, оялу, гарьләнү тойгысы кайчак кешенең гомере буена бара, кешеләр ул авыр тойгыларын олы яхшылыклар эшләп кенә җиңеләйтә алалар. Бәлкем, тәмуг ул утта яну түгел, ә җирдә яшәү чорында кешенең ярлыкагыл ителмәгән олы гөнаһлары өчен җаннары өзгәләнүдер?

Мәчетләребездә якты бәйрәмебез Корбан гаете намаз-вәгазьләрендә, ел саен корбан чалуның зарурлыгын аңлатканда, Ибраһим пәйгамбәрнең Аллаһыбыздан сорап алган баласы җиде яшкә җиткәч, төшендә Аллаһ тарафыннан шул баласын корбан итеп чалырга боерылуы, баласының бик риза булуы, үзенең кинәшләрен бирүе, чалырга җыенганда аның урынына җәннәттән зур бер тәкә пәйда булуы турында бәйнә-бәйнә сөйләнә. Бу мисал 14 гасыр элеккеге чор өчен алай кыргый да тоелмагандыр, корбан чалу, хәтта кешеләрне дә, гадәти күренеш булган. Минемчә, бу гамәл метофора—Аллаһыбызга чиксез тугрылыкны күрсәтү алымы гына. Малаемның аптыраганнан бирелгән соравына шулай дип җавап бирәм.

Корбан чалуга килгәндә, тагын бер мәсьәләне күтәрмичә кала алмыйм. Минемчә,

корбан чалуны мәжүсилеккә якын булган Аллаһы өчен корбан чалу түгел, Аллаһыбыз мәгъкуль күргән, аның рәхмәтенә ирешү өчен булган хәйрия гамәле итеп карау Исламның асылына турырак килер иде.

Мәчетләребез янында корбанга бәрәннәр сатуны оештыру әйбәт гамәл, мөмкинлегенә карап сайлап алып та була, бәяләре дә унай, шул ук вакытта кайбер затлар чагыштыру булмаганда 10 килолы бәкәйләренә биш мең сорарга да тарсынмыйлар, корбан бәйрәменнән зур файда эшләү ягын карыйлар.

Күңелдә ризасызлык тудырганы—мәчет янында корбанны чалу, эшкәртү урынының көйләнмәвендә. Күрсән, сарык көтүенә бүреләр кергән сымак, агач араларында, сарай артларында берьюлы дистәләгән кеше корбан чала, кем ничек урын таба, шуна асып эшкәртә. Юкка гына анда гаеп эзләп бер көтү журналистлар йөрми, соңыннан безне кыргыйлыкта гаепләргә тырышалар. Ә бит ул урынны чистартып, чалу өчен бер палатка куеп, эшкәртү өчен элгечләр белән арата кую зур чыгымнар да сорамый. Фатирларда яшәүчеләр өчен дә бик уңайлы гамәл булыр иде.

Халкыбызның гореф-гадәтләренә килгәндә, шул ук гарәпләр тәҗрибәсенә таяну саклана. Күптән түгел бер абзыйның, кыш көне хатынымны җирләдем, күмгәндә мәетенең астына камыш салырга авылның мулласы рөхсәт итмәде, хатыным мина бик салкын дип төшемә керә дип өзгәләнеп язган соравына, бик «укымышлы» хәзрәт, гарәпләрдә андый гадәт юк дип җавап биргән иде. Тик ул укымышлы гарәпләрнең мәетне эссе комга салганнарын, ә бездәге салкын кышларда бозлана башлаган коры җиргә салынганын искә алмый. Камыш бит алтын белән чиккән берәр ятак түгел, Аллаһыбыз яраткан табигый үлән. Гарәпләрдә ком белән тәһарәт алу да каралган, бәлкем, безгә дә комга күчәргәдер?

Ураза тотуга багышланган ТНВдагы тапшыруда да, бер яшь ананың, «бала имезгәндә ураза тоту тиешме дип соравына, бер хәзрәтнең ык-мык килеп, тота алсагыз тотыгыз, алай мәҗбүри түгел» дигән җавабы да бик сәер тоелды. Ул ничек итеп 17шәр сәгать буе ашамаган-эчмәгән анага бала имезергә кушадыр. Ананың соравы артында «без яшь чакта бала да имездек, урак та урдык, «ничу» уразаны калдырырга» дип торучы усал биеме, биатасымы тору мөмкинлеген онытa.

Әниемнең сугыш вакытында, итәк тулы балалар белән калып, ачлы-туклы челләдә урак урганда ураза тотулары, башлары әйләнеп егылырга җиткәч, чишмәгә төшеп кипкән авызларын чайкаулары, ул вакытта йотылгандыр инде дип кайгыруы хәтеремдә. Тормыш итү өчен тиешле булган авыр эшләр башкарганда ураза тотуның мәҗбүри булмавын аларга аңлатмаганнар. Бер яктан, колхоз эшенә чыгып норманы үтәмәсәң Гулаг торган, икенче яктан, салкын келәттә чәй эчеп ятучы муллалар.

Мин бу мисалларда дин әһелләребезнең Аллаһыбызның киң мәрхәмәтен бөртекләп кенә өләшү теләген, урысчалап әйтсәк, «не пущать»ны гына күрәм.

Бездә, кешенең кайчан үлүенә карамастан, муллалар кушуы буенча иртән үк җирләү гадәте бар, күп очракта хәтта якыннары кайтканны да көтмиләр. Сугыш кырларында һәлак булганнарны, гарәпләрнең мәетне эссе чүлдә тиз генә күмүләре аңлашыла, мин алар турында түгел.

Чаллыда эшләгәндә Түбән Кама сусаклагычы булачак урыннарда зиратлар күчерү белән шөгыльләнгән бер кешенең сөйләвен ишеткәнем бар. Аның сөйләвенчә, татар зиратларында алар мәет сөякләренең борылып ятуларына, хәтта башларының икенче якта булуларына тап булганнар, димәк ул кешеләр тере килеш күмелгән булганнар. Чыннан да кайбер очракларда кешенең үлеп беткән булуын белү җиңел түгел. Чакырылган табиблар да, фельдшерлар да ялгышырга мөмкин, аны тикшерү җиһазлары белән генә анык билгеләргә мөмкин. Шуны да истә тотып патологоанатомнар (үлгәннән соң ярып тикшерүче табиблар) мәет суынып бетмичә, бер тәүлектән дә иртә мәеткә тимиләр. Ә без таң алдыннан вафат булганны да төшкә чаклы илтеп күмәбез, мәшәкатен киметәбез. Мин бу очракта христианнарда кабул ителгән, мәетне өч төн өйдә кундырып, кешечә аның белән саубулашу гадәтен күбрәк хуплыйм.

Инде күмгәннән соң чардуган, истәлек ташы кую турында да һәрвакыт бәхәсләр

туа. Бер мулланың кеше үлгәч ул сезнеке түгел, Алла кулына күчә, шуна күрә гади агач чардуганнар гына булырга тиеш, бернинди ташлар да ярамый, китап кушмый дигәнен ишеткәнем бар. Ата улны, ана кызны белмәгән, манкортлык кин таралган заманда, үлгәннәребезнең истәлегенә мондый карашны анлап булмый. Әби-бабаларының рухларына олы хөрмәт, хәтер сакламаган гаиләләрдә чын йөрәктән Аллаһыбызга табына башлауларына бик ышанасы килми. Минемчә ХӘТЕРНЕ фарыз булган изге гамәлгә тинләргә кирәктер.

Еш кына күркәм гомер иткән, балаларына зур дәүләт калдырып киткән кешенең өч тиенлек чардуганын, куйган истәлек ташыннан балаларының игелексезлеген күрәсең, шул Хәтерләренә карап, нәселләренең киләчәкләрен, үзләрен нәрсә көткәнен күз алдына китереп була.

Шулай ук, мөфти-хәзрәтләребез бик теләп телевидениедә, фоторәсемнәргә төшкән заманда, Коръән укырга җыенган бүлмәдә бөтен әти-әни, әби-бабаларның, сугышта һәлак булганнарның рухына дога кылганда, аларның фоторәсемнәрен алдыру яки каплау, зираттагы кабер ташларына рәсемнәр куюны тыярга тырышу да—шул «мәчеткә электр лампасы куярга ярамый»ны хәтерләтмиме? Ул истәлекләр исәннәр өчен кирәк. Авылыбызның, үзем озак еллар эшләгән Кукмараның зиратында йөрергә яратам. Рәсемнәрен күреп үзләре белән очрашкандай буласың, аларга карап яхшылыкларын искә аласың, гаебеңне тойсаң, гафу үтенәсең, бәхиллек сорыйсың, рухларына дога кыласың. Зират бит ул үткән тормышыңны барлау, аның мәгънәсен аңларга тырышу урыны.

Бүгенге милләтебезнең бәлаләре булган таркаулык, хәтерсезлек, хокуксызлык шуның күрсәткече. Балаларыбызга милли белем бирә алмау, дәүләтебезне югалтканда шәһит киткәннәргә һаман да хәтер истәлеге куя алмау, Болгарыбызның тарихи җирендә кешеләрнең ханнар мәчетенә терәп дигәндәй дуңгызлар асравы, изге Тукаебыз яшәгән «Болгар» номерларын җимерүебез, халкыбызның эчкечелек, тәртипсезлек, фахишәлек юлына басуы, динебездә, яшьләребез арасында төрле секталарга таралу, радикаль төркемнәр оешу һәм башка күңелсез гамәлләр дин әһелләренең, дини тәгълиматның бүгенге көн сорауларына җавап бирә алмавында. Болар барысы да милләтебезне түбәнчелеккә төшергән «җилкәнсез» калуның нәтиҗәсе. Аны күтәрү өчен изге Исламыбызның асылына кайту кирәк, ул чагында инде мәчетләребез дә бүгенгедәй буш тормас иде.

Кемнәргәдер көферлек булып тоелачак бер фикеремне әйтмичә калдыра алмыйм. Мин бүген шәһәрләребездә чат саен, авылларыбызда икенче, өченче мәчетләр, мәдрәсәләр ачуны безнең иң зур казанышыбыз дип санамыйм. Болай да 6-7 бабай йөргән мәчет янына тагын 3-4 бабай йөриячәкне төзү кирәк микән? Беренчедән, алар күбрәк аерым дин әһелләренә «эш урыннары» булдыруга гына каралган, икенчедән укытулар оештырылса да, гарәп телендә догалар ятлаудан узмыйлар, хакимиятләрнең халыкны шул тар киртәләр эчендә тоту сәясәтенә генә хезмәт итәләр дип уйлыйм.

Туган телләрен, милләтләрен онытканнарның ихлас күңелдән Аллаһы Тәгаләгә, иманга килүләренә мин ышанмыйм. Шуннан чыгып халкыбыз, шулай ук дин әһелләре алдында да телебезне, милләтебезне саклау, аны үстерү мәсьәләләре торырга тиеш. Моның өчен мәчет санын арттыру түгел, халкыбызның булган матди мөмкинлекләрен җыйнап, төрекләр тәҗрибәсендә һәр район үзәгендә, шәһәрләрдә Россия укыту системасындагы мәктәпләр каршында, бары тик хәйрия акчасына яшәүче бушлай интернат-тулай тораклар оештыру кирәк. Шулай ук аерым урта, югары белем алучы студентлар өчен дә. Ул тулай торакларда чын татар мохите булырга тиеш—татар телен укыту, татар югары мәдәниятендә тәрбияләү, Ислам дине нигезләрен бирү һәм халкыбызның бөек дин галимнәре Муса Бигиев һәм башкаларның тәгълиматларын өйрәнү дәресләре булдыру зарур. Чөнки урыс илендә безгә үзебезнең мәгариф системасын булдырырга мөмкинлек бирмәячәкләре күренеп тора, моның ачык мисалы булып милли телебездә укытуның буылуы, татар-төрек лицейларының бетерелүе, милли университет булдыру идеясен фикциягә әйләндерелеп калдырылуы тора. Инде мәктәпләрдә укыту процессына йогынтыбызны югалтканбыз икән, укучыларның дәрестән соңгы вакытларын

алгарышка юнәлтелгән милләт балалары итеп тәрбияләү мөмкинлеген сакларга тиешбез. Менә, йөз еллар буе татарны саклап калган, үстергән, бер тиен урыс патшасыннан акча алмыйча, кече һәм олы мәдрәсәләр тоткан халкыбыз мисалы тора. Безгә дә, булмаячак иманны дәүләттән көтеп ятмыйча, шул юл турында уйларга вакыттыр.

**P.S.** Минем озаккарак сузылган уйлануларымны дөрес аңламыйча, көферлектә гаепләп мәңгелек тәмугка билгеләүчеләр дә булыр. Беренчедән, ислам шәригатендә иҗтиһат—үзенчә фикер йөртү, уйлану төшенчәсен беркем дә юкка чыгармаган. Икенчедән, горурлыгым булган бер гамәлемне язып китәсем килә. Тукай районының 1997 елда ачылган яңа хастаханәсендә мәчет һәм чиркәү бүлмәләре ясадык, аларны бик зәвыклы итеп, бөтен дин канунарына туры китереп, талантлы яшь художник, ул вакытта әле студент—Булат Фаил улы Ибраһимов башкарды. Андый гамәлләр юк кына түгел, алар турында уйларга да курыккан заман иде әле. Бүген ул түрәләребез мәчетләр ача, рәхмәт аларга. Мина ике олы каршылыкны җиңәргә туры килде. Берсе—Чаллы атакаеның чиркәү бүлмәсендә «службалар» уздыру, анда үзләренең кибетләрен булдырырга рөхсәт бирмәгән өчен нык ачулануын. Икенчесе—үзебезнең министрнын эштән куу белән янап, аларны япыруны таләп итүе. Чиновникнын «как бы чего не вышло»сын, үзенең кәнәфиен югалтудан калтырап торганын аңлыйм. «Әллә 37нче елга кайттыкмы, мин эшләгәндә алар эшләячәк, мин аларга кул күтәрергә бирмәячәкмен, алардан файдадан башка беркемгә дә зыян юк, бик телисез икән, мине эштән алыгыз»,— дип, каты сөйләшергә туры килде.

Аллаһы йортлары-бүлмәләрен ачу ул безнең үсеш юнәлешенә салынган иде. Беренчесе. Кешеләрнең яшәү рәвешләрендәге начар күренешләр белән бәйләнгән сәламәтлеге какшавы. Авыру вакыт—кешенең Аллаһыбызга иң якын торган, уйланырга, офтанырга, үкенергә теләге туган чагы. Күңеле нечкәргән чагында шул изге яктылыклы бүлмәләргә кереп, үзенә Аллаһыбыздан кылган начар гамәлләрен кичерүне, аңардан исән-сау калуда ярдәм соравы, христианнарның шәмнәр куюы, кешенең иманга килүендә бик зур адым булып тора.

Икенчесе—дәваланучылар арасында, үзебезнең хезмәткәрләр—табиблар, шәфкать туташлары арасында намазга басучылар булуы, аларның почмакларга качып-посып намаз укырга мәҗбүр ителүе иде. Өченчесе—хастаханәбездә Аллаһы йортлары булу, хезмәткәрләрнең рухын чистарту, аларны иманлырак итү, күрсәтелгән медицина ярдәмен изгелек эшләүгә тиңләүгә өндәү, икенчерәк мәгънә бирү, шуның аша авыруларга карашны тәрбияләү иде. Олы дини бәйрәм көннәрендә авыруларны коймак белән сыйлау, мөхтәрәм Әлфәс хәзрәтнең догаларын, вәгазьләрен ишеттерү безнең хастаханәнең дәрәҗәсен күтәрә иде, авыручылардан олы рәхмәтләр ишетә идек. Безнең ул гамәлләрне Ходай Тәгаләбез кабул итсен.

# Фирдәвес Гарипова

## АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Каенлык

Каенлык авылы Буа районында, район үзәге Буа шәһәреннән 16 чакрымда, җирле үзидарә советы Күл Черкене авылыннан 5 чакрым ераклыкта, Татарстанның көньяк-көнбатыш тарафында урнашкан.

Тарихи белешмәдә авыл ул (1359 ел мәгълүматлары буенча) Кайнык дип искә алына. Кырланлы суы ярына утырган бу авылның 109 йортында 349 ир-ат һәм 296 хатын-кыз көн күргән, мәчет эшләгән.

Авыл оешу турында авыл аксакаллары болай дип сөйли.

Мәмәтхуҗа дигән авылда яши торган өч кешенең үгезләре югала. Үгезләрен эзли-эзли, алар шушы урынга кадәр килеп җитәләр. Үгезләрен табалар да, киртәләр кисеп карда ясап, үгезләрен калдырып кайтып китәләр. Аннары авылдашлары белән киңәшкәч, бу матур урынга килеп утыралар. Үгезләр читкә китмәсен өчен ясалган карда каен агачыннан булганга, халык телендә Кайнык киртәсе—Кайынлык киртәсе дип аталган топоним сакланып калган. Каен күп үскәнгә авыл да Каенлык исеме алган. Бераз соңрак халык авыл оешкан беренче урынны калдырып, ярты чакрым җиргә, тау астына күчеп утырган. Авылның беренче нигезләнгән урыны халык телендә Иске йорт яки Кайнык киртәсе (Каенлык киртәсе) исеме алган. Иске йорт урыны Урман тавы башында.

Хәзерге вакытта авыл бер яктан катнаш урман, ә икенче яктан нарат урманы белән әйләндереп алынган. Авыл кырыеннан Зөя елгасы ага. Ул Иделгә килеп кушыла. Авыл Инеше Зөягә ялгана.

Авылны нигезләүче бабайлар табигатьнең бик матур урынын сайлаганнар. Аның янында елга-инешләр, күлләр, сазлыклар, ышна-басулар, тау-калкулыклар, печәнлек һ.б. күп.

### Кибәч

Кибәч авылы Питрәч районында, район үзәге Питрәч авылыннан 54, Казаннан 66 чакрымда урнашкан.

Кибәч атамасы тарихи белешмәләрдә шактый искә алына.

XVIII йөз мәгълүматларын үз эченә туплаган белешмәдә (Д.А.Корсаков) күрсәтелгәнчә, Кибәче авылында 122 керәшен татары көн иткән.

Авылга ни өчен Кибәч дигән исем куйганнар? Олылар бу турыда болай сөйли. Авылның Түбән очында сазлык (күл) булган һәм ул бик озак вакытлар бер дә кипмәгән. Ә бер вакыт кешеләр аның кимегәннән-кими баруын сизә. Бу күл янына килгәч кибә ич, кибә ич дия торган булганнар. Шуннан соң авылга Кибәч исеме кушылган, сазлык

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

та кибеп беткән. Билгеле, бу халык этимологиясенә нигезләнгән фараз гына.

Авылның урта бер жирендә тирән елга бар. Ул Югары очтан Түбән очка таба юнәлгән. Аны Бала елгасы дип йөртәләр. Кайчандыр, бик көчле язгы ташу вакытында көчле агым бер баланы агызып алып китә, аны беркем дә коткарып кала алмый. Хәзер бу елга тагын да тирәнәйгән. Авыл кырыенда тагын Захар, Аю, Кызлау, Әтрәч елгалары ага. Захар елгасында, кайчандыр, Захар исемле кеше баткан һәм елганы аның исеме белән атаганнар. Авыл кырыенда гына чишмә бар. Аны Кыр чишмәсе дип атыйлар.

Авылның тирә-ягында калын урманнар. Сәрдә, Әби, Кәжүнни, Нарат, Кормаш урманнары. Әби урманы атамасын жирле халык болай аңлата. Урманга әби алпавыт хужа булган. Ул усал карчык булып, һәрдаим атка атланып йөргән, бер генә кешене дә урманга рөхсәтсез кертмәгән.

Авыл зур түгел, хужалыклар саны 160тан артмый. Халыкның күпчелеге—карт-карчыклар. Авыл йортлары чәчелеп утырган, таркаулык күзгә бәрелә.

Авылдан бер чакрымнар ераклыкта керәшен зираты бар. Зиратның тирә-ягы тотып алынган. Елга ике тапкыр (яз һәм көз көннәрендә) халык зиратка бара. Анда барыр алдыннан һәр кеше мичкә яга, төрле тәмле әйберләр пешерә. Шул ризыкның бер өлешен табакка тутырып, махсус ашъяулыкка төреп зиратка алып баралар, һәр кеше туганының кабере янында ризык чәчеп-түгеп аны искә ала. Баштарак барып кабер өсләрен чистарталар, себерәләр. Зиратка барыр алдыннан мунча ягып керәләр, чөнки зиратка ак һәм пакь килеш бару зарур.

## Киекле

Киекле авылы Нурлат районында, район үзәге Нурлат шәһәреннән 16 чакрымда, Чистайдан 102 чакрым ераклыкта урнашкан.

Киекле атамасы байтак тарихи белешмәләрдә искә алына.

XVIII йөз мәгълүматлары теркәлгән тарихи белешмәдә күрсәтелгәнчә, Бормәт авылында (Киекле авылы икенче төрле Бормәт дип тә йөртелә) 176 ясаклы татар яшәгән. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә билгеләнгәнчә, Олы Чирмешән суы ярына утырган Бормәт (Киекле) авылындагы 198 хужалыкта 591 ир-ат һәм 593 хатын-кыз көн күргән, мәчет эшләгән.

Олылар авыл оешуны болай сөйлиләр. Элек бу урыннарда беркем дә яшәмәгән һәм монда кара урман үскән. Казанның аргы ягындагы Тау иле авылыннан Бормәт, Корман һәм Богдан исемле өч кеше бу урынга килеп, урнашырга урын карый башлыйлар. Богдан чуаш була, ул таудан соң бераз баргач, тигез урынны сайлап йорт төзи, авыл нигезли. Бу авыл исеме Богдан бабай хөрмәтенә Богдашкино дип йөртелә. Бормәт бабай таудан бераз баргач елга буенда тигез урынны ошата һәм Бурмәт авылына нигез сала. Корман бабай Корманай авылын оештыра.

Хәзер авыл Киекле дип йөртелә. Бормәт исеме урысча вариантта Бурметьево рәвешендә кулланыла.

Ни өчен Киекле дип? Олылар әйтүенә караганда, бу тирәләрдәге урманнарда төрле-төрле киекләр күп яшәгән, шуңа нисбәтле рәвештә авыл Киекле дип йөртелә башлаган.

Авылдан якын гына Зур Чирмешән елгасы агып үтә. Анда элек 6 ташны әйләндерә торган зур су тегермәне эшләгән.

Авыл тирәсендә күлләр шактый. Чишмәләрдән исә мондый исемдәгеләрен искә алып китәргә мөмкин: Тарлау чишмәсе, Салкын чишмә. Бу соңгы чишмә изге дип санала, аны карап һәм тәрбияләп торалар. Кешеләр чишмә янына килеп изге теләкләрен телиләр, янына сөлге, су эчәр өчен савыт куялар. Яна өйләнешкән парлар туй көнендә чишмә янына баралар. Бу чишмә һәркемгә якын һәм үз.

Авыл янында сакланып калган урман Тигәнәш урманы дип йөртелә. Анда һәр елны сабантуй үткәрәләр. Урман бик матур, анда җиләк күп була, каен, шомырт, усак, имән агачлары үсә. Урманга халык шомыртка йөри.

Шушы әрәмә уртасында Аккош күле җәелеп яткан, аның янында аккошлар бала чыгарганнар. Кызганыч, бу күл хәзер корыган. Исеме генә, истәлек буларак, халык хәтерендә сакланган.

Авыл шактый зур. Хуҗалыклар саны 250-300 гә якын.

Авыл урамнарын халык Югары оч, Түбән оч, Бозаулык дип йөртә. Авылның ике очында да хәзер мәчет бар.

Авылда өч зират бар: Түбән оч зираты, Югары оч зираты һәм Иске зират. Өч зират та олылар тарафыннан каралып һәм тәрбияләнеп торыла. Печәннәрен вакытында чабып алалар, тирә-юньнәре ныгытылган һәм рәшәткә белән әйләндерелгән. Авыл халкының әби-баба алдында намусы чиста.

## Мамадыш-Әкил

Мамадыш-Әкил авылы Зеленодол районында, район үзәге Зеленодол шәһәреннән 47 чакрым ераклыкта, Кубня тимер юл станциясеннән 15, Козловка пристаненнән 42 чакрым ераклыкта урнашкан.

Мамадыш-Әкил атамасы тарихи чыганакларда һәм белешмәләрдә шактый еш очрый.

Казан ханлыгы чоры авыллары теркәлгән исемлектә составына Мамадыш атамасы кергән авыллар Маматыш Пять дип теркәлгән. 1565-67 еллар мәгълүматларын туплап биргән Зөя өязенең теркәү кенәгәсендә авыл Маматыш Пять дип тә, Мамадыш-Әкил атамасы белән дә беркетелеп калган. А.Артемьев тарафыннан бастырып чыгарылган тарихи белешмәдә (1859 ел) күрсәтелгәнчә, Гөбенә суы ярына урнашкан Мамадыш-Әкил (җәя эчендә бирелгән икенче төрле атамасы Замостная) авылындагы 108 хуҗалыкта 325 ир-ат һәм 313 хатын-кыз гомер кичергән, гыйбадәт кыла торган бер йорт булган. Июнь уртасында Мамадыш-Әкил авылы халкы күршедәге Татар Танае, Карашәм, Татар Әҗәле һәм Кызыл Яр авыллары белән Кала алу уены җыены үткәргән.

Тарихи белешмәләрдән, халык хәтерендә сакланган хатирәләрдән күренгәнчә, авыл халкы чукындыру сәясәте вакытында христиан диненә күндерелгән булган. Керәшен зираты урыны хәзер сөрелгән, бетерелгән булуга карамастан, халык аны хәтерендә саклый. Вакытлар үтү белән, чукындырылган халык исламга кире кайткан. Тау ягында атамалары составында «Мамадыш» сүзе булган авыллар турында Каюм Насыйри болай яза:

«Мамадыш авылы—моннан башка янә шул тирәдә өч-дүрт авыл бар—бер кешенең балаларыннан таралгандыр. Ягъни, биш авыл бер исем белән аталадыр. Берсен Мамадыш-Әкил дип йөртәләр. Янә Танай авылын Тәүгилде—Мамадыш диләр. Янә Салтыган авылы бардыр, аны Мамадыш-Салтыган дип атаганнар: хәзер дә Ышналы башы дигәннәре шул авылдыр. Янә анда Багай дигән рус авылы бардыр, Багаево-Мамадыш диләр аны. Янә Арсланово дигән рус авылы бар, хәзер дә аны Мамадыш-Арсланово дип әйтәләр. Янә Гордеево дигән рус авылын Мамадыш-Гордеево дип йөртәләр. Бу биш авыл барысы да бер кешенең балаларыннан чыккандыр...»

Мамадыш-Әкил авылы Татарстанның Чуаш республикасы белән чиктәш урынында—табигатьнең бик матур җиренә урнашкан.

Авыл яныннан ага торган Гөбенә суын буып, зур плотина ясаганнар. Плотина тирәсе гүзәл, әрәмәләр үсә, янында зур болын. Мамадыш-Әкилдән Татар Танаена бара торган юл кырыенда чишмә бар. Ул чишмә йорты эченнән килеп чыга, су эчәргә теләгән кеше янына куелган чүмеч белән алып су эчә.

Инде элек авылда булган шактый мәзәк хәлгә тукталыйк. Бу вакыйганы Татар Танае олылары сөйләде.

Мамадышта берәүнең ата-анасы кунакка китә. Яшьләр өйдә аулак өй ясарга булалар. Бер чирек аракы да хәзерләп куялар. Болар матур гына итеп аулак өй ясап утырганда, хуҗалар яратмаган, аракы эчәргә хирыс кеше килеп керә. Хуҗалар аракы бетте диләр, ә үзләре калган хәмерне табакка салып, баскан каз янына яшереп куялар. Каз су дип белеп аракыны эчә дә исереп егыла. Хуҗалар күп уйлап тормыйча, әрәм булмасын дип казның мамыгын йолкыйлар да, үзен тиреслеккә ыргыталар. Бераздан каз айный һәм кыйгак, кыйгак дип кычкырып кайтып керә. Бу хәлне бөтен авыл белә.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**«МЕҢ ДӘ БЕР КИЧӘ»**, урта гасырлар гарәп әдәбияты ядкәре; һинд, фарсы һәм гарәп фольклоры мотивларына таянып 8-9 йөзләрдә язылган хикәятләр җыелмасы. Аның барлыкка килүе озак еллар дәвамында фәнни дискуссия темасы булды. Күпчелек белгечләр фикере буенча җыентыкның нигезен якынча 9 йөздә гарәпчәдән фарсы (пәхләви) теленә тәрҗемә ителгән «Хәзар әф-санә» җыентыгы тәшкил итә. Ә ул, үз чиратында, һинд оригиналларына барып тоташа дип фаразлана (пәхләви телендәге текст бүгенге көннәргә кадәр килеп җитмәгән). Сюжет кысасын Шәһрияр хөкемдар, аның Шәһрезадә исемле вәзиренең зирәк кызы турындагы гарәп әкияте тәшкил итә. Үлемгә хөкем ителгән бу кыз 1001 кичә дәвамында Шәһриярга мавыктыргыч әкиятләр сөйләп, аларны иң кызыклы урынында бүлдереп, туктап кала торган була. «М.Б.К.» нең гарәп кульязмаларының күбесе 17-19 йөзгә карый, берничәсе генә—15 йөзгә (җыентык тәмам оешкан вакыт). Җыентыкка кергән хикәятләр эчтәлеге б-н 3 төргә бүленәләр: 1) тылсымлы әкиятләр һәм чыгышы б-н һинд яки фарсыга караган фантастик характердагы повестьлар; 2) янәсе Багдадта Һарун әр-Рашид һәм аның вәзире Җафар б-н бәйле булган вакыйгалар (күбесенчә грекларның мәхәббәт турындагы хикәятләренә барып тоташкан мәхәббәт турындагы романтик хикәяләр); 3) мәмлүкләр заманындагы Каһирәдә булган вакыйгалар турында бәянләгән «шәһәр» әкиятләре. Җыелмага ш.у. үзләре барлыкка килгән һәм мөстәкыйль әсәр булып танылган аерым әсәрләр дә кергән (мәс., дингезче Синдбад, зирәк Хәйкәр турындагы әкиятләр һ.б.). «М.Б.К.» әкиятләре киң дөньяга таныла, күпчелек халыкларның фольклор һәм әдәбиятларына зур йогынты ясый, ш.и. татарларга да. Төп сюжет һәм мотивлары татар әкиятләрендә, Мәҗлиси, Мөхәммәдъяр, К.Насыйри, Г.Тукай әсәрләрендә чагылыш таба. Татарчага төрек теленнән Ф.Халиди тарафыннан тәрҗемә ителә, 1897-99 елларда нәшер ителә.

Әсәр.: Тысяча и одна ночь: В 3 т. М., 1987.

Әд.: Гостер А., Крымский А. К литературной истории «Тысячи и одной ночи». М., 1900; Эструп И. Исследование о «1001 ночи», её составе, возникновении и развитии. М., 1904; Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993.

**МИЛЬШТАТ** (Milstadt) (Мюллер) Эрих (1904, г. Ростов-на-Дону—1970, Берлин), немец драматургы, тәрҗемәче. 1921 дән Германиядә яши. Банкта клерк, матбугатта мөхәррир булып эшли. 1930 да немец эшчеләре делегациясе б-н Советлар Союзына килеп китә. Фашистлар хакимияткә килгәч, эмиграциягә (Чехословакия, Англия) китәргә мәҗбүр була. 1947 дә Германиягә кайта. М.Җәлилгә багышланган «Кызыл ромашка» исемле телефильм (1959) һәм шул ук исемдәге нәфис фильм (1963, реж. Латар Беллач) сценарийлары авторы. Сценарий язылышында СССРга килә, шагыйрьнең туганнары һәм якыннары б-н очраша. Немец теленә М.Җәлил, М.Е.Салтыков-Щедрин, казах фольклоры әсәрләрен тәрҗемә итә.

*Р.Ә.Мостафин.*

**МИНГАЛИМ** (Мингалимов) Рөстәм Гали улы (15.9.1937, Куйбышев өлкәсе Камышлы р-ны Йолдыз ав. туа), шагыйрь, драматург, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). Казан ун-тын (1967), СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби (Мәскәү, 1978) һәм Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы театр курсларын (Мәскәү, 1980) тәмамлый. 1954 елда Казахстан ССР Көкчәтау өлкәсендә чирәм җирләрне үзләштерүдә катнаша. Ташкент шәһ. з-дларында слесарь һәм станоклар көйләүче (1956-58), Минзәләгә кайтып геофизик экспедициядә электр җиһазлары буенча слесарь булып эшли (1959-62). 1967-75 елларда «Яшь ленинчы» газ-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип вазифаларын башкара. 1975-77, 1989-97дә ТР Язучылар берлегендә әдәби консультант. М. балаларга атап язылган «Әйт, Кояшым!» (1966) һәм зурлар өчен «Эзләр» (1967) исемле беренче шигъри җыентыклары белән үк татар поэзиясендә тормыш күренешләрен үзенә генә хас

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

образлы фикерләү һәм форма чаралары ярдәмендә гәүдәләндерергә тырышучы, масштаблыкка, ассоциатив фикер һәм хис бердәмлегенә омтылучы, метафораларга бай, ирекле ритмикага корылган шигырьләр остасы буларак мәйданга чыга. Алга таба «Күперләр» (1969), «Алкын су» (1971), «Күз карасы» (1974) җыентыкларына үзара сөйләшүгә корылган интонация, фән һәм техника дөньясына караган образларны актив куллану хас. 1980 еллардан М. иҗаты тагы да тирәнрәк фәлсәфи уйлануларга корылган. «Иртәгә» (1975), «Ике авыл арасы» (1979) поэмаларында шагыйрь илләрне, халыкларны, милләтләрне борчыган дөньяви проблемаларны хәл итү турында уйлана. «Нәкъ унбиш ел үткәч» (1972), «Уздылар» (1972), «Борчулы минутларда» (1975) кебек шигырьләрендә сагышлы уй-кичерешләргә, лирик кичерешләр динамикасын ачып бирергә омтылуга өстенлек бирелгән. М. балалар өчен дә иҗат итә: «Ә сәгать келт-келт итә» (1968), «Төнге әкият» (1973), «Бәхетле исем» (1977), «Галстуклы кәҗә» (1992), «Эх, Самара яклары» (1998) җыентыклары. Драматургия өлкәсендә дә күп эшли. Аның «Урман улы—Зурмөгез» (Мәскәү үзәк курчак т-ры сәхнәләштерә, 1978), «Сихерләнгән урман» (шул ук театр сәхнәләштерә, 1979), «Шүрәлеләр үч алмый» (Яр Чаллы татар драма т-ры сәхнәләштерә, 1982) әкият-пьесалары буенча спектакльләр куелды. «Кайда сез, ирләр?» (Татар академия т-ры сәхнәләштерә, 1982), «Өченче бүлмәдә эт яши» (Әлмәт татар драма т-ры сәхнәләштерә, 1983), «Кунак кызы гел килмәс» (шул ук театр сәхнәгә куя, 1985), «Кире уйларга соң инде» (Татар драма һәм комедия т-ры сәхнәләштерә, 1987) пьесаларында әхлак, мәхәббәт, тәрбия, гаилә проблемалары күтәрелә. Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрендә күбрәк милләт язмышы мәсьәләләренә басым ясый: «Татар түбәтәе» (1992-2000) шигырьләр циклы, «Кем кулларына калдырыйм» (1995) поэмасы. М. А.Алиш исем. ТР Язучылар берлеге (1997) һәм Г.Тукай исем. ТР Дәүләт (2005) премияләре лауреаты.

Әсәр.: Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1987; Тау астында илле бүре: Пьесалар. К., 1990; Дәрт чүлмәге. К., 2003; Зелёный сон. М., 1978; Жемчуг на ладони. Стихи. Уфа., 1995.

Әд.: Галиуллин Т. Рустем Мингалим // Здравствуй, поэзия! М., 1987; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М. Габделхакова.*

**МИНЗӘЛӘВИ** Габдеррәфигъ бине Габделгаффар (18 йөз ахыры, Уфа губернасы Минзәлә өязе Яхшыбай а.—19 йөз башы), шагыйрь. Уфа губерниясе Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укый. 19 йөзнең 1 нче яртысы мөселман тормышын яктырткан, дидактик эчтәлекле «Ихванларә васыять» («Кардәшләргә васыять», 1943) исемле кульязма шигъри поэма авторы.

*М.В.Гайнетдинов.*

**МИНЗӘЛӘВИ** Кәшшафетдин Шаһимәрдән улы (1864, Уфа губернасы Минзәлә өязе Сөлек а.—1920 дән соң), шагыйрь, мөгаллим. Татар һәм казах телләрендә яза. Сөлек мәдрәсәсендә һәм Шыгай авылы «Мәрҗания» (1883-92) мәдрәсәсендә белем ала. 1892 дән Каркаралы ш. мәчетендә мулла һәм мөдәррис вазифаларын башкара. 19 йөзнең ахырында яза башлый. Дастаннар, фольклор һәм әдәби сюжетларга ияреп язган мажаралар, шигъри кыйссалар авторы (барысы 100 чамасы, башка мәгълүматларга караганда 80 чамасы): «Кыйссаи хәким», «Кыйссаи Әбелхарис», «Кыйссаи кимпер», «Кыйссаи Бәдәр» һ.б. авторы. М. иҗатында яшь буынны тәрбияләүдәге әхлакый һәм рухи мәсьәләләр, дини һәм дөньяви белем бирү, дини-этик проблемалар чагылыш таба. Акын булып таныла: казах телендә шәрекъ әдәбиятында танылган сюжетларга нигезләнгән дастаннар башкара. Идел, Урал буе, Казахстанда яшәүче төрки-татар халкында популярлык казана. Утыз Имәни шигырьләрен җыеп, «Китабе мөһимматез-заман» (1898) исемле җыентык бастыра.

Әд.: Гарифуллин Д. Якташыбыз—казах акыны // Гасырлар авазы—Эхо веков. 1995. май; Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. К., 1999.

*А.М.Ахунов.*

**МИНСКИЙ** (псевд., чын фам. Аллаһбирдиев) Габдрахман Мөхәммәт улы (29.9.1906, Әстерхан шәһ.—26.3.1983, Казан), язучы. Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1938).1924-25 елларда Әстерханда башта уку йорты, соңрак «Кызыл Шәрекъ» исемле татар яшьләре клубы мөдире булып эшли. Шунда эшләгәндә үзенең «Татар мәдрәсәсендә бер көн һәм бер төн» , «Наданлык», «Ачлык корбаннары» дигән беренче пьесаларын яза. 1926 елда Татар театры техникумында укый. 1930 еллар башында «җидегәнчелектә» гаепләнеп җавапка тартыла. Тикшерү нәтиҗәсендә гаепсез табылса да, матбугаттан, әдәбияттан читләтелә. 1932-35 тә Чиләбе шәһ.дә яши: «Төзү ударнигы» г-тасының җаваплы сәркатибы вазифасын башкара. 1938 дә Баку шәһ.нә (Әзәрбайҗан) күчеп китә һәм 1941 гә кадәр Баку киностудиясенең сценарийлар бүлегендә консультант булып эшли. М. сценарийлары буенча «Артем

тавы» (1939), «Яна хәят үзәне» (1939), «Ватан улы» (1940) дигән кинофильмнар төшерелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947-51 елларда ТАССның Әзәрбайҗандагы бүлегендә мөхәррир һәм корреспондент. 1952 дән Казанда: «Чаян» ж-лында әдәбият һәм сәнгать бүлеген житәкли (1952-57), Татар. кит. нәшр.да баш мөхәррир урынбасары (1957-60). М. әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Аның реаль вакыйгаларга һәм үзе күргәннәргә нигезләнеп язылган Бөек Ватан сугышы турында хикәяләре бар («Хикәяләр», 1954; «Батырлар сукмагы», 1958). «Мәхәббәт хикәяләре» (1958), «Язның беренче көне» (1963) кебек хикәяләр җыентыкларында яшьләр тематикасы үзәктә тора. Әстерханда революция алды вакыйгалары «Яшенле яңгыр» (1966; рус теленә тәрҗемәсе «Грозовой дождь», 1974) повестенда чагылыш таба. Драматург буларак М. нигездә әхлак-этика проблемаларына багышланган әсәрләре белән билгеле. Аның «Мансуровлар гаиләсе» (1928 дә куела), «Шлем» (1930 да куела), «Гөлчәчәк» (1940 та куела), «Бөдрә тал» (1957 дә куела), «Лачыннар» (1965 тә куела) пьесалары Татар академия т-ры, Татар драма һәм комедия т-ры, Башкорт драма т-ры сәхнәләрендә уңыш белән барды. М. үзенең замандашлары, күренекле әдипләр—Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Г.Кутуй турында истәлек язмалары белән дә танылды («Замандашларым», 1964; «Онытылмас очрашулар», 1973 җыентыклары). Әзәрбайҗан язучылары Җабар Җабарлы һәм Мәһди Хөсәен әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. «Почет Билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Первая симфония: Рассказы. М., 1974; Синең җырың: Пьесалар. К., 1981; Повестьлар һәм хикәяләр. К., 1986.

Әд.: Хәйри Х. Язучы һәм журналист // Язучы һәм тормыш. К., 1979; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МИҢЛЕБАЕВ** Кыям (Кыяметдин) Сәлах улы (25.6.1929, Буа кантоны Кече Чынлы а.—3.9.2005, Казан), тәрҗемәче, язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). 1953 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1955-89 елларда Татар. китап нәшриятендә (1955-58—мөхәррир, 1958-66—балалар әдәбияты редакциясе мөдире, 1967 дән матур әдәбият редакциясендә), берүк вакытта, 1966 дан Казан ун-тында тәрҗемә теориясе һәм практикасын укыта, 1997-2003 елларда ТР ФА Татар энциклопедия ин-тында энциклопедик басмаларны татар телендә чыгаруга әзерләү бүлегендә эшли. Русчадан татарчага Л.Н.Толстойның «Детство. Отрочество. Юность» («Балачак. Үсмерчак. Егетчак», 1955-57) трилогиясен, «Казаки» («Казаклар», 1974) повестен, В.Я.Шишковның «Угрюм-река» («Хәсрәт дәрьясы», 1963) романын, В.П.Катаевның «Белеет парус одинокий» («Ялгыз җилкән», 1965) повестен, А.Н.Толстойның «Гиперболоид инженера Гарина» («Инженер Гаринның гиперболоиды», 1972) романын, «Хождение по мукам» («Михнәтле заман», 1976-79) трилогиясен, «Аэлита» (1983) романын, Э.Войничның «Овод» («Кигәвен», 1981) романын, Г.Маркесның «Сто лет одиночества» («Ялгызлык», 1987), Ж.Амадуның «Габриэла, корица и гвоздика» («Габриэланың гыйшкы», 1999) романын, балалар өчен Н.Н.Носовның «Приключения Незнайки» («Незнайка мажаралары», 2003) китабын тәрҗемә итте. «Бакый» (1997), «Акыллы атын мактар...» (2004) романнары авторы. Әдәби тәрҗемә теориясе, сынлы сәнгатькә багышланган мәкаләләр авторы. Б.Урманче, Л.Фәттах, И.Зарипов рәсемнәре альбомнарын төзүче.

Әсәр.: Перевод—это искусство. К., 2004.

Әд.: Кыйблага тугрылык. К., 2004; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1984

**19 февраль.** Кичә Сафуан абый килгән иде, 10 гр мумиё биреп китте. Менә шуны эчсәң, бөтен чирләрең кырып алган кебек юкка чыгар, ди. Мин андый чүп-чарларга ышанмыйм дип карадым. Аптырагач, алып калдым. 18еннән эчә башладым. Иртән ашаганчы бер борчак хәтлерәк итеп кабып куям. Чын мумиёдырмы, ялгандырмы— ансын әйтеп булмый. Болай үзе авызда тиз эри. Тәме әчкелтем. Көйгәнрәк ис килә. Кайнаткан сумала сыманрак.

Бүген «Социалистик Татарстан»да минем шигырьләр чыкты. Алты шигырь. «Аврора»ның 1983 ел 11 санында Е.Вечтомова тәрҗемәсендә берничә шигырь басылган. Аларның басылганын да ишетмәгән идек. Әмир Мәхмүдов шалтыратып әйтте. Ул Ленинградка барган булган, шунда күреп кайткан. «Аврора» журналында элек тә берничә шигырь чыккан иде. Бу санда Вечтомованың сүз башы белән бирелгән. Хәзер бу журнал кечерәк формат белән калынрак итеп чыга башлаган икән. Болай матуррак төсле.

Яңактагы яра төзәлеп җитмәде әле. Перевязка ясыйбыз. Әни 21ендә кайтып китә, билет алдык. Бу арада көннәр җылынып тора. Көндезләрен 4-6лар тирәсе, ләкин иртәнге якта томан була.

**20 феврал**ьдә берни язмаганга ай. Бөтенләй үк тик кенә торылмады инде ул үзе. Журнал, газеталар укыла.. 1985 елга китап әзерләп биргән идем. Әле бер, әле икенче хикәя хакында телефон аша булса да редактор белән киңәшләшергә туры килә.

**24 февраль.** Резеда Вәлиева килде. «Туган көн бүләге»н редакцияләп, техредактор кулына тапшырган. Күп кенә юмористик хикәяләр китапка керми калды, күләм сыйдырмады. 16 табак биргән булсалар, рәхәтләнеп яңа хикәяләрдән генә әйбәт китап чыгарып була иде.

Кичә Фәрваз Миннуллин белән Әхмәт Гадел Совет Армиясе көне белән котлап киттеләр. «Шигырь китапханәсе»ндә супер тышлык белән сайланма әсәрләрне чыгаруны сорап директорга язган хатны Фәрвазга биргәннәр. Идарә моннан ун ел элек үк исемлек төзеп куйды, ди. 87нче елда Р.Мингалимовныкы чыгарга тиеш икән. Минем китап нәрсә белән бетәр. Тагын бер сөйләшеп, бу нәрсәгә ачыклык кертергә кирәк булыр.

Ташкент өлкәсеннән Даниялардән посылка килде. Үзләренә соңгы вакытта хат та язган юк иде. Кыен булып китте. Алар бит безгә беркем дә түгел. Бары тик минем иҗатны яратучылар гына.

«Дружба народов» журналының 1984, 1 санында «Первая борозда»га статья чыккан. Мөхәммәдъяров дигән кеше язган, сүз күбрәк тәрҗемә турында бара. Ә,

---

*Дәвамы. Башы 1нче санда*

гомумән, ул минем иҗатны белгән кешегә ошый.

Яңактагы яра төзәлеп җитми әле. Хәзер башка хирург—Дилүза Арджановна дигән кеше килеп йөри. Хәлил Галимович үзе авырып киткән. Беркөн өеннән шалтыраткан иде, минем китапларны бик ошаткан. Минем өстәл китапларына әйләнде алар, ди.

Иҗатымны халык ярату ягыннан алсак бик бәхетле язучы инде мин. Газета-журналда басылган әсәрләргә дә хатлар килә. «Совет мәктәбе» журналын укучылар укымыйдыр дигән идем, аны да укыйлар икән. 2 санда берничә шигырь чыккан иде, Әлмәт укучыларыннан хат килеп төште. Әле журналның чыкканына да кайчан гына.

Миңа килгән хатлар хәзер инде меңгә җитәдер. Катыргы тартмаларга тутырып гаражга чыгарып куйдык әле. Рус кызларыннан да хат килүе гаҗәп. «Старшина-сержант», «Дружба народов», «Литературная газета», аеруча «Комсомольская правда» кебек газета-журналларда чыккан шигырь-хикәяләрдән соң хатлар күп килә. «Байкал» журналында басылган һәм «Советская женщина» журналында чыккан хикәяләрдән соң хатлар күп килде. Хатлар гына түгел. Ленинград, Астрахань, Семипалатинский шәһәрләреннән рус кызлары килә башлады.

**5 март.** Кичә кичкә кадәр коточкыч температура күтәрелде. 39,4. Врачларга шалтыратып торганда гына Айтуган абыйлар килде. «Табыну» чыгып җиткән. Шуның авторский 7 нөсхәсен алып килде. Бу китапны да исән-сау килеш күрдек, шөкер.

Врач озак көттермәде, бер ярты сәгатьтән килеп җитте. Тагын шул Агупова дигән врачның дежур чагы иде. Сестра булып Зифа килгән иде. Ике укол кададылар. Берсе температураны төшерер өчен. Ансының исеме—реопирин. Бу уколдан соң бик каты тирләрсең дигәннәр иде, чыт иткән тир дә чыкмады. Йөрәккә җиңеллек өчен сульфокамфокаин кадады. Ләкин ул укол миңа бик килешми. Янадан кадатмаска кирәктер аны. Ахры, аның составында димедрол бардыр. Ә миңа димедрол, анальгин ише нәрсәләр ярамый. Яңактагы яра яңа төзәлеп килә.

Кичә бер шигырь язган идем, сәгать ярым вакыт эчендә. Эш ярамый башлады, ахры. Айтуган абыйлар белән яңа чыккан китапның шатлыгын билгеләп үтәргә дә туры килмәде. Мин чирле булгач кыенсынып кына утырдылар.

Кичә сайлау көн иде. Минем урынга да Нурсөя сайлап кайтты.

**1 май.** Быел 1 майга агачлар яфрак яра алмады. Яз сонарып килде. Кышын кар да күп түгел иде инде. Әле бер тапкыр урамга чыгып караган юк. Ике айга якын, ягъни 5 марттан 23 апрельгә кадәр больницада ятып чыктык. Аннан чыккач, Нурсөя чирләде. Бик арый инде ул. Йә мине борып яткырырга, йә яраларны бәйләргә, йә редакцияләргә минем хикәя-шигырьләрне илтергә кирәк. Шуның өстенә ашарга пешерергә. Тәрәзәләрне юарга, өйләрне җыештырырга, керләр юарга һәм тагын миллион эш көтеп тора аны. Стеллаж куйгач өр-яңадан дөнья купты, больницадан чыккач капитально бер җыештырган иде инде. Йокы бүлмәсенә ишек артына китаплар куярга бик әйбәт стеллаж булды. Урынны күп алмый, китапны күп сыйдыра. Юкса журналларга урын җитми башлаган иде. Соңгы вакытларда язган юк. Больницада чакта «Бай эти»не Туфаннан укыттым, янадан эшләп чыккан идем. Машинкага биргәнче тагын бер карап чыгасы булыр әле. Больницада бер-ике шигырь язылды, алары да бик искитәрлек түгел. Хәзер җәй көне эшләп булмас инде. Әле укыйсы журналлар өелеп тора, алар өстенә яңалары килә. Нурсөя чирләгәч, кулдан эш төшеп тора. Кайбер шигырьләрне машинкада бастырып газета-журналларга җибәрәсе бар. Үземнең дә кәеф шәптән түгел, бик язасы килеп омтылып-омтылып куям да сүреләм.

**5 май.** Ниһаять, көннәр җылына башлады. Бүген 16-18 градус. Агачлар яшәреп маташа. Урамга чыккан юк әле. Бүген Нурсөя Фәридә белән бакчага китте. Быел беренче баруы. Яңгырлар яумый. Язга чыкканнан бирле яңгыр яуганы юк. Бер шәп кенә яңгыр булса агачлар шундук яшәреп китәрләр иде. Тузанга батып утыралар.

2 майда Мәдинәләр килде. Мәдинә икенче романын язып бетергән инде. Сыпыра. Зур жанрда эшләгән язучыларның эшләре шәбрәк. Китаплары

өзгәләнеп-таланып чыкмый. Әсәрләре йомшак кына булса да, этләшеп йөри торгач барыбер дөньяга чыгаралар. Ә бер китап булып чыккач, мактаучысы да табыла. Шулай итеп ул телгә керә. Аннары аны русчага тәрҗемә итәләр. Мәскәүдә чыгаралар. Ә Мәскәүдә китабы чыккан авторны иң яхшы язучыга исәпли башлыйлар.

21 майда безнең съезд ачыла. Председатель булырга теләүчеләр бик күп диләр. Ике Ренат, Разил, Туфан булыр дип тә сөйләнәләр. Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, кемне куйсалар да отказать итмәс, урыны бик шәп бит. Анда утыру белән үзләренең томнарын чыгару турында кайгырта башлыйлар. Барлык әсәрләрен Мәскәүдә чыгаралар. Ә язучыга шуннан да зур бәхет бармыни?

Минем быел чыккан «Табыну» кибетләрдә беткән. Бик тиз. Үзебез бер пачка гына алып калдык.

**7 май.** Бу ике көндә көннәр җылы торды. 20 градуслардан артык булгандыр. Өйләр бик кызу. Һаман ягалар. Янып үләрлек. Көне буе өйдә эреп ага язып ятам. Йөрәк турысына кружка белән су утыртсаң, кайнап чыгар иде.

Агачлар яфрак яра башлады. Яңгырлар юк. Бөтен дөнья тузан. Минем урамга чыккан юк әле. Бу ике көндә бер-ике шигырь яздым. Журналлар укыдым. Кичә Флера килде, малае белән. Малае бик тере күренә.

**9 май.** Көн шундый матур, җылы. 28 градуслар була диде. Нурсөя Фәридә белән бакчага китте. Быел өченче тапкыр баруы. Тазалыгы бер дә шәп түгел. Машинаны да кабызып карамаган әле. Минем урамга чыккан юк. Өйләр бик эссе. Һаман ягалар. Тышта 25 тән артык торганда нигә ягалардыр. Көн дә суытыр, ягудан да туктарлар әле.

Бүген «Иностранная литература» журналын укырга булыр. Язасы килми. Редакцияләрдә әйберләр ята. «Татарстан яшьләре»ндә ике хикәя «тозланды» инде. Әйбәт диләр дә чыгармый яткыралар.

**15 май.** Бүген «Җиңү көне» дигән бер шигырь язып куйдым. Минем иҗатта әти образы аз чагылыш тапкан икән. Бусы менә икенче шигырь. Берәр цикл әзерләп булса, Җиңүнең 40 еллыгына әйбәт булыр иде. Иҗатка да яңа агым килеп керер иде. Шагыйрь нәрсә генә язса да үз биографиясеннән әллә ни ерак китми инде. Хәтта көн кадагына сугылган публицистик шигырьләрдә дә үз кичерешләрең чагыла. Кыскасы, тагын биографияң килеп керә. Мин бигрәк тә дөреслектән читкә китәргә яратмыйм. Билгеле, туган авылым фәлән дип 20-30 авыл турында җыр язган шагыйрьләр дә бар. Минемчә, алар шагыйрь түгел инде. Шагыйрьнең лирик герое авторның уй-хыяллары, узган юлы, куйган максаты, шул максатка бару үзенчәлекләре белән тәңгәл килергә тиеш. Тикмәгә генә: «Һәр язучы бер генә китап язып калдыра»,—димиләрдер. Ул бит бер китап кына язганнан әйтелмәгән. Ничә китап язса да үзе турында яза дигәннән әйтелгән.

**17 май.** Өченче көн Гөлзадә Сафиуллина дигән артистка шалтыратты. Риф Гатауллинның «Үлемсез ил моңы» дигән исемдә концерты була икән, Тынычлык фондына, шунда чакырды. Минем дә өч җыр башкарылачак диде. Бүген шунда барырга торабыз. Соцгородта, Ленин исемендәге культура сараенда. Машина белән үзебез килеп алабыз, китереп куябыз дигәч, барырга вәгъдә бирдем. Утырып бетереп булса.

Ә 21 ендә язучыларның X съезды ачыла. Анда да барасы килә иде. Озак утыра алмау бик начар. Югыйсә җылы вакыт. Кешеләр белән аралашып, иҗат турында бәхәсләр тынлап кайтыр идем. Беркая чыкмыйча өй тавыгына әйләнеп бетәсең. Стеналар кыса башлый. Кешегә тикмәгә генә иркенлек, башкалар белән аралашу кирәкми шул. Минем әле 20 елдан артык язып бер съездда да катнашкан юк. Хәтта Островскийга куйган кебек рация дә куймыйлар. Хәзерге заман техникасы белән аны гына эшләп булыр иде югыйсә. Теләк юк.

**18 май.** Кичә Риф Гатауллин һәм Гөлзадә Сафиуллина концертына бардык. Концерт бик әйбәт булды. Өч сәгатьтән артык дәвам итте. Концерттан соң сәхнә артына кереп аларны котлап, бәйрәм ясап утырдык. Төнге беренче 20

минутларда гына кайттык. 5 сәгать утырырга туры килде. Ике кеше бер зал халыкны өч сәгать буе авызларына каратып тордылар. Концерт программалары бик зур иде, концерттан кергән акча Тынычлык фондына күчереләчәк. Бик күп шигырьләр дә укыдылар. Шагыйрьләрдән Ф.Сафин, М.Әгъләмов, Р.Миннуллин, Э.Шәрифуллина, Ф.Гыйззәтуллиналар бар иде. Композиторлардан Риф үзе һәм Ф.Әхмәтов кына иде. Залдагы шагыйрьләрне дә сәхнәгә чакырып берничә сүз әйттерделәр. Бу нәрсә концертны төрләндереп җибәрергә әйбәт булды. Молодцы! Болар турында берәр мәкалә язып чыксаң да ярар иде. Минем дә өч җыр яңгырады.

**21 май.** Бүген Татарстан язучыларының 10нчы съезды булды. Нурсөя белән мин дә бардым. 18 ел Язучылар союзында член булып торып, беренче тапкыр съездда катнаштым. Такси белән килеп алдылар. Чаллыдан шагыйрь Хәниф Хөснуллин һәм Себердә яшәүче шагыйрь Булат Сөләймановлар килеп алдылар. Казанда яшәүче «дуслар» килеп вакланып тормадылар. Беренче тәнәфескә кадәр үк бик арыдым. Аннары Туфан Миннуллиннар, Мәскәүдән Миргазиян Юныслар мине күтәреп балконга менгереп куйдылар. Ярты зал чаклы балконда Нурсөя белән икәү генә утырдык. Дөресрәге, мин колясканың артын төшереп ятып тордым.

Г.Ахунов отчет докладында өч-дүрт тапкыр минем бик актив һәм нәтиҗәле эшләүне әйтеп китте. Проза буенча М.Мәһдиев доклад ясады. Поэзия буенча И.Юзеев. Илдар да минем иҗатның тирәнәя баруын күрсәтеп үтте.

Өченче яртыда төшке ашка таралыштылар. Шунда без дә кайтып киттек. Күреп, сөйләшәсе кешеләр күп иде. Ләкин бик арыткач, тизрәк кайтып китү ягын карадык. Без барганда инде С.Хәким съездны ачып маташа иде. Урыным да сөйләшеп утырырдай кешеләр янына туры килмәде. М.Юныс минем янга килеп басуга безне сырып алдылар да аның белән дә рәтләп сөйләшеп булмады.

Съездның ахырына чаклы утыра алмасам да бару начар булмады. Тик температура 38ләр тирәсе күтәрелгән иде. Кәеф яхшы булса иртәгә дә барырга исәп.

**28 май.** Иртәгесен барып булмады. Температура бик каты күтәрелде. 40,1 гә кадәр җитте. Болай ук югары күтәрелгәне юк иде бугай әле. 4 көн буе төшмәде. Бераз хәл рәтләнгәч, бакчага киттек. Көннәр 32 градуска кадәр. Бераз яңгыр явып узды. Тын алырга җиңел булып китте. Бакчаның бөтен файдасы—саф һава һәм матурлык.

Съездның икенче көнендә Миргазиян Юныс килде. Аның белән озак кына сөйләшеп утырдык. Ике китабымны бирдем. Болай принципиаль егеткә ошаган үзе. Иҗатында кыю. «Юлда уйланулар»ы бик ошаган иде.

**8 июнь.** Биш көн бакчада торып кайттык. Көннәр кызу, 30дан артык. Яңгырлар юк. Әйберләргә көн саен су сибәргә кирәк. Алмагачларга, сливаларга әллә нинди корт төшкән. Калганы калыр әле дип агу сиптермибез.

**3 июль.** Кичә Нурсөя кайнар су колонкасын алып кайтты. Бүген газовик килергә тиеш. Ярый әле бакчада мунча кереп кайткан идек. Нурсөя юкә себеркесе белән бик каты чаба-чаба мунча керткәч, тәннен тирләп ятуы бераз кимеде. Ләкин эчләрнең авыртуы чамасыз.

**7 июль.** «Казан утлары»ның 6 санын укып чыктым. М.Мәһдиевнен «Мәңгелек яз» романы ике санда килде. Ис китәрлек түгел. Теле шәп. Ләкин әсәрләрен бер сюжетка кора белми. Ахырыннан укысаң да барыбер. Сюжетсыз, конфликтсыз әсәр—әсәр түгел инде ул. Автор әйтерсең укучы күз алдында бер зур агачны тотып юна башлый. Ахырга таба ул агачтан йомычкадан башка берни дә калмый. Әсәр башындагы геройларын онытып, башка персонажларга күчә. Теленең җорлыгы, халыкчанлыгы укучыны тотып тора. Бәлки, сюжетсыз әсәрләр дә кирәктер. Халык укый бит. Әнә «Иностранная литература» журналында өтерсез, ноктасыз, сюжетсыз эссе-романнар да чыга. Бу—жанрны төрләндерүнең бер ысулыдыр, бәлки...

Быел җәй дә, кыш та чирдән арынып булмый. Чилләдә дә салкын тия бөерләргә. Шыбыртма тиргә батып ятам. Тирләтмәгәндә температура күтәрелә.

Колонканы Самат Маннанов дигән газовик ясап китте. Ләкин барыбер әйбәт

булмады. Автоматически сүнми.

**15 июль.** Бүген бакчага китәбез. 4 көн кунып кайтырга исәп. Күнел дә тыныч түгел. Узган атнада күрше подъездда ике квартирны басканнар. Нурсөя: «Гомер буе хыялланып тун алдым, урлап чыкмасалар ярый инде»,—дип йөри. Кайчагында бик ашкынып тапкан нәрсә белән ни дә булса булып та куя. Алла сакласын. Әйбер күбәйгән саен тынычлык кими бара. Көннәр буе ишекне бикләмәгән чаклар бар. Кеше килсә керә алмый китмәсен дип өйдә үзем генә калганда ишекне бикләтмим. Нурсөя: «Карак керсә?!»—ди. «»Сөйләшеп утырырбыз»,—дим. Д.Лондонның кайсыдыр хикәясендә шундый эпизод бар. Карак белән авыру хуҗа дуслашып китәләр.

**26 июль.** Бүген бакчага барабыз. Өч көн өйдә булдык. «Ялкын»га «Әти» дигән циклны әзерләп җибәрдек. Айдан артык инде берни дә язган юк. Алла бирсә көзгә җинне сызганырга кирәк булыр.

Иҗат эшенең шунсы шәп: фәлән вакытка фәлән нәрсә язып бетер дип көчләмиләр. Юкса бу эссе җәйләрдә ничек эшләр идең.

«Социалистик Татарстан»ның 22 июль санында минем «Ил таңы» дигән җырны биргәннәр. Резеда Ахиярова музыкасы. Ул Резеда Ахиярованы моннан 10-12 еллар элек әнисе безгә җитәкләп килгән иде. Менә бу минем кыз, музыка училищесын бетерә, синең сүзләргә берничә җыр язды, консерваториягә керергә әзерләнә, дигән иде. Хәзер ул консерваторияне бетергән, 30-40 җыры бар. Танылып килә торган композитор. Беренче килгәндә ул миңа 6нчы классларда укучы бала булып күренгән иде. «Бу бичара баланы пианино янында бәйләп тоталардыр инде»,—дип уйлаган идем...

Безнең илнең бөтен нәрсәсе табигатькә бәйле. Янгыр яуса икмәк уна, ләкин комбайннар басуга керә алмый. Хәтта безнең бакчага бару-бармау да кояш белән болытка бәйле.

**29 июль.** Бу көннәрдә бер-ике шигырь язылды. «Ялкын»нан Хәйдәр шалтыратты. Теге циклны бик ошаттык, шатланып шалтыратуым, ди. Тик исемен «Әти» дип кенә түгел, озынрак итеп куясы иде, ди. «Әткәм төсе—тыныч көннәрдә» дип куярмын, ахры.

**4 август.** Бүген өйдә торабыз. Мин хатлар яздым. Нурсөя алмадан как ясый. Алмалар күп коела. Бәлеш пешереп тә, как ясап та өлгермәле түгел. Шулай да тырышабыз инде, чыгарып ташламыйбыз. Ашау ягына килгәндә—бирешмибез.

**6 август.** Бүген бик каты боз яуды. Кичке сәгать 5 белән 6 лар арасында. Балконга төшкән бозлар виноград хәтле зурлыкта иде. Боз алдыннан һәм аннан соң озак итеп көчле янгыр яуды. Бу боз игеннәрне дә кырып салгандыр әле. Өйдә балконнан карап утырганда кызык тоелса да кырларда, басуларда бик кызык түгелдер.

**16 август.** 15ендә «Социалистик Татарстан»га шигырьләр җибәрдем. «Туры җавап», «Колхоз гаражында», «Күршеләр һәм без» һәм берәр куплетлы өч шигырь. Бар да юмористик әйберләр. Хәзер «Казан утлары» өчен берәр цикл әзерлисе бар. Шуннан соң уйланылган нәрсәләрне яза башларга, китап әзерләргә тотынырга вакыт җитәр. Көз житә. Көз—трай тибүдән туктап, иҗатка тотыну чоры.

**16 август.** Көннең җылылыгы 16-17 градус булды. Бакчада укырга булыр дип Ләис Зөлкарнәевнең китабын алган идем, табигать үзе китап бит ул. Укылмады. Гомумән тышта укый алмыйм икән мин. Болытларга, агачларга кунып сайраган кошларга, ничек кояш баеганын, бөтен дөньяның төсләр диңгезенә кереп чумганын карап яту кызыграк.

**21 август.** Бүген Хәниф Хөснуллинның «Алтын тояк»ын укып чыктым. 81 нче елны чыккан китап. Нишләп без алмаганбыздыр аны. Шигырьләре ошады. Үзе җибәрмәсә тәки укылмый калган булыр иде бу китап. Шигъри детальләре матур. Башкаларны кабатламый. Ихластан язылган шигырьләр.

Хәниф китабыннан соң Ләис Зөлкарнәевнең «Балачак күге»н укыдым. Бу егет тә әйбәт кенә яза. Зөлфәтнең яшь чагынарак ошатам мин аның иҗатын. Кайнарлык бар, дәрт бар.

«Татарстан яшьләре»нең бүгенге санында минем «Җайсыз бәхет» дигән

юмористик хикәя чыккан.

Кичә бакчадан кара миләш җыеп кайттык. Кайткан чагында бер бабай безнең машина астына керә язды. Әле дә шул күз алдыннан китми. 20-30 см гына әләкми калды. Машина белән йөрүнең куркыныч яклары бар шул.

Галимәгә «Табыну»ны җибәрдем. Хәниф Хөснуллинга хат яздым. «Агыйдел»нең 7 санын укып ятам. Киләсе елга язылмыйм. Әдәбиятлары артыгын йомшак, берни дә бирми. Шулар союз күләмендә шаулап йөриләр, җитмәсә.

Әнигә акча салдык.

Кичә Үзәк телевидение 1нче программадан Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр»ын күрсәтте. Әйбәт әсәр, акыллы язылган. Формасы яна. Сәхнә өчен бәлки драматик киеренкелек җитмидер, ләкин телевидениедә әйбәт яңгырый. Безнең театр, безнең язучылар Үзәк телевидениегә чыга—әйбәт. Әле күптән түгел генә Марсель Сәлимҗановка СССРның халык артисты дигән исем бирделәр. Бу да күңелле күренеш.

**28 август.** Бүген өйдә торабыз. Нурсөя компотлар ясады.

Бүгенгесе көнгә 2000 км юл йөргәнбез. Май урталарында беренче тапкыр чыккан идек. Димәк, дүрт айдан артык вакытта шунын кадәр йөрелгән. Түгәрәкләп дүрт ай дип алсаң, һәр айда 500 км юл була. Урын өстендә яткан кешегә ярыйсы инде бу.

**2 сентябрь.** Төштән соң тагын Фәниснең температурасы 40ка җитте. Скорый чакырттык. Уразова дигән врач килде, авызыннан сүзе чыкмый, һич ни сөйләгәнен аңлап булмый. Но-шпа уколы бирде. Температурасы югары булгач, больницага дигән иде, бармады Фәнис, бармасаң, кул куй, дип, подпись алып китте. Температурасы 39,7 иде, кабат градусникны куйдырды. Фәнис: «Әллә мин симулянтмы, больницага керергә тормыйм әле»,—диде.

Бүген **28 сентябрь.** Кичке сәгать 5тә Фәниснең температурасы кинәт күтәрелде 39,5 булды. 29 сентябрьдә иртән 38,2 иде, ә көндез 39,8 гә күтәрелде, кич 38,8. 28ендә 1 порошок антигриппин эчкән иде кичтән, йөрәк кызыша дип төне буе йоклый алмыйча бәргәләнеп чыкты, кулларына урын тапмыйча җәфаланды. Бу даруга димедрол кушыла икән, Фәнискә димедрол ярамый, йөрәге кызышып бик борчыла. Ә температураны төшермәде, реланиум (йокы даруы) эчсә дә төнлә күз дә йоммады. Гомумән, йокысы бик начар, температурасы булмаган вакытта да. Сидеге дә бик начар. Бенемицин эчә башлады. Ике капсула көнгә эчәргә, иртән һәм кич. Баш ярыла дип пенталгин да эчте. Күп дару да бирергә куркыта, кеп-кечкенә гәүдәгә ул дарулар күпме агу кертәдер.

**19 ноябрь.** Күптән көндәлек язган юк. Әллә нәрсә белән көн үтә. Бүген «Яшь ленинчы»га җибәргән бер хикәянең ахырын янадан эшләп куйдым. Ахырын редактор ошатмаган. Күптән ята иде инде чират көтеп. Җитмәсә, машинка ватык. Мастер чакырткан идек, көне буе көттек—килмәде. Быел машинка ватыла да ватыла. Дүртенче тапкыр ватылды инде. Өч тапкыр Габдрахман Алишевка алып барып төзәттергән идек, тагын алып барырга кирәк.

Киләсе елга чыгарга тиешле хикәяләр җыентыгының корректурасын бәйрәмгә кадәр үк укып җибәргән идем, һаман төшеп китә алмый икән әле, редактор шалтыратты. Бер хикәяне обллит уздырмаган...

**23 ноябрь.** Кичке сәгать 5тән соң Фәниснең хәле авырайды. Температурасы 39,9. кич 7дә промывка ясадым. Көндез һәм кич аш вакытларында 1 таблетка граммурин, кич 1 антигриппин, 1 но-шпа, кордиамин 20 тамчы. Йокларга 2 таблетка тазепам, 0,5 таблетка пенталгин эчте. Кич, хәле бик авыр вакытта спецклиниканың вакытлыча күчкән регистратурасын тапмадык. 03 чакыртсаң да файдасы шунын кадәр, йә алып китәбез дип баш әйләндерә, бармыйм дисә, отказга кул куйдырып китә. Көтеп күпме җәфаланып утырасың. Спецклиникадан чакыртсаң, дежур врач килә инде бер-ике-өч сәгатьтән. Укол ясый да китә, ичмасам, әз генә шул даруның тәэсирен дә көтеп тормыйлар. Фәнис артыгын тыйнак, врачны да сирәк чакырта. Ходайның бирмеш көне айга ике тапкыр чирләргәдер инде. Температурасы 39,9. кичке сәгать унда 39,5.

**26 ноябрь.** Өч көн буе бик матур гына чирләп яттым. Температура 39лар. Шимбә, якшәмбе көннәр булгач, врач чакыртып тормадык. Кул астында булган дарулардан файдаландык. Гомумән, мине иң интектергән нәрсә—йоклап булмау. Йоклап булса бер җир авыртмас төсле. Иң көчле йокы дарулары да ала алмый.

Бүген инде температура юк, ләкин авызга тәм кермәгән әле.

Кичә Гариф Ахунов шалтыратты. «Социалистик Татарстан»га килгән шигырьләргә күзәтү ясаган идем. Шәп булган, мондый мәкаләләрне синнән генә яздырырга кирәк икән, ди. Үз иҗатына таләпчән караган кешенең тәнкыйть сүзе үтемле була ул, ди. Ярый, бирсен Ходай.

**30 ноябрь.** Бер атна хәлем бик начар булды. Бүген ярыйсы әле, тфү, тфү. Мин чирләсәм кеше кебек кенә чирләмим, кырыкка җиткереп ятам. Температура беткәч тә аппетит булмыйча җәфаланам.

Өченче көн Рәшит Әхмәтҗанов сидуксен һәм бер бик зур тавык боты керткән иде. Кичә шуның тавык ботыннан аш пешереп ашаган идек, шуннан соң аппетит ачылды. Рәшиткә тавыгың шифалы булды дип әйтергә кирәк әле, сөенсен.

Бүген телевизордан минем чыгыш. Ничегрәк төшкәнмендер инде.

Бу арада көннәр бик салкын тора. 27 градус әле. Ә өйдә 15-16 гына. Юрган астында җылы киемнәр киенеп ятмалы.

**6 декабрь.** Телевизордан чыгышны ошаттылар бугай. Күп кенә танышлар шалтыратты. Ләкин язучылардан күп кеше карамаган, чөнки ул көнне Тукай клубында әдәби җомга иде.

Әле һаман бисиптол эчәм. Салкын тию бетми. Ютәл килеп чыга, борыннан ага.

Кичә 36 нчы мәктәптән 8 «А» класс укучылары килде. Укытучылары күптән инде бер очрашасы килә дип шалтырата иде. Рус балалары белән уртак тел табуы кыенрак. Чөнки минем бит русча чыккан әйберләр бик әз. Алар шул «Упругие паруса»ны укыганнар инде. «Татар язучыларыннан кемнәрне укыганыгыз бар?»—дип сораган идем. Г.Әпсәләмовның «Орлята»сын укыганнар икән. Рус язучыларыннан кемнәрне яратасыз, дигәч, классикларны дип җавап бирделәр. Исемнәрен сорамадым инде, оялтасым килмәде. Гомумән, балалар әдәбиятны бик әз укый. Алар яшендә безнең укымаган китап булмагандыр. Минем янга ни өчен килгәннәрдер болар, укытучылары, фәлән язучы белән очрашырга дип, бәлки, «мероприятие» планлаштырган булгандыр.

Берсекөнгә безнең бәйрәм. Татарстан Язучылар союзының 50 еллык бәйрәме. Опера театрында җыелышып тантаналы төстә билгеләп үтәчәкбез. Барасы килә, ләкин тазалык та шәп түгел. Язучылар съездына барып кайткач та 40 белән яттым. Әле ул җәй көне иде. Бусы кыш бит. Оештырсалар, бәлки, барырмын да дип торам.

**9 декабрь.** Кичә тантаналы җыелышка бардык. Камил Кәримов белән Госман Садәне күтәрешергә чакырган идек. Алар мине дә, колясканы да таксига чыгардылар. Үзебез такси чакыртып бардык. Союз мине алып баруны оештырмады. Шулай да баруым ярады инде, Опера театрының эчен күреп кайттым. Опера карар өчен барып булмас иде әле. Докладлар вакытында утырып тордым, концерт башлангач, залда утны сүндергәч, колясканың артын төшереп, бераз ял итеп алдым. Нурсөянең бик алып барасы килгән иде инде. Көн салкын гына иде. 15-16лар булгандыр. Сразы машинага утыргач, бик өшетмәде инде. Опера театры мин көткәнгә караганда кечерәк тоелды. Болай матур бизәлгән үзе. Концерты ах итәрлек түгел иде. Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Газинур Фарукшин, Вафирә Гыйззәтуллина, Ринат Ибраһимовлар җырлады. Иң әйбәт җырлаучысы Х.Бигичев булды бугай.

Язучылардан Лев Ошанин, РСФСР литфонды директоры урынбасары, Мари язучылар союзы председателе (фамилиясе Рыбаков) чыгыш ясадылар. Р.Беляев, Т.Миннуллин докладлары булды, С.Хәким кызык кына чыгыш ясады. Хәтта аның өчен кыен чыгыш дияргә мөмкин. Без, ди, хәзер язучылар союзына член итеп вактөякләрне ала башладык. Үзем дә гаепле, чөнки приемный комиссиядә утырам.

Алмас иден, төрле яктан кысалар, Курск дугасындагы кебек, ди.

Бик күп язучылар килеп күрештe. Н.Фәттах,Ф.Хөсни, К.Миннебаев, Ш.Галиев, Т.Миннуллин, Р.Харис, Р.Гатауллин, Р.Вәлиев, Г.Зәйнашева, Р.Батулла, Әдхәт Синугыл, Г.Рәхим, Р.Миннуллин һ.б., һ.б.

Беркөнне очрашуга килгән укучылар: «Барлык язучыларны күреп беләсезме?»— дип сораганнар иде. «Күбесен беләм»,—дияргә була инде хәзер. Быел съездга һәм монда барып шактый кеше күрдек.

**14 декабрь.** Һаман бисептол эчәм. Шулай ук каен бөресе настойкасы. Берничә көн туктап торган идем, тагын кайдадыр салкын тигән, ахры.

Быел өйләр салкынча тора. 20ләр тирәсе. Көн суытса аннан да кими. Тәннен ите беткәнгәдер инде, күрәсең, әзгенә суык та ярамый.

**16 декабрь.** Бүгеннән мумиё эчә башладым әле. Сафуан абый бик мактый аны. Үлгән кешене дә терелтә дип сөйли. Мин андый нәрсәләргә ышануын ышанмыйм. Шулай да бер сынап карыйм дип булса да эчәсен инде.

Соңгы вакытларда тагын дару белән дә йоклап булмый башлады. Эч поша. Ныклы гына эшләгән эш юк. Сирәк-мирәк шигырьләр язгалыйм. Башны әллә нинди чуп-чар уйлар баса. Кирәкмәгән нәрсәләр уйлап көн үтә. Бу арада кичләрен телевизор да караган юк. Ремонтка илткән идек, әле тагын атна-ун көнсез төзәтмәсләр. Икенче бер кечкенәне алырбыз дигән идек, кибетләрдә юк икән.

Яна язу машинкасы «Эрика» алган идек. 280 сумга. Татар хәрефләре куйдырырга дип бер алкашка биреп җибәрдек тә, хәзер шуңа эч поша инде. Алып киткәндә үк исерек иде. 13е алып киткән иде, китерми әле. Володя атлы бәндә. Кемгә эш кушсаң, шул алкаш. Үзем дә дурак инде, өч йөз сумлык машинка өстенә 25 сум акча да биреп җибәрдем. Эчми нишләсен инде ул.

**27 декабрь.** Елның соңгы көннәре. Салкын. Иртән 28 градус иде. Мумиёны бер генә көн эчтем дә, нишләптер туктаттым. Зәкия апалар килде. Кеше килсә дә режим бозыла бит.

Нурсөянең дә тазалыгы шәптән түгел, беркөнне аякларының сызлавына чыдый алмыйча елап чыкты. Кышка кердисә кычынуы башлана. Кичәдән тоз һәм ылыс ванналары чиратлашып ала башлады. Бүгеннән грамурин эчә. Аның да әзрәк йөреп керсә бөерләре кузгаламы шунда. Бандаж да киеп йөри инде. Гел күтәрергә туры килә, мине ваклап-ваклап күтәреп булмый бит. Әле телевизорны ремонтка күтәреп киткән иде, аны алып кайтасы бар.

Язу машинкасын китерде Володя. Бик шәп эшләмәгән инде. Житмәсә, өндәү билгесен югары регистрга куйган. Бу машинканың ударлары бик көчсез. Немецлар да әштер-өштергә өйрәнә башладылар, ахры. Теге иске машинканың, моннан 25-30 ел элек ясалганының удары шундый шәп. Өстәвенә интервалын кирәгенчә көйләп булмый. Тагын берәр мастер чакыртырга туры килер инде.

Бүген Айтуган абый шалтыратты: китапның сигнальный экземпляры чыккан. Бер 15 көннәрдән бөтенләй дә чыгар инде.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Органга—өрделәр

Анардан күпләр шүрләде. Күзенә чалынмаска теләп, түрә тикле түрәләр кырын карап узды. «Правда»чы, соңрак «Чаян»чы дигән кушаматы өркетте аларны.

Өлкән буын искәрде, әлбәттә. Бу «усал кеше»—Сабир Сәлмән улы Бәхтияров. Алдан ук әйтеп куям: Сабир агай бер дә явыз түгел, киресенчә, гаять итагатьле, зыялы зат иде. Бераз гына мутлыгы бар-барын. Кызлар күзләргә яратты. Монысын, сердәш егете буларак, мин генә белдем. Серебез шунда ук мәңге ачылмас сандыкка бикләнде. Аның белән илленче еллар башында ук танышкан идек. Теге сер тирән яшерелгән, анысын язып тормам, ахрысы...

С.Бәхтияров 1913 елда Башкортстанда туган типтәр. Казанда тәзүчеләр институтын тәмамлый. Бусы ничек алайдыр инде: ажгырып торган ир-егет алгы сызыкта булмыйча, сугыш тәмамланганчы ук, Мәскәүдә югары партия мәктәбендә укый. Мин танышканда «Правда» гәзитенең урындагы үз хәбәрчесе иде. Атаклы фельетончы. Республика түрәләрен утлы табада биетте. Талант ягына килгәндә, үткен каләмле, күсәге юан, эшлексез-гамьсезләрнең башына каты бәрде, бүтән тормаслык итеп орды. Шунын өчен үзен дә күралмадылар. Башта Мәскәү орды үз хәбәрчесенә. Өстеннән әләкләр күбәеп киткәндер дип беләм.

Аннары эшсез калган, ләкин партия номенклатурасында торган С.Бәхтияровны партия өлкә комитеты бюросында «Чаян» журналынын җаваплы редакторы итеп расладылар. Чуртанны суга җибәрү иде монысы. Гаебе бар икән, кемнең кемлегенә карамастан, бигрәк тә аерым җитәкчеләрне тәнкыйть утына алуын дәвам итте. Ул редактор чакта «Чаян»да шактый фельетоннарым, кыска юмористик-сатирик хикәяләрем басылды. Тегелмәләрдә барысы да саклана. Сабир Сәлмән улы үз хәбәрчеләрен фельетонга әләккән явыз җитәкчеләрдән яклый белде.

Кыскасы, С.Бәхтияров ора бирде, аны урындыгыннан өрә тордылар. «Чаян» журналыннан да шулай китте, дөресрәге, пенсия яшен сылтау итеп, китәрделәр.

Ни әйтәсең—фельетончы язмышы!..

## Күчем хан токымы

Үземә, чыннан да, берәр төрле министр буласы калган аны! Тик утырыр идем шунда гозер белән килгән гражданнарны кабул итеп. Редакциядә бит анда шикаять белән килүчеләрнең артыннан үзең чыгып йөгерәсең. Йә җиң сызганып эшкә тотынасың...

Себердән килгән Якуб абзый Зәнкиев белән ни чыгып китеп булмый, ни эшләр әмәл юк. Калын күзлеге аша текәлеп, сине бораулый башлый. Өстәлгә бер көлтә мәкаләләрен таратып сала да һәрберсенә бармак төртә-төртә тезеп китә:

—Менә бусы мәктәпләрдә татар телен укыту тәҗрибәсе—беренче чиратта басылырга тиеш. Мәдәни кичәләр калып торса да ярый. Түмән татарлары сөйләме, аларның гореф-гадәтләре икенче рәттә бара. «Күчем хан тарихы»н карап җибәрергә онытма! Өчесе дә бик мөһим! Болары...

—Ярар инде, Якуб ага, чираты белән һәммәсе дә басылыр,—дим.—Әлегә мәкаләләрегезнең кире борылганы юк. Өстәмә фактлар соралса, хәбәр итәрмен.

—Оныталар бит, әдәбият бүлегендә кешеләре дә еш алышынып тора.

—Контроль хатлар бүлегендә ич, Якуб ага.

—Ярар алайса, сиңа ышанам, иптәш Гумеров.

Себер татары белән гәпләшү шулайрак дәвам итә. Аны игътибар белән

тынламыйча ярамый. Сугыш ветераны, РСФСР мәктәпләренең атказанган укытучысы, фольклорчы галим. Әйткәнемчә, Төмән сөйләшенең бөтен шивәләрен (диалектларын) нечкә белүче.

Бер заман, житмешенче елларда жиде йөз битле (кульъязмада) калын гына роман күтәреп килде. Моны гомерем буе яздым, ди. Бу юлы инде хәбәрчебезне турыдан-туры Татарстан китап нәшриятына жибәрдек. «Иртеш таңнары» дигән әлеге роман, нәшрият редакторлары тырышлыгы белән, 1974 елда аерым китап булып басылып чыкты. Бер данәсе мина да эләкте. «Казандагы дустым, талантлы журналист Гусман (анынча) Гумеровка бер истәлек», дип автографын имзалап бирде. Әсәр китап киштәмнең күренекле урынында узган елларым хатирәсе буларак әле дә саклана. Берәр китапханәгәме, музей-фәлән гәме тапшырырмын дип торам. Автор 2002 елда «Иртеш таңнары» китабы өчен Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек дип табылды. Бусы шатлык өстенә шатлык иде. Ни дисән дә Өркет (русчасы Иркутск) шәһәрендә туган Якуб ага Зәнкиев гомере буе безнең Себердәге ин кадерле кунагыбыз булып яшәде. Барыбыз өчен дә кызыксынып укырлык тарихи роман язып калдырды. Тагын бер кат укып чыгыгыз әле шул әсәрне!..

## Шүрәле аулау

Соңгы йөзьеллыкта яшәп киткән шәхесләр арасында аныкыдай сәер исем-фамилия очрамады шикелле. Желеген сугыш суырган арык-ябыклар янында юантык гәүдәле, жор телле шаян сүз остасы, атаклы татар рәссамы Байназар Әлминев нык аерылып торды, һәммә гамәлләре дә анын һөнәри талантына тәңгәл килә иде димәсән...

Кардәшем шунда эшләгәнгә Матбугат йортының дүртенче катына урнашкан Татарстан китап нәшриятына еш күтәреләм. Яныбызга коридорның аргы башыннан авыш-түеш атлап Байназар абзый килеп туктый. Ярата ул безне. Әзер рәсемнәрен, әле эшләнеп бетмәгән эскизларын мактый-мактый караганга.

—Әйдәгез әле, «һинд» чәен татып карыйк (чәйнен дифицит еллары), сыйлыйм үзегезне,—дип, бүлмәсенә алып кереп китә.

Байназар Әлминев Татарстан китап нәшриятында озак еллар буе басмаларны иң яхшы бизәүче рәссам булып эшләде. Анын Габдулла Тукай әкиятләренә ясаган сурәтләреннән генә дә зур-зур күргәзмәләр оештырырга мөмкин иде. Төрле халәттәге Шүрәлеләрне озаклап карыйбыз—үзебезчә мактыйбыз.

—Былтыр дигән батыр егет син түгелме соң, Фәсхетдин?—ди Байназар абый хезмәттәше, авыл хужалыгы бүлеге мөхәррире Ф.Шакировны шаяртып.

—Ә Шүрәле кем?—дибез.

—Бәлки, Мөжәйдер,—ди рәссам. Анысы нәшриятнын баш редакторы Мөжәһитовка ишарә инде.

—Пумала чәчле «Су анасы» танылмый менә!

—Сәлимә дип уйлый күрмәгез тагын. Безнең секретарша чибәрләрнең чибәре. Характеры ясалса, ясалгандыр,—дип йомгаклый әңгәмәдәшебез бу теманы.

Чыннан да Сәлимәкәй кәттә ханым. Аны Су анасына тиңләрлек түгел.

Шундый шаян табигатьле, биниһая талантлы рәссам иде Байназар Әлминев. Дөнья тиклем китаплар бизәү белән беррәттән, заман Шүрәлеләрен аулауга да зур әһәмият бирде. Андыйлары озак еллар буе «Чаян» журналында басылып килде.

Ахырдан «Автошарж» ясап, үзен тарих өчен мәңгеләштерде. Исеме жисеменә мач булган икән дим!..

**Госман ГОМӘР**

## Мәхмүт Галәүнең тууына 125 ел

Мәхмүт Галәү (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани)—XX гасыр татар реалистик прозасының күренекле вәкиле, татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салучыларның берсе, драматург, журналист, нашир, публицист, тәрҗемәче.

Язучы 1886 елның 8 сентябрендә хәзерге Татарстанның Арча районы Ташкичү авылында мөгаллим-хәлфә гаиләсендә туа. Нәсел шәҗәрәсе белән ул татарның бөек мәгърифәтчесе, дин һәм тарих галиме Шиһабетдин Мәрҗанигә якын кардәш тия. Әдипнең бабасы—Мәрҗанинең бертуган энесе.

Башлангыч белемне әтисеннән алгач, ул Казандагы «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлый. 1903 елда Әстерхан татар мәктәбенә мөгаллим булып урнаша. 1907 елда Әстерханда дөнья күрә башлаган рәсемле көлке журналы «Туп»ны оештыручылардан берсе була. Милли-мәдәни җәмгыятьләр һәм сул юнәлештәге яшерен оешмалар белән элемтәдә торуда гаепләнеп, ул охранка тарафыннан эзәрлекләнә башлый. 1907 елда Мәхмүт Галәүне мөгаллимлек эшеннән чыгаралар. Шул елны ул Оренбургкка күчә һәм «Кәримов—Хөсәеновлар» ширкәтенең типографиясенә хәреф җыючы һәм корректор булып эшкә керә. 1914 елда «Белек» исемендә кечкенә генә үз нәшриятын ачып, 1918 елга кадәр аның эшенә җитәкчелек итә. 1911 елда Мәхмүт Галәү беренче сыйныф балалары өчен «Төрки уку китабы» исеме белән табигать, тәрбия, хезмәт, төрле һөнәрләр турындагы хикәяләрдән төзелгән ике кисәкле хрестоматия китабы бастыра.

Октябрь инкыйлабы Мәхмүт Галәүнең тормышын кискен үзгәртә. 1919 елда ул—Башкортстан Халык Мәгарифенең кантон бүлегендә мәктәпләр секторы мөдире, 1920 елда—Оренбург губернасының мәгариф бүлегендә нәшрият эшләрен җитәкли. 1921 елда эшсез калгач, хосусый нәшриятларда хезмәт итә. Алар таратылгач, Мәскәүдәге Мәркәз нәшриятында эшли. 1930 елда югары даирәләргә язган бер шикаять хатында ул: «1926 елдан бирле мин тагын эшсез. Ничек кирәк алай, ярым ач хәлдә көн кичерәмен»,—дип билгеләп үтә. Иң гаҗәбе шунда: М.Галәүнең матур әдәбият өлкәсендәге нәтиҗәле иҗат эше нәкъ менә шул елларга туры килә. Әсәрләрдә яна кеше проблемасы, искелек белән яңалык көрәше, шәһәр белән авыл мөнәсәбәте кебек әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә («Каяу», «Күкеле сәгать», «Күпнең берсе», «Төеннәр», «Искедән калган мирас» һ.б. хикәяләр).

Язучы үзенең каләмен драматургиядә дә сынап карый: «Саламторханнар», «Курчак туе», «Пугач явы» исемле пьесалар иҗат итә. Мәхмүт Галәү үзенең күңеле түрендә йөрткән күптәнге иҗади хыялын—татар халкының зур бер чор эчендәге тарихи тормышын инләп алган эпопея язу турындагы ниятен эшкә ашырырга керешә. Гомуми исеме «Канлы тамгалар» дип алынган бу эпопея дүрт китаптан торырга тиеш була. Беренче китапта XIX гасыр татар авылының, авыл һәм шәһәр халкының 1877 елгы ачлык фаҗигасен кичерү вакыйгалары, икенче китапта 1897 елгы халык исәбен алу, шуңа бәйле рәвештә авыл халкының фетнә күтәрүе һәм Төркиягә күчеп китүе, өченче китапта рус-япон сугышы һәм 1905 елгы беренче инкыйлаб чоры һәм, ниһаять, «Өермәләр» дип исемләнгән дүртенче томда большевиклар инкыйлабы елларындагы давыллы вакыйгаларны гәүдәләндерү күздә тотылган була. «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнары безгә 1930-34 елларда Мәскәүдә русча чыккан басмалары һәм шуларның татарчага тәрҗемәләре аша билгеле. Өченче һәм дүртенче кисәкләре, каралама хәлендә әзер булсалар да, әдипнең кульязма архивы белән бергә юкка чыгалар.

Замандашларының истәлекләренә караганда, Мәхмүт Галәүне Мәскәүдәге фатирында кулга алып, хөкем итәр өчен Казанга китерәләр. Махсус коллегия утырышы 1937 елның 4 ноябрендә була. НКВД биргән белешмә кәгазе буенча әдипнең вафаты (атып үтерелүе) 1938 елның 12 ноябрендә дип фараз кылына.

## Хәниф Хәйруллинның тууына 80 ел

Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин 1931 елның 12 сентябрендә Татарстанның Сарман районы Сарман авылында туа. 1950 елда авылындагы урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, бер ел шул ук районның Азалак авылында укыта. 1951—1956 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аннары утыз елга якын район газеталарында (Сарманда—«Югары уңыш өчен», «Ленинчы», Буада—«Байрак») хатлар бүлеге мөдире, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип вазифаларын башкара.

Хәниф Хәйруллин—әдәбиятка журналистикадан килгән язучы. Аның беренче очерклары, колхоз авылы тормышының төрле мәсьәләләренә багышланган публицистик мәкаләләре көндәлек матбугатта илленче елларда күренә башлый. Озак вакытлар авыл мохитендә яшәү һәм газета редакциясендә эшләү аңа колхоз тормышы, хезмәт кешеләре, аларның эш-гамәлләре, борчу-шатлыклары, уй-хыяллары белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә. Бер үк вакытта ул туган төбәгенең революцион үткәнен, Гражданнар сугышы һәм колхозлашу чорында анда барган социаль үзгәрешләрне, катлаулы вакыйгаларны җентекләп өйрәнә. Тормыш материалы нигезендә Х. Хәйруллин алтмышынчы еллар дәвамында документаль бәянгә (повесть) тартым «Бакыр базының серләре», «Алмаз ихтыяр», «Канлы еллар, авыр еллар», «Хуҗида үскән батыр» кебек очеркларын һәм балалар өчен «Тылсымлы таяк табышы» исемле мажаралы бәянен иҗат итә.

Шулай да Х. Хәйруллинны язучы итеп танытакан әсәр—«Канатлар талмасын» бәяне. 1971 елда язылып, башта «Казан утлары»нда (1973 ел, 1, 2 саннар), соңыннан аерым китап булып чыккан бу әсәрне укучылар да, әдәби тәнкыйть тә авторның җитди уңышы итеп кабул итәләр. Әсәрдә автор алтмышынчы еллар колхоз тормышында барган үзгәрешләр, яңалыклар җирлегендә хуҗалык белән идарә итү, җитәкче кешенең (колхоз председателенең) хезмәтне яңача оештырудагы роле кебек актуаль мәсьәләләрне күтәрә, уңышлы яклар белән бергә, кимчелекле якларны да күрсәтә һәм шул заманга хас булган каршылыкларны ача.

Х. Хәйруллин шулай ук авыл тормышына багышланган һәм кешенең холык-фигылен әхлак нормалары күзлегеннән, фәлсәфи-психологик планда ачарга тырышкан «Картлык... кемгә шатлык?» исемле бәян авторы буларак та укучыларга билгеле.

Язучы 1998 елның 25 июнендә вафат була.

## Илдар Низамовка 75 яшь



Язучы, публицист Илдар Низамов 1936 елның 3 сентябрендә Әтнә районы, Олы Бәрәзә авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлагач табигатьне ярату, елга-диңгезләрне кичәргә омтылу аны Казан елга техникумына укырга алып килә. Техникумнан соң Агыйдел елга пароходчылыгында штурман булып эшли башлый, армиягә алынып, хезмәтен төгәлләп кайткач та инженер-диспетчер булып эшен дәвам итә.Студент вакытында әдәби иҗат эшен башлаган егет 1960 елда Уфага «Кызыл Таң» газетасына эшкә чакырыла, биредә ул Башкорт дәүләт университетының татар филологиясен читтән торып тәмамлый.

1968 елда И.Низамов янәдән Казанга кайта һәм 1974 елга кадәр «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли.

1974-1976 елларда Мәскәүдә Югары партия мәктәбендә укып кайтканнан соң И. Низамов ун ел Татарстан китап нәшриятында иҗтимагый—сәяси әдәбият редакциясе мөдире булып хезмәт куя, аспирантурада белем ала. 1981 елда филология фәннәре кандидаты исеменә, 1996 елда исә профессор дәрәҗәсенә ия була, Казан дәүләт университетының татар журналистикасы кафедрасында өлкән укытучы, доцент вазифаларын башкара.

Илдар Низамов иҗатының төп тематикасы—табигать, анын җанлы гәүдәләнеше. Татар халкының күренекле шәхесләре турындагы очерклар, әдәби парчалар анын «Күнелендә ниләр бар?» (1970), «Дәрья күзе» (1974), «Өмет» (1977), «Илдә мин дә сандугач» (1978) сайланма әсәрләр рәвешендә нәшер ителгән «Мәхәббәт хакы» (1986) җыентыкларында урын алган.

Илдар Низамов—татар телен, сөйләм үзенчәлекләрен чын күңелдән кайгыртып, аның яшәешенә күп хезмәт куйган галимнәрдән. Ул—әлеге өлкәгә караган дистәгә якын дәреслек, кулланма программалар, йөзгә якын фәнни мәкалә авторы. «Матбугатның тәэсирле сүзе», »Уем—тел очымда: татар сөйләме нигезләре», «И туган тел» h.б. китаплары әнә шундыйлардан.

И. Низамов татар телен саклау, үстерүдәге фәнни эшчәнлеге белән берлектә Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы телләрне гамәлгә ашыру комитеты әгъзасы, Республика терминнар комиссиясе рәисе булып та эшли.

Матбугат өлкәсендәге тырыш хезмәте өчен ул 1980 елда Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясенә, 1987 елда исә «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була, 1979 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!



Рашат Низами

# ТӨСЛЕ КАРАНДАШЛАР

Инде егерме еллап вакыт үтсә дә,ул чактагы вакыйгалар,кино тасмасындагы кебек,күңелдә нык уелып калган икән шул.

...Беренче сентябрь иртәсе. Мин,җиде яшьлек малай,зурларча итеп беренче тапкыр мәктәпкә барам. Яраткан этем Акбай белән җәй буе казлар көтеп,бу күңелсез хезмәттән шактый туйган идем. Инде менә минем өчен дә аңлап бетермәгән өр-яңа кызыклы дөнья башланачак. Сумкалы,китап-дәфтәрле,каләм-ручкалы,бәйрәмдә генә кия торган яңа күлмәкле яңача тормыш...

Әнием мәктәпкәчә озата килде мине. Каршы алучы укытучының кулына тапшыргач,эшенә китеп тә барды ул. Укытучы апа исә мине өлкәнрәк сыйныф малайлар кулына тапшырды,мәктәп бинасына узарга булышыгыз,янәсе.

Тегеләр,көлешә-көлешә,бер-берсенә күз кысып,мине үзләренә эләктереп тә алдылар.Бусаганы атлап,киң генә коридор уртасына килеп кердек.Ак буяулы ниндидер ишек каршында туктаттылар мине.

—Шакы,тиз!—диде малайларның берсе,көлемсерәп. Тыңламыйча булмый ич инде. Кызык ич. Нәни йодрыгым белән ишек тактасын шакыйм. Ишек үзенчә бер тылсым белән ачыла башлаган иде,этеп-төртеп мине шундук бүлмә эченә кертеп тә җибәрделәр.

Килеп керү белән аркама кинәт,чыжылдатып,җиңелчә ике тапкыр талчыбык белән сыдырдылар. Кулымда күпме тапкыр чыбык тотып та казларга ник бер тапкыр сукканым булсын минем. Шуңа күрәме ,куркудан кычкырып җибәрә яздым.

—Тс-с,шаулама! Шулай тиеш...—диде малайларның өлкәнрәге,эшнең зурга китүеннән куркып.

—Шулай тиеш!—дип куәтләде аны икенчесе.

—Син мәктәптә беренче тапкырмы?

—Әйе,беренче...

—Сине нәрсә белән сыйларга соң?.. Тукта,—диде бер малай һәм кара такта янындагы тартмадан шикәрдәй ап-ак акбур кисәге тартып чыгарды.

—Аша шуны! Шулай тиеш...

Мин акбурны кулымда әйләндергәләп тордым-тордым да авызыма каптым.

—Тиз бул, камырша!—дип ашыктырды мине малайлар, үзләре исә канәгатьлектән буылып көләләр.

Акбур үзе ни ачы да, ни төче дә түгел. Авызымда күпмедер әвәләгәннән соң, мин аны, сытып-ватып, ихтыярсыздан төкерегем белән бергә йотып җибәрдем. Мәктәпнең беренче сые әнә шундыйрак булды.

Авыз кырыемда әлеге сыйның эзләре уелып калган икән, укытучыбыз Мансур абый:

—Син нәрсә, малайка, мәктәпкә аяк басмас борын акбурга буялып беткәнсең,—дип орышып алды үземне.

* * *

Икенче көнне мин тагын куанып та, бераз куркып та мәктәпкә барам менә. Терсәкләрем белән аркамдагы сумкамны рәтләгәндәй итәм. Көн матур, кояшлы. Юл кырыендагы яшькелт үләннәрдән ниндидер хуш, дымлы ис бөркелеп тора. Мәктәпкә илтүче сукмагым өстендә берән-сәрән генә алтынсу яфраклар да ялтырый.

Чү, сукмакның бер читендә, куе чирәмлек эчендә, озынчарак кына кәгазь тартма күзгә чалынды!.. Як-ягыма каранып та тормыйча, мин аны тизрәк иелеп алам. Тышлыгына салават күпере төшерелгән бу тартмада «Цветные карандаши» дигән сүзләр ярылып ята. Аның тәрҗемәсенә ул чакта төгәл генә төшенеп җитмәсәм дә, тартма эчендә җиңелчә шылтыраган тавышлардан шуны аңладым: карандашлар бу!..

Табышым бик тә кызыктыргыч иде шул, магнит сыман тәмам үзенә тартып тора. Каушый-каушый гына ачып карасам—тартма эчендә, бер-берсенә елышып, җиде төстәге җиде карандаш посып ята. Төсле карандашлар... Тышлыктагы салават күпере үзе дә әнә шунда кереп яткан диярсең...

Кем калдырган моны? Аны кемдер югалткандыр дигән уй башыма да кереп карамады. Төнлә күктән, йолдызлар арасыннан килеп төшкәндер сыман тоелды ул миңа. Әбием әнә, балык һәм бакалар да күктән төшә, дип сөйли торган иде бит. Ә нигә ышанмаска ди? Йолдыз атылганнан соң, шуның кыйпылчыгын эзли-эзли бәрәңге бакчасын таптап бетергәнем булды минем.

Табылдык карандашларны тартмасы-ние белән тизрәк сумка төбенә яшердем. Бераздан шатлыгым... курку белән алмашынды. Кемнеке булырга мөмкин бу карандашлар? Аның күктән төшүе икеле бит...

Кыңгырау шалтырау белән мәктәп коридорында шау-шу басылды, дәресләр башланды. Сумкамны сак кына, куркып кына ачам. Кемдер карап торыр да табышымны күреп алыр, «минеке!» дип бөтен класс алдында кычкырыр шикелле. «Әлифба» китабын сак кына тартып чыгарганда карандашлар җиңелчә генә кыштырдап алды. Ни кызганыч: менә нинди карандашларым бар дип мактанырлыгым юк иде минем.

Бер дәрес узды... Икенче дәрес... Минем бәхеткә күрәме, төсле карандашлар турында ләм-мим, беркайда бер сүз дә әйтүче күренми. Өченче дәрестә дә мине тетрәтерлек, мине уңайсыз хәлләр каршында калдырырлык вакыйгалар булмады. Инде таралыр чакка да ерак түгел.

Ә менә дүртенче дәрес... рәсемнән иде. Укытучыбыз Мансур абый—авылның оста рәссамы. Плакатлар язу, мәктәп яисә клуб бинасын төрлечә бизәүләр бар да аның кулы аша уза.

Ул класска керү белән, каз бәбкәләредәй калкынып, дәррәү аякка бастык. Кулындагы озынча линейкасын өстәлгә этәрде. Бу линейка миңа яссы бер талчыбык сыманрак тоелды. Аермасы шунда—бөгелүне белми, туры гәүдәле ул.

Без үзебезнең рәсем дәфтәрләрен партага чыгарып салган арада ул үзе кара такта тирәсендә туктаусыз бөтерелде. Вәт гаҗәп! Шаккатып карап торабыз: ә дигән арада анда чып-чын кишер һәм алма сурәтләре пәйда булган иде...

—Менә сезгә үрнәк,—диде укытучыбыз бик таләпчән төстә.—Шушы ике сурәтне ашыкмыйча гына дәфтәрләрегезгә ясый башлагыз. Карап карыйк, кемнеке ничек килеп чыгар икән...

Безнең япь-яшь башкайларыбыз тук башактай аска иелде, һәркемнең каләме яңа ачылган дәфтәр битендә кишер һәм алма сурәтен ясау белән мәшгуль иде.

Мансур абый, кулындагы линейкасын мәгърур гына тотып, парта рәтләре арасыннан йөренә башлады. Кем ничек,ни рәвешле булдыра,аның күрсәтмәләрен ничегрәк үтиләр,янәсе. Менә ул урамның иң югары очында яшәүче Лотфи янына килеп тукталды. Малайның кул аркасына «шап» итеп линейка сырты килеп төшү белән,барыбыз да берьюлы сискәнеп,шул якка таба борылдык.

Укытучының тавышы усал,гайрәтле яңгырады:

—Торып бас! Ә син нигә каккан казык кебек тик утырасың?..

Лотфи мескенебез бер агарды,бер күгәрде. Елар дәрәҗәгә җитеп аягүрә басты. Тимерче Хәсәншәех малае ул, әтисе телсез. Үзе сөйләшә алмаса да, тимернең телен яхшы белә дип сөйлиләр аның хакында. Аракы эчкән кешене җене сөймәс аның. Күптән түгел әнә Мансур абый салмыш килеш аның тимерче алачыгына килеп кергән. «Булдыра алсаң,миңа тимер чәчәк ясап бир әле»,—дип, кул хәрәкәтләре белән аптырата икән. Хуҗа кеше моны мыскыллау дип аңлаган һәм алачыгыннан куып чыгарган аны.

Менә шуның өчен карандаш хәтле Лотфидан үч алырга тырышуы түгел микән? Әнә каныкты,бәйләнде бит шуңа:

—Син нигә эндәшмисең,малай актыгы?

Лотфи мышык-мышык килә,җөмләсен дә авызыннан өзеп-өзеп кенә чыгара:

—Мин төсле карандашларымны... югалттым...

Аның бу сүзләреннән соң тәнемә ток китереп суккандай булды! Менә ничек икән... Мишә елгасында җәй буе бергә су коенып үскән иптәш малаемның карандашларын тапканмын да аны сумка төбенә каракларча яшергәнмен ләбаса... Сумкама кагылырга, якынаерга куркам—теге карандашлар парта өстенә сикереп менәрләр дә минем чын йөземне фаш итәрләр кебек. Классташларым «алдакчы» диеп кенә калмаслар,«карак» диеп тә бармак төртеп күрсәтәчәкләр үземә.

Лотфиның калтыранып әйткән сүзләре бу юлы инде колак пәрдәсен ертып алды кебек:

—Әти шәһәрдән алып кайткан иде... Ух,өйгә кайтсам,үтерә бит ул мине... Ой!..

Мансур абый җилтерәтеп малайны почмакка илтеп бастырды.

—Тик утырганчы әнә шунда басып тор! Дәрестән соң калырсың... Синең белән икәүдән-икәү генә аерым сөйләшербез.

* * *

Дәреснең тизрәк беткәнен көтә-көтә тәмам көтек булдым. Күз алдымда,төсле карандашлар белән бергә,кишер һәм алма сурәтләре туктаусыз биешә...

Кайтканда,юк-бар сәбәп табып,сабакташларымнан артта калдым.

Гөнаһсыз сумкам авырайды,җилкәмне таш кебек аска тарта. Мин, бөкре малай сыман,башны түбән иеп атлыйм. Җиде төстәге җиде карандаш,җиде ук булып,тәнемнең әллә кайсы төшләренә кадала төсле.

Мин куркаклык күрсәттем бугай,дөресен әйтеп бирергә кыюлыгым җитмәде. Чөнки «алдакчы»,«куркак» дигән сүзләрне табигатем күтәрә алмас иде. Ә менә Лотфи минем аркада әнә нинди бәхетсезлеккә,җәзага дучар ителде.

Белмим,гаебемне ничек йоласы да,бу бәладән,авыр йөктән ничек котыласы икән?

Аякларым ирексездән чирәмлеккә таба атлады. Менә бит ул, менә: мине гөнаһка тарткан урын!..

Караңгыда кинәт ут кабынгандай,аңымда бер уй яктырып китте! Мин үзем өчен бик тә җайлы,уңайлы чишелеш таптым бугай...

Песи сыман як-ягыма каранганнан соң,сумкадан карандаш тартмасын сак кына тартып чыгардым. Менә ул элекке урынына,куе чирәм арасына чалкан төшеп ятты. Бу минутларда минем нинди канәгатьлек,рәхәтлек кичергәнемне белсәгез икән! Күңел кинәттән канатланып китте. Сумкам да ничектер үзеннән-үзе җиңеләеп калды шикелле.

Хәзер инде Лотфиның мәктәптән кайтканын көтәргә кирәк.

Ул озак көттермәде. Әнә, канаты салынган коштай, вак-вак атлап сукмактан килә. Мин, очынып-атылып, сөенче алыр өчен аның каршына йөгерәм...

—Лотфи, сөенче!.. Карандашларны юлда таптым, әйдә, тиз бул...

Сабакташым башын күтәрде, нәни гәүдәсе тураеп-озынаеп китте, күзләрендә шатлык очкыны кабынды.

— Чынлапмы, малай?..

— Чынлап... Әнә, күрәсеңме?—дип бармагым белән чирәмлек арасына төртеп күрсәтәм.

Лотфиның ничекләр сөенгәнен күрсәгез иде! Зур ачылган күзләренә йолдыз тамчысы кунды диярсең. Төсле тартманы иң кадерле, газиз бер нәрсәседәй ике куллап күкрәгенә кысты.

— Дустым, рәхмәт! Син коткардың мине...

* * *

Анымы, әллә үземнеме коткардым—аңларлык хәлдә түгел идем, билгеле. Шушы гөнаһсыз ялган гамәл кылып дөрес эшләдемме-юкмы—менә шушы сорауга бүгенге көнгә кадәр төгәл җавап бирә алганым юк, ышанасызмы?..

---

*Әдәби эстафета Мамадыш районы*
*Кече Кирмән мәктәбендә*

## Өнемдәге—төшемдә

**Кибеткә барам, имеш.**
**Ямьле кояшлы бер көн.**
**Як-ягыма каранам,**
**Урамда юк һичберкем.**
**Кибеткә кердем менә.**
**Бу тагы ни могҗиза?**
**Кибетче урынында**
**Су анасы утыра.**
**Куркуымнан тиз генә**
**Чыгып киттем урамга.**
**Казанга барырга дип**
**Эзләп йөрим машина.**
**Ни күзем белән күрим—**
**Машиналар юк икән.**
**Машиналар урнына**
**Пар атлар тезелеп киткән.**
**Утырдым да мин шунда,**
**Әйттем сәер кучерга:**
**«Әйдә, Казанга барыйк.**
**Тиз бар,—дим,—туктап торма.»**
**Чаптырып китеп бардык.**
**Туп-туры алга карап.**
**Кучер дигәне—Шүрәле.**
**Утыра койрык болгап!**
**Борды да ул атларны,**
**Урманга алып барды.**
**Кергәч иң куе җиргә,**
**Мине төшереп калдырды.**
**Йөрим шулай адашып**
**Берьялгызым урманда.**
**Хәзер кая барырга?**
**Дөм караңгы бит монда.**
**Аптырап йөри торгач,**
**Күренде ут шәүләсе.**
**Шунда барырга булдым—**
**Коткармасмы берәрсе?**
**Баргач, мин күрдем анда**
**Кәҗә белән Сарыкны.**
**Тәмләп ботка ашыйлар,**
**Бөкләп куеп аякны.**
**Нинди көн бу? Уянып,**
**Календарьга күз аттым.**
**Тукай туган көн икән,**
**Шуны күреп шаккаттым.**

**Диләрә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.**
*бнчы сыйныф.*

## Тукай телен яклап

**Тукай теле өчен көрәшүче**
**Булыр микән килер заманда?**
**Туган телне оныта баралар**
**Еллар үткән саен һаман да.**
**Хәтта сөйләшергә кимсенәләр**
**Чиста ата-ана телендә.**
**Тукай телен белми яши алар**
**Ата-бабалары җирендә.**
**Татар малай «моя мама» дия,**
**«Әнкәй, хәлең ничек?»—димичә.**
**Депутатлар өстә чыгыш ясый,**
**Татар сүзен бер дә әйтмичә.**
**Туган телне һич тә онытмагыз!**
**Тел капкасын, зинһар, япмагыз!**
**Ерак бабайлардан мирас булган**
**Бөек Тукай телен саклагыз!**

**Алсу ИСРАФИЛОВА,**
*5нче сыйныф.*

## Тукайга

**Шигыреңне укыйм яратып,**
**Алам рухи тәрбия.**
**Синең белән горурланып**
**Җырлый халкың мәдхия.**

**Өйрәтәсең һәммәбезне**
**Эш беткәчтен уйнарга.**
**Тараклы алып чапканчы**
**Бик яхшылап уйларга.**

**«Су анасы» әкиятеннән**
**Күп нәсыйхәт аңладым.**
**Бик тырышсам да, малайга**
**Ярдәм итә алмадым.**

**«Туган тел»не, «Бишек җырын»**
**Әнием кичен көйли.**
**Аркамнан сөеп, әбием**
**«Шүрәле»ңне гел сөйли.**

**Быел Кәҗә белән Сарык**
**Хәлендә калды халык:**
**Капчык асып чыгып китте:**
**Булмасмы печән табып?**

**Җиктереп пар ат Казанга**
**Киткәндә басты сагыш.**
**Ияреп моңлы азанга,**
**Ни уйлый нәни Апуш?**

**Зөлфәт ХАЖИЕВ.**
*7нче сыйныф.*

# ЖЕФФИҺӘМ ЙОМШАКБИКӘ

Зәйтүнә әби тугызынчы катта яши. Безнең йортның иң өлкән кешесе ул. Вакытым булганда мин аның янына кереп утырырга яратам. Әнием фани дөньядан киткәч,мин аны әнием урынына күрәм. Мәрхүм әтием белән әниемне бер көн дә догадан калдырмый,рәхмәт. Биш вакыт намазлы бу әби җор телле һәм гыйбрәтле язмышлы.

Зәйтүнә әбиемнәр гаиләсендә кызы һәм тагын ике җан иясе яши: песиләре Йомшакбикә һәм этләре Жеффи. Кергән саен песи белән этнең дус яшәүләренә сокланам.

Менә хәзер дә тугызынчы катка менеп барам. Уемда Жеффи. Мине бүген ул каршы алмас инде. Шуңа күрә кесәмә ул яраткан конфет-печеньеләр дә салмадым. Этне башка кешеләр кулына тапшырганнар. Нинди кешеләр икән аның яңа хуҗалары?..

Жеффины миңа да еш кына урамга алып чыгарга туры килә иде. Аскы катка без аның белән лифтта төшәбез. Ул нәкъ әдәм баласы кебек,күзләрен тутырып күзгә карый. Аның шундый карашыннан мин әллә нишләп китәм. Үзе эт, ә күз—кешенеке. Минем тәнгә каз ите йөгерә. Күз карашы аның бик тә моңсу тоела миңа. Нәрсәдер әйтә кебек,тик теле генә юк сөйләргә. Шунда мин аны конфет-печенье белән сыйлыйм. Ул—тәмле тамак,баллыны бик тә ярата. Койрыгын болгый-болгый,тыпыр-тыпыр биеп ашап та куя.

Шундый уйлар белән, Жеффины юксынып, кыңгырау төймәсенә бастым. Колагым ялгыш ишетә дип торам,Жеффи тавышы лабаса бу! «Мин бу,мин бу!» дигәндәй дәртләнеп өрә башлады! Ишек ачылуга,Жеффи каршылады. Койрыгын зыр-зыр болгый,тәпиләре белән шыпырдый һәм дә томырылып күзләремә карый. Күчтәнәчем булмаганга гаепле кеше сыман аптырап басып торам. Хәер,шундук Зәйтүнә әбиемнән,ничек болай,нәрсә булды,дип сораша башладым.

Жеффины бирәсе килеп бирмәгәннәр, билгеле. Урамга гел алып чыгып йөрергә кеше булмаганнан инде. Зәйтүнә әбинең кызына командировкада еш йөрергә туры килә,ә әбинең яше олы.

Жеффи киткәннән соң Йомшакбикә башта аны-моны аңламаган. Күрәсең, дустын урамга гына чыгып киткән дип уйлагандыр инде. Кичкә таба да Жеффи күренмәгәч, юксына башлаган. Бер бүлмәдән бер бүлмәгә кереп мыраулап йөргән. Икенче көнне юксынуы тагын да көчәйгән. Тәрәзә төбенә менгән, төшкән. Озаклап тәрәзәдән карап торган. Үзгә тавышлар чыгарып әбинең аягына килеп сарылган. Кичтән салынган ризыкны ашамавын күргәч, икенче ризык биргәннәр—иснәп тә карамаган Йомшакбикә. Жеффиның бөтенләйгә китүен сизенгән, күрәсең, пескәй ишекле-түрле дә йөрми башлаган, гел бер урында моңаеп яткан.

Аптыраган хуҗалар Жеффиның хәлен сорап яңа хуҗаларга шалтыратканнар. Яңа хуҗалар үзләре дә Зәйтүнә әбиләргә шалтыратырга торалар икән. Жеффи да төнне чинап чыккан, ашамаган, моңсу күзләреннән яшь тамчылары аккан. Минем атларның күз яшьләре белән елаганы турында ишеткәнем бар иде. Этләр дә елый икән бит шулай.

Башка чара калмагач,Жеффины үз өенә китергәннәр. Килеп җитеп машинадан төшүгә,эт сикерә-чаба ишеккә атылган. Башка вакытта лифт буенда туктап көтеп торган эт бу юлы атылып тугызынчы катка менеп киткән. Үз катына менеп җиткәч, «Мин кайттым,ишекне ачыгыз!» дигән кебек дәртләнеп өрергә тотынган. Шуны ишетүгә, пескәй дә, пуля кебек атылып, ишек буена килеп җиткән. Ишектән килеп керүгә Жеффи әле Йомшакбикәгә, әле Зәйтүнә әбигә килеп сарылган, баскан җирендә тыпыр-тыпыр биегән. Пескәй белән борыннарын-борынга куеп иснәшкәннәр. Бу аларның үзләренчә үбешүләре булгандыр инде. Юлдан кайткан Жеффига ашарына салган әби. Эт,бер дә кыстатып тормыйча,ашарга тотынган. Карыны ачкан пескәй дә карап кына тормаган,Жеффиның савытыннан сыптырыпмы сыптыра икән. Койрыкларын болгашып,куанышып бер-берсенә юл куя-куя савытны бушатып куйганнар болар...

Зәйтүнә әбием сөйли дә сөйли. Аның тавышында бу ике җан иясен ничек яратуы да,аларның янә кавышуларына куануы да ярылып ята. Кечкенәдән алып

үстергән бу көчекнең чит кешеләрдә сагынып-саргаеп, рәнҗеп яшәвен бер дә теләми иде шул ул.

Мин үзем дә әбине сөенеп һәм сокланып тыңлыйм. Уйланып та алам. «Этле-мәчеле» яшәп, арткач, урамга чыгарып ташланган адәм балалары искә төшә. Бу эт белән бу мәче кебек яши алсын иде әле күпләр!

**Дания ГАРӘФИЕВА-ШӘРИПОВА.**
*Казан.*

*Ә сезнең ничек анда: этләр, мәчеләр, тавыклар, үрдәкләр, казлар, күркәләр, сарыклар, кәҗәләр, сыерлар, атлар «этле-мәчеле» яшәмиме?*

---



## Алсу Нургатина

***

**Әллә таныш, әллә таныш түгел,**
**Күргән саен сүзсез елмая.**
**Күзләрендә төссез моңсу караш**
**Чагылып кала көлгән уңайга...**

**...Таныш түгел абый, дүрт яшь ара...**
**Без янәшә инде бүген дә.**
**Кояш көлми, йолдызлар да тынган.**
**Нинди төсләр күңел күгендә?!**

**Үпкәләмә...Йөрәк ярасына**
**Мин кабаттан инде кагылмам,**
**Без янәшә чакта—мин бәхетле,**
**Аерылгач—өзелеп сагынам...**

**Хисләреңне әллә яшерәсең,**
**Син моңсулык иңгән күзеңә?**
**Ләкин нигә сүзсез кагыласың**
**Күз яшьләре тамган йөземә?!**

**Таныш абый... Әллә таныш түгел?**
**Ул яулады минем йөрәкне.**
**Яшьтәшләрем көлә, аңламыйча**
**Миңа бары тик ул кирәкне...**

**Күзләр күздә күптән, куллар кулда...**
**Йөрәкләрнең чыңы сизелә...**
**Бала диеп көлмә, мин зур инде.**
**Син канатлар куйдың иңемә...**

Хисләр чынлыгына ышанам мин,
Ышанычны җуймам кабаттан.
Таныш түгел абый, дүрт яшь ара.
...Ә мин инде аны яратам!

## Туган авыл

«Тау башына салынгандыр безнең авыл»,—дигән Тукай,
Туган авылын шулай зурлаган.
Минем авылым исә бераз башка,
Тау битенә таба юл алган.

Тукай төсле мин дә авылымның,
Ямен, суын, тәмен дә беләм.
Куңелемдә печән чапкан вакыт
Җәйге иртәдә абыем белән...

Тукай төсле мин дә болыннардан
Чәчкә җыеп илһам аламын.
Вакыт табам каләм тибрәтергә,
Мин Тукайга гашыйк баламын.

Хәтеремдә, әгәр читкә китсәм,
Авылыма сагынып кайтулар.
Тау астында чишмә суы белән
Йөрәк ярсуымны басулар...

Авылымда җырчы кошлар сайрый,
Алар белән мин дә моңланам.
Җәйге таңда чык бөртеге төсле,
Киләчәккә таба юл алам.

Әрәмәдә үскән тал-тирәкләр
Тукайны да сагынып көткәннәр.
Минем исә төшләремә керә
Күл буенда үскән җикәннәр.

Авылымның җылы, йомшак җиле
Әнкәм төсле назлап иркәли.
Өй каршында үскән шомырт кызы
Күңелемне күрә үтәли...

Кайвакытта җылы яңгыр булып
Тәрәзәгә чиртә сагыну.
Юк, читләрдән эзләмәгез бәхет,
Туган якка кирәк табыну...

Чит җирләрдә ялгыз каңгырып йөреп,
Бер кайталар икән киткәннәр.
Балачактагы күк кулын изәп
Көтәр микән мине җикәннәр?!

Кояш чыгар, алтын әтәч белән
Авылымда кабат атар таң...
Тукай төсле сөям җаным-тәнем белән,
Туган авылым, сине я-ра-там!!!

*Хикәя яза аласызмы?*

# БАШЛАНСА ЯҢАБАШТАН...

***Йокыдан да уянып җитмәстән Наилнең башына шундый бер уй килде...***

Төшемдә беренче мәхәббәтем Ләйсәнне күрдем , үземнең дә егет чак икән. Әгәр дә яшьлегемә кире кайтып булса, ничек итеп яшәр идем микән? Шагыйрь Зиннур Мансуров язганчамы:

*Аллаһ ирке белән яшәп ятса*
*янәшәдә тагын бер дөнья,*
*шунда кабат гомер кичәр идем,*
*ап-ак биттән башлап барын да.*

Ярый, хуш, кинәт яшәреп, кайдадыр янәшәдәге дөньяга күчтең дә ди. Ә хәтер нишләр? Барысы да онытылыр микән? Әгәр шулай булса, димәк, мин бөтенләй башка кеше булачакмын дигән сүз инде бу. Ул вакытта аның миңа ни катнашы бар да, ни кызыгы була соң әле?

Әйтик, әгәр дә мәгәр хәтер саклана калса, ничек булыр иде микән? Ул вакытта анда мондагы гаиләдән, дуслардан, хезмәттәшләрдән, алай гынамы соң—туган-үскән җирләрдән аерылып, бөтенләй чит-ят тарафларда ничекләр итеп яшәп ятмак кирәк ди. Юк-юк, мондый тормыштан берүк Аллам үзе сакласын! Гаҗәеп рәхәт, әллә нинди фәрештәләрдәй чибәркәйләр белән бергә булсаң да, һаман да шул Ләйсәнне сагынып-юксынып, андагы тормышка ияләнеп-түзеп яшәп буламы соң?

Бу чынбарлыкка туры килми торган шигъри хыял гына икән.

Әгәренки яшьлеккә шушы тормышта яшәп яткан хәлдә кире кайта алсаң ничек булыр иде микән? Ярый, тәнең яшәрде дә ди. Ул вакытта, әлеге дә баягы, хәтер белән нишләргә? Барысын да онытыргамы? Юк, болай да барып чыкмый әле бу: мине танырлар, ә таныш кешеләрне мин танымасам ничек була соң? Мондый тормышта да яшәп булмастыр, ахрысы.

Димәк, яшьлеккә кайта калсам, хәтерне җуймыйча яшәргә, әмма бик күп вактөякне онытырга кирәк булачак икән. Бу очракта Зиннур Мансуровның:

*Әгәр мине яңа дөнья дәшсә,*
*кат-кат басмам бер үк тырмага—*

дигән икенче төрле ният-теләге яңа тормыш башлау өчен нигез була ала икән бит. Дөреслектә, бу һич тә икенче түгел, яңа дөнья була ич!

Аның:

*юлны башлар идем, истә тотып*
*алган сабакларның барын да—*

дигән сүзләрен дә хәтердә тотар идем.

—Димәк, болай булгач, һичбер икеләнү-шөбһәләнүсез яшьлеккә кайтырга кирәк,—дип нәтиҗә ясады Наил һәм яңа көнне дәртләнеп, шактый үк яшәреп башлап җибәрде.Аны алда яшьлеге көтеп тора түгелме соң?

**Бәдигъ**




# БӘЙГЕ ТӘМАМ

1нче санда игълан ителгән әлеге конкурска килгән хикәяләрнең барысы да диярлек басылып чыкты. Жинүчеләр—өчәү. Бу—Казанның 37нче гимназиясе укучысы Булат Садриев, Гүзәлия Тарханова һәм үзен «Сүнмәс утлар балкышы» китабын дәгъвалаучыларның берсе...» дип атаган серле зат. Әлеге уникаль китап аларның өчесенә дә бүләк ителә. (Йомгак ясаганда хикәяләрнең җыйнаклыгы да истә тотылды.). Котлыйбыз!

Бүләкне редакциягә килеп аласы. Вакытын килешү өчен телефоннар: 292-93-16, 562-11-28.

# БӘЙГЕ ДӘВАМ ИТӘ!

Конкурсның «икенче сериясен»—«Хикәя яза аласызмы-2»не башлап җибәрәбез! Хикәячекләрнең күләме бер журнал битеннән артмасын. Бүләк шул ук, җиңүчеләр дә өчәү булыр. Башламнар алдыгызда. (Киләсе бәйгенең башламнарын табышсагыз, җибәрә торсагыз шәп булыр иде, иятәре күрсәтелер).

*Укытучы егет класска килеп керү белән, унберенченең кызлары бердәм хихылдаша башладылар...*

***

*Алар аерылышып, инде елыйсы еланып, бер-берсе турында яманы да, яхшысы да сөйләнеп, онытылып бетте дигәндә ул Аны яңадән очратты.*

***

*Кунакханәнең мин туктаган бүлмәсе кояш карый торган якта булып, төн уртасы якынлашуга карамастан, һаман бөркү иде. Йокыга китә алмаячагымны аңлап, диңгез ярына чыктым...*

***

*Айратның бармаклары шуып китте һәм Фәридәгә дигән СМС ялгыш Миләүшәгә «очты»...*

***

*Халык агымына ияреп җир астына төшеп барганда Аяз сискәнеп китте: аның аяк очында—эскалаторның көмеш баскычында—ике нәни песи баласы утыра иде. «Карале син, әй, болар да Тукай мәйданында булачак пикетка ашыгалар, ахрысы!»—дип уйлады егет.*

***

*«Камил Сәлимович! Мин сине яратам!»—кара тактага шулай дип язылган иде! Яшь укытучы кулына акбур алды.*

***

*Яшь адвокат Нуриев кесә телефонының онытылып калганын вокзалга килеп җиткәч кенә сизеп алды. Такси тотып, тиз генә яңадан фатирга кайтып килергә кирәк иде.*

*Кайтса... Кыңгырау сүнгән, тимер ишек эчтән бикле.*

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*Электрон адрес E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

## Ул үсмер чагында ук академик булган!

Соңгы язмам ахырында Франциянең даһи галиме, математика, астрономия һәм геодезия фәннәре үсешенә искиткеч зур өлеш керткән Алексис Клод Клеро турында аерым сөйләрмен дигән идем. Клеро уналты яшендә үк, дөньякүләм танылган галим буларак, чал чәчле кәсептәшләре тарафыннан Париж академиясенә сайланырга лаек дип бәяләнә. Әмма король указындагы кагыйдәләр буенча унсигезен тутырмаган шәхесләрне академиягә сайларга ярамаган. Король югалып калмаган, Клероны академик дәрәҗәсенә күтәрер өчен ике указ игълан иткән: беренчесе уналты яшьлек лаеклы шәхесләрне академиягә сайлау рөхсәте турында булса, икенчесе, яшь егет академик званиесенә ия булгач, янә унсигез яшьтән генә андый абруйлы дәрәҗә бирү хакында була. Шулай итеп, корольнең беренче указы бер генә көн, яшь галимне академиягә сайлау көнендә генә гамәлдә булган.

Клеро Парижда, математика укытучысы гаиләсендә туган. Унике яшендә үк дүртенче дәрәҗәдәге кәкре сызыклар турындагы тикшеренүе белән Париж академикларын шаккатыра. Аның авторлыгыннан шикләнүчеләр дә була. Бу мәсьәләгә ачыклык кертү өчен академиклар яшүсмердән имтихан алалар. Даһи бала имтиханны уңышлы уза. Кыскасы, сабыйның унике яшендә үк чын галим булып житлеккәнлеге раслана. Аның әле генә аталган тикшеренүе Берлин академиясенең жыентыгында нәшер ителә.

Яшь кенә галим яңа тикшеренүләрен икеләтә кәкре сызыкларның үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлый. Моны аңлатыр өчен мисал итеп винт сызыгын китерәләр: әгәр яссы кәгазь табагында диагональ сызганнан соң кәгазьне цилиндр рәвешендә төрсәк, диагональ винт сызыгына әверелә. Винт сызыгы яссы кысасыннан чыккан, пространство сызыгы булып киткән. Шундый тикшеренүеннән соң галимнәрнең барысы да Клероны мәшһүр математик дип кабул итә.

Алексис Клероның энесе дә бик кечкенәдән талантлы математик булуын раслый, ундүрт яшендә геометриянең кайбер мәсьәләләре буенча тикшеренүләр башкара, аларның нәтиҗәләре Париж академиясендә хуплана һәм академиянең жыентыкларында нәшер ителә. Мөгаен, ул да абыйсы шикелле олуг математик булган булыр иде. Әмма малай 17 яшендә дөнья куя.

Шәхсән үземне, астроном булырга жыенган студент егетне, Клероның астрономия һәм геодезиядәге тикшеренүләре сокландырган иде. Аларның берсе Франция һәм Англия галимнәре арасында озакка сузылган бәхәсне туктатырга булыша. Ньютонның тәгълимати тикшеренүләре планетабызның полюслар юнәлешендә кысылган, ягъни үзәктән котыпларга (полюслар) юнәлгән радиуслары экватор яссылыгындагы радиуска караганда кыскарак булуын раслый. Ә француз галимнәре Париж меридианындагы дуганың озынлыгын экспедицияләр вакытында үлчиләр, дуга очындагы нокталарның нинди киңлектә булганын билгеләп, меридиандагы дуганың 1 градусы ничә километрга тәңгәл икәнен билгелиләр. Нәтиҗәсе Ньютонныкына капма-каршы булып чыга. Менә шунда башлана да инде «ике ил арасындагы» бәхәс. Ниһаять, Париж академиясе яңа экспедицияләр оештырырга карар кыла. Аларның берсе экваторга якын Перуга, икенчесе төньяк котыпка якын Лапландиягә жибәрелә. Икенче «бригада»ның эшендә Клеро да катнаша. Шундый төгәл тикшеренүләр Ньютонның тәгълимати нәтиҗәсен раслый.

1765 елның 17 маенда 52 генә яшендә дөнья куйган галим тормышының кырык елдан артык өлеше фән файдасына өзлексез хезмәткә багышланган була бит. Шул кырык ел ижади тормышның нәтиҗәләре, уйлап карасаң, бихисап галимнәрнең гасырлар буена тупланган казанышларына тәңгәл килә. Андый шәхеснең дөньяга килүе үзе бер могжиза инде ул.

**Ким ШАКИРОВ**

### КИЛӘСЕСЕ КАЗАНДА

12 августта Кытайның Шэньчжэнь шәһәрендә XXVI Бөтендөнья студентлары уеннары ачылу тантанасы булды. 32 спорт корылмасында ярышлар 24 төр буенча үткәрелде. Универсиаданы ачу тантанасын 60 меңнән артык тамашачы күзәтте, 6 мең кеше тәртип саклады.

Ярышларда 152 илдән 8 меңнән артык спортчы катнашты. Парадта Россия җыелма командасы флагын алып бару хокукы Татарстан спортчысына—халыкара классны спорт остасы, авыр атлетика буенча Европа чемпионы, дөнья чемпионаты призеры, Казан федераль университеты аспиранты Андрей Демановка бирелде.

Россия делегациясе составында 475 спортчы бар, аларның 38е Татарстаннан. Россия спортчылары ярыш программасының барлык төрләре буенча да чыгыш ясый.

Универсиаданы ачу тантанасында Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Р.Миңнеханов FISU (Халыкара студентлар спорты федерациясе) әгъзалары өчен оештырылган рәсми кабул итү мәҗлесендә чыгыш ясады. Ул FISU президентының беренче урынбасары итеп Россия вәкиле, Россиянең студентлар спорты берлеге президенты Олег Матыцинны сайлаулары өчен рәхмәт белдерде.

Президент Р.Миңнеханов карашынча, студентлар спорты актив үсәргә тиеш. «Без сезнең барыгызны да 2013 елгы җәйге Универсиадада Казанда көтәбез»,—диде ул, Халыкара студентлар спорты федерациясе әгъзаларына мөрәҗәгать итеп. Рәсми кабул итү тантанасыннан соң кунаклар концерт карады. Анда Россия һәм Татарстанның иң яхшы иҗат коллективлары катнашты.

### БРАЗИЛИЯГӘ ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘР

Август аеның 15-19 көннәрендә Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Бразилиядә эшлекле сәфәрдә булды.

Татарстан Президенты Сан-Паулуда «BrazilInvest» компаниясе (илнең тәүге хосусый үсеш агентлыгы, инвестицион яки коммерция банкы ролен уйный) президенты Марио Гарнеро әфәнде белән очрашты, машина төзү, химия һәм нефть химиясе, суднолар төзү һ.б. өлкәләрдә бергә эшләү мөмкинлекләре тикшерелде.

Шуннан соң Президент шушы ук шәһәрдә «Fundasro Dom Cadra!» бизнес-мәктәбе халыкара консультатив советы әгъзалары өчен эшлекле аш мәҗлесендә катнашты. «Бергә эшләү өчен зур мөмкинлекләребез бар,—дип ассызыклады Татарстан башлыгы.—Әлеге сәфәребезнең Бразилия бизнес-бергәлеге белән яңа бәйләнешләр урнаштыру мөмкинлеге бирәсенә ышанабыз».

Татарстан делегациясе биредә шулай ук «JBS» корпорациясе (сыер ите җитештерү буенча дөньяда иң зур компаниянең берсе) идарәсе әгъзалары белән очрашты. Сөйләшү барышында Татарстан Президенты республиканың агросәнәгать комплексы белән таныштырды һәм Бразилиянең авыл хуҗалыгы гиганты белән хезмәттәшлек итәргә кызыксыну белдерде.

«Безнең мәнфәгатьләр өлкәсе чикләнмәгән. Бразилия безгә хезмәттәшлек өчен зур потенциал тәкъдим итә. Без очрашачакбыз, эшләячәкбез, барлык юнәлешләрдә дә хезмәттәшлек итәчәкбез»,—дип белдерде Президент. Сөйләшүләрдә Татарстан һәм Бразилия бизнес-бергәлекләренең орыну нокталарын җентекләбрәк өйрәнүче эш төркемнәрен булдыру турында карар кабул ителгән.

### ПРЕЗИДЕНТ КИҢӘШЛӘШӘ

22 июль көнне РФ Президенты Д.Медведев Владимир шәһәрендә тарихчылар белән очрашты. Катнашучылар арасында Россия Фәннәр академиясе Этнология һәм антропология институты директоры Валерий Тишков, Россия тарихы институты директоры Юрий Петров, Археология институты директоры Николай Макаров һәм башкалар бар иде. Бу очрашуда Казан университеты профессоры Искәндәр Гыйләҗев (милли республикалардан берләнбер вәкил) катнашты. Очрашу Россия дәүләтчелеге башлануының 1150 еллыгына багышланган иде (ул киләсе елда билгеләнәчәк). Үзенең чыгышында И.Гыйләҗев бу юбилей рус халкы өчен генә түгел, ә Россиядә яшәүче башка халыклар өчен дә әһәмиятле дата дип ассызыклады, чөнки бу халыклар Россия дәүләтчелеге тарихына кабатланмас өлешләрен керткәннәр.

## УНИВЕРСИАДА ПАРКЫ ТӨЗЕЛӘЧӘК

Казанлыларга Универсиада паркын төзү мөмкинлеге барлыкка килде, һәр айны иң яхшы эшләр аерып алыначак, авторларын Универсиада-2013 символикалы продукция белән бүләкләячәкләр.

Казанда Универсиада паркының карар проектына иң яхшы идеягә бөтенроссия күләмендәге ачык конкурс игълан ителде. Бәйгедә һәркем катнаша ала. Бәйгене оештыручылар—«Казан-2013» башкарма дирекциясе хәбәр иткәнчә, конкурс Бөтендөнья студентлар уеннарының тарихы һәм традицияләре белән тирәнтен танышу, шулай ук Казан шәһәренең төзекләндерү өлкәсендә яна карар булдыру мөмкинлеге бирә.

Универсиада-2013 паркының вариантын тәкъдим итү өчен Kazan 2013.ru сайтындагы анкета-гаризаны тутырырга, кыскача аңлатма хәбәр, презентация материалларын дизайн-проект, рәсем яисә эссе форматында әзерләргә кирәк була. Проект идеясен аңлату өчен эскизлар, шулай ук 3D видео-анимация, макет һәм видеоинсталляция форматындагы материаллар да хуплана. Конкурс проектлары 2011 елның 1 октябренә кадәр кабул ителә. Иң яхшы дүрт хезмәт конкурста катнашу өчен сайлап алыначак.

## КАЗАН—ЯШЬЛӘР ШӘҺӘРЕ

2012 елда Казанда Бөтендөнья мирасы комитетының яшьләр сессиясен үткәрү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының ЮНЕСКО эшләре комиссиясе җаваплы секретаре Григорий Орджоникидзе белән очрашты. Хөкүмәт йортында узган очрашу Бөтендөнья мирасы комитетының 36нчы сессиясен үткәрүгә әзерлек мәсьәләләре хакында фикер алышуга багышланды. 36нчы сессиянең төп утырышы 2012 елның 25 июненнән 5 июльгә кадәр Санкт-Петербургта узачак. Г.Орджоникидзе сүзләренчә, сессия белән параллель рәвештә яшьләр форумын үткәрүгә бәйле тәкъдим дә бар. Мондый форумнар ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы корылмалары булган теләсә кайсы төбәктә үткәрелә ала. Казан нәкъ менә шуңа күрә дә 2012 елда яшьләр форумын үткәрү урыны итеп сайланды.

## ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ КАЗАНДА УЗАЧАК

Кытайның Шанхай шәһәрендә, Халыкара йөзү федерациясе (FINA) киңәшмәсендә, 2015 елның 17 июленнән 2 августка кадәр Казанда су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты узачагы билгеле булды. Әлеге документ Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов, Казан мэры Илсур Метшин, FINA башлыгы Хулио Сезар Маглионе тарафыннан имзаланды.

## КАЗАН—УФА ТЕЛЕКҮПЕРЕ

Уфада «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең вәкиллеге ачылды.

Телерадиокомпаниянең генераль директоры Илшат Әминов белән Башкортстан элемтә һәм гаммәви коммуникацияләр министры Борис Мелкоедов бу унайдан символик кызыл тасманы кисте.

Тантанада шулай ук Татарстан Республикасының Башкортстан Республикасындагы тулы вәкаләтле вәкиле А.Максютов, «Башкортстан татарлары» берләшмәсе рәисе Р.Бигнов, БСТ һәм «Башкортстан» телерадиокомпанияләре житәкчеләре Г.Якупов белән Р.Дәүләтбаев та катнашты.

Хәзер яңалыкларда һәм «Яңа Гасыр» телеканалының бүтән тапшыруларында ут күршеләребезнең тормышы турында сюжетлар, репортажлар, очерклар ешрак күрсәтеләчәк.

Уфадагы филиалда хәбәрчеләр пункты һәм реклама хезмәте эшләячәк. Филиалның директоры Фәнис Фәтхи—зур тәҗрибәле журналист. Ул Башкортстанда туып-үскән, Казан дәүләт университетын тәмамлаган, күп еллар «Азатлык» радиосында, 10 елдан артык «Татар-Информ» агентлыгының Башкортстандагы үз хәбәрчесе булып эшләгән.

Хәзерге вакытта «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең хәбәрчеләр пункты Мәскәүдә, Әлмәттә, Ижауда, Төмәндә уңышлы гына эшләп килә.

## ИСТӘЛЕК БИЛГЕСЕ БУЛАЧАК

Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне торгызу буенча республика фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Идел буе болгарларының Ислам динен рәсми кабул иту хөрмәтенә Истәлек билгесе—мозаикалы панно эскизын килештерү буенча киңәшмә үткәрде.

Киңәшмәдә катнашучыларны панно эскизы белән аның авторы, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Фәрит Вәлиуллин таныштырды. Эскизны эшләүдә бөек сынчы-рәссамыбыз Бакый Урманче мирасы файдаланылган.

## СЫНЧЫ ИЖАТЫ—СУРӘТЛӘРДӘ

Алабуга дәүләт музей-тыюлыгының күргәзмәләр залында «Ракурслар. Илдар Ханов ижаты фотографлар күзлегеннән» дигән күргәзмә ачылды. Ул рәссам, сынчы, шагыйрь, дәвалаучы, фәлсәфәче, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Илдар Хановның 70 яшьлек юбилеена багышлана.

Экспозициядә Казан һәм Чаллы фоторәссамнарының сынчы иҗатын чагылдырган 70тән артык эше урын алган. Алар арасында «Эволюция», «Тормыш агачы», «Саклаучы фәрештә», «Уяну» композицияләре белән беррәттән, танылган «Жир-ана» һәм «Көрәш» тә бар.

Хәзерге вакытта Илдар Ханов үз тормышының төп проектын гамәлгә ашыра—Галәм әхрамын төзи.

Кама сәнгать һәм дизайн институты студентларының Илдар Ханов сыннары буенча башкарылган эшләре күргәзмәгә өстәмә бизәк булып тора.

### МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН ФОТОСТУДИЯ

Казанда мөселман фотостудиясе ачылды. Хәзер мөслимәләр үзләренә ничек унайлы, шулай фотога төшә ала, дип хәбәр итә islam.ru. Студия житәкчесе Сәйдә Шиһапова сүзләренә караганда, ул мөслимәләр өчен студия оештыру турында күптән хыялланган. Чөнки сурәткә ир-ат фотограф төшергән вакытта мөслимәләр үзләрен бигүк унайлы хис итми, һәм бу фотосурәттә дә чагылыш таба.

### АЛСУ—ТЫНЫЧЛЫК ЖЫРЧЫСЫ

Татарстанның халык артисты Алсу ЮНЕСКОның тынычлык артисты итеп сайланган. Рәсми тантана Парижда үткәрелгән. ЮНЕСКО «Тынычлык артисты» дигән мактаулы исемне үз һөнәри эшчәнлеге белән халыклар арасындагы мәдәни багланышларны ныгытуга зур өлеш керткән музыкант, актер, рәссамнарга бирә. Бөтендөнья оешмасының мактаулы йөкләмәләрен Канада һәм Британия эстрадасы йолдызлары Селин Дион һәм леди Ширли Бэсси, Америка актрисасы Мариса Беренсон, француз жырчысы һәм композиторы Жорж Мустаки бик теләп үти.

Халыкара конкурслар лауреаты һәм гуманитар проектларда теләп катнашучы Алсуны былтыр ЮНЕСКО генераль директоры Ирина Бокова Парижда оешманың 65 еллыгы хөрмәтенә үткәрелгән тантананы алып барырга да чакырган булган. Алсу үз иҗатын «Салават күпере» фондын оештыручыларның берсе сыйфатында актив хәйрия эшчәнлеге белән дә бәйләп бара.

### ХУШЛАШУ СҮЗЕ

Татар галәме зур югалту кичерде. 17 июльдә Анкара шәһәрендә 94нче яшендә татар халкының каһарман улы, милләтне XX гасырның тарихи вакыйгалары, бөек шәхесләре белән бәйләп торган күренекле сәясәтче, журналист, җәмәгать эшлеклесе, Бөтендөнья татар лигасының шәрәфле президенты **Гали Акыш** вафат булды.

Гали Акыш дөньяның төрле илләрендә яшәп, һәрвакыт милләтебезгә хезмәт итте, Исхакыйлардан килгән азатлык идеалларын таратты, татар дөньясын берләштерүче булды. Аның сәяси эшчәнлеге Варшавада «Прометей» оешмасында башланып, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Мюнхен шәһәрендә «Азатлык» радиосында дәвам итте. 17 ел дәверендә Гали Акыш «тимер пәрдә» артында яшәгән халкыбызга хакыйкый сүзне ирештереп торды. 2000 елда янә Төркиягә кайтып, ул үзенең соңгы көннәренә хәтле күпсанлы милләттәшләребезгә ярдәм итеп, бүгенге татар хәрәкәте, Татарстан тормышы белән һәрдаим кызыксынып яшәде.

Татар җәмәгатьчелеге Гали Акышның арабыздан китүен бик авыр кичерә. Бөтендөнья татар конгрессы аның туганнарының, якыннарының кайгысын уртаклаша. Бу олпат шәхеснең исеме халкыбыз тарихында һичшиксез алтын хәрефләр белән уелып калыр, яңа буыннарны милләтнең якты киләчәге өчен көрәшкә өндәп, рухландырып торыр. Авыр туфрагың җиңел булсын, Гали ага.

**Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Илаһи көз.

*Дүртенче биттә:* язучы **Илүсә Нәбиуллина**.

# Яңа китаплар




**Нажар Нәҗми.** Милли җаным: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар, шигырьләр, поэма / идея авт. һәм төз. Р. Миңнуллин.—Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.—479 б. Тиражы—2000 данә.

Бу китапка башкорт һәм татар халкының мәшһүр шагыйре Нажар Нәҗминең шигъри әсәрләре, халык язмышын кайгыртып язылган публицистик язмалары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, каләмдәшләренә юллаган хатлары тупланды. Җыентыкта шулай ук шагыйрь иҗатына багышланган мәкаләләр, истәлекләр, шигырьләр, аңа язылган хатлардан үрнәкләр дә кертелгән, фотосурәтләр дә урын алган.




**Адлер Тимергалин.** Карурман аша: повестьлар һәм кыйсса / Адлер Тимергалин.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.—400 б. Тиражы—2000 данә.

Авторның әлеге китабына совет режимы шартларында кеше шәхесенең фаҗигале борылышларын реалистик сәнгать алымнары белән тәэсирле итеп сурәтләгән «Игезәкләр» повесте, Ф.Әмирхан әсәреннән алынып, яңадан терелтелгән Фәтхулла хәзрәт образы аша торгынлык заманындагы совет чынбарлыгын сатирик планда тасвирлаган «Фәтхулла хәзрәтләре» фантастик повесте һәм башка әсәрләре туплап бирелгән.



Илүсә Нәбиуллина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)